# Казан утлары

7.1983




# КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ

## *1983 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясен бирү турында*



А. Гыйләҗев.



Р. Еникеев.

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:

1983 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирергә:

1. **Гыйләҗев** Аяз Мирсәетовичка, язучы — «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары өчен.

2. **Еникеев** Ренат Әхмәтовичка, композитор — «Муса Җәлил истәлегенә» исемле вокаль-симфоник поэмасы һәм соңгы елларда иҗат ителгән камера әсәрләре өчен.

**КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре**
**Г. УСМАНОВ.**

**Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе**
**И. САДЫЙКОВ.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

7

1983

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

РСДРПның II СЪЕЗДЫНА 80 ЕЛ

**К. ФАСЕЕВ. Партия — чорыбыз байрагы** . . . . 3

В. В. МАЯКОВСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

**В. МАЯКОВСКИЙ. Сул марш.** Шигырьләр . . . 9

**З. ФӘТХЕТДИНОВ. Ачылган серләр.** Мажаралы повесть . . . . . . . . . . . . . . 12

М. ШАБАЕВКА 50 ЯШЬ

**М. ШАБАЕВ. Шигырь утым алга дәшә мине.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 100

**Р. ГАТАУЛЛИН. Гомер уртасыннан хатлар.** Цикл поэма . . . . . . . . . . . . . . 107

**М. ХӘБИБУЛЛИН. Өченче вагон.** Хикәя . . . . 118

**Г. ЛАТЫЙП. Муса дисәм.** Шигырьләр . . . . . 134

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

**Р. БАТУЛЛА. Чабак-тау.** Очерк . . . . . . . 139

БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Р. МОСТАФИН** (143 бит), **З. ХӘБИБУЛЛИН** (155 бит).

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

**М. БИБИШЕВ. «Истәлеккә шәһәр бүләк итәм»** . 144

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

**Ф. АБДУЛЛИН. Җылы юллар.** Очерк . . . . . 151

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**И. АХУНҖАНОВ. Күңел кайнарлыгы** . . . . . 156

**Г. МОРАТОВ. Тормыш куйган сораулар** . . . . 162

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Бүгенге татар драматургиясе турында сөйләшү** . 164

БИБЛИОГРАФИЯ

**Р. МӨХӘММӘДИЕВ.** Ихтирам . . . . . . . . 176
**Р. МОСТАФИН.** Кырыс реализм . . . . . . . 179
**Р. ЯГЪФӘРОВ.** «Алтмыш арба бодай бир...» . . 183
**Г. МИРЗАГИЛДИНА-БАЯЗИТОВА.** Мирсәй Әмир белән очрашу . . . . . . . . . . . . 185

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

**М. СӘЛИМОВ.** Чэпэ. Юмореска . . . . . . . 187
**КИЗӘНОВ.** Тәкәббер тәкә. Шигырьләр . . . . 188

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

---

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

---

Производствога бирелде 21.04.1983 ел. Басарга кул куелды 16.06.1983 ел. ПФ 07069. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Я-179. Бәясе 90 тиен.

---

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

**Камил Фасеев,**
философия фәннәре докторы

# ПАРТИЯ — ЧОРЫБЫЗ БАЙРАГЫ

Моннан 80 ел элек тарих иң әһәмиятле вакыйгаларның берсенә шаһит булды. 1903 елның июль аенда Россия эшчеләр сыйныфының революцион оешмасы — большевиклар партиясе туды. Хәзер җир шарында иң куәтле, җитлеккән социалистик җәмгыятьнең җитәкче һәм рухландыручы көче булган Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең тарихы шуннан башлана.

Партиябезнең үсү һәм чыныгу тарихын совет кешеләре белән бергәттән барлык илләрнең демократик һәм революцион җәмәгатьчелеге кызыксынып өйрәнә, үрнәк һәм гыйбрәт ала.

Партиянең II съездыннан соң узган еллар югарылыгында торып уйлаганда, бу партияне оештыручы, рус халкының ялкынлы йөрәкле даһи улы Владимир Ильич Ленинның зирәк акылына, марксистик фикер тирәнлегенә, революцион инанганлыгына, теоретик һәм практик көченә, алдан күрә белү сәләтенә хәйран каласың...

Тарихи прогрессны хәрәкәткә китерүче төп көч — халык массалары. Шуның белән бергә иҗтимагый тормышта бөек шәхесләрнең роле дә бик зур. Без моның гаҗәп матур үрнәген фәнни коммунизмга нигез салучылар, эшчеләр сыйныфының бөек остазлары һәм юлбашчылары — Карл Маркс, Фридрих Энгельс һәм Владимир Ильич Ленин эшчәнлегендә күрәбез.

Мәгълүм ки, барлык материаль һәм рухи байлыкларны тудыручы булсалар да, хезмәт ияләре гасырлар буе коллыкта изелеп, таланган һәм мәсхәрәләнгән килеш яшәделәр. Дөрес, халыкның авыр язмышына борчылып, аңа азатлык һәм бәхет юлын күрсәтергә тырышучылар да аз түгел иде. Ләкин марксизмга кадәрге вәгазьчеләр һәм күрәзәчеләрдән халык игелек күрә алмады. Бу хакта олы әдибебез Галимҗан Ибраһимовның 1913 елда әрнеп әйткән сүзләре искә төшә. «Адәмнәрнең бәхете, сәгадәте, мәсгудияте» турында лаф орган «алла илчеләренә», галимнәргә, философларга мөрәҗәгать итеп, «Көтүчеләр» дигән әсәрендә ул болай язды: «Юлыгызның яктылыкка, бәхеткә, иреккә ирештермәвен тәҗрибәдә күреп, яңа юллар эзләргә кушмыйсызмы?..

Сөйләгез! Без, тормышның төбендәгеләр, сездән җавап сорыйбыз! Ничә мең еллык тәҗрибә иске юлларның хатасын ачмадымы? Без җавап көтәбез! Миллионнарча ач балалар, ачлыктан баласын имезергә сөте булмаган миллионнарча аналар, гомеренчә эшләп тә, ахырда урамга ташланган картлар, аһ-зарлары, кайгылары белән җир йөзен каплаган барча мәзлумнар — без сездән җавап көтәбез...»

Мәзлумнар гасырлар буе көткән җавап табылырга тиеш иде. Ниһаять, ул табылды. Иске юлларның һәм вәгазьләрнең хатасын аңлап, эксплуатациядән, хә-

ерчелектән котылуның бердәнбер дөрес юлын халыкка пролетариат идеологлары Маркс, Энгельс, Ленин күрсәттеләр.

Шунысы гыйбрәтле: XIX гасырның уртасында Маркс белән Энгельс — Европада, ә шул гасырның соңында, XX гасыр башында Ленин Россиядә бер-беренә тиң хезмәт башкардылар, иҗтимагый фикер үсешендә, революцион хәрәкәттә, эшчеләр сыйныфы һәм инсанлыйк хезмәт ияләре язмышында тирән борылыш ясадылар. Быел, Маркс туууына — 165, үлүенә 100 ел тулу уңае белән, бу хакта аерып алып әйтү бигрәк тә урынлы.

Кешелек XIX гасырга аяк басканда, Көнбатыш Европа илләре феодаль тәртипләрне җимереп, капиталистик мөнәсәбәтләр урнаштыру процессын кичерде. Шуның нәтиҗәсендә пролетариат үсеп чыкты һәм капиталистик эксплуатациягә каршы көрәш башлады. Әмма бу көрәш әле оешмаган стихия иде, пролетариат үзенә йөкләнгән тарихи миссияне аңлап җиткерми иде. Максатка ныклап төшенмәгән хәлдә, якты идеалга ирешү юлларын белмәгәндә, уңышлы хәрәкәт тә була алмый. Димәк, эшчеләр сыйныфын ачык идея, фәнгә нигезләнгән максат, революцион теория белән коралландырырга, аның көрәшенә дөрес юнәлеш бирергә кирәк иде.

Моны кем эшләргә тиеш иде соң? Ул чакта шактый киң таралган тәгълиматлар — Кант, Гегель, Фейербах тудырган немец философиясе, Смит һәм Рикардоның политик экономиясе, Сен-Симон, Фурье, Оуэн алга сөргән утопик социализм эшчеләр сыйныфына ярдәмгә килә алмады.

Эшчеләр сыйныфының мәнфәгатен беренче булып даһи акыл ияләре Маркс һәм Энгельс аңлады. Алар чын азатлык һәм гаделлек өчен, кешелекнең якты киләчәге булган социализм өчен көрәштә хәлиткеч көч — пролетариат икәнлеген күрсәттеләр. Телгә алынган идея агымнарына тирән анализ ясап һәм кимчелекләрен тәнкыйтьләп, Маркс һәм Энгельс алдынгы иҗтимагый фикерне иң югары баскычка күтәрделәр, дөньяны үзгәртеп коруда куәтле идея коралын — фәнни коммунизм теориясен иҗат иттеләр.

«Массалар аңын биләп алгач, теория материаль көчкә әйләнә»,— диде Карл Маркс. Ул, үзенең иң якын фикердәше, дусты, көрәштәше Фридрих Энгельс белән бергә, шушы хакыйкатьне гамәлгә ашыруга бөтен гомерен, ихтыярын, оештыру көчен бирде. Теория массалар аңына үз-үзеннән керми. Эшчеләрне революцион теория белән коралландыру һәм аның көрәшенә җитәкчелек итү вазифасын аның үз партиясе генә башкара ала. Маркс һәм Энгельс шундый партиягә нигез салдылар, 1847 елда «Коммунистлар союзы»н төзеп, аның программасын — атаклы «Коммунистлар партиясе манифесты»н яздылар. Алар эшчеләрнең халыкара бердәм оешмасы I Интернационалга җитәкчелек иттеләр, мөстәкыйль пролетар партияләр тууга турыдан-туры булыштылар.

Капитализмнан социализмга күчү законнарын, пролетариатның тарихи революцион миссиясен, дөньякүләм социаль прогрессның тулы һәм ышанычлы юлын ачыклаган Маркс һәм Энгельсның бөек хезмәте һичкайчан онытылмас, марксизм мәңгегә кешелекнең сүнмәс маягы булып балкыр.

Инде XIX гасырдан без яшәгән гасырга аяк басканда Россиядәге хәлгә күз салыйк. Илдә капитализм үсә генә түгел, башка буржуаз илләрдәге кебек, соңгы этабына — социаль каршылыклар тагы да кискенләшкән, тирән кризис кичергән империализм чорына керә. Эшчеләр сыйныфы царизмга һәм буржуазия хакимлегенә каршы актив сугышка күтәрелә. Бу вакыйгаларны зур игътибар белән күзәтеп торган Маркс һәм Энгельс Россиядә «иң зур социаль революция өлгереп килә», «Россия — Европадагы революцион хәрәкәтнең алдынгы отряды»,— дип яздылар.

Тик Россиянең үзендә моңа ышанучылар әле аз иде. Вак буржуаз народниклар капитализм үсешен, пролетариатның формалашуын инкарь итсәләр, экономистлар «стихияле агымга» буйсынуны җайлы күрделәр, эшчеләрне бары тик

«бер сумга бер тиен» дәгъваларга гына өндәделәр, аларны буржуазия койрыгына тагу юлын карадылар. Өстәвенә «легаль марксистлар» дип аталган икейөзлеләр, капитализмны аклап, эшчеләрне буржуаз идеология тоткынлыгында тоту өчен тырыштылар.

Илдәге иҗтимагый-экономик һәм политик үзгәрешләр перспективасын бары тик марксизм теориясенә таянып кына дөрес аңлатырга мөмкин иде. Бу юнәлештә беренче адым Г. В. Плеханов тарафыннан ясалды. Женевада ул оештырган «Эшчеләр сыйныфын азат итү» группасы марксизмны Россиядә актив тарату эшен башлап җибәрде. Ләкин үз иленнән, андагы эшчеләр хәрәкәтеннән читтә торганга күрә, диалектик фикер йөртү җитмәү һәм марксизмның катып калган догма түгел, бәлки иҗади фән икәнлеген аңламау сәбәпле Плеханов эзлекле революционер була алмады, оппортунизм агымына кушылды.

Империализм чорында, революцион хәрәкәтнең үзәге Россиягә күчкән шартларда марксизм теориясенә турылыклы булып, аны иҗади алга үстерү буенча гигант хезмәтне В. И. Ленин башкарды. Ул яңа эпохага тирән анализ ясады, аның социаль каршылыкларын фаш итте, социалистик революция турында тәгълиматны яңа мөһим положениеләр белән баетты. Ленин ачыктан-ачык: революция илнең барлык ишекләрен шакый, һәм ул дөньякүләм социалистик революциянең башлангычы (прологы) булыр, дип игълан итте. Күрәсез, нәкъ Маркс белән Энгельс кебек: иҗтимагый вакыйгаларга реалистик бәя биреп, һәртөрле уйдырма-хыялны кире кагып, алдан күрә белү даһилыгы һәм эшчеләр сыйныфының революцион көченә тирән ышанып!

Социалистик революциянең алшартлары җитлегү — объектив процесс. Әмма революцион ситуацияне социализмның җиңүенә китереп җиткерү өчен субъектив факторларның көчле булуы кирәк. Бу — революцион сыйныфның югары аңлы, коммунистик инанган һәм нык оешкан булуы дигән сүз. Моңа исә эшчеләр сыйныфының үз партиясе булганда гына ирешергә мөмкин. Һәм Ленин бу мәсьәләне дә Маркс һәм Энгельс үрнәгендә хәл итте: эшчеләрнең, хезмәт иясе массаларының политик аңын үстерү, царизмга һәм капитализмга каршы аяусыз көрәшкә туплау, социализмның җиңүенә алып бару өчен чын-чынлап революцион партия кирәк дип санады.

«Бирегез безгә революционерлар оешмасын — һәм без Россиянең астын өскә китерербез!» — В. И. Ленинның бу сүзләре капитализмнан социализмга күчүдә партиянең хәлиткеч ролен бик ачык аңлата.

Россия социал-демократик эшчеләр партиясе дөньяга җиңел генә килмәде. Ленинга, коммунистларга аның өчен киеренке көрәш алып барырга кирәк булды. Партиянең II съездында 26 социал-демократик оешмадан 43 делегат катнашты. Алар арасында төпле марксистик позициядә торучы эзлекле революционерлар гына түгел, оппортунизм һәм реформизм чире йоккан, идея-политик карашлары буталчык кешеләр дә бар иде. Партия төзелүне игълан иткән чакта ук бу ике төркем арасында тирән каршылыклар туды. Партия төзелеше, аның максатлары, көрәш стратегиясе һәм тактикасы турында бәхәстә социал-демократиянең ул вакытта иң авторитетлы ветераны дип саналган Плеханов та ялгыш фикерләрне яклады. Аның якташлары Мартов, Аксельрод, Засулич Россия эшчеләр сыйныфы партиясен Көнбатыш илләрендәге реформистик партияләр үрнәгендә күзалладылар (белгәнебезчә, алар аннары, марксизмга хыянәт итеп һәм меньшевизм агымын тәшкил итеп, II Интернационал оппортунизмы сазлыгына баттылар).

Съездда Ленин II Интернационал партияләреннән үзгә, яңа типтагы партияне, ныклы оешкан һәм каты дисциплиналы, буржуазия йогынтысына бирешмәүчән, оппортунизм һәм реформизм белән һич тә килешмәүчән, эшчеләр сыйныфының чын-чыннан җитәкчесе булырлык, царизмны һәм капиталистик стройны җимереп ташлау өчен көрәштә һичнинди киртәләр һәм киенлыклар каршында тез чүкмәүчән партияне төзү бурычын куйды. Партия, диде Ленин, эшчеләр сыйныфының алдынгы отряды, авангарды, фәнни теория белән коралланган юлбашчысы булырга тиеш. Ленин һәм аның яклы революционерлар шундый партиянең оешуына ирештеләр дә.

Туп-туры әйтергә кирәк: Лениннан, аның искиткеч фидакарьлегеннән, килешмәүчән коммунистик принципиальлегеннән башка илебез хезмәт ияләрен иң гадел социалистик тормыш тантанасына алып килгән партиябезне күз алдына китерү дә мөмкин булмас иде.

Гаять дәрәҗәдә катлаулы, авыр һәм сокланырлык данлы юл узды безнең ленинчыл партиябез. Тарихның һәр этабында ул үзен халык бәхете өчен көрәшүче бердәнбер партия буларак исбат итте. 1905—1907 еллар революциясе, кара реакция еллары, беренче дөнья сугышы һәм февраль революциясе давыллары аша ул халкыбызны Бөек Октябрь социалистик революциясенә алып килде. Совет халкы партиянең зирәк һәм акыллы җитәкчелегендә, аның программасын һәм политикасын хуплап, эксплуататор сыйныфлардан тәмам котылды, язмышын үз кулына алып, яңа тормыш, дөньяда беренче социалистик җәмгыять төзеде, аның куәтле материаль һәм культура потенциалын тудырды, социалистик Ватанны күп санлы явыз дошманнардан саклап калды, тарихта күренмәгән батырлык күрсәтте. Барлык казанышлары өчен совет халкы Коммунистлар партиясенә бурычлы.

Партия үз программасында алга куйган бөек бурычларны тайпылышсыз һәм уңышлы үтәп килә, шуның белән бүтән илләрдәге тугандаш партияләргә марксизм-ленинизм нигезендә нык тору, революцион теориягә, коммунистик идеалга хыянәт итүчеләргә, сыйнфый дошманнарга карата килешмәүчән позиция үрнәген бирә.

Бер-ике генә мисал.

Буржуаз дәүләтне җимереп, хезмәт ияләре интересларына тулысынча җавап бирүче дәүләтне, ягъни пролетариат диктатурасын урнаштыру — фәнни коммунизмда иң мөһим төп мәсьәлә.

Бу — Коммунистлар партиясенең беренче бурычы дип өйрәттеләр Маркс һәм Энгельс. Шуңа карамастан, Көнбатыш Европадагы социалистик партияләрнең җитәкче даирәләре пролетариат диктатурасы идеясеннән баш тарттылар, буржуаз парламентаризм һәм реформалар аша гына, капиталистик дәүләткә тимичә генә социализмга күчеп була, дигән ялгыш караштa тордылар һәм хәзер дә торалар. РСДРПның II съездында шундый ук фикерне бернштейнчы экономистлар һәм бундчылар күтәреп чыкты. Янәсе, башка социалистик партияләр программаларында булмагач, безгә дә пролетариат диктатурасы турында пункт кертмәскә кирәк. Съездның Ленинга кушылган күпчелеге бу оппортунистик дәгъваны кире какты. Бу марксизм-ленинизмның зур җиңүе иде. Ул партиянең революцион тактикасын, илебездә социализм язмышын хәл итүче иң әһәмиятле фактор булды.

Капитализмнан социализмга күчү чорында пролетариат диктатурасы котылгысыз һәм демократик дәүләтнең максатка ярашлы формасы икәнлеге Октябрь революциясе һәм башка илләрдә җиңгән социалистик революцияләр тәҗрибәсендә тулысынча расланды. Безнең илдә инде ул бөтенхалык дәүләтенә әйләнде. Социалистик дәүләтне ныгыту, социалистик демократияне өзлексез киңәйтү һәм камилләштерү — тулы коммунистик җәмгыятькә ирешү закончалыгы. Партия безне шул юнәлештә ышанычлы адымнар белән алып бара. Ленинчыл партиянең бөтен дөньяны сокландырган зур казанышларыннан берсе — милли мәсьәләне хәл итү. Бу бит — иҗтимагый фикерне күптәннән борчыган, буржуаз идеологлар тарафыннан бик нык буталган һәм беркайчан да чишә алмаслык дип исәпләнгән иң нечкә, иң четерекле проблема. РСДРПның II съездында да ул кискен бәхәс тудырды. Съездның пролетар интернационализм югарылыгында торган күпчелеге, бер яктан — вак буржуаз милләтчелек, икенче яктан, милли нигилизм тенденцияләренә отпор биреп, В. И. Ленин тәкъдимнәрен кабул итте, барлык милләтләр эшчеләре өчен бердәм, интернациональ партия төзү принцибын һәм милләтләрнең үз язмышларын үзләре билгеләү хокукын раслады.

Без әле генә Совет Социалистик Республикалар Союзының 60 еллык юбилеен билгеләп уздык. Бу бәйрәм бөтендөнья җәмәгатьчелегенең игътибарын җәлеп ит-

те. Дуслар безнең белән бергә шатланды, ә дошманнарның ачуы тагын да куера төште. Чөнки, буржуаз идеологлар бернинди ялган белән дә инкарь итә алмаслык гаделлек җиңде. «Бездә эксплуататорлык строе калдырган хәлендәге милли мәсьәлә уңышлы хәл ителде, тәмам һәм катгый хәл ителде,— диде иптәш Ю. В. Андропов.— Тарихта беренче тапкыр буларак, илнең күп милләтле составы йомшаклык чыганагыннан көч һәм чәчәк ату чыганагына әверелде».

Йөздән артык милләтнең, тугандаш гаилә тәшкил итеп, бер дәүләткә туплануы, аларның хәерчелек һәм караңгылык дөньясыннан яктылыкка, һәрьяклап чәчәк ату дөньясына кискен сикереше — күпләргә могҗиза кебек тоела. Тик бу — могҗиза түгел, бәлки социализм закончалыгы, ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру буенча Коммунистлар партиясенең әзлекле, акыллы, оста эшчәнлеге җимеше, милләтләрнең СССРга берләшүе нәтиҗәсе.

1903 елда, партия әле оешкан гына чакта, ул 3,5 мең чамасы революционерларны берләштерә иде. Бүген КПСС үзенең сафларында эшчеләр сыйныфының, колхозчы крестьяннарның һәм совет интеллигенциясенең 18 миллионга якын иң алдынгы вәкилләрен туплый. Ул әнә шулай коммунистларның мәһабәт армиясенә, чын-чыннан халык партиясенә әйләнде. Җитлеккән социализм җәмгыятендә аның җитәкчелек роле үскәннән-үсә, авторитеты һаман арта бара.

КПССның XXVI съезды совет халкының материаль һәм культура тормышын тагы да югарырак дәрәҗәгә күтәрү, социалистик иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерү, кешеләрне коммунистик рухта тәрбияләү һәм һәр яктан җитлеккән шәхесләр формалаштыру буенча фәнни нигезгә корылган программа эшкәртте. Совет халкы партия куйган бурычларны чын күңелдән котлап кабул итә һәм уңышлы башкарып чыгу өчен зур тырышлык белән эшли. Коммунизм тантанасын якынайтыр өчен партия безне фидакарь хезмәткә рухландыра, шуның белән бергә эшлексезлек, дисциплинасызлык, әхлаксызлык, комсызлык, эчкечелек, җәмәгать милкенә кул сузу, культурасызлык, тупаслык, бюрократизм кебек социалистик тормыш рәвешенә чит булган күренешләрне бетерергә чакыра. Бу мәсьәләгә КПСС Үзәк Комитетының 1982 ел ноябрь Пленумы аерата зур игътибар бирде.

Коммунистлар партиясенең халыкчан, гуманистик һәм интернационалистик асылы аның җирдә тынычлыкны ныгыту политикасында, империалистик реакцияне, аның агрессив планнарын аяусыз фаш итүендә, азатлык сөючә барлык халыкларның мөстәкыйль үсешен, бөтен дөньяда демократик хәрәкәтне, эшчеләр сыйныфының, Коммунистик партияләрнең империализмга каршы, иҗтимагый прогресс һәм социализм өчен көрәшен яклауда, дөньякүләм социалистик системаны ныгытуда ачык чагыла.

80 еллык тарихында КПСС һәрвакыт марксизм-ленинизм теориясенә таянып эш итте һәм итә, аны социалистик төзелеш тәҗрибәсе белән раслый һәм баета килә. Партиянең какшамас көче — марксизм-ленинизм фәненә тугрылыкта, коммунистларның идея-политик бердәмлегендә, халык белән тыгыз элемтәсендә. КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советының һәм СССР Министрлар Советының 1982 елның 12 ноябренда Коммунистлар партиясенә, совет халкына мөрәҗәгатендә болай әйтелә: «Совет халкы партияне үзенең сыналган коллектив юлбашчысы, зирәк җитәкчесе һәм оештыручысы итеп саный. Партиянең иң югары максаты һәм аның бөтен эшчәнлегенең мәгънәсе — эшчеләр сыйныфына, хезмәтчел халыкка хезмәт итү. Партия һәм халыкның какшамас бердәмлеге совет җәмгыятенең җиңелмәс көч чыганагы булды һәм шулай булып кала. КПСС хезмәт ияләре ышанычын изге итеп кадерли, массалар белән элемтәсен даими ныгыта. Вакыйгалар нинди генә борылыш алмасын, нинди генә сынаулар булмасын, партиябезнең үз тарихи миссиясе югарылыгында калачагына халык практикада инанды».

Партиянең 80 еллык юбилее — бөтен халык бәйрәме. Совет кешеләренең барысы да партиягә йөрәктән кайнап чыккан мәхәббәтен, тирән ихтирам хисен

белдерә, якты, изге өметләрен аңа баглый. Аларның җылы тойгысы фронтовик шагыйрь Гали Хуҗи иҗатында матур чагылыш тапкан:

Син, Партия, бердәй күрдең безне,
Син уяттың безне тормышка;
Синең йөздә күрдек йөзебезне,
Тойдык сине һәрбер сулышта.
Син юнәлеш бирдең теләкләргә,
Һәммәбезнең бердәй якыны;
Тоташтың син безнең йөрәкләргә,
Тормыш булып, Ленин аркылы.

Әйе, партия — социалистик җәмгыять үсешенә, халкыбызның изге омтылышына дөрес юнәлеш бирүче бөек көч, политик системабызның үзәге. Халык үзенең барлык казанышларын һәм өметләрен аның эшчәнлеге белән бәйли. Шуңа күрә партия коммунистлардан үзләренең авангардлык ролен эзлеклерәк һәм тулырак үтәүләрен, партия члены исемен һаман югарырак күтәрүләрен, массалар белән элемтәне өзлексез ныгыта баруларын таләп итә. РСДРПның икенче съездының 80 еллыгы турында КПСС Үзәк Комитеты карарында әйтелгәнчә, «КПСС һәр коммунистның бөек идеалларның тантанасы өчен фидакарь көрәшче булуы турында, марксизм-ленинизм идеяләрен, партия политикасын тирәнтен белүе, аңлавы һәм тормышка ашыруы турында кайгырта. Партиядә тору бертөрле дә өстенлекләр бирми, ул илдә эшләнгән бар нәрсә өчен, социалистик төзелеш һәм иҗтимагый прогрессның язмышы өчен коммунистларның тагын да зуррак җаваплылыгын гына аңлата».

КПСС Үзәк Комитеты партиянең 80 еллык юбилеен коммунистларны һәм барча хезмәт ияләрен Ватаныбыз куәте хакына, бәхетле һәм тыныч тормыш, коммунизм тантанасы хакына яңа хезмәт уңышлары белән билгеләргә чакыра. Бу данлы дата әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренә дә дәрт һәм дәрман өстәр, партиялелек һәм халыкчанлык рухы белән сугарылган, тирән эчтәлекле һәм кызыклы яңа әсәрләр иҗат итүгә рухландырыр.

# В. Маяковский

## Сул марш

*(Матросларга)*

Сез атлагыз марш адымы белән!
Ни мәгънә бар буп-буш сүздә?
Ораторлар, тукта! Иптәш маузер,
сүз бирелә
Сезгә.
Адәм белән Хава биргән закон
калсын артта, калсын артта.
Ташла мескен атын син тарихның.
Сул аяктан атла!

Ишетәсезме, тельняшкалы халык!
Сез кисегез
океаннарны!
Югыйсә соң броненосецларның
киле ашалганмы?!
Күр, ыржайган британ арысланы
акыра,
карап безнең якка.
Ә коммуна яши,
ул буйсынмас.
Сул аяктан атла!

Анда,
ерак җирдә, тау артында —
күз яшьләре, ачлык, хәсрәт.
Миллионлаган халык,
диңгез аша
адымыңны яшьнәт!
Чолгаса да банда
һәм кысса да
елан кебек корыч алка,—
Антанталар җиңмәс Россияне.
Сул аяктан атла!

Бөркет күзе сүнми!
Бүген безне
сукырайтмас иске заман!

Пролетариат,
әйдә, бу дөньяның
син ал бугазыннан!
Күкрәк киереп,— алга!
Зәңгәр күкне
ал флаглар белән капла!
Кем ул баса уң аякка?
Сулы белән атла!

*1918*

**КАМИЛ МОСТАФИН** тәрҗемәсе

## Ә сез уйнап бирә алырсызмы?

Сүрән көннең болгаттым мин картыларын
буяу сибеп җибәрдем дә стаканнан;
бер коштабак койка алып, күрсәттем мин
кыйгач яңак сөякләрен океанның.
Калай балык тәңкәсеннән укыдым мин
яңа ярлар чакыруын сабырым сынып.
Ә сез,
яңгыр торбаларын флейта итеп,
берәр ноктюрн
уйнап бирә алырсызмы?

*1913*

## Тыңлагызчы

Тыңлагызчы!
Әгәр дә йолдызларны кабызалар икән —
димәк — бу кемгә булса да кирәк?
Димәк — кем булса да аларның булуын тели?
Димәк — кем булса да шул төкрекчекләрне
энҗе бөртекләре дип атый.
Һәм, чиллә тузаннары давылында
хәлдән таеп,
алла янына бәреп керә,
соңгардым дип куркып
елый-үкерә,
аның сеңерләнеп беткән кулларын үбә,
һәрвакыт бер генә булса да йолдыз булсын дип
үтенә!—
йолдызсызлык газапларын күтәрә алмаячагына
ант итә!
Ә соңыннан,
тыштан түзсә дә,
эчтән борчылып бетә.
Кемгәдер сүз ката:
«Хәзер сиңа ярыйсы ич?
Куркыныч түгел һич?

Әйеме?!»
Тыңлагызчы!
Әгәр дә йолдызларны кабызалар икән —
димәк — бу кемгә булса да кирәк?
Димәк — бу мөһим эш —
һәр кич
өй кыеклары өстендә
бер генә булса да йолдыз кабыну?!

*1914*

## Мыскыллаулар

Хыялымны тавис койрыгыдай кабартам да,
җанны атам кәтелмәгән рифма өере иркенә.
Тегеләрнең —
үзләрен туендырган имән тамырын
танау белән актаручыларның —
гәзит баганалары эченнән ыржайганнарын
тагын ишетәсе килә.

*1916*

## Айлы төн

*(Пейзаж)*

Ай булачак.
Инде
беленә.
Күккә эленде тулы укасы.
Ихтимал, алла
гаҗәеп
көмеш кашык белән
болгатадыр йолдыз ухасын.

*1916*

## Яз

Шәһәр кышкы тышкысын салды.
Селәгәен тыймый кар кере.
Тагын да яз. Хәтерләтә салкын
аңгыра, сафсатачы юнкерны.

*1918*

**РЕНАТ ХАРИС** тәрҗемәләре

# Зөфәр Фәтхетдинов

# АЧЫЛГАН СЕРЛӘР

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ

## I бүлек



Май жиле инде кара-кучкыл төскә кергән былтыргы яфракларны себереп бара да, һавага күтәреп, бер мәл бөтереп ала һәм урамнарга, Казанка ярларына сибеп ташлый. Гадәттә тыныч кына аккан бу елга салкыннан бөрешкәндәй күренә, су өсте дерелдәп торган җыерчыклар белән каплана. Җилдән чайкалган өрәңге ябалдашлары эчпошыргыч моңсу авазлар чыгара.

Салкынча. Жуков кулларын уыштыргалады һәм, түземсезләнеп, сәгатенә күз төшереп алды. «Илдар нигәдер соңара,— дип уйлап алды ул.— Моңарчы андый гадәте юк иде, эшендә берәр нәрсә килеп чыккан ахры».

Александр тагын бер ара көтеп торды да Закировның эш урынына шалтыратты. Телефон җавап бирмәде. «Монда килергә чыккандыр»,— дигән карарга килде Александр.

Жуков, чуен рәшәткә янына килде дә су өстенә карап тора башлады. Аның уйлары һаман шәһәр Советы башкарма комитеты хезмәткәре Древцовның үтерелүе һәм аның квартирының талануы турындагы эш тирәсендә бөтерелде.

Бу эшне тикшерүгә ул моннан ике генә көн элек килеп кушылды. Эш белән моңарчы шөгыльләнгән лейтенант Тренькин әллә ни алга китә алмаган иде. Хәл чыннан да катлаулы. Беренчедән, җинаятьчеләрнең максаты ачык түгел: әллә бу террорлык актын — гади бер караклык, ә кеше үтерүне очраклы хәл итеп күрсәтергә тырышумы, әллә, киресенчә, кеше үтерү — алдан һич күздә тотылмаган гади бер өй басу гынамы? Икенчедән, тикшерү барышында Тренькинның кайбер хаталары аркасында җинаятьнең ачылуы катлауланган иде.

Җинаять эшләнгән урынны кабат карау, яңа кешеләрдән сорау алу юлы белән Жуков күп кенә нәрсәләрне ачыклый алды. Шулардан чыгып ул,— дөрес, хәзергә үзе өчен генә,— мондый нәтиҗәгә килде: җинаятьченең төп максаты Древцовның квартирыннан заманында атаклы рәссам булган этисеннән калган кыйммәтле нәрсәләрне урлау булган.

Шуңа күрә ул элеккесенә капма-каршы булган икенче бер версия өстендә эшли иде. Таланган квартирны кабат караган вакытта алар унитаз бачогында мәрмәр төпчек савыты табып алдылар. Аны җинаятьче ташлаган булуы ачык иде. Экспертиза Древцовның нәкъ менә шул нәрсә белән бәреп үтерелгән булуын раслады. Өйдәге кыйммәтле әй-

берләрнең бик җентекләп эзләнүе һәм җинаятьчеләрнең эшне бик тиз тотулары да Жуковның күзенә ташланмый калмады. Һәлак буласы көнне Древцовның дачадан очраклы рәвештә генә кайткан булуы ачыкланды: туганнары аны телеграмма белән шәһәрара телефонга чакырган булганнар.

Бүген Александр «домушниклар»[1]ның картотекасын тикшерде. Архив тузанына күмелгән берничә җинаять эше белән танышып чыкты. Мәскәүгә берничә запрос җибәрергә дә өлгерде.

Александр уйларыннан аерылды һәм үзенең бердәнбер гадәти костюмына, ялтырар дәрәҗәдә чистартылган ботинкаларына күз төшерде һәм алардан канәгать калды. НКВД офицеры формасын еш кими иде ул. Бүген алар ахирәт дусты Илдар белән ресторанга барырга, анда үзләренең элекке сабакташлары белән очрашырга тиешләр.

Жуков ашыгып килгән аяк тавышларын ишетте һәм, су өстеннән күзен алырга теләмәгәндәй, ашыкмый гына шул якка таба борылды. Килүче кеше Закиров иде.

— Сәлам, Сашутка! Гафу ит, дускай. Кем әйтмешли, хәерчегә юл каршы.

— Ни булды тагын?

Закиров көрсенеп куйды:

— Инде чыгып барышым иде, баскычтан төшешли Михаил Иванович Чурбанов эләктереп алды. Начальство янынннан чыгып килеше икән. Кыскасы, безнең бүлеккә кызык кына бер эш биргәннәр, ә ул, озакка сузмыйча, аны миңа тапшырды...

Александр, аның халәтен аңлап, баш иэде.

— Эш муеннан,— диде Илдар,— ә без, җүләрләр, әллә кая барырга җыендык.

— Я, ярый, шыңшыма. Сөйләшенгән икән — барырга кирәк,— Жуков Илдарны учы белән төртеп җибәрде.— Менә хәзер Элька Бабанинаны күрерсең, бар борчуларың җилле көндәге төтен кебек таралып бетәр.

Дуслар «Центральный» ресторанына ашыктылар. Шул мәл аларга кемдер эндәште. Икесе дә берьюлы борылып карадылар. Асфальтка дагалы күн итекләре белән каты-каты басып, аларга таба бер хәрби килә иде.

— Исәнлекме, малайлар!— диде теге, алар белән тигезләшкәч.— Ау этләредәй чабасыз, көчкә куып җиттем үзегезне.

Бу Саша белән Илдарның элекке сабакташы Коля Батенев иде. Дуслар бу егет белән әледән-әле очрашып торалар, ул хәрби училищеда укый һәм елына ике тапкыр каникулга кайта иде... Ә хәзер аның петлицаларында ике ал кубик ялтырый — аңа моннан бер ел элек лейтенант дәрәҗәсе биргәннәр иде.

— Мин автобуста бара идем, сез күгәрченкәйләрне күрдем дә, төшмәкче булдым, ә ул мине бер квартал ары алып китте,— диде ул.— Шуңа күрә, аякларны кулга тотып, сезгә таба элдертергә туры килде.

Николай фуражкасын салды, тирләгән маңгаена кулъяулыгын тидереп алды, кесәсеннән зур гына сәгать чыгарды:

— Соңарабыз бугай.

— Эшкә түгел әле,— диде Закиров,— өлгерербез...

Аларның элекке сабакташларыннан унбишләп кеше озын өстәл тирәсенә утырганнар да, кызып-кызып, нәрсә турындадыр гәпләшәләр иде.

— О-о-о!— дип бер тавыштан кычкырып җибәрделәр инде кыза төшкән яшьләр.— Күрешмәгәнгә күпме вакыт!!

Кул кысышулар, хәл-әхвәл сорашулар башланды.

---

[1] «Домушник» — җинаятьчеләр телендә — өй басучы карак. (Биредә һәм киләчәктә автор искәрмәсе.)

Соңга калганнарның бүтәннәре дә әкренләп килеп җитте. Зәңгәр күлмәк кигән зифа буйлы чибәр Эля Бабанина да килде. Аның матур муены нечкә алтын чылбыр белән уратылган иде. Озын керфекле зәңгәр күзләре ягымлылык һәм йомшаклык сирпеп торалар төсле. Илдарга кыз тагын да чибәрләнгән төсле тоелды, һәм ул йөрәгенең еш-еш тибә башлавын сизде. Юк икән шул, аңа карата булган хисләре сүрелмәгән икән. Илдарның бөтен барлыгын ниндидер кыюсызлык биләп алды. Алдан әзерләп куйган матур сүзләре кайдадыр югалды, мие фикер йөртә алмас дәрәҗәдә каткан иде.

«Мин йөрәгем белән тыелгысыз дәрәҗәдә шул кызга омтылам,— дип уйлады Илдар.— Ничә ел инде ул минем күршемдә яши. Ә мин үземнең хис-тойгыларымны аңа белдерә алмыйм. Әгәр бүген әйтеп бирсәм?..» Бу уйдан тәненең эсселе-суыклы булып киткәнен сизде ул...

— Син нәрсә, картлач, борыныңны салындырдың?— диде Александр, аңа кагылып.— Биергә чакыр үзен тизрәк, юкса бүтәннәр алып китәр.

Сүз артыннан сүз чыгып, алар залның халык белән тулуын сизми дә калдылар. Биергә теләүчеләр оркестр урнашкан мәйданчык янына җыелган иде. Бер-берсен алыштырып, танголар, фокстротлар уйналды. Менә оркестрның музыка фонына кинәт яшь бер җырчының яңгыравык көчле тавышы килеп кушылды:

Москва златоглавая — звон колоколов,
Царь-пушка державная, аромат пирогов,
Конфетки, бараночки, лебеди-саночки...
Эх, вы, кони залетные, слышу песнь с облучка...

Бу күңелле җыр кешеләргә дәрт өстәп җибәргәндәй булды, күпләр, кузгалып, бию мәйданчыгына ашыктылар.

Матур тенор бераз сагышлырак ноталар белән дәвам итте:

Гимназистки румяные, от мороза чуть пьяные
Грациозно сбивают рыхлый снег с облучка.

— Я, нәрсә син бозау төсле шаккатып калдың?— дип пышылдады Жуков.— Бар инде тизрәк, моннан да уңайрак форсат таба алмассың.

Илдар урыныннан торды, һәм кыюсыз гына елмаеп, Эляны биергә чакырды. «Мәктәптә чакта мин күтәрелеп карарга да кыймый йөргән горур отличница — шул Элямы соң бу?— дип уйлады ул.— Хәер, мин хәзер дә артык кыю булуым белән мактана алмыйм бит».

Илдар битендә кызның кайнар сулышын, учында кулларының җылысын тоеп, йөрәгенең атылып чыгардай булып тибүен сизеп биеде. Кызга нәрсәдер әйтергә, аның белән сөйләшергә кирәк иде. Ләкин аның башына бернинди төпле уй килмәде. «Менә агач бүкән!— дип сүкте ул үзен.— Ләкин нәрсә әйтергә соң? Күптән яратып йөрим, дипме? Әгәр көлә башласа? Көлсә соң! Барыбер әйтергә кирәк... Менә хәзер өстәл янына утыргач, тыныч кына уйлыйм да аны тагын биергә чакырам һәм барын да ярып салам»...

Закиров теге егет җырлап бетергәч кенә аңына килде. Алар өстәл янына килделәр. Жуков үз урынында юк иде.

— Ә Сашутка кайда?— дип сорады ул Буренкиннан.

— Шайтан белсен, каядыр китте! Ниндидер бер сакаллы кешене күреп алды да, кискә тап булган сунарчы кебек, аның артыннан ашыкты.

— Күптәнме?

— Син биергә киткәч үк.

Илдарның күңелен шик биләп алды. Китәсе булса, Александр моны аңа әйтми эшләмәс иде. Ул нинди сакалбай икән тагын? Бәлки берәр танышыдыр? Шуның белән сөйләшергә генә чыккандыр? Ә бәлки...

Закиров Эля янына килде:

— Тагын бер тапкыр биербездер бит...

Кыз аңа күзләрен тутырып карады:

— Әлбәттә, әлбәттә...

— Мин бер генә минутка, Эля. Мин хәзер...

Ул чыгу ягына таба ашыкты. Жуков беркайда да юк иде. Швейцар аңа әле генә өч ир кешенең чыгып китүен әйтте.

Илдарның шикләнүе борчылуга әверелде, ул, ашыгып, урамга чыкты. Битенә кичке салкын һава бөркелде. Көн инде сүнгән булса да, алсу буяуга манылган болытлар күктән йомшак яктылык сирпеп торалар төсле тоела.

Үтеп йөрүчеләрнең силуэтларына игътибар итә-итә, Закиров үзәк урам буйлап ашыкты. Караңгыда кешеләрнең йөзләрен аерып хәл юк иде, аңа таныш сын күренмәде. Кая китте икән соң ул?

«Әллә инде Древцов эшенә бәйле булган берәрсенә тап булдымы?»— дип уйлап алды Илдар.

Ул кире әйләнеп килде һәм, як-ягына карый-карый, тыкрык буйлап йөгерде. Йорт ишекләре янында туктап, тавыш-фәлән юкмы, дип тыңлап торды. Берни дә ишетелми иде. Тагын ике өйне үткәч, ул кыйшайган капкадан эчкә кереп китте. Бер кешесез тын ишегалды түрендә утын әрдәнәсе агарып күренеп тора. Ә сулдарак — ишексез капка: йорт үтәли йөрешле иде. Илдар ишегалдын йөгереп үтте дә әлеге капка аша янәшә урамга барып чыкты. Ләкин анда да беркем күренми иде.

Ул кире йортка әйләнеп керде. Бер мәл колак салып, як-ягына каранып торды. Әйләнә-тирәдәге бар нәрсә кичке караңгылык эченә күмелгән иде. Ашамлык калдыклары һәм хлорка исе килә. Менә кинәт нидер кыштырдаган тавыш ишетелде. Ул сагаеп кына подъездга таба берничә адым ясады. Кибеп беткән ишек ярыклары аша зәгыйфь кенә ут яктысы саркый.

«Тәмәке кабызырга шырпы яндыралармы соң? Әллә малай-шалай шаярамы? Закиров ишек янына килде, аны каерып ачты. Һәм, эчтәге хәлне күреп, тораташ булып катты.

Керү юлында ук, ишеккә йөз белән борылган килеш, ике ир кеше ниндидер кәгазьләрне карап маташалар иде. Берсенең кулында пистолет, икенчесе янган шырпы тоткан. Аңардан бераз сулдарак, агач баскыч астында, бер кеше ята. Ярым караңгыда аның көрән тапларга буялган ак күлмәге генә күренә иде.

Бу коточкыч күренештән Илдарның йөрәге тибүдән тукталгандай булды: «Әллә Сашамы бу?»

Әлеге кешеләр берәү дә йөрми торган подъездга кем дә булса керер дип көтмәгәннәр, күрәсең. Шулай да аларның озынрак буйлысы беренче булып аңына килде:

— Легаш? [1] — диде ул куркыныч-ачулы тавыш белән һәм коралын Закировка төбәде.

Бу карлыккан саңгырау тавыш Илдарны кузгалырга мәҗбүр итте, һәм ул, көтмәгәндә, аягы белән озын буйлының кулына китереп типте. Тегенең пистолеты каядыр сулга, караңгы идәнгә барып төште. Ә кара сакаллысы, шырпысын ташлады да сугар өчен кизәнде, ләкин Илдар йодрыгы белән сугып, тегене аяктан егарга өлгерде. Һәм шунда ук озын буйлының күкрәк авызына төндырыр өчен аңа ташланды. Теге артка чигенде, ләкин, сөртенеп, баскычка ауды, үзе артыннан Закировны да өстерәде. Ул Илдарны өстеннән алып ташламакчы булып карады, ләкин Закиров аны ычкына алмаслык итеп китереп кыскан иде.

— Аягыннан өстерә шуны! — дип акырды озын буйлы үзенең эшнәсенә.— Батыр шуңа кыптыңны[2]! Тизрәк!

---

[1] Легаш, легавый — караклар жаргонында милиция кешесе дигән сүз.

[2] Кыпты — пычак.

Сакалбайның инде идәннән торган булуын чамалап, Илдар да аягына басмакчы булып карады, ләкин теге озын бәндә аның кулын келәшчә белән эләктергәндәй ныклап кыскан иде. Закиров бер аягын үзенә таба тартты, аның белән стенага терәлде дә чак кына гәүдәсен читкәрәк күчерде. Сакаллының силуэты ачык ишек фонында күренү белән, аңа тибеп җибәрде. Сакаллы бер мәл чайкалып торды да идәнгә ауды.

Закиров уң кулын тартып алырга маташып карады, ләкин җинаятьче аңардан көчлерәк иде, һәм Илдар ычкына алмады.

— Яндыр шырпыңны, Йөнтәс! Пушканы тап та дөмектер шуны!

Тегесенең, яңа йокыдан уянгандай, ишек янында капшана башлавы ишетелде.

— Ат инде тизрәк, эттән туган нәрсә! — дип яңадан акырып җибәрде бандит. — Тик ян-яктан кил, миңа тидерә күрмә!

Хәлнең мөшкеллеген аңлап, Илдар ни эшләргә икәнлеген чамалады: көтмәгәндә башы белән җинаятьчеңең битенә китереп бәрде дә бөтен көченә артка тартылды. Тегесе бу юлы аны тотып кала алмады.

Закиров караңгыда чамалап кына икенче җинаятьчегә ташланды, ләкин аны туры китерә алмады. Сакалбай идәндәге пистолетны табып өлгергән иде, һәм Илдарга каратып атып җибәрде. Кысан подъездда ату тавышы туптан аткандай яңгырады. Закиров Сакалбайның кулын эләктереп алды. Яңадан ату тавышы ишетелде, түшәмнән штукатурка коелды. Илдар тегенең коралын тартып алырга маташып карады, ләкин булдыра алмады — алар янына килеп җиткән икенче җинаятьче йодрыгы белән аның күкрәгенә каты итеп сукты, һәм ул ишектән атылып чыкты да баскыч төбенә егылды.

Ишекнең эчке ягыннан:

— Ат, падла! — дигән тавыш яңгырады. Ләкин нигәдер алар бер мәлгә тоткарландылар.

— Бир әле монда, мин үзем! — диде әлеге үк тавыш.

Илдар, үз коралын алу өчен, кулын кесәсенә тыкты. Башыннан: «Соңардым, ахрысы, предохранительдән алынмаган»,— дигән уй йөгереп үтте.

Закиров пистолетын тартып чыгарды, ләкин Озын, ишек яңагы артына посып, корал тоткан кулын ишегалды якка сузды. Илдар, үзен ишек белән каплар өчен, яткан килеш гәүдәсен читкә ташлады. Тагын ату тавышы яңгырады. Ядрә Илдарның янәшәсендә генә җиргә килеп бәрелде. Һәм шул чак, уйлап эшләүдән бигрәк, инстинкт белән, ул бар көченә ишеккә китереп типте. Һәм бу хәрәкәт аны үлемнән коткарып калды: коры такта ишек, кинәт ябылып, коралның металл көпшәсенә килеп бәрелде, һәм шул ук мизгелдә тынлыкны тагын ату тавышы ярып үтте.

Пистолетны предохранительдән алып, Закиров ике тапкыр ишеккә төзәп атып җибәрде, ә үзе, йөгереп барып, стенага елышты. Теге якта тагын аттылар — як-якка вак йомычкалар чәчелде. Тып-тып басып, агач баскычтан менеп киткән аяк тавышлары ишетелде.

«Качалар, хәшәрәтләр!» — дигән уй белән Илдар ишекне тартып ачты һәм берничә тапкыр атарга өлгерде. Кемдер ухылдады. Ул, кулларын бутап, караңгылык эченә чумды. Илдар берара колак салып торды. Өстәрәк кемдер хырылдый иде. Андагы квартирдан тәрәзә пыяласы ватылган тавыш ишетелде. «Берсе дөмекте бугай, ә икенчесе качмакчы», — дип уйлады ул. Аннары баскычтан күтәрелде дә, капшана-капшана, стена буйлап квартир ишегенә таба китте. Баскыч төбенә җитәрәк кенә кемнеңдер гәүдәсенә абынды һәм, ишек яңагына бәрелеп, башын авырттырды.

Закиров шырпы кабызды. Аңа пистолеттан аткан җинаятьче, стенага сөялеп, тынсыз утыра иде. Илдар аның кулыннан коралын алды һәм, ишекне төртеп ачмакчы булып, бөтен гәүдәсе белән этеп карады.

бу да файда итмәде. Ул йөгереп аска төште, ишегалды аша үтеп, күрше урамга чыкты, ләкин анда да беркем дә юк иде. Аның йөрәге шомланып тибә башлады. «Баскыч астында яткан кеше Саша түгел микән?» Ул, тыны кысылып, янадан подъездга йөгереп керде, шырпы яндырып, идәндә ятучының йөзен яктыртты һәм йөрәгенең әрнеп сызлануын сизде. Илдар колагын Александрның күкрәгенә куйды: йөрәге бик тирәннән сизелер-сизелмәс кенә тибә иде. Димәк, исән!

— Исән! — дип, шатлыгыннан үз-үзен белештермичә, шашып кычкырып җибәрде ул һәм йөгереп урамга чыкты. — Сашутка исән! Әй, кем бар монда?!

Ләкин ишегалды җан өшеткеч тынлык белән җавап бирде. Һәм ул якындагы телефонга таба бар көченә йөгерде.

### II бүлек

Светловолжск шәһәре милициясенең Совет район бүлегендә дежур торучы өлкән лейтенант Геннадий Севчукның кәефе шәптән түгел — бүген алар хатыны белән сүзгә кергәннәр иде. Соңгы вакытларда аларның мөнәсәбәтләре ничектер бозылып китте әле. Ул хезмәт урынына, үзе әйтмешли, «кәефе нульгә төшеп» килә, анда да сүрән кыяфәттә утыра. Өстәвенә әледән-әле хәтере чуала башлады. Гаиләсендәге күңелсезлек турында ул беркем белән дә, хәтта якын дусты Рәфкать Измайлов белән дә уртаклашмады — тумыштан шундый йомык табигатьле, бар нәрсәне эченә сеңдерүчән кеше иде ул.

Менә кинәт телефон шалтырады. Севчук трубканы алды, берара тыңлап торды да ачыкларга кереште:

— Алай... Нинди урамда дидегез?.. Уң як Болак? Ә аерым билгеләре нинди?.. Яхшы, хәзер килербез.

— Рәфкать,— диде ул Измайловка,— Уң як Болак урамындагы илленче өй янында кеше талаганнар. Таланган хатын көтеп торачак. Машина ал да шунда бар.

— Есть!

Измайлов ишеккә таба ашыкты, коридорда оперативникларның аяк тавышлары яңгырады, тышкы ишек шапылдап ябылды, һәм янадан тынлык урнашты. Севчукка ялгыз калу кыен иде. Ул немец теле дәреслеген алды, кирәк битен тапты, ләкин артикульләрнең ничек төрләнүен һич аңлый алмады — уйлары таркалды. Башында бар нәрсә буталды, нинди дер вакыйгалар, кешеләр искә төште...

«Әйе, бу хәлдә мин бүген күп нәрсә өйрәнә алмам, ахрысы»,— диде Геннадий үз-үзенә, дәреслекнең калган битләрен актара-актара.

Аның күңелсез уйлары күп тапкырлар төрле хәбәрләр белән бүленә торды. Төнге сәгать бердә төзелеш идарәсенең каравылчысы шалтыратты һәм сәгать уникеләрдә билгесез кешенең тәрәзә аша конторга кергән һәм андагы бар нәрсәне пыран-заран китергән: кәгазьләрне таратып ташлавын, андагы эш киемен ерткалап бетергән хәбәр итте. Ләкин җинаятьче андагы әйбер-сәйберне алмаган иде. Каравылчы, тагын өстәп, ул мөгаен кулын пыялага кискән булса кирәк — идәндә кан таплары калган,— дигән фикер әйтте.

Севчук өйрәнелгән гадәт буенча бу хәбәрне журналга теркәп куйды һәм, озак уйлап тормастан, малай-шалай эше бу, дигән карарга килде. «Оператив группа кайтыр да, җибәрермен,— дип уйлады Севчук. — Ә хәзергә участок уполномоченныена әйтеп куярга кирәк».

Нәкъ шул вакыт аңа хатыны шалтыратты.

— Беләсеңме, Геннадий, мин иртәгә аерылышу турында гариза бирергә булдым. Икебез өчен дә шулай яхшырак булыр...

Хатыны бу сүзләрне бер тында әйтеп ташлады. Геннадийның үзенең дә мондый карарга килгәләгәне булса да, бу сүзләр аның өчен һич көтелмәгән иде. Ул каушап калды.

— Нигә шулай ашыгасың? — дип, үзенә дә таныш булмаган карлыккан тавыш белән сорап куйды Геннадий. Ул бу эшне сузуның берни бирмәячәген дә аңлый, ләкин ниндидер көч аны җимерелеп баручы гаилә куышының хәрабәләренә тотынып калырга мәҗбүр итә иде. — Тыңла әле, әйдә хәзергә аерылышмый торыйк, ә? Үтенеп сорыйм. Әйдә, бер-беребездән читтә торып карыйк, шунда барысы да ачыкланыр. Я инде, сиңа бүтән бернинди үтенечем юк...

— Булмый,— диде металл чыңлавына охшаш хатын-кыз тавышы, һәм трубкада кыска гудоклар ишетелде.

Бу хәл Севчукны бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Моннан соңгы вакыйгалар аңа төштә күргән нәрсәләр кебек кенә тоелды: кемнәрнедер китерделәр, төрле протоколлар язылды, тоткарланган кешеләрдән аңлатмалар алынды.

Инде таң атып, кош-корт уянгач һәм Севчукның күзен йокы баскач, республиканың Эчке эшләр халык комиссарлыгыннан телефонограмма килде:

«Республика милициясенең барлык район бүлекләренә. Урта буйлы, коңгырт чәчле, таза гәүдәле, сакаллы һәм мыеклы җинаятьчене эзләү һәм кулга алу өчен һич кичекмәстән чара күрегез. Аның уң иңбашы яисә уң кулы яралы булырга тиеш. 22.00 сәгатьтә эзәрлекләүчеләрдән эз яшерде. Җинаятьче кораллы. Бу вакыйгага кагылышлы булган сезгә билгеле барлык фактлар турында кичекмәстән хәбәр итегез».

Севчук кинәт айнып киткәндәй булды — бөтен тәне буйлап чиркандыргыч салкын йөгереп үтте, күкрәге сыкрап алды — бу күңелсезлек буласының бер билгесе иде. Ул үз-үзенә бер үк сүзләрне кабатлады: «Бу вакыйгага кагылышлы булган сезгә билгеле барлык фактлар турында хәбәр итегез».

Ул төзелеш идарәсе каравылчысы хәбәренең әлеге телефонограммага кагылышлы икәнен бөтен барлыгы белән сизенә иде. «Бу хәбәрне алгач, мин нинди чара күрдем соң? — Севчук башына суккандай калтыранып куйды. — Әллә берни эшләмәдемме?!» Ул куркынган кыяфәт белән ачык журналга күз төшерде: күрелгән чаралар графасында бернинди язу юк иде.

— Ал-а-а-й,— диде ул һәм, хәле бетеп, урындыкка утырды. — Менә сиңа мә! Ничек итеп мондый ялгышлык ясадым соң әле мин? — Һәм Геннадий хатынының, шалтыратып, уйларын чуалтуын исенә төшерде.

Йөрәге хәвеф буласын сизенүдән сыкрап куйды.

Ул урыныннан торды һәм бүлмәдә арлы-бирле йөренә башлады. Бер-берсен узарга теләгәндәй, башында төрле уйлар кайнашты: «Ул бит контордагы тужурканы ярасын бәйләр өчен ерткан. Ә кәгазьләр? Ә аларын идәнгә тамган кан эзләрен яшерер өчен, бүлмәгә кергән кеше башта ук аларга игътибар итмәсен өчен, вакытны отар өчен чәчеп ташлаган! Ә мин, юләр... — Ул башын куллары белән кысты. — Ә мин монда оеп утырам... Хәзер үк Измайловны шунда җибәрергә кирәк. Ул кулыннан килгәннең барын да эшләячәк, барын да...» Севчук, йөгереп, коридорга чыкты, постта торучы милиционерга кычкырды:

— Тиз генә Измайловны чакырыгыз. Бик тиз!..

Ул моннан соң нәрсә булачагын аермачык итеп күз алдына китерде: «Берничә сәгатьтән, әлеге вакыйга булган урынны карап чыккач, аның турында хәбәр итәргә мөмкин булыр. Шуннан соң сорарлар, нигә телефонограмманы алгач ук хәбәр итмәдегез, диярләр. Төпченә башларлар: нәрсә, ничек, кайда, фәлән-фәсмәтән... Минем эшлексезлек күрсәтүем ачыкланыр, нык кына кыздырырлар. Үз гаебеңне хатынга

сылтап булмый бит инде. Әйтсәң, начаррак та булуы бар әле: мораль яктан таркалуда гаепләүләре бар...»

Ул бүлмәгә кире әйләнеп керде. «Әгәр хәзер үк хәбәр итсәм? Ни булачак? Әмма, нәрсә дип хәбәр итим ди мин? Үземнең фараз кылуларымнымы? Хәер, аларын вакыйга булган урынны караганнан соң туган нәтиҗә итеп тәкъдим итәргә мөмкин. Ә ул арада Измайлов тегендәге обстановканы белеп кайтачак. Минем өчен бәладән котылу юлы бит бу, кызыктыргыч юл...»

Севчук, тәрәзәдән башын тыгып, бер мәл, үзен центрифугада сынарга әзерләнгәндәй, башын боргалап торды, аннары яңадан өстәл янына килде. «Юк,— диде ул, ниһаять. — Инде без дә шулай алдаша башласак, кемгә генә ышанырга кала соң?»

Ул ике куллап урындык артына терәлде:

— Шайтан белсен, әллә ни булды миңа! Мөгаен, Неля хаклыдыр: башыма шундый әшәке уйлар килә икән, димәк, мин — юньле кеше түгел.

Берничә минуттан Измайлов, ике оперативникны һәм эт йөртүчене ияртеп, әлеге төзелеш идарәсенә китте. Тәмам яктырган иде инде. Кояш офыктан шактый күтәрелгән, аның нурлары, агач яфраклары аша үтеп, бүлмәдә тигезсез таплар булып таралды. Геннадий учын күзләре өстенә куйды да күптән юылмаган, тузанлы пыяла аша урамга карап тора башлады. Начар күренгәнгә, ул тәрәзәне бөтенләй ачты.

«Бәлки мин ялгыша торганмындыр? — дип уйлады ул ниндидер өмет белән. — Чыннан да малайлар шуклыгы гына булуы да ихтимал ич?! Алай булса, Измайлов хәзер кайтып җитәргә тиеш».

Измайлов группасы төзелеш идарәсе конторасын тикшереп чыкты һәм идәндәге кан тапларына игътибар итте. Төнге кунакның кайсы якка таба китү мөмкинлеген һәм канның нинди юнәлештә тамуын чамалап, алар, теге кешенең уң ягы — кулы яисә иңбашы — яралы булырга тиеш, дигән карарга килделәр.

Кан эзенең дәвамын таптылар — эзләр азык-төлек кибете янында югала иде. Измайлов, теге кеше машинага утырып элдерткән булса кирәк, дигән карарга килде. Каравылчыны эзләргә тотындылар. Ун минут чамасы үткәч, ул үзе килеп чыкты. Каравылчы хатын кибеткә каршы гына яши һәм, әйтүенә караганда, кибетне квартир тәрәзәсеннән генә карап утыра икән. Башта оперативниклар аның бу сүзенә ышанмадылар, ләкин аларның Сакалбай турындагы сорауларына каршы каравылчы хатын шунда ук:

— Күрдем мин аны,— диде. — Төнге сәгать берләрдә бу тирәдә кайнашты. Ике тапкыр кибетне әйләнеп чыкты, урам этедәй минем будкага да кереп карады. Мин инде, берәр нәрсә эләктерергә чамалап йөри бу, дип уйлаган идем. Әмма нәкъ шул мәлдә, ватык арбадай шалтырап, күрше егете Фоатның йөк машинасы килеп туктады. Теге Сакалбай — Фоат янына. Нәрсә турында сөйләшкәннәрдер — әйтә алмыйм, әмма шуннан соң дьяконга охшаган әлеге кеше аның кабинасына менеп утырды, һәм алар китеп тә бардылар. Ә кая киткәннәрен алла белсен. Күршем ике сәгатьтән соң гына әйләнеп кайтты.

Измайлов Фоатны уятты. Ул егерме биш сум бәрабәренә Сакалбайны Святовск поселогына илтүен әйтте. Шофер егетне үзләре белән машинага утыртып алып киттеләр. Ул оперативникларга Сакалбайны кайда төшереп калдыруын күрсәтте. Эт авырлык белән эзгә басты, берничә тапкыр югалтып азапланды. Ә Идел буе монастырена, дөресрәге, аның Идел суына ук алып төшүче таш баскычына җиткәч, эз бөтенләй юкка чыкты. Оперативниклар анда шактый озак маташтылар, ләкин бу файда бирмәде...

Измайлов иртән сәгать сигезләрдә генә әйләнеп кайтты.

— Беләсеңме, картлач,— дип башлады ул сүзен бусаганы атлау белән. — Уңмадым әле мин бүген. Менә маңгайга нинди фонарь куйдым, күрәсеңме? Тип-тигез урында, таш баскычта абындым бит...

— Сузма зинһар, тизрәк сөйлә! — дип, Геннадий түземсезләнеп аның сүзен бүлдерде.— Вакыт көтми, хәбәр итәргә кирәк тизрәк...

## III бүлек

Республика Эчке эшләр халык комиссарлыгының тикшерү бүлегендә киңәшмә уналты сәгатьтә башланды. Анда милициянең район бүлекләреннән дә кайбер кеше катнашты. Начальник урынбасары, юанрак гәүдәле, пеләшләнә башлаган башлы майор Галләмов соңгы көннәрдә булган вакыйгаларның асылын аңлатып бирде. Ул аягүрә баскан килеш, гадәтенчә бераз чайкала-чайкала сөйләде. Кәгазьләренә күз төшермәде — хәтере яхшы иде аның. Кичәге вакыйгаларга да тукталды. Арыган, калтыравык тавыш белән милициянең таныш булмаган кешене тоткарларга маташуын, аның әзе Святовск поселогында, Идел буе монастыре тирәсендә юкка чыгуын сөйләде. Майор, Закиров яралаган җинаятьче һәм төзелеш идарәсе конторасына керүче бер үк кеше булырга тиеш, дигән фикерне әйтте. Дәлилләр китерде: аяк киеме калдырган эзләр бер үк төсле, һәр икесеннән кан аккан, вакыйгалар үзләре дә берсе артыннан икенчесе килә. Җинаятьчегә эз яшерергә мөмкинлек биргән сәбәпләрнең берсе — Совет районы милиция бүлеге хезмәткәрләренең эштә сүлпәнлек күрсәтүләре, дип басым ясап әйтте.

— Иптәшләр,— дип дәвам итте Галләмов, ачык тәрәзәгә караган килеш. — Жуковның теге ике кешене ни сәбәпле шик астына алып, алар артыннан китүе әлегә ачык түгел. Ул үзе авыр хәлдә больницада ята. Врачлар, эшләр уңышлы барган очракта да Жуков белән бер атнасыз сөйләшеп булмаячак, диләр.

Галләмов графиннан стаканга су салды һәм бераз эчеп куйды.

— Монда утыручыларның хәтеренә төшерим: Жуков, Тренькин белән бергә, Древцовның үтерелүе һәм аның квартирасы талануы турындагы эшне алып бара иде. Без инде бу эшнең ни хәлдә булуы турында Тренькинны тыңладык. Кызганычка каршы, ул безне шатландырмады. — Майор күзлеген салды һәм боерык тоны белән сүзен тәгәлләде:— Бүлек тикшерү эшенә җитәкчелекне өлкән лейтенант Закировка тапшыра.

Ул Илдарга таба борылды һәм аңа сынаулы караш ташлады да бераз әкренрәк тавыш белән:

— Иптәш Закиров, бу уңай белән каршы әйтер сүзегез юкмы? — диде.

Закиров урыныннан торды:

— Юк. Ләкин минем өстә болай да ике ашыгыч эш...

Галләмов аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Эшләрегезнең барысын да капитан Черныхка тапшырырсыз. Ул иртәгә ялдан килә. Һәм шуны истә тотыгыз, Закиров, эшкә бөтен көч белән тотынырга кирәк. Инде ике атна үтте, ә нәтиҗә — песи күз яшедәй генә...

Аннары киңәшмәгә җитәкчелек итүче, әле шактый яшь булса да, коңгырт чәченә чал кунган, гимнастеркасының якасына өч шпал кадалган чибәр генә кеше урыныннан кузгалды. Кабинетта пышылдаулар шып туктады, тынлык урнашты.

— Иптәшләр,— диде бүлекнең җитәкчесе подполковник Чурбанов,— соңгы көннәрдә Жуков үзе алга сөргән версия буенча картотеканы һәм

архив материалларын өйрәнә иде. Аның ресторанда Древцовны үтерүгә катнашы булган берәр кешене очраткан булуы бик ихтимал. Тагын шуны да исәпкә алмый булмый: Жуков тикшергән барлык эшләр моңа кадәр җинаятьчеләрнең кулга алынуы белән төгәлләнә иде. Минемчә, ул алга сөргән версия нык игътибар таләп итә. Һәрхәлдә ул безгә билгеле булган фактларны һәм вакыйгаларны бер җепкә тезәргә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта җинаятьне җаваплы совет работнигына каршы террорлык акты дип аңлата торган элекке версиядән дә баш тартырга ярамый. Шуңа күрә Тренькинга күпмедер вакыт шул юнәлештә эшләргә туры килер. Күпме икәнлеген Закиров үзе хәл итсен. Мөгаен, хәзергә бу ике версияне капма-каршы куярга кирәк түгелдер.

Автономияле республиканың Эчке эшләр халык комиссары белән тоташтыра торган телефон шалтырый башлады. Чурбанов трубканы алды. Йөзенең кинәт киеренкеләнеп китүенә, аның, ашыгып, нидер яза башлавына карап, барысы да ниндидер җитди вакыйга булганлыгын шәйләделәр.

— Гафу итегез, иптәшләр,— диде Чурбанов сөйләшеп бетергәч.— Дәвам итик... Иптәш Закиров, үтерелгән җинаятьченең һәм, мөмкин булганча, Сакалбайның кем булуын бик ашыгыч рәвештә ачыкларга тырышыгыз. Бу бер. Икенчесе: мин сезгә вакыйга булган урында, үтерелүченең квартирында булырга киңәш бирер идем. Бу күп нәрсә ачыклар, уйланыр өчен азык бирер. Менә шул. Киңәшмә тәмам.

Чурбанов бүлекнең кайбер хезмәткәрләренә тоткарланырга кушты. Ул, калган кешеләрнең үзе әйтәчәк нәрсәләрне аңларга һәм бәяләргә сәләтле булу-булмауларын белгеләргә теләгәндәй, аларның һәркайсын аерым-аерым күздән кичерде, бер кавым уйланып торды.

— Әле генә Халык комиссары шалтыратты... Светловолжскидан Идел буйлап сигез чакрым түбәндәрәк төнге сәгать өчтә берничә минут дәвамында билгесез рация эшләгән. Ул тапшырганнарның бер өлешен безнекеләр язып алырга өлгергәннәр. Шифрны ачу өстендә эшләү бара. Оператив группа ачыкланганча, эз Святовск поселогы кырыендагы Идел буе монастыреннан алты чакрым ераклыкта югалган. Шул тирәдә, юл буендагы куаклыкта тәгәрмәче тишелгән велосипед табылган. Рация эшләгән урында бу велосипедның эзләре калган булырга тиеш, дигән фикер бар. Ә хәзергә, әйдәгез картага күз төшерик.

Чурбанов бүлмәдәгеләрнең барысын да республиканың картасы янына чакырды. Ул, кулына күрсәткеч таяк алып, аны төрле төскә буялган билгеләр буйлап йөртте.

— Мөгаен, ул менә монда тапшыру алып барган һәм, эше беткәч, борылмалы юлдан киткән булырга тиеш. Күрәсезме, менә монда ул юл Иделдән якын ук үтә...

— Аның нәкъ менә шунда көймәгә күчеп утырган һәм агым уңаена түбәнгә төшеп киткән булуы да бик ихтимал,— диде өлкән тикшерүче майор Стеклов. — Агым тизлеген дә исәпкә алырга кирәк.

— Бу мөмкинлекне сызып ташлап булмый,— диде Чурбанов,— ләкин алда, ярты чакрым гына ераклыкта юл тармаклана... Һәм шунда аны машина көтеп торган булуы да бар. Ә аннан радист өч юнәлештә китә ала. Димәк, борылмалы юлның елгага якын килүен, анда көймәгә утырырга мөмкин булуы фактын аларның безне алдау өчен файдаланган булулары ихтимал. Моның киресен дә фараз кылып була: дошман безнең нәкъ шулай дип уйлаячагыбызны алдан ук истә тоткан...

— Шулай да, иптәш подполковник, бер юлны исәпкә алмаска була: ул, мөгаен, оператив группа килә торган якка хәрәкәт итмәгәндер. Бу бит Светловолжскидан бирегә килә торган бердәнбер юл,— диде Закиров. Ләкин шунда ук әйткәннәренең дөреслегенә үзе үк шик белдер-

де: — Алай дисәң, монда бит әле тагын вакытны да искә алырга кирәк. Оператив группа ул тапшыру алып барган җиргә күпме вакыттан килеп җитә ала?..

— Дөрес бу. Хәзер уйлап карыйк инде...

— Мөмкинме? — ишектә йомышчы күренде.

Чурбанов шул якка борылды.

Йомышчы, тиешле формасын китереп, подполковникка мөрәҗәгать итте һәм аңа билгесез разведчикның эшләренә бәйле булган мәгълүматлар салынган пакетны тапшырды.

— Нәкъ менә шул сез әйткән мөмкинлектән чыгып фикер йөртеп карыйк,— дип дәвам итте Чурбанов, пакет эчендәге кәгазьләр белән таныша-таныша. — Радист, әлбәттә, рациянең эшләве һәм тапшыру алып бару урыны безнең контрразведчикларга билгеле булачагыннан чыгып эш иткән. Ләкин кемгә күпме вакыт кирәк соң? Эш уңышлы булган очракта рацияне пеленгалау һәм ул эшләгән урынга килеп җитү өчен ким дигәндә кырык — кырык биш минут кирәк. Юл чатында без утыз биш минуттан соң гына була алабыз. Ә радист ни эшли? Рацияне җыю, урнаштыру өчен аңа биш минут артыгы белән җиткән. Юл чатына кадәр — ике чакрым. Велосипедта ул араны алты-җиде минутта үтеп була. Шулай итеп, аның әле запаста егерме минут вакыты кала. Велосипеды ватылган тәкъдирдә дә юл тармакланган урынга ул бездән күпкә алданрак килеп җитә. Нәкъ менә шундый очрак өчен шпионның автомашина яисә көймә хәзерләп куйган булуы мөмкин.

Радистның нинди вариант буенча эш иткәнлеген тикшерү өчен, бүлек җитәкчелеге махсус группалар төзергә карар итте. Шулай ук рацияне эзләүне оештырырга кирәк дип табылды. Ул кайдадыр, торак пунктлардан ерак булмаган урман эчендә яшерелгән булырга тиеш, дип фараз кылынды. Галләмов белән Стеклов исә рацияне юл чаты белән Святовск поселогы арасындагы районда кеше йөрми торган текә ярдан эзләргә кирәк, дип саныйлар. Якын тирәдәге бүтән өч торак пунктка аерата нык игътибар итәргә кирәк, дигән нәтиҗәгә килделәр.

Майор Петр Прохорович Стеклов — гражданнар сугышында актив катнашкан, губерна ЧКсының махсус отряды командиры ярдәмчесе булган кеше, радистны эзләү буенча бу җитди эшне, аның фикеренчә, яшеренеп ятучы дошманнар, кара эчле кешеләр күп яшәгән Святовск поселогыннан башларга кирәклеген әйтте. Святовскида туып-үскән кеше буларак, ул бу поселок территориясендә урнашкан Идел буе монастырен шомлы, хәтәр урын дип саный иде.

Стекловның чыгышыннан соң киңәшмә ябылды, ләкин анда катнашкан кешеләр таралырга ашыкмыйлар иде.

— Петр Прохорович,— диде Чурбанов,— майорга мөрәҗәгать итеп,— минем ул монастырь турында күп ишеткәнем бар. Син биш минут эчендә,— ул сәгатенә карап куйды,— кыскача гына сөйләп бир әле: аның тарихында безнең кызыксындырырлык нәрсәләр бар?

Стеклов монастырь-крепостьның моннан өч йөз ел элек Алексей Михайлович патшалык иткән вакытта ук бөтен Рәсәйнең патриархы Никон инициативасы буенча төзелеп, башкала руханиларының һәм император гаиләсе әгъзаларының аерым химаясе астында булганлыгын сөйләп бирде. Патриарх Никон патшаны үзенә буйсындырырга, руханилар властен патша властеннан өстен куярга маташканлыгы өчен җәбергә эләккәч тә монастырьның хәле үзгәрмәгән. Аның тирәсенә күп төрле кешеләр килеп урнашкан. Еллар үткәч, бу авыл Святовск исеме алган. Монастырь исә теләсә нинди фетнәчеләргә, раскольникларга каршы көрәшү өчен форпост булып хезмәт иткән. Никон яклылар һәм иске диндәге раскольниклар православие тәгълиматына бүтән диндәге кешеләргә караганда да күбрәк зыян китерәләр — чөнки алар динне эчтән торып җимерәләр, дип санаганнар. Шуның өчен монастырь-

ны төзегән вакытта ук анда иске агым яклы еретикларны (староверларны) җәзалау өчен яшерен палаталар булдырылган. Соңрак, тирәюньдә православие диненең иске агымы яклылар кырып бетерелгәч, әисән калганнары урманнарга яшеренгәч, монастырьдагы әлеге яшерен палаталар чиркәү байлыкларын юлбасарлардан яшерү өчен файдаланылган.

Инде илленең өстендә булса да, майор Стеклов яшьләргә хас дәрт белән кызып-кызып сөйли иде. Ул гражданнар сугышы вакытында монастырьның дошманнар тарафыннан Совет властена каршы көрәштә файдалануын, атаклы атаман Мефодийның күпмедер вакыт шунда качып ятуын әйтеп үтте. Ул вакыт безнекеләр, Мефодийның шунда икәнен белеп, монастырьны тыгыз боҗра белән өч тапкыр камап алганнар, һәрвакыт Мефодий баш җитмәслек серле юл белән аннан кача алган.

— Без соңгы тапкырында атаманның эзенә төшеп, монастырьны камап алгач,— дип дәвам итте Стеклов,— мин, шушы монастырь стеналары янында утыз еллап яшәгән булсам да, гомеремдә беренче тапкыр үз колагым белән җир астыннан килә торганниндидер гөрелдәү ишеттем. Бала чагымда бабам миңа әйтә иде: «Шайтан җир асты кыңгыравын кага башладымы — бәла буласын көт тә тор: монастырьда яшәүчеләрнең берәрсен иблис сәнәк белән кадап үтергән булыр»,— дия иде. Мин ул чакта аңа ышанмаган идем. Ләкин озак вакыт кара-каршы атышканнан соң, без монастырьга бәреп кергәч, изге опостоллар чиркәвендә безнең задание белән бандада йөргән кешене нәкъ менә шул чиркәүдә пономарь булып йөргән бабам әйткән әлеге юл белән үтерелгән килеш таптык. Сүз уңаенда шуны да әйтим, бабам үзе дә сәер генә үлде.

Майор тәрәзә янына килде дә тәмәке кабызды. Барысы да аның сүзен дәвам итүен тәкатьсез көтеп торалар иде.

— Әтием миңа шул чак әйтте: «Синең бабаң язмыш кушканнан элек үлеп китте, чөнки ул артык күпне белә иде. Мин аның үлеме өчен монастырь хуҗасы Викентий-атадан үч алырга тиеш. Иллә мәгәр ярлы бер ялчы кеще нәрсә эшли ала соң? Ул бит мине черкине сыткан кебек сытып үтерәчәк. Әсезгә, минем балаларыма, хәер сорашырга гына кала»,— диде. Һәм архимандрит Викентий, шул рәвешчә, безгә бурычлы булып калды.

Стеклов папиросын сүндерде дә тәрәзә яныннан китте:

— Соңрак, инде патша бәреп төшерелгәч, бабамның тарихын әти миңа тәфсилләп сөйләде. Әлары турында бүтән вакыт...

Әллә тартынуданмы, әллә ышанып җитмичәрәкме, Закиров сорап куйды:

— Әсоң сез теге монастырьда тапкан кеше чыннан да сәнәк белән кадап үтерелгән идеме?

— Шайтан сәнәге турында раслап әйтә алмыйм,— дип елмайды Стеклов. — Әменә аның гәүдәсе машина инәсе үткән төсле тигез сызык белән уталы кадалган булуны үз күзем белән күрдем.

— Сез, Петр Прохорович, атаман һәм аның шайкасы җир астындагы яшеренер урыннар аша качканнар дип саныйсызмы? — дип сорады Чурбанов.

— Минем монда шигем юк. Һәм ул урыннардан дошманнарның явыз максатларда файдаланулары бар. Михаил Иванович, мин монда бер ачыклык кертергә тиеш: һәр очракта да атаман бер ялгызы гына качып котыла, ә банданың бүтән кешеләре я юк ителәләр, янсә безгә әсир төшәләр иде. Кулга алынган бандитларның берсе дә башлыкларының кайчан һәм нинди юл белән юкка чыгуын белмиләр иде. Дөрес, монастырьга килгән вакытларында Мефодий үзе белән күп дигәндә ун-унбиш кеше ала иде. Әбандада — йөз илләләп кеше. Кыскасы, монастырьда ул үзен өендә кебек хис иткән, качып котыла алачагын бел-

гән, шуңа күрә үзе белән сак өчен генә шулай аз кеше ала торган булган. Аның каравы, бүтән җиргә барганда андый аз санлы бандитлар белән юлга чыгарга җөрьәт итмәгән.

— Ә сез, иптәш майор, аның һәр очракта ни өчен бер ялгызы гына качып китүе турында уйланмадыгызмы? Икенче төрле әйткәндә, ул яшеренер урыннар шулай бер кешелек кенә булганнармы, әллә ул, ниндидер зур бер серне ачмас өчен, үз кешеләрен аңлы рәвештә шулай үлемгә дучар иткәнме?

— Дөресен генә әйткәндә, мондый сорау минем башка баштарак килмәде. Ул турыда мин инде безнең тирәдә бандитлар юк ителгәч, ә атаман Мефодий, бер танышымның сүзләренә караганда, Әстерхан тирәләрендә үтерелгәч кенә уйлана башладым. Минем фикеремчә, атаманның берьюлы берничә кешене яшерерлек мөмкинлеге булган. Ә менә нигә ул моны эшләмәгән — әйтүе кыен. Минемчә, монда бер нәрсә бәхәссез: ул шулай тырышып саклаган сер кеше гомеренә торырлык булган. Менә шуңа күрә мин эзләүне Святовск поселогыннан һәм монастырьдан башларга тәкъдим итәм.

— Иптәш майор, ә атаман Мефодий үзе бу тирәләргә кайдан килеп чыккан соң? — дип сорады Закиров.

— Ул монастырьның башлыгы Викентий-атаның улы булган.

— Ә-ә,— дип сузды тегесе гаҗәпләнеп. — Болай булгач, аның нигә гел бу тирәдә кайнашуы, мондагы һәр нәрсәне белүе аңлашыла.

— Иптәшләр! — диде Чурбанов. — Без монда артыграк утырдык, миңа шәһәр комитетына барырга вакыт. Петр Прохорович сөйләгән нәрсәләр, минемчә, кызыклы гына түгел, файдалы да булырга тиеш. Радист турындагы эшне сезгә тапшырам, майор. Ләкин Святовск поселогы белән артык мавыгып китмәгез. Светловолжскига да игътибарны киметмәскә кирәк. Дошман агентурасы үзенә кирәкле информацияне тик шунда гына таба ала. Бүтән торак пунктларда азмы-күпме игътибарга лаеклы предприятиеләр юк. Радист эшкә тотынган — бу исә, безнең информация читкә китә башлаган, дигән сүз. Бәлки ул үзенең хуҗаларына эшкә тотынуын гына хәбәр иткәндер. Бу чыннан да шулайдыр дип өметләник. Юкса, без монда дәүләт икмәген бушка ашап ятабыз булып чыга.

Барысы да таралыша башладылар.

— Иптәш майор,— диде Закиров, Стекловка мөрәҗәгать итеп, — әтиегез сөйләгәннәрне безгә дә әйтегез инде.

Алар янына бүлекнең яшь сотрудниклары Юрий Мишаков, Таһир Мотыйгуллиннар да килде, һәм барысы да, тыннарын кысып, Стекловка текәлделәр.

— Алайса, без кузгалыйк, юлда сөйләшербез... Монда эш Святовскида берничә гасыр буе телдән-телгә күчеп йөргән риваятьләр белән бәйләнгән. Ә риваятьләр алар гадәттә дөреслектән ерак булалар. Еллар үтү белән, хакыйкать, диңгездә баткан кораб ләм белән капланган кебек, төрле уйдырмалар белән өртелә,— аның асылына барып җитү кыенлаша...

Майор күзлеген салды, аның пыялаларын марля кисәге белән сөртте һәм дәвам итте:

— Бабам кинәт кенә үлеп китәр алдыннан әтиемә шундый бер нәрсә турында сөйләгән. Көннәрдән бер көнне кичке гыйбадәттән соң ул чаң кагу урынында йоклап киткән. Кояш әле яңа гына баеган, җылы чак булган, салмак кына җил исә икән. Менә шунда бабам изрәп киткән дә бер почмакка сөялеп утырган. Уянып китсә: кап-караңгы, ә баш өстендә кемдер тегермән ташы әйләндерә төсле. Ул, сискәнеп, аягүрә баса, як-ягына карана һәм ни булганын аңлый алмый тора. Чаң кагу урынының читендә, әмма кырыенда ук түгел, кое сыман бер нәрсә ха-

сыйл була. Караса — коеда монастырь башлыгы Викентий-атаның йөзе. Бабам, монастырь башлыгы кыяфәтенә кереп, шайтан үзе килгән дип уйлый, чукына башлый һәм куркуыннан күзләрен йома. Ачса — берни дә юк!

Майор сүздән туктап, күзлеген күкрәк кесәсенә салды.

— Святовскида бүгенгә тикле шундый риваятьләр йөри: янәсе, үткән гасырларда кешеләр чаң кагу урынында төн уртасында ак стена фонында әледән-әле астан ниндидер серле ут белән яктыртылган капкара табутның пәйда булуын күрә торган булганнар. Янәсе, ул кешеләргә анда тагын ниндидер өрәкләр дә йөгерешеп йөриләр төсле тоелган. Менә шундый хәлләр...

— Ә сезнең бабагыз? Ул нинди нәтиҗәгә килгән соң? — дип сорады лейтенант Мотыйгуллин.

Стеклов елмайды.

— Аның нинди нәтиҗәгә килгән булуын белмим, тик, әтинең әйтүенә караганда, шушы вакыйгадан соң бабам халыкта йөргән сүзләрнең чын булуына ышанган һәм үзе күргәннәрне кайбер кешеләргә сөйләп тә өлгергән. Әти фикеренчә, аны нәкъ менә шул нәрсә һәлак иткән: икенче көнне үк аны агулап үтергәннәр — бабам монастырь ашханәсендә туклана торган булган.

Алар коридорның иң азагындагы тәрәзә янына килеп туктадылар. Стекловның кабинеты шунда гына иде. Майор, тәрәзә төбеннән күзгә күренми торган тузанны сыпырып алгандай итте дә, кулындагы папкасын шунда куйды, тирән сулыш алды һәм тирәсенә җыелган егетләргә җылы караш ташлады. Ул яшьләрне ярата, аларга карата аталарча игътибарлы иде. Һәм тегеләре дә аңа ихтирам белән карыйлар иде.

— Мин бүген имеш-мимешләрне һәм риваятьләрне уйдырмалар белән кушып сөйләп йөрүче корткага охшап калганмын икән, тагын өстәп, шуны әйтергә телим... Әгәр җир асты гөрелтесе, минем бабай уйлаганча, җир асты кыңгыравы монастырьда яшәүче алла колларыннан берәрсенең үтерелүен хәбәр итсә, чаң кагу урынында төнлә табутның пәйда булуы икенче бер афәтнең килүен кисәтүче билге булган: иртәгесен Святовскида яшәүче «фетнәче еретиклардан» берәрсенең үле гәүдәсен таба торган булганнар. Шулай итеп, поселок даими курку астында яшәгән. Мин моны үземнән чыгып та әйтә алам...

Майор тәмәкесен тартып бетерде, чалбар кесәсеннән кабинетының ачкычын чыгарды һәм бер мәл уйланып торды.

— Минем әти унҗиденче елда, Никишинның кирпеч заводында алган үпкә авыруыннан дөнья куйганда, әйтеп калдырды: «Эшчеләр юлыннан беркайчан да тайпылма,— диде.— Туздыр бу бүре оясын. Бабаң өчен үч алуың шул булыр... Минем бу сүзләремне исеңнән чыгарма», диде...

Стеклов тирән көрсенеп куйды:

— Аның сүзләрен хәтердә саклыйм. Тик менә монастырь башлыгы юкка чыкты. Үзеннән соң юлбасарларның атаманы булып киткән улын, кара эшләрен һәм күңелсез риваятьләрен генә калдырды. Мин шуларның беркадәресен генә булса да ачмый торып пенсиягә китәргә теләмим.

— Иптәш майор, сез монастырьны, һич югында аның чаң кагу урыннарын тикшереп карамадыгызмыни соң?

— Карадым, тикшердем, күп тапкырлар тикшердем, ләкин бар тырышлыгым, картада багучылар әйтмешли, буш мәшәкатькә кайтып калды. Монастырьдагы бар нәрсә элекке осталар тарафыннан гадәттән тыш нечкәләп эшләнгән. Мин ышанам: анда әзләнерлек нәрсәләр күп...

Стеклов бүтән риваятьләр турында сөйләп тормады: калганнары кеше ышанырлык түгел иде. Хәлбуки, майор үзе аларны да тикшереп карау ягында тора иде.

— Иптәш майор! — дип кычкырдылар коридорның аргы башыннан. — Сезне Халык комиссары урынбасары чакыра.

Стеклов гафу үтенде һәм шунда таба китте.

## IV бүлек

Күк күкрәүләре һәм көтелмәгән кыраулары белән май да үтеп китте. Июнь башында эссе, бөркү көннәрдән соң, шау-шу килеп, боз катыш яңгырлар яуды. Дымлы җир тәнгә рәхәт җиләслек бөркеп тора башлады. Больница палатасының ачык тәрәзәсеннән тупылларның яңа ярылган яфракларыннан исерткеч ис килә. Александр Жуков нәфис яшел яфракларда очкын булып ялтыраган яңгыр тамчыларына карап тора иде.

Баш шаулый. Кул һәм аякларга резинадан жгут салынган төсле. Кайдадыр күңел түрендә бер үк уй тынгы бирми: «Ничек болай килеп чыкты да, ничек мин ялгышлык эшләдем соң?..» Аның агарынган йөзенә бераз сары төшкәндәй тоела иде.

Дөрес, дәвалаучы врач аның туганнарын һәм дусларын, иң куркынычы инде артта калды, дип ышандырды. Шулай булса да, аңа озак вакыт сөйләшергә дә рөхсәт итмәделәр. Больницага көн саен килеп йөргән Закиров та дусты янына тугызынчы тәүлектә генә керә алды.

Илдарның Александрга әйтер сүзе күп булса да, аны ялыктырмаска булды. Дымсулана төшкән күзләре белән авыруның йөзенә караган килеш аның хәлсез кулын гына кысты.

— Син, Сашутка, нык бул. Иң мөһиме, борчылма. Врач синең эшләр әйбәт бара, диде. Тик әле бераз ятарга кирәк. Аңладыңмы?

Александр, аның белән килешеп, башын иәде.

— Оныта язганмын, безнекеләр сиңа күп сәлам әйттеләр.

— Рәхмәт... Аларга да миннән... сәлам,— диде Жуков хәлсез генә.— Ә Сакалбай белән әшнәсе ничек?..

— Әшнәсе инде теге дөньяда. Аның кем булуын әлегә белә алмадык. Ә син сакаллыны танудың, шулай бит?

— Әйе...

— Хәтереңдәдер, аның исеме Валерий Фролов, кушаматы Йөнтәс. Шулаймы?

— Әйе, шулай...

— Молодец син, Саша. Мин бездәге фоторәсем буенча аны гомердә таный алмаган булыр идем...

— Фролов сиңа утын пүләне белән бәргән...— диде Закиров.

— Мин алар төзегән сценарий буенча эш иткәнмен булып чыга... Алар хәйләдә мине уздырганнар...

Шул чак ишек ачылды, һәм хатын-кыз тавышы:

— Җитәр, авыруга күп сөйләшергә ярамый,— диде.

Закиров Александрның кулын йомшак кына кысты:

— Хәзергә, дускай, синең версияң дөрес. Хәзер шуның буенча эшлим.

Закиров урыныннан торды. Ул, Александрның кәефен бозмас өчен, Йөнтәснең качуы турында аңа берни әйтмәде.

— Я, ярый, Сашутка, хуш. Тизрәк терел. Иртәгә тагын килермен.

Закиров саклык белән генә ишекне япты. Аны күреп сөйләшкәннән соң Александрның кәефе бераз күтәрелде.

Жуков Древцовның эшен күңеленнән кичермәкче булды, ләкин булдыра алмады. Аның томанланган хәтерендә нindидер кешеләр, сүзләр калкып чыкты.

...Менә ул чаңгыда шуып бара. Яңа гына яуган йомшак кар салкын кояш нурларында очкыннар чыгарып җемелди, күзне камаштыра.

Чаңгычыларның кыюраклары берән-сәрән генә Иделнең текә ярыннан шуып төшеп китәләр. Александр, яр буендагы кечкенә генә наратлыктан чыгып, ярга якынлашып килүче сары чәчле кызны күрде. Аның алдыннан, кулларын бик сәер рәвештә алга ыргыта-ыргыта, бер егет шуып бара иде. Чаңгы таякларын алга таба артык еракка сузганлыктан, аңа хәрәкәт итүе кыен иде. Шулай да ул бар көченә тизлекне арттырырга тырыша, еш-еш атлый иде. Озын шарфы, җилдә җилфердәп, аякларына чорнала, барырга комачаулый иде.

— Кара әле бу фраерга, чаңгыда ничек әлдертә,— дигән сүзләрне ишетте Александр. Борылып карады. Якындарак кына бераз кызмача дүрт ир кеше басып тора иде. Икесе чаңгы таккан. Алар, якынлашып килүче егет белән кызга караган килеш, үзара нидер сөйләшәләр.

Дүрт кешенең берсе, сары чәчле кыз белән килүче егеткә мөрәҗәгать итеп, тәкәллефсез генә:

— Ишетәсеңме, мастер, җәмәгатьчелек сезнең бу текә ярда слалом үрнәген күрсәтүегезне сорый. Кызый да сездән шуны ук көтә торгандыр дип ышанам,— диде.

Яшьләр ирексездән яр астына күз ташладылар. Егет куркуыннан артка ук чигенеп куйды, ә сары чәчле кыз хәвефләнеп:

— Сез нәрсә шаярасыз?! Монда сөякләреңне дә җыя алмассың!— диде.

— Сөяк җыярга үзебез булышырбыз, аның өчен борчылма,— диде әзмәвердәй бу кеше һәм, дустына мөрәҗәгать итеп, өстәде:

— Иптәшкә батырлык һәм каһарманлык үрнәге күрсәтергә ярдәм ит. Мин беләм: ул үзе моны тели, тик аңа стимул гына кирәк.

Егеткә якынрак торган озын буйлысы тиз генә аның янына йөгереп килде һәм бар көченә тегенең шарфыннан тартты, аннары, шул шарфка тотып, аны яр буена өстерәп китерә башлады. Икенчесе егетне арттан этеп җибәрде.

Барысы да ярдан бик кызу шуып төшеп киткән чаңгычы белән ни буласын күзәтә башладылар. Баштарак егет, тирән елга аша салынган тар басмадан чыгучы кеше төсле, кулларын чайкап барды. Тиздән, барысының да гаҗәпләнүенә каршы, гәүдәсен төз тота башлады. Ләкин, ярның уртасына җитәрәк, егет сөртенде һәм, таякларын, чаңгыларын сындыра-сындыра, тәгәрәтелгән йомры кар төсле аска мәтәлде.

— Оят түгелме сезгә! — дип кычкырды сары чәчле кыз, аңына килеп.— Харап иттегез бит кешене!

— Сөяркәсе янына юлга чыгарга булышыгыз әле шуңа,— дип, әзмәвердәй адәм ямьсез итеп сүгенеп җибәрде.

— Үгезнең сүзе — минем өчен закон,— диде озын буйлы һәм, кызны култыгыннан тотып, яр кырыена таба тарта башлады. Куркуыннан кызның күзләре зурайды. Ул ике куллап озын буйлының киеменә ябышты. Тегеләрнең икенчесе кызның чаңгысына басты. Кыз егылды. Озын юри аның өстенә ауды.

Александр бу шайка белән чәкәләшми булдыра алмаячагын аңлады. Башта чаңгыларын салмакчы булган иде, ләкин кире уйлады һәм, кыю атлап, кызга якынлашты.

Озын кеше кыз өстеннән торырга ашыкмый иде.

— Ай-һай, Дюдя, мәткәнең кәефен чамалады бит! — дип ат кешнәгәндәй кычкырып көлде Үгез.

Моннан соңгы вакыйгалар күз ачып йомган арада алмашынды. Александр Озынны аягыннан тартып шуыштырып китерде дә, әле генә чаңгычы егет мәтәлгән яр астына тибеп төшерде. Аның янындагы әшнәсе Александрга ташланды. Жуков читкә тайпылып өлгерде һәм шунда ук аны беренчесе артыннан олактырды.

Ул арада кыз, аягына басып, читкәрәк китте һәм, бик нык каушаган хәлдә, ни буласын күзәтеп тора башлады.

Тегеләрнең икесе, чаңгы кигәннәре, Жуков өстенә ташландылар. Берсенең кулында пычак бар иде.

— Я, шпана, әйдәгез таудан төшик, аста сөйләшербез,— диде Жуков, аларга төрттереп.

Жуков текә яр кырыена ук килде дә, хулиганнарның игътибарын кыздан читкә юнәлтер өчен, боерык биргәндәй кычкырды:

— Әй, аумакайлар, әйдәгез минем арттан!

Тегеләрнең берсе, бу мыскыллы сүзләргә түзмичә, Жуков артыннан ташланды. Тизлекне торган саен арттыра барып, икесе дә түбәнгә очтылар. Эзәрлекләүчене аркасы белән тоеп, Жуков кинәт сулга борылды. Теге дә тәҗрибәле чаңгычы булып чыкты: шундый ук вираж ясады. Александр, артык зур тизлекне бераз киметергә теләп, тагын берничә тапкыр юнәлешне үзгәртеп карады, ләкин теге аңардан калышмый иде.

Жуков бик яхшы аңлый иде: форсат туры килү белән теге хулиган чаңгы таягының үткен очы белән аның аркасына төртәчәк, аяктан егачак...

Яр текә булуга карамастан, ул баскыч сыман киртләч-киртләч: урыны белән җир бөтенләй диярлек тигезләнә. Жуков менә шул хәлдән файдаланырга булды. Эзәрлекләүче, уйлап-нитеп тормастан, аның «йөрешләрен» кабатлый, ә үзе һаман аңардан арттарак калып килә иде. Ярның яртысындарак, шундый тигез бер мәйданчыкны үткәч, Жуков кинәт читкә борылды, эзәрлекләүче дә шуны ук эшләде, ләкин борылганда ул әлеге мәйданчыкка төшеп кенә җиткән иде, шуңа күрә чаңгының каршылыгы кинәт артты, ул тигезлеген югалтты һәм кар эченә кереп чумды. Жуков аңарга якын ук килеп туктады. Теге, чаңгысы бер аягында калган килеш, көч-хәл белән торып басты, битендәге карны сыпырып төшерде, Жуковка ярсулы караш ташлады һәм аның янына югарыга менәргә талпынды, ләкин чаңгысыз аягы таеп китте, һәм ул тагын да аскарак шуып төште...

Һәм менә хәзер, больницада шуларны уйлап ятканда, әлеге чалшайган, ачулы йөзне Жуков тагын кайдадыр күргәнен исенә төшерде. Әйе, әйе, чыннан да күргәне бар! Хәзер үзе өчен зур ачыш ясаячагын сизүдән аның хәтта тыны кысыла башлады...

«Әйе, нәкъ шулай... Теге кеше нәкъ шул Үгез иде!..»

— Сестра! Сестра! — дип чакырды ул зәгыйфь тавыш белән.— Тизрәк НКВДга шалтыратыгыз, тизрәк килсеннәр!..

## V бүлек

Барлык сроклар үтеп бара, ә Закировның эшендә әллә ни алга китеш күренми иде. Древцовның үтерелүе турындагы эшкә, тигәнәк шикелле, вак һәм эре бүтән эшләр ябыша иде. Аларның кайберләрен шунда ук буш кабыкны алып ташлаган кебек куптарып атарга мөмкин, кайберләре исә чишелмәгән мәсьәләләр булып кала бирделәр, күп вакыт таләп иттеләр. Шулай да Закиров андый эшләрнең туачагын алдан күрергә кирәк иде дип санады, аларга көтелмәгән нәрсәләр итеп карамады. Мәсәлән, җинаятьчеләр кулыннан һәлак булуына өч ай элек Древцовның эшләгән җирендә квартир ачкычын югалткан булуы ачыкланды. Бу детальне ул ахырынача тикшерде, ләкин бу көтелгән нәтиҗәләр бирмәде. Янсә тагын менә мондый нәрсә. Древцовның кызы әйткәнчә, берничә атна буена кемдер аларның өй телефоныннан шалтыраткан, әмма, бер сүз дә әйтмичә, шунда ук трубканы куя торган булган. Мондый шалтыратулар атнаның төрле көннәренә туры килгән. «Өйдәгеләрнең тормыш расписаниесен өйрәнгәннәр,— дигән карарга

килде Закиров.— Һәрхәлдә, әллә ни чибәрлеге булмаган ирле хатын белән кызыксынучы эше түгел бу».

Бу көннәрдә Илдарны гел бер уй биләде: Древцовлар квартирын аларга элек тә кереп йөргән кеше баскан булырга тиеш. Ләкин Жуков белән Тренькин Древцовның танышларын берәмтекләп тикшереп чыккannar, хәтта очраклы кешеләрне — слесарьларны, госстрах агентларын да игътибарсыз калдырмаганнар. Ләкин бу бернәрсә дә бирмәгән.

Аны тагын икенче нәрсә борчыды: махсус заказ буенча эшләнгән йозакка җинаятьче ничек ачкыч ярата алган? Техник экспертиза шундый карарга килде: ишек ачкычларның икенче нөсхәсе белән ачылган. Каерып ача торган нәрсәләрнең эзе күренми.

Кулындагы кәгазьләрне кат-кат укыганда да, Древцов торган өйне һәм аның квартирын күз алдына китергәндә дә Закиров үз-үзенә һаман бер үк сорауны бирде: «җинаятьче ачкычларны кайдан алган?» Йозакны ясаган кеше хәзер исән түгел. Ул кеше йозакны кем өчен ясавын белмәгән дә, чөнки аны Древцовның фронтташ дусты ясаткан.

Әгәр квартир хуҗасының ачкычы кыска гына бер вакытка, әйтик, күчермәсен алу өчен, бүтән бер кеше кулына күчкән, дип фараз кылсаң? Мондый вариантның булуы мөмкинме? Мөмкин. Әйтик, ачкычны сиздермичә генә кесәсеннән алганнар, ди. Ләкин кайчан? Бәлки җинаятьче Древцов артыннан күзәтеп йөргәндер, әйтик, ул ишек бикләгәндә, югарыдагы баскыч мәйданчыгыннан карап торгандыр? Древцовның эшкә китү вакытын белгән кеше моның өчен подъездда биш-ун минут булырга тиеш. Бу әле эш уңышлы барганда. Ләкин аның ачкычны һаман бер үк кесәгә салуына ышаныр өчен, бу кешегә баскыч мәйданчыгында берничә тапкыр таптанырга, тәмәке тартырга, күршеләрдән берәрсенең кунагы булып кыланырга тиеш. Мөгаен, бу шулай булгандыр да. Моннан нәрсә килеп чыга соң? Тикшерү эшендә әле исемнәре аталмаган күршеләрдән сорау алыргамы? Йөнтәснең бу үтерүгә катнашы барлыгын расларга маташып карарргамы? Менә бу инде конкретрак фикер. Алай иткәндә, версия фактлар җирлегендә тикшереләчәк.

«Шунда бер очтан баскыч мәйданчыгын һәм андагы тәрәзә төбен тикшерергә кирәк булыр»,— дип карар кылды Закиров.

Алай да Древцовның ачкычын кайда кесәсеннән алганнар да, ни арада кире салып өлгергәннәр? Үз квартирының ишеге төбеннән подъезд янында аны көтеп торучы машинага кадәрге арада моны циркта эшләүче фокусчы да булдыра алмас. Шул арада бит әле тагын аның күчермәсен дә алып өлгерергә кирәк. Машина килеп туктый торган урыннан Древцовның кабинетына кадәр дә шундый ук ара.

«Алайса, кайда кергәннәр соң аның кесәсенә?» — дигән уй, тынгы бирмичә, аның башында буталды. Древцов мунчага йөрмәгән, ваннага керүне мәгъкуль күргән. Кибетләргә йөрүдән һәм бүтән хуҗалык эшләреннән аны хатын-кызлар азат иткән. Ул тик ара-тирә дуслары һәм танышлары янына гына бара торган булган.

— Алай... ала-ай...— дип куйды Закиров.— Менә тагын тупик.

Ул урыныннан торды һәм билет кассасына тартым кечкенә генә кабинетында бер почмактан икенчесенә йөрергә тотынды. Бүлмәнең тәрәзәсе зәгыйфь кенә юкә агачлары үсеп утырган ишегалдына караган иде. Ул арада Илдар Жуковны исенә төшерде. Сәгатенә күз салды. Авырулар янына сәгать 18.00 дән соң кертәләр. «Өч сәгатьтән аның янына китәм»,— дип уйлап алды Закиров. Кинәнеп эшләү өчен аңа Александр җитми, алар бер-берсен сүзсез дә аңлыйлар иде бит. Бүлек җитәкчесе подполковник Чурбанов әйтмешли, Жуков белән Закировның уйлары бер үк дулкында эшлиләр иде. Берсенең якында булуы икен-

чесендә дә үзенә ышаныч уята. Бу — мәктәптә укыган вакыттан бирле шулай булып килде.

Закиров ишегалдына күз ташлады. Анда бинаны ремонтлау өчен тышкы җайланмалар куеп маташалар. Илдар анда эшләүчеләрдән көнләшеп куйды: «Алар ичмасам ни эшләргә кирәк икәнен ачык беләләр, ә менә мин... максатыма күзе бәйләнгән кеше төсле атлыйм, әледән-әле юнәлешне югалтам, сөртенәм. Һәм бу хәлнең очы-кырые күренми. Хәзер мин ташлар актарырга, җир сөрергә, рәхәтләнеп риза булыр идем, тик эш кенә барсын иде. Кайдан эзләргә соң җепнең очын?»

Ул урындыкка килеп утырды, куллары белән башын кысты. «Александрга ни генә әйтә алам соң мин бүген?» — дип уйлады ул.— Берни әйтә алмыйм». Үгез кушаматлы кешенең кем булуы билгесез. Шулай булгач Йөнтәскә илтә торган юл да күренми. Ул, әлбәттә, яшеренеп ята, хәзергә өскә калку ихтималы аз. Алай дисәң, кем белә...

Телефон шалтырады.

— Тыңлыйм.

Трубкада Чурбановның тавышы ишетелде:

— Иптәш Закиров, сезнең эшләр ничегрәк бара?

— Хәзергә бернинди яңалык юк, иптәш подполковник.

— Ике көн эчендә нинди эшләр эшләдегез соң? Дюдяның кем икәнен белә алдыгызмы?

— Без Тренькин белән архивта соңгы өч ел эчендә булган барлык эшләрне актарып чыктык. Судка эләккән кешеләрнең картотекасы белән таныштык, ләкин хәзергә уңышка ирешә алмадык...

— Мәскәүгә запрос җибәрегез. Бу бер. Икенчесе: Древцов яшәгән өйдәге кешеләр белән сөйләшегез. Минемчә, ЖЭКка кереп чыгу да зыян итмәс. Кыскасы, уйланырга һәм уйланырга кирәк. Ашыгырга вакыт. Ике көннән доклад белән килерсез.— Һәм ул телефонны элде.

Тикшерү эшенең торышы Чурбановны бик нык борчый. Хәер, нервлары ахыр чиккә җитеп киеренкеләнгән Закиров үзе дә моны аңлый иде.

«Ныклап торып бер пешерсә дә, берни әйтә алмас идең — эштә алга китеш юк бит,— дип уйлады Закиров.— Кемгә ничек итеп басым ясыйсын белә ул, иң әһәмиятлесе — акыллы киңәшләр бирә белә. Бу киңәшләрнең никадәр файдалы булуына монда эшләү дәверендә күп тапкырлар ышанганым бар».

Кабинетка, ялкау гына атлап, Тренькин килеп керде һәм урындыкка барып утырды. Сөйләүләренә караганда, Тренькинның этисе — җиңел промышленностьта зур кеше. Бала вакытта Эдуардны эш кушып интектермәгән булулары күренеп тора. Биредә дә Тренькин эшне яратмый — аннан ничек тә булса читтә калырга тырыша иде. Импульсив кеше, тигез һәм тыныч кына яши алмый. Кайчак, үзе төзегән һәм реаль чынбарлыктан ерак торучы «конструкция» һәм «модель»ләргә ышанып, төп нәрсәләрне күрми үтә. Ләкин күпләр, ул әле яшь, тәҗрибәсез дип, аны гафу итеп киләләр. Тәкәллефсез булуы, мин-минлеге өчен күп кеше Тренькинны яратмый. Кайберәүләр аңа булган бу карашларын ачыктан-ачык әйтә, ә кайберләре сүзсез генә белдерәләр.

Башта Тренькинның үзенә генә тапшырылган Древцов эшенә Жуковны да катнаштыргач, тикшерүче Черных: «Менә, нәфис болан белән кәҗә тәкәсен бер арбага җиктеләр»,— дип куйды. Кемнең «болан», кемнең «кәҗә тәкәсе» булуында берәүнең дә шиге юк иде. Әмма моңа кадәр Тренькин белән бергә эшләргә туры килмәгәнгә, Закиров аны аз белә иде.

Ул арада Тренькин тәмәке кабызып җибәрде һәм хатын-кызлар турында гәп сата башлады. Үз уйларына чумган Илдар аның сүзләренә

игътибар итмәде. «Аңа әйтергә кирәк булыр: иртәгә үк Древцов яшәгән йорттагылар белән танышып чыксын,— дип уйлады ул.— Бәлки берәр нәрсә ачыклый алыр. Ә мин шул тирәдәге вак оешмаларны әйләнеп чыгармын — Иөнтәс нәкъ менә шундый кечкенә конторааларда эшләргә ярата».

— Менә шулай,— Тренькинның тавышы еракткан ишетелгәндәй тоела иде,— мин идеаль хатын-кыз юк дигән нәтиҗәгә килдем. Дөресрәге, андыйлар ике очракта гына була: берсе — без үзебез яратканы, икенчесе — без әле танып белмәгәне.

— Ләкин андый очракта хатын-кызлар безнең хыялда гына яши булып чыга бит,— диде Илдар, үзенең аны тыңлавын белдерер өчен генә.

— Нигә алай булсын? Хыялда гына түгел. Син урамда барганда әле таныш булмаган гүзәл бер хатын-кыз очратасың һәм аны идеаль итеп кабул итәсең. Ә ул бит безнең хыялда гына түгел, чынбарлыкта яши. Анысы дөрес, аның эчке дөньясын син хыялыңда үзең сурәтлисең. Ләкин аның белән якыннан танышуың була, әле кайчан гына булган соклануларың юкка чыга. Үз тәҗрибәмнән чыгып, сиңа шуны әйтә алам: чибәрләрне күп очратканым бар, тик алар барысы да бер калыптан: тыштан ялтырап, эчтән калтырыйлар.

— Ә синең үз хатының да...

Тренькин илтифатсыз гына кул селтәде. Аның бөтен кыяфәте, гүя: «Аңладым мин сине, дәвам итмәсәң дә була»,— дия иде.

— Өйләнүен өйләндем, ә аңынчы миемне селкетмәгәнмен, әтинең сүзләренә колак салмаганмын. Ә ул дөрес әйткән икән. Син, Эдик, чибәр кызга гаилә йөгенен киертергә азапланма, ди иде ул, барыбер тотып кала алмассың. Чибәр хатын — ул шәхси милек булудан битәр җәмәгать милке. Кем теләсә шул, аңа карап, сәнгать әсәренә сокланган кебек соклана ала. Менә шуннан чибәркәйнең башы әйләнә башлый. Чибәрлек ул гакылны бар дип тә белми.

«Күрәсең, бу гаилә учагында артык пешкән булса кирәк,—дип уйлады Закиров.— Шуңа күрә эчен бушатасы килә. Ә бәлки тумыштан ук шундый ачык холыклы кешедер?»

— Менә мин монда Древцов эше буенча кайбер нәрсәләрне сызгалаган идем, карап кара,— диде ул һәм Тренькинга шушы арада башкарылырга тиешле эшләр планын тапшырды.— Яңа фикерләр булса, әйдә әйт, уйлашырбыз.

Илдар Чурбановның телефоннан шалтыратуын әйтте. Аннары Тренькин нindидер дустына шалтыратып, аны үзенә кунакка чакыра башлады. Тегесе баш тарта иде булса кирәк. Шуннан соң Тренькин шаярып, кавказ акценты белән:

— Гинацвали, әгәр тау Мөхәммәт янына килми икән, мин үзем тау янына барам,— диде.

Закиров исә һаман кәгазьләре белән маташты, газапланып, һаман шул бер үк сорауга җавап эзләде: «Җинаятьче ачкычны кайдан алган?»

Һәм кинәт, Тренькин Мөхәммәт пәйгамбәр турында сүз кузгаткач, аның башына бер уй килде: җинаятьчеләр үзләре Древцов янына килә алмаганнар икән, аны үзләре теләгән, ягъни, ачкычтан күчермә алып була торган җиргә чакырып китерә алганнар ич! Ничек соң әле бу турыда мин-бүкәннең элегрәк башына килмәгән? Аларның бит моны берәр җайлы сәбәп табып эшләгән булулары бар. Әйтик, нинди дә булса җыелышка яисә очрашуга чакыру сылтавы белән. Ул — гражданнар сугышында катнашкан, шәһәрдә танылган кеше. Бәлки әле нинди дә булса чакыру кәгазе дә җибәргәннәрдер — ветераннар белән очрашу өчен йортлар идарәсенә яисә мәктәпкә, кыскасы, өске киемне —

пальто-плащны салырга кирәк була торган урынга чакыртулары ихтимал. Ул бит, туганнарының кисәтүенә карамастан, ачкычын нәкъ менә тышкы кием кесәсендә йөртә торган булган. Кызының әйтүенчә, ул кешеләргә артык ышанган, саклык белән эш итү кирәклеге турында әйтә башласалар, моны ишетәсе дә килмәгән.

Закиров кәгазьләр салынган папканы сейфына куйды да пиджагын киде. Телефонга тотынды. «Әгәр фикерем расланмаса? — дип уйлады ул,— нишләргә?» Бу уйдан аның тәне эсселе-суыклы булып китте. Ул тагын пиджагын салды. Древцовлар квартирының номерын җыйды. Ләкин җавап бирүче булмады. Шуннан соң Илдар тиз-тиз җыенды да Древцовның эш урынына ашыкты.

## VI бүлек

Стеклов күпердән аска карады. Су өсте баеп баручы кояш нурлары астында шадраланып ялтырап ятучы зур мәрмәр плитәгә охшаган иде. Якынлашып килүче көймә калдырган вак дулкыннар гына аста су икәнлеген хәтерләтәләр.

Аның су кереп аласы килеп китте, ләкин шунда ук кире уйлады: теге каһәр суккан радикулит китереп каптырса, ике атна буена биленне бөгә алмаячагыңны көт тә тор. Аннан да мөһиме — эшләп булмаячак, ә эш көтми. Алар бүген, бер группа солдатлар һәм милиция работниклары белән, яр буендагы куаклыкларны карап чыктылар, шик уятырдай түмгәкләрне махсус капшагыч белән тикшерделәр, кайбер урыннарда кәз катламын алдылар. Ләкин рацияне таба алмадылар. Берничә чакрым җирне биләгән мәйданда рацияне эзләү тайгада тамгалы җәнлекне эзләүгә тиң икәнен ул аңлый иде.

Радист эз яшерү чарасына алдан ук хәзерләнгән булган, дигән нәтиҗәгә килде Стеклов. Велосипедын да шины тишелгәнгә күрә ташламаган — ул аны үзе тишкән. Чөнки велосипед табылган урыннан берничә генә метр ераклыкта алар төзек тәгәрмәч эзен күрделәр. Бу әле табылган велосипед эзе иде. Дошман агентының хәйләсе шулай итеп ачылды.

«Радист көймәгә күчеп утырган, дип фараз кылыйк, ди. Аның агымга каршы, Светловолжскига таба китүе шикле. Беренчедән, ишкәкләр белән агымга каршы әллә ни еракка китә алмыйсың. 29 майда иртән, балыкчыларның әйтүенчә, бу тирәләрдә моторлы көймә күзгә чалынмаган. Тик ике баржа һәм «Казан» пароходы гына үтеп киткән. Бу соңгысын пароходчылыкта да расладылар».

«Ә икенчедән — нәрсә? — дип уйлады Стеклов.— Тукта әле, без бит бу районга Светловолжскидан патрульлек итүче милиция катерларын җибәрә ала идек! Безнең аларны җибәрмәвебез, әлбәттә, хата булган. Ләкин радист, мөгаен, аларны җибәргәннәрдер, дип уйлагандыр. Шуңа күрә нигә дип ул рациясе белән безнең каршыга чыксын ди? Дөрес, ул рациясен суга да ташлый алган булыр иде. Тик тәҗрибәле шпион мондый нәрсәгә бармас. Разведкада кыска вакытка гына да рациясез калу — ике кулсыз калу белән бер. Алар бит почтадан яисә элемтәнең башка төрләреннән файдалана алмыйлар.

Стеклов блокнот белән карандашын чыгарды да радист көймәдә агым буйлап киткән тәкъдирдә тиз йөрешле катерның кайсы урынрак аны куып җитә алуын исәпли башлады. Ул Светловолжскидан бирегә кадәр булган араны, катерның чама белән чыгып китү вакытын һәм көймәнең йөзү тизлеген искә алды. Аның исәпләүләре буенча шулай килеп чыкты: катер көймәне Святовск поселогы тирәсендә куып җиткән булыр иде. «Димәк, ул кеше көймәдән элегрәк, Святовскига

чама белән чакрым-чакрым ярым кала чыккан булырга тиеш. Эзләү эшен нәкъ менә шул тирәдә алып барырга кирәк».

Телефон будкасыннан ул Халык комиссарлыгына шалтыратты, тиз генә машина һәм бер-ике кеше җибәрүләрен үтенде. Чирек сәгатьтән алар лейтенант Таһир Мотыйгуллин белән Святовск поселогына таба баралар иде инде.

Кояшның кызгылт тоныкнурлары агач ябалдашларына кунган. Юлга төшкән күләгәләр куерып килә торган эңгер һәм томан белән өртелә башлаган. Кичкә таба бераз суытты. Текә борылышларда машинаның пыялалары төшерелгән ишеге аша биткә ылыслы урманның хуш исендә төнәтелгән салкын һава дулкыны бәрелә.

Икесе дә сүзсез бардылар. «Яшь чакта,— дип уйлады Стеклов,— табигатьнең гүзәллеген күрмисең, шулай булырга тиеш дип кенә карыйсың...»

Аның бу уйларын Мотыйгуллин бүлде:

— Карагыз әле, озын колак чаба! — диде ул. Аңа, шәһәрдә туып үскән кешегә, тере куянны күрү гаҗәп тоела иде. Куян берара юл буйлап чапты да юл читендә куе булып үскән кычыткан эченә кереп чумды.

— Менә шайтан! Аны кычыткан да чакмый,— диде шофер сабыр гына елмаеп.— Әгәр караңгыдарак булып, фараларны кабызсак, куян яктыртылган юлдан бер чакрым чамасы йөгерер иде.

Тагын тынлык урнашты. Мотыйгуллин кулын кабинадан чыгарды. Салкынча һава агымы аның учларына рәхәтлек бирә иде.

Юл чаты күренде. Стеклов, шоферга таба иелеп:

— Муса, машинаңны Святовскига бер чакрым кала туктатырсың,— диде.

Тегесе баш какты. Борылыштан соң юл бозылды, әледән-әле машинаны сикерткәли башлады. Озын буйлы Мотыйгуллин урындыгына ябышты, башын иде. Тик Стеклов кына юлның сикертмәле булуына игътибар итмәгән төсле иде. «Төрле башваткычларны һәм серләрне ачу буенча махсус контора оештырырга уйласалар, мин: андый оешма бар инде, тик вывескасын гына алыштырырга кирәк,— дияр идем. Чыннан да, безнең агай-энегә ни белән генә шөгыльләнергә туры килми — ишек йозагыннан алып самолетларга кадәр».

Уң якта, урман артында нәрсәдер ялтырап китте.

— Аҗаган,— дип куйды майор, үз-үзенә генә әйткәндәй.

«Алай да табышмак уйлап чыгаруга караганда аны чишү кыенрак,— дип уйлады Стеклов.— Шуңа күрәдер инде, әкиятләрдәге патшалар ул табышмакларны чишүне түгел, уйлап табуны үзләре өчен кулайрак күргәннәр. Ә менә табышмак катлаулы һәм кем өчендер мөһим булса,— аны сер дип атыйлар. Әй-йе... Кайбер серләрне ачу өчен, кеше гомере дә җитми». Һәм аның уйлары хәтер түреннән тагын аңа теш авыртуы төсле гел тынгылык бирми торган Идел буе монастырен казып чыгардылар.

— Иптәш майор, Святовскига бер чакрымнан аз гына артык калды. Кайда туктыйбыз? — дип сорады шофер

— Әйдә, Муса, сулга. Машина юлдан күренмәслек булсын.

— Аңладым.

Урман эчендә тынлык хөкем сөрә иде. Эчпошыргыч тавыш белән черкиләр безелди башлады. Мотыйгуллин, битеннән күзгә күренми торган пәрәвез җепләрен алып ташлый-ташлый, бераз йөреп килде.

— Муса, син безне шунда көтәрсең!

— Есть, иптәш майор!

— Әйдә киттек,— диде Стеклов Мотыйгуллинга.

Алар, кычыткан белән аралашып үскән куаклыкларны һәм абага

үләннәрен ерып, алга атладылар. Мотыйгуллин, кычытканнан саклаunion, кулларын иңбашына куеп атлады. Майор, юан чыршыларның кытыршы кәүсәсенә кагылып, кулларын битенә якын китерә-китерә, бераз алданрак барды. Шул рәвешчә бер чакрым чамасы үттеләр.

— Беләсеңме, Таһир,— диде Петр Прохорович, артына борылып,— бала чактан ук чәер исен яратам мин. Менә хәзер дә тәмәке иснәүчеләр кебек шуны иснәп барам...

Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин нәкъ шул мәлне алда саесскан тавышы ишетелде. Майор туктап калды һәм шыпыртлап:

— Синең күз үткенрәк, яхшылабрак кара әле, нәрсә бар икән анда? — диде.

Икесе дә тукталдылар.

— Алда су күренә.

— Анысын мин болай да беләм. Оясына кеше якынлаша башласа, саесскан шулай итә. Беркем дә күренмиме?

— Юк.

Стеклов, бераз гына уңгарак каерып, тагын алга атлады. Еш-еш туктап, агач кәүсәләренә сыенып, колак салып торгалады. Лейтенант та аның хәрәкәтләрен кабатлады. Ул инде черкиләрне куып маташмый иде. Менә майор тагын туктады. Бу хәл Мотыйгуллинның эченә шом салды. Һәм шунда ук аңлап алды: тавышына караганда, саесскан яр буйлап сулга таба очып китте. Димәк, теге кеше — капма-каршы якта. Ә бәлки ул балыкчыдыр? Кем йөрмәс монда? Бу бит фронттагы нейтраль сызык түгел. Анда гына ул очраган һәр кеше диярлек дошман була. Нигә соң әле ул шулай сагайды?»

Лейтенант бу фикерен Стекловка әйтергә генә теләгән иде, кинәт аңа уңда, кырык метрлап арырак, куаклар селкенеп куйгандай тоелды. Лейтенант, тын да алмыйча, агачка сыенды. Ул сагаеп кына Стекловның кулына кагылды:

— Уңда, куаклык эчендә кемдер бар...

Майор башын шул якка таба борды, чүгәләп утырды һәм, киек барын сизенгән сунарчыдай, тынып калды.

Алар шактый озак көттеләр. «Бәлки миңа гына шулай тоелгандыр?» — дип, Таһир шикләнә үк башлады: анда беркем дә булмаса, оятыңнан кая барырга белмәссең. Ичмасам берәр җәнлек тә килеп чыкмый шуннан. Җиңелрәк булыр иде».

Вакыт үткән саен, Мотыйгуллин үзен ныграк сүкте: «Әллә шайтан телемнән тарттымы минем? Юкка Стекловның игътибарын бүлдем».

Кинәт куе кара тап булып күренгән куаклыктан бөкрәя төшеп атлаучы кеше сыны аерылды. Таныш түгел кеше бер кавым туктап басып торды, аннары җирдән кәрзин алды да, аксый-аксый, поселокка таба кузгалды.

— Аксак бер карт бугай ла бу,— дип бераз күңеле төшеп пышылдады лейтенант. Ләкин шунда ук аңарда шик уянды: «Куаклар эчендә нишләп шулкадәр маташты соң ул?»

Майор, иелә төшеп, тавыш-тынсыз гына әлеге куаклыкка таба китте.

Менә ул куаклык. Икесе дә чүгәләделәр. Майор, як-ягына каранакарана, бераз көтеп торды һәм фонарен кабызды. Кулы белән җирне капшап карады, аннары яшел стена аша алга атлады. Җирдән дым исе, былтыргы яфрак исе килә иде. Аңа тагын яшь яфраклар исе һәм тагын әллә нинди ят ис тә кушылган. Лейтенант борынын тартып куйды: «Шулай дип уйлаган идем аны, куаклык эчен бәдрәфкә әйләндергән, җүнсез. Бәлки шуңа күрә озак маташкандыр да? Алла белсен аны».

Майор фонарен сүндерде.

— Таһир, син калып тор. Ул-бу булса, обстановкага карап эш ит. Ә мин тегенең артыннан барыйм әле.— Һәм ул агачлар арасында юк

булды. Мотыйгуллин, пистолетын чыгарып, агачка сөялде дә сагаеп тыңлана башлады. Елга якында гына булса да, су тавышы ишетелми. Ләкин зәгыйфь кенә җил, йокысыннан яңа уянгандай, урманга таба исә башлаган чакларда, су исе үзен сиздерә иде. Кайдандыр ерактан пароход гудогы ишетелде, һәм тагын бар нәрсә тынып калды.

...Ул арада майор аксак картны куып җитте һәм аңардан берничә дистә метр арттарак калып атлый башлады. Карт туктамады, тик әледән-әле як-ягына гына каранып барды. «Яннан күрү сәләте бар ахрысы бу картта: артында ни булганын чамалап бара,— дип уйлады Стеклов.— Рация белән әллә соң шушы кеше эшләгәнме?»

Карт бик тыныч, хәтта артыгы белән тыныч атлый иде. Һәм бу хәл ике төрле хис уята: аның шикле кеше булуына ышанасы килми, ләкин хәрәкәтендә нәрсәдер сагаерга мәҗбүр итә иде.

Картның кәрзинне җиңел генә күтәреп баруына караганда, майор фикеренчә, рация кәрзиндә булырга тиеш түгел иде.

Стекловның аяк астында чыбык сынган тавыш ишетелде, ләкин карт моңа да игътибар итмәде. «Әллә чукрак инде? Ә бәлки ул шулай кылана гынадыр? Ихтимал! Хәзер үк моны тикшерергә кирәк.— Майор адымнарын ешайтты, шул ук вакытта карт та ашыгыбрак титаклый башлаган кебек тоелды аңа.

— Тукта! — дип кычкырды Стеклов, картка якыная төшеп.

Ләкин теге атлавын дәвам итте һәм тирән чокыр янына килеп җиткәч кенә туктады. Карт акрын гына башын борды. Менә хәзер ун метр чамасы арадан төнге кунакны җентекләбрәк карарга мөмкин иде. Аның кәкре борыны, бераз бөкрерәк сыны Стекловка бик тә таныш тоелды.

Ул бу карт белән кайчан һәм ничек очрашкан булуы турында баш ватып торган арада, теге, искитмәле җитезлек белән, артына борылды да аңа кәрзин белән китереп бәрде, ә үзе чокырга сикерде. Майор кәрзиннән читкә тайпылды, картка таба ыргылды, ләкин җирдән чыгып торган юан нарат тамырына сөртенде. Бу хәл аны үлемнән коткарды, чөнки нәкъ шул мәлдә теге пистолеттан атып җибәрде. Пуля Стекловның башыннан фуражкасын очырып төшерде. Майор җиргә ауган мәлдә үк кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды һәм ике тапкыр атып өлгерде. Стеклов җинаятьченең тирән чокыр буйлап елгага таба китүен сизде. Ул аягүрә басты, ләкин шунда ук аягы коточкыч авыртудан тагын җиргә ауды. Аста, текә ярның сөзәк урынында үскән куаклык эчендә, агач ботаклары сынган тавыш ишетелде. Кораллы җинаятьче куакларны үгез сыман ерып бара иде.

Майор, агачка тотынып, аягүрә басты, бер аягы белән титаклап, текә яр буена таба китте. Аның карт күрерлек урынга килеп чыгуы булды, шунда ук ату тавышы яңгырады, пуля аның колак яныннан гына сызгырып үтте. Майор җиргә утырды һәм поселокка таба качып баручы дошман ягына таба берничә тапкыр атты, ләкин тидерә алмады. Карт куаклык эченә кереп чумды. Стеклов аны хәзер берничек тә туктатып булмаячагын аңлады. Майор аксак картның җитезлегенә, бигрәк тә аның төз атуына гаҗәпләнеп торды. Ләкин шул ук вакытта үзенең атып та тидерә алмавына гарьләнү хисе биләп алды. ЧКда озак еллар эшләү дәверендә аның мондый гарьлекне бер тапкыр да хис иткәне юк иде әле. «Хурлык. Нинди хурлык!» Бу турыда бит рапортта язарга туры киләчәк! Малай-шалай төсле алдады бит! Яшьләр өчен нинди әйбәт үрнәк! Алар алдында нинди абруем булсын ди минем хәзер?! Көлкегә калдым бит! «Хәлсез, аксак карт артыннан барган, ә тегесе аны кәрзин белән бәреп еккан, котын алган, ә үзе исән-имин качып котылган, диячәкләр».

«Шулай да берничә көн баш ватуым тикмәгә булмаган. Рациянең яшерелү урынын дөрес чамаладым бит. Аны бу урыннан алырга беренче көннәрне үк килмәячәкләрен сизендем. Әлбәттә, радист үзе

яисә бүтән берәү безнең эзләнүләребезне белгәннәр. Көндезләрен эзли бирсеннәр, ә без төнлә килербез дә мәшәкатьсез генә алып китәрбез, дип тә уйлаганнардыр әле. Ә менә без төнлә килеп төштек! — Майор көрсенеп куйды.— Хәзер рациясен табасы иде ичмасам».

Стекловның бу минутлардагы халәте ачлык елны үз җирен сөреп-чәчеп, зур кыенлыклар белән анда иген үстереп тә, саксызлыгы аркасында ул игенне яндырган крестьян халәтенә охшаш иде. Ул күңелендә әрнү катыш ачыну сизде. Бу ачыну аның ихтыярын баса, уйларын тарката иде. Хәтерендә, акрын-акрын, моннан ун ел элек булган вакыйгалар бер-бер артлы котылгысыз рәвештә калкып чыккан саен, аңарда бу ачыну хисе көчәя барды.

«Менә хәзер әле генә кулдан ычкындырган кешенең кем икәнлеген хәтерләдем бугай... Ул бит шпионнарның да шпионы, күп кешенең башына җиткән явызларның да явызы Вячеслав Варев,— дип пышылдады Стеклов, үз ачышына үзе шаккатып. Һәм шунда ук маңгаена салкын тир бәреп чыгуын сизде.— Аның аркасында бөтен гражданнар сугышын минем белән бергә үткән иң яхшы дустым Вася Быков һәлак булды бит».

Шул чакта, дустын күмгәндә, ул кабәхәтне тапмый калмам, дип, Стеклов үз-үзенә ант иткән иде. Ә хәзер ул кеше менә монда гына, якында гына иде бит. Ычкынды! Борын төбеннән ычкынды, өстәвенә Стекловның үзен теге дөньяга җибәрә язып калды.

Һәм аның бөтен барлыгын чиксез гарьләнү биләп алды. Үз-үзен ачулануы иде бу аның. Ә мондый ачу-рәнҗү кешене икеләтә газаплый. Көчсезлек, чарасыз калу хисен тою моңарчы Стекловка таныш түгел иде. Аның каравы бүген ул аны артыгы белән татыды.

Аны ярсу биләп алды, һәм бу нәрсә ничектер аңа көч бирде. Һич кичекмәстән бөтен бу төбәкне камап алырга, юлларны ябарга кирәк! Ләкин кешеләрне кайдан алырга? Соң инде! Бер сәгатьтән бу берни дә бирмәячәк. Менә тиздән Мотыйгуллин йөгереп килеп җитәр. Ләкин аңа Варевны куып җитәргә кушу — файдасыз. Караңгыда эзсез табып булмаячак. Ул кабәхәт хәзер үк яшеренәчәк, төпкә ятачак, һәм аны табу җиңел булмаячак. Җинаятьченең Святовскида яшәве икеле. Аның кебек кеше өчен бу — яңгырдан соң җыелган урам күлдәвекләренә зур көймә җибәрү белән бер — шунда ук күзгә ташланачак. Ул, мөгаен, Светловолжскида яши торгандыр — анда халык күп, яшеренүе җиңел. Ярый, хәерле булсын, табылыр. Ә кәрзиндә рация юк иде. Ул безне элегрәк күргән булырга тиеш. Хәйләкәр һәм явыз, шайтан алган нәрсә!

...Варев турында беренче кабат Стеклов моннан ун ел элек ишеткән иде. Ул бер заводта булган авария сәбәпләрен тикшерә иде. ОГПУ-да диверсия эше кузгатылды. Аны тикшерү озакка сузылды. Ахыр чиктә, ярты ел чамасы узгач, азмы-күпме шикле кешеләрдән дүртесен аерып алдылар. Шулар арасында бухгалтер Вячеслав Варев та бар иде. Василий Быков шул ук заводта бухгалтер булып эшли иде. Ул тикшерүләргә актив булышты. Аның ярдәме белән күп нәрсә ачыкланды һәм корткычларның берсе фаш ителде. Ләкин ул кулга алучыларга коралы каршылык күрсәткәндә үтерелде. ОГПУда кайберәүләр саботажны үтерелгән җинаятьче ялгызы гына оештырган, дип санадылар. Ә менә Быков, саботаж бер генә кешенең эше түгел, дип барды. Ул үзе белән бер йортта яшәүче күршесе Варевтан шикләнүен әйтте, фаш ителгән саботажчының аның квартирына килгәләп йөрүен үз күзем белән күрдем, диде. Шуннан соң Варевны тикшерә башладылар. Ә Быков, бу эшне тизләтер өчен, дошманны үзе генә фаш итәргә була. Эшне алып барган суд тикшерүчесе аның бу ниятен хупламый, ризалык бирә. Ләкин ул Быковка вак кына бер нәрсә турында кисәтми — һәм бу тегенең һәлакәтенә китерә.

Быков, хезмәте буенча, яшерен документлар белән эш иткән, һәм бу нәрсәне файдаланырга була. Ул бухгалтердан өч атнага ике мең сум акча биреп торуын үтенә. Аның максаты мондый була: Варев бу акча өчен расписка таләп итеп, соңыннан аны шантаж өчен файдаланмасмы, әгәр расписка-мазар сорамаса, үзенә тозак коруларыннан шикләнеп, акчаның нәрсәгә икәнен төпченмәсме?

Быков, акча сорап, Варев янына килә дә Бөгелмәдә промышленность товарлары складында мөдир булып эшләүче туган сеңелесенең зур суммада акчасы ким чыгуын һәм, әгәр тиз арада бурычын капламаса, аның төрмәгә эләгәчәген әйтә. Бухгалтер аңа акча биреп торырга риза була, ләкин, акчаны саклык кассасыннан алырга кирәк, ди һәм эштән соң кассага бергәләп кереп чыгарга чакыра. Алар шулай эшлиләр дә. Варев акчасын ала һәм, соңыннан билгеле булганча, аларны бер кырыйда көтеп торучы Быковка бирмәс борын, номерлары аерым бер кәгазьгә алдан ук язып алынган икенче акчалар белән алмаштыра.

Варевны бик нык күзәтү астына алалар. Ләкин тегесе Быковның туганнары белән бөтенләй кызыксынмаган булып кылана. Өч атнадан Вася акчаны кире кайтарып бирә, һәм шул ук көнне кичен ишегалдында аның үле гәүдәсен табалар. Варев моннан соң юкка чыга. Быковны үтерүче Николаев кулга алына. Менә шул кеше Быковның нәрсәдә хата җибәргән булуын һәм ничек итеп тозакка эләгүен сөйләп бирә.

Суд тикшерүе шуны ачыклый: элек патша жандармериясендә хезмәт иткән Варев үтерелгән бер кызылармеецның документларын үзләштергән була. Гражданнар сугышы вакытында адмирал Колчакның контрразведкасында эшли. Аклар тар-мар ителгәч, банда оештыра һәм Идел буенда юлбасарлык итә. Соңрак Мәскәүдән зур шпион Варев-Поленскийны эзләргә кирәклеге турында хәбәр алына. Соңыннан мәгълүм булганча, ул Германия разведкасының агенты сыйфатында берничә тапкыр дәүләт чиген үтеп чыккан икән. Ул елларны аңа берничә тозак куеп карыйлар, ләкин һәр очракта да ул качып котыла. Тәҗрибәле, сизгер акыллы бу җинаятьченең көче аның үзенә кирәкле кешеләр белән тиз аралаша белүендә һәм әледән-әле аларга үзенә бер төрле сынау оештыруында була. Күпләр аның бу тикшерүен сизми дә калалар. Стекловка мәгълүм булган соңгы бер очракта да шундый нәрсә кабатлана. Варев Халык комиссарлыкларының берсендә инженер булып эшләүче Дочков белән таныша, аракы эчү, хатын-кызлар белән чуалу җирлегендә аның белән дуслашып китә һәм саклык белән генә аңардан үзенә кирәкле информацияне ала башлый. Ә Дочковның үзүзен тотышында болай беренче карашка гел күзгә ташланмый торган үзгәрешләрне сизү белән аны тикшерергә була.

Чыннан да бу вакытта Дочков үзенең Поленскийга карата (Варевның яңа фамилиясе) булган шиге турында ОГПУга хәбәр иткән була. Варев тегеңә аларның уртак сөяркәләре булган бер ханымны Халык комиссарлыгына эшкә урнаштырырга тәкъдим итә. Чибәркәй Неляга начальникларның күзе бик тиз төшәчәк,— ди ул,— һәм алар бу ханымны үзләренә якынлаштырырга тырышачаклар, әйтик, секретарь итеп алачаклар. Ә син моны эш урынында югары үрмәләү өчен файдалана алачаксың.

Неляны эшкә бүтән рядовой сотрудникларны алган кебек алалар, һәм бу Варевта берниндн шик уятмый. Бу эш белән шөгыльләнүче ОГПУ хезмәткәре болай фикер йөртә: Варев комиссарлыкка үз кешесен урнаштырып, аны яшерен информация алу өчен файдаланырга уйлый. Димәк, беренчедән, ул Дочковның серне безгә ачканлыгын белми, юкса эшчәнлеген активлаштыра төшмәс иде. Икенчедән, Варев алына торган информацияне чагыштыру өчен һәр ике каналдан файдаланмакчы була. Нелли Чудинованы эшкә урнаштыруда ярдәм итеп,

тикшерүче аның аша Варевның шпион булуын исбат итәргә, ә иң мөһиме,— аның ярдәмчеләрен табарга теләгән.

Чудинованы комиссарлыкка үзенә бер төрле «жим» итеп урнаштырып, Варев алда нәрсә буласын зур киеренкелек белән көтә башлый. Ханымны «югарырак баскычка» күтәрсәләр, бу аның өчен куркыныч турында сигнал булырга тиеш. Тикшерү нәкъ менә шуннан гыйбарәт. Җинаятьче Дочковның мөмкинлекләрен ул яхшы белә. Неляга үз идарәсендә техник хезмәткәр итеп урнаштыру чыннан да бу кешенең кулыннан килә торган нәрсә, ә инде ханымны тагын да югарырак күтәрү — аның «теше үтәрлек» нәрсә түгел. Моны, әлбәттә, куркынычсызлык органнары гына эшли алырлар иде. Һәм әгәр шулай эшләнсә, бу хәл Варевка, Дочков минем турыда ОГПУ органнарына хәбәр иткән, дип уйларга нигез булыр иде. Неляны нинди срокта күчерерләр, кая күчерерләр? — моны белү Варев өчен аерата мөһим була.

Ай ярым үтәр-үтмәс, Чудинова халык комиссары урынбасарларының берсенә техник секретарь итеп күчерелә. Һәм Варев, бер генә көн дә сузмыйча, канализация коесы аша кача. Ул торган өйнең күзәтү астында булуы да ярдәм итми.

Стеклов үз вакытында Варев турында мәгълүматлар җыйган һәм бу вакыйгаларга кагылышлы һәр кәгазь белән танышкан иде. Әле дә хәтерендә, ул теге чакта чекистларның ике зур хата җибәргән булуларын үзенчә билгеләп үткән иде: Чудинованың икенче эшкә күчерелүендә, моның бик тиз эшләнүеннән битәр, аның аеруча мөһим промышленность тармагы белән җитәкчелек итүче кешегә билгеләнүе Варевны сагаерга мәҗбүр иткән.

Стеклов бу уйлардан тәмам арып җиргә ятты. Шулай да: «Менә нинди ерткычны ычкындырдым мин бүген!» — дип, үз-үзен җәзалауны дәвам итте.— Ахмаклык ягыннан мин тегеләрне барысыннан да арттырып җибәргәнмен. Өстәвенә әле тагын бүтәннәрнең хаталарын тикшереп яткан булам».

Шул чак, йөгерүдән тыны кысылып, Мотыйгуллин килеп җитте. Ул зират белән чиктәш булган чокыр янына килеп туктады да як-ягына карангалый башлады.

— Синме бу, Таһир? — диде Стеклов тыныч кына.

— Ни булды сезгә, иптәш майор? — Мотыйгуллин, куркып, аның янына ташланды.— Әллә яраландыгызмы?

— Миңа нәрсә булсын! Нигә куаклык яныннан киттең? Хәзер үк кире кайт та яхшылап күзәт!

Мотыйгуллин аптырап калды. Ул бит күреп тора: майорга нидер булган, әнә ич бик сәер кыяфәттә ята, кулында пистолеты.

— Бәлки сезгә ярдәм кирәктер? — диде Таһир каушап.

— Беләсеңме... сул аякны, табанынннан тотып, нык кына тарт әле... Тайдырдым, ахрысы. Аннары тегендә йөгер.

Лейтенант Стекловның аягын тартуга, майор аңын югалтты. Мотыйгуллин су буена төшеп менде, аның маңгаена сулы чүпрәк куйды. Майор шуннан соң гына аңына килде.

— Таһир,— диде ул зәгыйфь тавыш белән,— хәзер үк тегендә... куаклык янына йөгер. Бәлки кем дә булса килер...

— Иптәш майор, ә соң сез?

— Хәзер үк йөгер. Мин иртәнгә кадәр күренмәсәм, Мусаны җибәр.

— Аңладым. Йөгерәм, иптәш майор.

Лейтенант куаклык эчендә берничә сәгать утырды, ләкин беркем дә күренмәде. Аның аяклары агачтай булып катты. Төнге урман салкыны тәненә үтеп керде. Көнчыгышта тоныкнурлар күренде. Кошлар уяна башлады. Таһир машина янына киткәндә, сәгать иртәнге өчләр иде. Шофер, кабинасының ишеген бикләгән дә, берни белештерми йоклый.

«Әйбәт урнашкансың урнашуын,— дип уйлады Таһир, салкыннан иңбашларын җыерып,— ләкин барыбер уятырга туры килер».

Шофер бик тиз аңына килде һәм, Мотыйгуллин аңлатып бирү белән, машинасын Святовскига куды. Ул арада Мотыйгуллин кире куаклык янына кайтты. Сәгать бишләр тирәсе иде. Инде яктырган, урман сыек томан белән өртелгән. Таһир игътибар белән әйләнә-тирәсен карарга тотынды. Куакларны әйләнеп чыкты һәм бер урында тораташ булып катып калды: алар кичә кич фонарь яндырып тикшергән җирдә, шайтан таягы төбендә җир казылган иде. Мотыйгуллин юан сабактан тартты һәм аның астында ярты метр тирәнлектәге чокыр күренде... Аның төбендә дүрт кырлы әйбернең эзләре калган иде. Мотыйгуллин бу эзне үлчәгәч, чокырда рацияне яшереп тотканнар, дигән нәтиҗәгә килде. Кайчандыр, әле бала чакта, сарай түбәсеннән егылып төшкәндәге төсле тыны кысылды, авызлары кипте.

«Ни арада алып китәргә өлгергәннәр? — дип аптырашта калды лейтенант.— Мин Стеклов янына барып килгән арада микәнни соң?»

Башыннан кечкенә генә бер өмет чаткысы булып: «Бәлки рацияне кичә үк алган булганнардыр? — дигән уй йөгереп үтте.— Чокыр өстенә ябылган һәм үлән тамырлары белән чорнап алынган җир катламын майорның күрмәве дә ихтимал, чөнки аны әрекмән яфраклары һәм куак ботаклары каплап тора». Таһир шул урын тирәсендә бераз йөренде дә монда артык торуның мәгънәсе юк, дигән карарга килде.



## VII бүлек

Закиров килгәндә, Светлана Древцова әле эшендә иде. Ул, «Байбак» дигән җырның көен чыгарырга азапланучы озын буйлы, кара күзле кызга кушылып, фортепьянода уйный иде. Илдар, минут саен сәгатенә карый-карый, түземсезләнеп, коридорда йөренде. «Әгәр хәзер җинаятьченең Древцов квартиры ачкычларыннан күчермә алуы турында минем версия расланмаса, бөтен эшне яңадан башларга кирәк булачак». Зарипов, түземсезләнеп, яңадан аудиториянең ишеген ачты. Бу юлы Древцова Илдарны күреп алды һәм, яшь җырчы алдында гафу үтенеп, ашыгып коридорга чыкты.

— Светлана Петровна, гафу итегез, сезне бүлдердем бугай... Ләкин минем сезгә бик ашыгыч йомышым бар,— дип, кыюсыз гына башлады Закиров.— Мин сезне озак тоткарламаска тырышырмын.

— Әйе, әйе... Мин тыңлыйм, рәхим итегез...

— Әйтегезче, кышын янсә язын сезнең әтиегезне кая булса да чакырмадылармы?

— Нинди мәгънәдә? Кая? Кем?

— Әйтик, военкоматка, ЖЭКка җыелышка, ветераннар белән очрашуга янсә шундыйрак бүтән бер җиргә...

Древцова уйга калды. Закиров тын да алмый көтте, аның йөзенә ялвару билгеләре чыкты: зинһар, үтенеп сорыйм сездән, коткарыгыз мине, исегезгә төшерегез, бу ифрат мөһим.

Древцова хәтерләмим дип башын чайкамакчы булган иде, ләкин күзе Илдарга төшкәч, сүзсез генә бер ноктага текәлеп калды.

«Аңлашыла,— дип уйлады Закиров, күкрәк түрендә нәрсәнеңдер өзелеп төшкәнен сизгәндәй,— минем фараз кылуларым сабын куыгы кебек кенә булып чыкты».

Икесе дә бер мәл сүзсез тордылар.

Закиров акка буялган киң тәрәзә төбенә бармагы белән нидер сызгалады. «Мин бу ханымның күңел газабын тагын яңарттым, күрәсең,— дип уйлады ул,— бу аңа, әлбәттә, кадерле кешесе тормышында-

гы вак детальләрне искә төшерергә комачаулый». Нәкъ имтихан биргән вакыттагы төсле: билетны аласың да шунда, укытучы күз алдында ук, аны укып чыгасың һәм артык гасабилануың аркасында хәтер дигәнең бөтенләй эшләми башлый, син инде билеттагы сорауларның берсен дә белмисең кебек. Ләкин, тынычлану белән, һәр нәрсә үз урынына баса. Шулай итеп, Илдар күңелендә дә өмет чаткысы кабынды.

— Светлана Петровна, сез тыныч шартларда тагын бер тапкыр уйлагыз әле. Зинһар. Ә мин, рөхсәт итсәгез, кич белән сезнең өйгә кереп чыгар идем. Бәлки ирегез берәр нәрсәне ачыклый алыр.

Древцова сәгатенә карап алды:

— Беләсезме, ул хәзер өйдә. Безнең өйгә барыгыз. Мин дә тиздән эшемне бетерәм, туры өйгә кайтырмын.

Закиров бу тәкъдимгә риза булды.

Древцованың ире Николай Петрович, аның звонок бирүен көтеп кенә торгандай, ишекне шунда ук ачты. Закировны танып алгач, кызу-кызу:

— Рәхим итегез, рәхим итегез, иптәш тикшерүче, үтегез. Мин монда чәй дә кайнатып куйган идем, туры өстәл янына утырыгыз,— диде.

Кунакчыллыгы өчен хуҗага рәхмәт әйтеп, Илдар түгәрәк валиклы күн белән тышланган диванга килеп утырды. Бүлмәгә күз йөртеп чыкты: анда бөтен нәрсә үзгәрешсез калган иде.

Николай Петрович аның сорауларына, яхшы билгеләренә генә укучы икенче сыйныф баласы кебек, уйлап-нитеп тормастан, тиз-тиз җавап бирде. Хәер, Закиров аңардан үзен юатырдай җавап көтми дә иде. Ул Николай Петровичның каенатасы белән салкынрак мөнәсәбәттә булуын, икесенең дә үз интереслары белән яшәгән булуларын белә иде.

Тиздән Древцова кайтты. Ул бусаганы атлап керү белән:

— Кызганычка каршы, бернәрсә дә исемә төшмәде. Мөгаен, андый нәрсә булмагандыр да,— диде.

Закиров, китәргә җыенып, урыныннан торды һәм кинәт:

— Светлана Петровна, сез хатларыгызны, алган открыткаларыгызны кайда саклыйсыз? — дип сорады.

— Ә без аларны менә болай...— диде Николай Петрович, хатыны өчен җавап биреп.— Кыскасы, ертып ташлыйбыз...

— Сез үзегезгә килгән хатларны шулай итәсездер. Ә әтиегез, бәлки, аларны саклагандыр?

— Булырга мөмкин,— дип аның белән килеште Николай Петрович.

— Коля, комодта әтинең тартмасын кара әле,— дип сүзгә катнашты Светлана Петровна.— Анда ул дусларыннан алган котлау хатларын саклый иде.

— Минем аның әйберләренә кагыласым килми,— диде аңа ире, ризасызлык белдереп. Һәм шунда ук: — Тартмадагы нәрсәләр белән иптәш тикшерүче үзе генә танышса, әйбәтрәк булыр иде,— дип куйды.

Закиров аның бу фикере белән килешергә ашыкты.

Комод тартмасында Древцовның күптәнге фоторәсемнәре, грамоталары, открыткалары һәм дусларыннан алган хатлары ята иде. Илдар аларны саклык белән генә актара башлады. «Соңгы көннәрдә бу кәгазьләр белән күп кеше танышкан,— дип уйлады ул, аларны бер урынга өеп,— һәм һәркем нәрсә булса да эзләгән». Әмма ул үзенең иң мөһим нәрсәне — зур җинаятьне ачу өчен кирәкле ачкычны эзләвенә шикләнми иде.

Грамоталарның, хатларның һәм открыткаларның эчтәлеген укый-укый, ул тәмам арыды, ләкин, адресы машинкада басылган бер конвертны кулына алгач, сискәнеп киткәндәй булды. Почта штемпеленә күз төшерү белән, аның йөрәге сикереп чыгардай булып тибә башла-

ды. Конверттан чирек бит кәгазь чыгарды һәм, квартир хуҗаларына таба борылып, кычкырып укыды:

«Кадерле Петр Львович!

32 номерлы мәктәп коллективы Сездән шул мәктәпне тәмамлаучылар белән очрашу кичәсендә гражданнар сугышы турындагы истәлекләрегез белән чыгыш ясавызны үтенә.

Кичә шушы елның 15 мартында, шимбә көнне, 19 сәгатьтә булачак.

Сезгә алдан ук рәхмәтебезне белдерәбез.

Зур ихтирам белән, мәктәпнең укытучылар коллективы».

Закиров Древцова янына килде:

— Бу чакыру турында сез нәрсә әйтерсез?

Древцова, кәгазьдән күзен алмыйча:

— Туктагыз әле, аны чыннан да чакырганнар иде бугай шул...— диде.

— Ул анда бардымы?

— Әйе. Минә хәзер исемә төште. Баруын барды, ләкин бик тиз кайтты.

— Кайткач ни әйтте соң?

— Берни дә әйтмәде. Хәер, бәлки әйткәндер дә. Булып үткән вакыйгалардан соң хәтерем тәмам чуалган.

Закиров хатны үзе белән алырга рөхсәт сорады һәм шунда ук мәктәпкә ашыкты.

Аның юлы уңды: мәктәптә чыгарыш сыйныф укучылары өчен консультация бара иде. Аңа ул кичәне оештыручы Валентина Геннадьевна Зайцева булганлыгын әйттеләр. Тагын бер нәрсә ачыкланды: алар беркемгә дә язма чакыру җибәрмәгәннәр.

«Уф... ичмасам бер тотынып нәрсә табылды.— Илдар иркен сулап куйды.— Хәзер йомгакны сүтә башларга кирәк».

Иртәгесен иртәдән үк Закиров Древцов яшәгән өйдә торучылар белән шөгыльләнә башлады. Ә Тренькинга теге чакыру кәгазен ачыкларга кушты. Һәм бу юлы да аның эше уңды: күрше подъездда торучыларның берсе моннан ике атна чамасы элек ишегалдында сакаллы бер ир кешене күргән булуын әйтте, аның төс-кыяфәтен сурәтләп бирде. Бу билгеләр Фролов-Йөнтәснеке белән таңгал килә иде. Шаһит тагын шуны да өстәде: попка охшаган сакаллы ир кеше беренче подъездга кереп китте, диде. Таланган квартир нәкъ менә шунда иде.

Дөрес, Йөнтәснең «хезмәт кенәгәсендә» моңа кадәр кеше үтерү язылмаган иде. Күрәсең, бу юлы да җинаятьче мондый нәрсәне күздә тотмаган. Древцов үз квартирына көтмәгәндә кайтып кергән һәм, күрәсең, җинаятьчене тоткарламакчы булган. Көрәш башланган, һәм шул чакны Йөнтәс кулына беренче эләккән әйбер — мәрмәр көл савыты белән тегене бәреп үтергән. Һәрхәлдә Жуков шулай дип бара. Ә хәзер бу версияне шаһит сүзләре раслый.

Фроловның җинаять эшеннән күренгәнчә, соңгы елларда ул бер ялгызы гына эш иткән. Аның тактикасы да шуннан чыгып билгеләнгән: җинаять ясаласы объект янында яшәр урын табып, обстановканы бик җентекләп өйрәнү, тик шуннан соң гына эшкә керешү.

Ул башка җинаятьчеләр белән элемтә тотмаска тырышкан, очраклы кешеләргә ышанмаган, урланган малны да бүләргә яратмаган. Ялгыз яшәгән, шау-шулы урыннарга йөрмәгән. Ара-тирә эшкә урнашкан, ләкин мондый адымга ул билгеләнгән объектына якынрак булу өчен һәм эрамтамак булып яшәүдә гаепләмәсеннәр өчен генә барган.

Минә шушы нәрсәләрне искә алып, Илдар Йөнтәснең эшкә урнашуы мөмкин булган якын-тирәдәге берничә оешманы ашыгыч рәвештә тикшереп чыгарга карар бирде.

Вакыйга булган җирне карау протоколын игътибар беләнрәк укыган саен һәм Древцов квартирының планын күңелендә яңарткан саен, Закиров җинаятьченең элек тә бу квартирга кергәне булган, дигән фикерен ныгыта барды. Чыннан да, аның тиз арада иң кыйммәтле әйберләрне табып алуы, бернинди эзен калдырмавы шул турыда сөйли иде. «Бәлки җинаятьче хуҗаларның телефон аша сөйләшүләрен тыңлап, үзенә файдалы нәрсә тапкандыр?» Һәм Закиров үзенең эзләнүләрен телефон станциясеннән башлады. Ләкин өмете акланмады: станциядә Фролов эшләмәгән иде.

Станциядәге кызлар белән сөйләшкәндә, икенче бер нәрсә ачыкланды: моннан берничә көн элек ниндидер ир кеше аларга шалтыраткан да Валерий Маркович Фролов белән кызыксынган. «Мин ул сөйләшүне шуңа хәтерләп калдым,— дип аңлатты кыз.— Башта ул кеше ниндидер сакалбайны сорады. Минем: «Сакалбайларның кайсысы кирәк, бездә алар икәү»,— диеп шаяртып соравыма каршы ул Фролов фамилиясен атады».

Закиров башта бу шалтырату Тренькин эше булырга тиеш, дип уйлады. Аның шулай, беркемгә кисәтми-нитми, иптәшләре әйтмешли, вакыйгаларны узып китәргә тырыша торган гадәте бар. Ләкин Илдар шунда ук фикереннән кире кайтты: Тренькин инде күптән үзенең шикләнүен, бу шиген ачыклау өчен ниләр эшләвен әйткән булыр иде.

Көннең калган өлешен Илдар бүтән вак оешмаларга йөреп үткәрде. «Металлоремонт» мастерскоенда ул телефон станциясендәге кебек үк көтелмәгән хәбәр ишетте. Закиров мастерскойда телефон аппаратының булмавына игътибар итте. Ул заказлар кабул итүчедән:

— Туктагыз әле, сез Фроловны сорадылар, дидегез, ләкин сезнең телефоныгыз юк бит? — диде.

— Ә ул үзе монда килде. Таза гәүдәле, кара сакалы бар. Кепкасын күзенә үк төшереп кигән.

Илдар әлеге кешенең тышкы чалымнары, аның тавышы, өстендәге киеме турында биредәге тагын берничә кешедән сорап карады. Ләкин ул инде ишеткәннәренә әллә ни өсти алмады.

Хәзер инде шик юк: Йөнтәсне эзләүдә, аңардан уздырып, Тренькин түгел, бүтән берәү бара. Ләкин кем ул? Өй басучы Фролов тагын кемгә кирәк булган? Кемдер, кулга эләгүдән курыкмыйча, аны эзләвен дәвам итә. Димәк, ул аңлы рәвештә шулай тәвәккәлли, димәк, аның Йөнтәсне табарга теләве кулга алыну куркынычын да җиңәрлек.

«Фролов, безгә кирәк булган кебек үк, бүтән бер кешегә дә кирәк. Бәлки аны, үзләренә өлеш таләп итәр өчен, шпаналар эзлидер? Алай дисәң, алар Древцовның квартиры басылган булуны кайдан белсеннәр? Юк, эзләүнең сәбәбе акчага бәйләнмәгән. Монда икенче бер сәбәп».

Илдар Жуков янына — больницага ашыкты. Уйларына чумып тукталышка җитүгә, кешеләр төркеменең аны күтәреп диярлек трамвайга алып менүләрен һәм бер почмакка китереп кысуларын сизми дә калды ул.

«Нәрсәгә кирәк булды икән соң Фролов аларга? — Илдар үз-үзенә һаман бер үк сорауны бирде.— Бәлки аны үз эшләренә тартып, аның оста карак булуыннан файдаланмакчылардыр? Мөгаен, болай уйлау дөресрәк булыр. Фролов — тәҗрибәле җинаятьче. Соңгы елларда милициянең дә, үз ишләренең дә күзенә чалынмады, алар әйтмешли, «төпкә ятты». Ниндидер зур эш башламакчы була, күрәсең. Һәм Фролов, мөгаен, милициядән генә түгел, үзенең ишләре — җинаятьчеләрдән дә яшеренеп йөри.

Шулай да, Йөнтәсне нәкъ менә бу төбәктә эзләү фикере алар башына ничек килгән? Моның өчен, беренчедән, аның шундый җинаять эшләгән булуын, ә икенчедән, Йөнтәснең гадәтләрен белергә кирәк. Һәм тагын, мөгаен, бу кешеләрдән берсенең генә булса да,— әлбәттә, очрак-

лы рәвештә,— аны шушы тирәдә күргән булулары кирәк. «Һәрхәлдә, аларның башлыклары ахмак булмаска тиеш»,— дип уйлады Закиров.

«Тукта әле,— ул кинәт сискәнеп киткәндәй булды,— нигә соң әле мин Йөнтәсне кем дә булса эзли, дип саныйм? Эзләүче кеше үзе Йөнтәскә охшаган түгелме соң?! Охшаган!.. Фролов Фроловны эзли булып чыга бит әле бу! Тикшерүчеләрне ялгыш юлдан җибәрү өчен эшләнгән алым?»

— Шайтан белсен! — дип куйды Закиров, үзен-үзе белештермичә. Янында басып торучы өлкән яшьтәге бер хатын аңа шикле караш ташлады һәм, кешеләрне этеп-төртеп, трамвайның икенче почмагына таба ашыкты.

«Тиле кешегә саный башладылар инде үземне»,— Закиров көлемсерәде. Ул арада кондуктор «Культура паркы»,— дип, чираттагы тукталышны игълан итте. Илдар ишеккә таба китте.

Яңгыр сибәли. Түбәннән генә йөзеп баручы соры болытлар аша зәгыйфь яктылык сирпелә. Болытлар биек булып үскән тупылларның ябалдашларына тиеп-тиеп алалар сыман.

Закиров урам аркылы чыкты да тимер рәшәткә буеннан больницага таба ашыкты. Аны инде монда белеп бетергәннәр иде: урындыкта утыручы авырулар Жуковны бакчаның кайсы почмагында эзләргә икәнен әйттеләр. Менә өченче көн инде аңа һавага чыгарга рөхсәт итә башладылар. Илдар дустын шунда ук тапты. Жуков инде палатасына керергә җыенган иде.

— Сәлам, Сашок! — Илдар ерактан ук кычкырып җибәрде.— Ничек синең хәлләр? Ярыйсымы?

— Ярыйсы.— Жуков, елмаеп, аның кулын кысты.

— Син гафу ит, дустым, кичә эш күп булды һәм...

— Ташла әле. Болай да инде минем янга килеп, көн саен күпме вакытыңны әрәм итәсең. Мине берәр нәрсә белән шатландырсаң, әйбәт булыр иде.

Яңгыр көчәйде, һәм алар, бинага кереп, коридордагы тирән кәнәфиләргә утырдылар.

— Шатландырырлык әйбер юк шул әле, Сашок. Шулай да нидер әйтә алам. Сүз уңаенда сорыйм әле: кайчан чыгаралар соң сине? Яраңнан җепләрне алдыларммы әле?

— Алдылар. Бер ун көннән чыгам дип торам.

— Менә монысы әйбәт,— диде Закиров шатланып.— Күп калмаган.

— Тыңла әле, сузма зинһар, әйтәсе булсаң — әйт.

Закиров соңгы ике көн эчендә булган вакыйгаларны сөйләп китте. Жуков исә, әледән-әле нәрсәнедер ачыклап, кайтарып сорашып утырды, Илдар сөйләп бетергәч, Жуков аның җилкәсенә кулын салды:

— Сине котларга кирәк, картлач — молодец. Билләһи молодец!

— Шулаен шулай да,— диде Илдар уйчан гына.— Менә Валерий Фроловка охшаш бер Сакалбайның үз куләгәсен үзе эзләп йөрүе сиңа сәер тоелмыймы?

— Ә син, чын Фролов, эзен яшерер өчен, үзен-үзе эзли дип уйлыйсыңмы? Мин сине дөрес аңладыммы?

— Әйе, дөп-дөрес.

— Ә менә син үзең җинаятьче урынында булсаң, шуны эшләр идеңме?

— Мин бу турыда уйладым инде. Эзләүчеләрнең минем эзгә басмаганлыкларын белсәм, мин моны эшләмәс идем.

— Әгәр эзеңә басканлыкларын белсәң?

— Белсәм дә эшләмәс идем, мөгаен. Таякның икенче башы да бар бит әле монда — кемгәдер күренеп йөрергә кирәк. Һәрхәлдә, син шушы эзләнүләрең белән үзеңнең җинаятьчегә берәр төрле катнашың барын

күрсәтәсең. Бу очракта тикшерү органнары һичшиксез бу яңа кешене дә эзли башларга тиеш булалар.

— Мин, Илдар, беләсеңме, ничек уйлыйм: Фролов мондый адымга бармас. Сәбәбе бик гади: Древцовның үтерелүен аның шәхесе белән бәйләвебезне белми бит ул.

— Алайса безнең белән кем шулай шаяра соң? Нигә кирәк бу маскарад?

— Синең, җинаятьчеләр Фроловны үзләренең эшендә катнаштыру өчен эзлиләр, дигән фикерең белән килешсәк, кадерле тикшерүчем,— Александр арыган кыяфәт белән елмаеп куйды,— маскарадны нәкъ шулар оештырган булып чыга.

Илдар уйга калды, урындык артына сөялде дә күзләрен йомды.

— Бәлки шулайдыр да,— Закиров урыныннан ук сикереп торды.— Чыннан да шулай. Йөнтәсне күпмедер вакытка безнең күздән качыру өчен, алар төтен пәрдәсе җибәрәләр. Тикшерүче, аңына килеп, төтеннән соң күзендәге яшен сөрткәләгәнче шактый вакыт үтәчәк.

— Шулай шул. Монда әлеге кешенең индивидуаль заказлар буенча ачкычлар эшли торган мастерскойга ник мөрәҗәгать итүен дә ачыкларга кирәк. Шунысы хак: алар да нәкъ безнең кебек уйлыйлар, шуңа күрә бу төбәктә кайнашалар. Минемчә, аларның икенче максатлары да бар: Йөнтәсне эзләмиләрме икәнен белү, ә бер уңайдан, мастерскойны үзләре өчен файдаланып булу-булмауны ачыклау.

— Ай-һай, Сашок, мондый очракта алар мастерскойга мөрәҗәгать итеп маташырлар иде микән? Бу безне алдау өчен генә эшләнә: менә, янәсе, безнең куркыр нәрсәбез юк, без — намуслы кешеләр, ә мастерскойга болай, өй мәшәкате белән генә килдек... Мин аңлыйм, әлбәттә: аларга инструментлар кирәк. Әмма алар бу конторага икенче тапкыр килмәячәк.

Закиров Александрга күз төшерде һәм:

— Мәнсез кеше дә инде мин — күп сөйләшеп, сине ардырып бетердем,— диде.

Александр елмайды. Аның суырылып калган йөзенә кызыллык чыга башлаган иде инде. Ләкин зур күзләрендә арыганлык чалымнары бар иде әле. Ул тәрәзәгә күз төшерде:

— Яңгыр туктады бугай, бәлки саф һава суларбыз?

— Әйдә, Саша, әйдә...

Бакчага чыккач, Жуков кесәсеннән бер кечкенә китап чыгарды:

— Менә рус поэзиясенең атасы Державинны укый башладым әле. Палатадагы күршем биреп торды. Бик көчле тәэсир калдыра.

— Заманында аңа бөтен Россия сокланган — тикмәгә түгелдер,— диде Илдар.— Пушкин да аның турында язган. Әй-е... Булган бит шундый кешеләр. Аларның вакыты узган. Алар да, нәкъ менә безнең кебек, картаербыз, дип уйламаганнардыр, гомер мәңгелек булып тоелгандыр. Ләкин алар башкарган эшләрен үлемсез дип санап ялгышмаганнар. Аларга җиңелрәк булган.

— Җиңелрәк булганмы, юкмы — анысы билгесез. Бәлки киресенчәдер. Озаграк яшәгән булсалар, халыкка күбрәк файда китергән булырлар иде. Ә бәлки, аларның һәркайсы, бигрәк тә Пушкин, иң яхшы әсәрен киләчәктә язарга өметләнгәндер. Шуңа күрә бөек кешеләргә тормыштан китү аерата авыр. Менә шулай, Илдар.

Жуков дымлы урындыкка килеп утырды. Бакчаның исерткеч һавасын мул итеп күкрәгенә алды.

— Ә синең Державин шигырьләрен укыганың бармы? Димәк, укымагансың. Минем дә моңарчы укыганым юк иде. Шулай да син аны укы әле. Өстәвенә ул бит, тарихчы һәм әдип Карамзин кебек үк, татарлардан чыккан кеше.

— Булмас!

— Булмас, имеш. Менә син бу битләге сүзләрне укып кара. Анда язылган: «Державинның нәселе татар морзасы Баһриннан башланган»,— диелгән.

— Кара әле, шулай икән шул,— диде Илдар исе китеп. Ул Жуков янына килеп утырды һәм баш артын кашып алды.— Минем наданлыкны фаш иттең син.

Кинәт якында гына яшен яшьнәде, һәм шунда ук көчле күкрәү яңгырады.

— Әйдә, картлач, ашыгыйк. Хәзер коеп ява башлаячак!

Алар икәүләшеп палатага йөгерделәр.

## VIII бүлек

Яңгыр төн буе яуды. Күк күкрәп, тәрәзә рамнарына тикле селкетә дә Стеклов уянып китә иде. Аягы сызлый. Ул еш-еш урыныннан тора, аксый-аксый кухняга чыга, тәмәке тарта. Идән такталарының шыгырдавына хатыны Анастасия Федоровна да уяна.

Хатыны сизенә:ниндидер күңелсезлеккә очраган аның ире. Ул беркайчан да хатынына үзенең эше турында сөйләми, шулай да озак еллар бергә яшәгәнгә Анастасия Федоровна аның эшләренең уңышлымы, уңышсызмы баруын чамаларга өйрәнеп беткән иде.

— Ичмасам бераз йоклар идең, Петя, гел арлы-бирле йөренәсең,— диде хатыны әкрен генә.— Тайган аякка тынычлык кирәк.

Иртәнгә таба аның йокысы бөтенләй качты. Петр Прохорович эш турында уйламаска тырышып карады. Әмма хата җибәрүе турындагы аянычлы уйлар аны бөтенләй биләп алдылар. Ул бүген үк эшкә чыгарга булды. Ике көн өйдә утырды бит инде, бүтән түзәрлек әмәле калмады.

Иртәнге сәгать алтыда ул инде аяк өстендә иде. Анастасия Федоровна да торды, ашарга әзерләде. Петр Прохорович радионы җибәрде: Германия гаскәрләренең Франциядә алып бара торган сугыш хәрәкәтләре турында сөйлиләр иде.

— Петя, ә соң немец безнең өскә сугыш белән килмәс микән? — дип сорады хатыны борчулы тавыш белән.

Стеклов бер мәл тын утырды да:

— Кем белә аны...— дип кенә мыгырдады.

Сәгать сигездә, кул таягына таянып, эшенә китте. Бу көннәрдә аның бөтен барлыгын биләп торган эчке киеренкелек арыганлыкны киметә төшкәндәй тоела иде. Бүлектә майор велосипедның берничә җирендә бармак эзләре табылуын белде. Шушы арада велосипедын югалткан гражданнардан алынган гаризалар милиция бүлекләрендә тикшерелгән. Әмма юл чатында табылган әлеге велосипедның хуҗасын таба алмаганнар.

Көн уртасында оперативник Хөсәен Зарипов шалтыратты һәм Стекловка Совет районының милиция бүлегенә кергән бер кызыклы гариза турында әйтте. Гражданка Смирнова бу гаризасында велосипедлар белән спекуляция алып баручы әрәмтамак Чемизовка карата чара күрүләрен үтенгән иде. Шул ук көнне Чемизов бу гариза уңае белән аңлатма биргән. Ул ПВЗ маркалы велосипедны сатканлыгын раслаган. Әйтүенә караганда, ул аны кечкенә шөребеннән башлап үзе җыйган һәм моннан бер ай чамасы элек Светловолжскиның толчук базарында урта буйлы, кара тутлы кешегә саткан. Теге кеше сатулашып тормаганлыктан, аның йөз чалымнарын хәтерләми. Аңа теге велосипедны күрсәткәннәр, һәм Чемизов аны шунда ук таныган. Өстәвенә велосипедтагы бармак эзләренең кайберсе Чемизовныкы икәне беленгән.

«Шуннан нәрсә килеп чыга инде? — дип үз-үзенә сорау бирде Стеклов.— Радистны табар өчен нәрсә эшләргә кирәк соң?»

Бүлек җитәкчеләренә биргән рапортында майор: «Варев — радист роле белән генә канәгатьләнеп кала торган кеше түгел, ул — бик зур фигура»,— дип язды. Әмма фактлар аның бу фикерен расламыйлар, киресенчә, кире кагалар иде. Ул бит үзе дә Варевның рацияне алырга дип килүен инкарь итми. Юл чатыннан башлап Святовск поселогына кадәр арада яр буенда эзләнүләр барган вакытта аның кебек оста, тәҗрибәле шпионның шундый хәтәр нәрсәгә баруы бик тә икеле. «Варев кебек кешенең резидент булуы да бик мөмкин,— дип уйлады Стеклов.— Мөмкинен мөмкин, ә чынлыкта кем соң ул? Ничек кенә булмасын, бер нәрсә ап-ачык — биредә ул ялгызы гына түгел, һәм соңгы рольне дә уйнамый».

Аны Чурбанов янына чакырдылар. Стеклов гаепле кеше сыман, авыр хисләр белән барган иде. Подполковник аны ягымлы йөз белән каршы алды. Сәламәтлеге турында сорашты. Тиешенчә дәваланмаганы өчен шелтәләп алган булды.

— Петр Прохорович, син авырып яткан арада мин монда кайбер нәрсәләр эшләдем,— диде ул, майорның халәтенә игътибар итмәскә тырышып.— Өченче көн теге рация яшеренгән урынга барып кайттым.

«Менә, шайтан, анда барырга да өлгергән»,— дип канәгатьләнү белән уйлады Стеклов.

— Менә шулай. Башта миңа урманда сезнең белән булган вакыйга балалар өчен чыгарылган китаптагы бер рәсемне хәтерләтә иде. Анда бер карга көчекнең койрыгын чукый, һәм көчек әлеге каргага ташланган арада, икенче карга, майлы сөякне алып, очып та китә.

Стеклов бөтен гәүдәсе белән алга талпынып куйды. Мине дә бит шулай алдаганнар булып чыга, дигән уй аны дулкынландырып җибәрде.

Чурбанов сүзен дәвам итте:

— Ләкин соңыннан шик туды: Мотыйгуллин белән сез куаклык яныннан китеп торган арада караңгыда рацияне табарга гына түгел, алып китәргә дә кирәк бит әле. Өстәвенә бу төбәк камап алынган. Капкын тирәсендә икәүләп кайнашу да ачыкланмый — артык хәтәр.

Чурбанов сейфны ачты, аннан кәгазьләр алды да Стеклов янына килде.

— Ләкин, икенче яктан, чокырдагы рация эзләре, Варевның ул тирәдә күренүе,— ул анда һава суларга чыкмаган билгеле,—болар барысы да каршылыклы картина тудыра. Бу эшкә без университетның туфрак белгечләрен — биологларны тартырга мәҗбүр булдык. Менә аларның фикере,— дип ул кәгазьләрне Стекловка бирде.

Подполковник урындыкка утырды, стаканга су салды һәм аспирин таблеткасы эчеп җибәрде: кичәдән бирле туңдырып торганга, ул авырып ук китмәгәем дип курка иде.

Майор укып бетерде:

— Бу документтан күренгәнчә, чокырга капкач ролен үтәгән кәз катламы моннан өч-дүрт көн элек бераз күтәренкерәк хәлдә калдырылган.— Ул датага күз төшерде: Унҗиденче июньдә... «Экспертиза вакытында кәзнең дымлылыгы, балчыкның коелучанлыгы тикшерелде,— дип укып китте Стеклов,— үсемлекләрнең тамыр системасы өйрәнелде...» — Ул, кәгазьне читкәрәк этеп, өстәп куйды: — Димәк, алар бу кәз катламына унөченче яисә ундүртенче июньдә кагылган булганнар. Ә Варевны без анда уналтысында очраттык... Димәк, ул көнне, ягъни уналтысында, рацияне алып китмәгәннәр... Ләкин аннан элгрәк алып киткән булсалар, аңа ул тирәдә йөрү нигә кирәк булган? Юк, Варев юк-барга кайнашмас. Монда нәрсәдер бар. Тик шунысы шиксез: бу — безнең өчен

ифрат мөһим кәгазь,— диде Стеклов биологлар биргән документка ымлап.— Һәрхәлдә ул...

— ...безгә кирәгеннән алда буталмаска ярдәм итә,— дип Чурбанов, елмаеп, аның сүзен төгәлләде.

Стеклов, әйтәсе тәкъдимнәренең төрле вариантлары турында уйланып, бүлек башлыгына карап торды. Биологлар биргән документ оператив чараларны тамырдан үзгәртүне таләп итә иде.

— Документларның әһәмияте турында бераз соңрак сөйләшербез... Мин тагын менә нәрсә турында әйтергә теләр идем: ышанычлырак булсын өчен, галимнәр шул тирәдә тагын бер шундый ук чокыр казыганнар һәм бер тәүлеккә шул килеш калдырганнар. Һәм менә аның белән чагыштырганда...

— Алар да тикшерү экспериментлары үткәргәннәр булып чыга.

— Әйе. Мин сине алар әйткәннәрнең дөрес икәнлегенә ышандырмакчы булам. Юкса, беләм мин сине: юл буе шикләнеп барачаксың...

Чурбанов маңгаена кулын куеп торды, пульсын санады.

— Нәрсә, Михаил Иванович? Авырып киттеңме әллә,— дип борчылып сорады Стеклов.

Подполковник кулын гына селтәде:

— Юк, юк, зарарсыз.

Стеклов подполковникның йөзе табигый булмаганча кызарган, күз төпләре күгәргән булуга шуннан соң гына игътибар итте.

— Михаил Иванович, кадерлем, сиңа ятып торырга кирәк бит,— диде Стеклов аталарча җылылык белән. Чыннан да Стеклов аңа ата булырлык иде.

— Ә соң син үзең, Петр Прохорович, нигә дәваланмыйсың? Сиңа, хәтерем ялгышмаса, врачлар уң көнләп ятарга кушканнар иде.

Стеклов бер сүз дә дәшмәде.

— Петр Прохорович, әгәр рация чокырда булса, дошман ул чокырны күзгә бәрелерлек итеп ачык хәлендә калдырыр идеме?

— Юк.

— Дөрес. Калдырмас иде. Димәк, рацияне чокырдан син ул тирәгә килеп чыккан вакыттан берничә көн элегрәк алып киткәннәр. Шулаймы?

— Шулайдыр, мөгаен.

— Бу бер. Икенчедән, нигә алар чокырны тиешенчә япмаганнар?

— Моны да тикмәгә түгел, дип уйлыйм.

— Мин дә шулай уйлыйм. Тапсыннар, күрсеннәр, дип юри шулай калдырганнар. Әйе бит?

Стеклов уйга калды. Чурбанов, аның җавабын да көтмичә, дәвам итте:

— Әйе. Рация яшерелгән чокырның буш булуын күргәч, без, алар исәпләгәнчә, бу төбәк белән кызыксынмый башларга тиеш булабыз. Әгәр син Варевка юлыкмасаң, бу чыннан да шулай булыр иде. Безнең дошманнар моны алдан күрә алмаганнар. Алар үзләрен безнең урынга куеп караганнар да: без бу төбәкне күзәтүсез калдырабыз, дигән нәтиҗә ясаганнар. Чыннан да, шундый хәлдән соң кайсы җүләре бу тирәдә буталып йөрсен ди?

— Димәк, Михаил Иванович, куаклык эчендәге чокыр күз буяу өчен генә хәзерләп куелган. Аңлавымча, син, бу чокырда рациянең исе дә булмаган, димәкчесең?

— Син мине дөрес аңлагансың.

— Ә чокыр төбендәге эзләр? — диде ул, һәм Чурбановка әйтергә дә бирмичә, үзе үк җавап кайтарды: — Күрәсең, андагы эзләрне дә юри калдырганнар.— Һәм ул сүзләрен шик астына алды: — Ә бу деталь нәрсә белән раслана?

— Кадерле Петр Прохорович, радист урынында булсаң, син рацияне ничек күчереп йөртер идең.

— Кеше күзенә ташланмаслык итеп...

— Һәм...

— Һәм моның өчен рюкзакны яисә капчыкны җайлаштырыр идем. Рациянең формасын үзгәртер өчен, капчыкка башта күпрәк-чапрак яисә шуңа охшаш нәрсә тутырыр идем.

— Во! Кадерле Петр Прохорович, син бик дөрес җавап бирдең. Аппаратны чокырга да шул капчыгы белән салыр идең.

— Әлбәттә. Аны чыгарып торуның ни хаҗәте бар? Өстәвенә аны яшергәндә, ашыгасың-кабаланасың. Чокырда дым да артыграк — яңгырлар ява бит... Брезентсыз булмый.

— Ә алар, Петр Прохорович, алар рацияне чокырга шәрә килеш куйганнар. Белгечләр аның эзен дә тикшереп карадылар. Менә, син әйтмешли, бу деталь турында да кәгазь бар.

Стеклов, ул биргән кәгазьне укып чыкты, бер мәл кулында әйләндергәләп торды да Чурбановка кайтарып бирде. Тегесе аны сейфына салып куйды. Аннары майорга таба борылды:

— Әйдә хәзер нәтиҗә ясап карыйк инде,— подполковник урындыгына утырды.— Мин үзем, Петр Прохорович, шундый фикергә килдем: рация кайдадыр якында гына булырга тиеш.

Майор кинәт башын күтәрде һәм Чурбановка карап куйды:

— Әйе, әйе, майор, ул кайдадыр шул тирәдә. Һәм синең күптәнге танышың нәкъ шуны алырга килгән булган. Ләкин сез аны куркыткансыз. Ул куаклыкка яшеренгән һәм сез киткәнне шунда көтмәкче булган. Бер үк вакытта ул икенче бер максатны — әгәр аны куаклык тирәсендә күрсәләр, безнең тикшерүчеләрне ялгыш юлдан җибәрү максатын да күздә тоткан. Моның өчен ул чокырны алдан әзерләп куйган.

Стеклов уйчан гына башын селкеде:

— Син нәрсә, ул төбәкне күзәтү астына да алдыңмы инде?

— Алдым шул. Өченче көн иртән үк. Ләкин син үзең беләсең: урман эчендә күзәтү алып бару кыен. Безгә нәрсәдер уйлап табарга кирәк. Үзең беләсең, алар бүген булмаса — иртәгә барыбер киләчәк. Һәм, әлбәттә, маскарад киеме киенәчәкләр: турист булыпмы анда, гөмбә җыючы булыпмы. Әгәр шикле нәрсә күрсәләр, шунда ук юкка чыгачаклар. Шуңа күрә урмандагы барлык артык кешеләрне кичекмәстән аннан куарга кирәк,— буталып йөрмәсеннәр.

— Михаил Иванович, менә син миңа шуны әйт әле, нигә безнең дошманнар бу төбәккә ябышып яталар?

— Алар өчен,— дип башлады Чурбанов,— һәр минутта эзләүчеләр килеп чыгу ихтималы булган урынга караганда аулаграк җирдә эш итүе куркынычсызрак. Бу бер. Икенчесе — урыны бик уңайлы: якында гына торак пункты, Идел, олы юл. Син, Петр Прохорович, мөгаен, хаклысыңдыр: синең туган поселогыңда кемдер яшеренеп ята, ахрысы.

Стеклов шунда ук җанланып китте. Чурбановның поселок белән җитди рәвештә кызыксына башлавы аны шатландыра иде. Ә ул кызыксына икән — тәмам ачыкламый торып тынычланмаячак. Идел буе монастыре да аның игътибарыннан читтә калмаячак, ә бу — Стеклов өчен иң мөһиме. Петр Прохорович монастырь серләрен ачу турында күптән хыялланып йөри.

Гражданнар сугышыннан һәм егерменче еллардагы бандитлар хәрәкәте бастырылганнан соң поселок куркынычсызлык органнарының игътибарын үзенә артык җәлеп итмәде. Ул елларда монастырь белән бәйле булган риваятьләрне һәм төрле-төрле имеш-мимешләрне тикшерергә вакыт та булмады. Хәер, күп кеше аларга ышанмый да иде. Ул тарихи чорда күзгә күренеп торган дошманны җиңәргә, халык хуҗалыгын

торгызырга кирәк иде. Өстәвенә ЧКда квалификацияле кадрларның житешмәве дә үзен сиздерә иде.

Һәм менә шулкадәр озак вакыт үткәннән соң, поселок яңадан үзенә игътибарны җәлеп итә башлады.

Чурбанов куаклык тирәсендә яшерелгән рацияне бик җентекләп эзләргә кушты. Эзләү группасы иртәгәсен җидедә үк эшкә кереште. Радиусы йөз метр чамасы булган түгәрәк билгеләделәр дә озын саплы металл капшагычлары һәм мина эзләгечләр белән җирне «тыңлый» башладылар. Бу мәйданда ул-бу сизелмәгәч, Стеклов группаны елгага табарак күчерергә булды.

Кояш инде офыктан шактый күтәрелгән иде. Көн эссе, бөркү. Төшкә кадәр эзләүчеләр шактый арыдылар. Майор тирә-юньдә солдатлар казынып маташкан нарат төбенә килеп утырды. Аңа бер үк сорау тынгы бирми иде: «Кайда соң рация? Чурбанов белән безнең хата нәрсәдә соң?» Эзләнү эшендә система юклыкны һәм бу нәрсәнең рацияне табуга комачаулавын ул сизенә, ләкин бу «системаның» нәрсәдән гыйбарәт булырга тиешлеген үзе дә белми иде. Берничә көн баш миен эшләтми тордыңмы — фикер үткенлеген югалтасың. «Бәлки бу картлык галәмәтедер?..»

Лейтенант Мотыйгуллин житәкчелегендә берничә кеше яр буенда казына иде. Лейтенант итекләрен салды, чалбар балагын кайтарды һәм суга керде дә, комлы җирдән күзен алмыйча, яр буйлап китте. Солдатлар гаҗәпсенеп аңа карап тора башладылар. Кайсыдыр түзмәде:

— Эллә балык эзләвегезме, иптәш лейтенант? — дип сорады.

— Юк, монда нинди ташлар бар икән дип карыйм.

Һәм ул аксыл-көрән төстәге яссы известь кисәкләрен алып, аларны игътибар белән карарга тотынды. Суда тагын бераз йөрде дә аягына киенде һәм, кулына бер башы очлы металл таяк алып, теге вакытта дошман утырып торган куаклык янына китте.

Мотыйгуллин туктады, таякны мөмкин булганча җиргә кадады, аннары таякның җиргә кергән өлешен үлчәде. Тагын шулай итте. Һәр очракта таяк җиргә 60—70 сантиметрга бата һәм ташка әверелгән известняк катламына барып төртелә иде. Калкурак җирдә үскән куаклыкта да туфрак катламы шундый ук тирәнлектә иде.

«Калкулык — әйбер яшерергә дип чокыр казу өчен уңай урын,— дип уйлады лейтенант.— Җир асты суларыннан куркасы юк, атналар буе ятса да, рациягә берни булмаячак. Иң мөһиме — монда үтеп йөрүчеләрнең күрүеннән шикләнмичә, тынычлап казырга мөмкин». Ул, яр читенә баскан килеш, әгәр мин алар урынында булсам, чокырны кайда казыр идем икән, дип чамалап торды һәм шундый фикергә килде: «Бирегә куаклыктан да уңайлырак урын юк».

«Рацияне җиргә яшерергә ниятләгән кеше чокырны известьташ катламына төшеп җиткәнче казыган булырга тиеш»,— дип уйлады ул.— Ә казыганда чыккан туфракны һәм өч бармак калынлыгындагы известьташ катламын алар һичшиксез суга ташлаганнар». Бая ул шуларны эзләп йөрде дә. Ә тапкач, үзенең дөрес уйлаган булуына ышанды: димәк, каты катламны да казыганнар. Шулай булгач, капшагыч 60—70 сантиметрдан да тирәнгәрәк батарга тиеш. Һәм ул бер үк операцияне кабатлый башлады.

Мотыйгуллин төбендә рация эзләре калган чокыр янында туктап калды. Аннары капшагычын җиргә батырды. Үлчәп караса — 75 сантиметр. Тагын шуны ук кабатлады, каты токым монда башка урыннарга караганда да тирәнрәк иде. «Мөгаен, әзрәк известьташ катламын алганнар да, рациянең эзе ачыграк беленсен өчен, чокыр төбенә бераз моңдый туфрак салганнар. Ләкин, туктагыз әле, тукта, шпион әфәнделәр. Җирне кирәгеннән артыграк казып, аннары шул ук туфракны ки-

ре салып торуның нигә кирәге булды соң?..» Шул урында ул тотлыгып калгандай булды, һич көтелмәгән бер уйдан аның башы кайнарланып китте. Ул тизләнде дә чокыр төбендәге җирне куллары белән тиз-тиз алып ташларга тотынды. Каты токымга житкәч, известьташ катламын аралый башлады. Металл таяк ярдәмендә бу катламны да күтәрде. Аста зур гына таш күренде. Мотыйгуллин аны да кузгатты һәм чокырның ян-ягында куыш сыман бер бушлык күреп алды. Анда капчыкка салынган бер нәрсә бар иде. Лейтенант, ашыгып, аны капшап карады: рация ич бу!

— Таптым! — дип, балаларча шатланып, кычкырып җибәрде ул.— Таптым, иптәш майор!

Стеклов дәррәү урыныннан купты һәм, аягы авыртуны да онытып, титаклый-титаклый, куаклыкка таба йөгерә башлады. Килеп җитүгә, капчык бавын чиште дә клеенкага төрелгән рацияне тартып чыгарды. Рациянең капкачы юк иде.

— Ә-ә, менә нәрсә белән ясаганнар икән чокыр төбендәге эзне!

Стеклов известьташ катламына, металл таякка, линейкага күз төшерде һәм барын да аңлап:

— Ничә сантиметрга ялгышканнар? — дип сорады.

— Биш сантиметрны исәпкә алып житкермәгәннәр, иптәш майор.

Якында гына торган солдатлар, аларның ни турыда сөйләшүләрен аңламыйча, аптырап карап тордылар.

Дулкынланган майор лейтенантка таба атлады һәм аны кочаклады.

— Рәхмәт сиңа, энем. Миңа караганда акыллырак булып чыктың!

## IX бүлек

— Элеоноранны чакырыгызчы,— диде Закиров, телефон будкасының һич ябылмый торган ишеген кулы белән тоткан хәлдә.

— Хәзер, бер генә минут,— дип җавап бирде хатын-кыз тавышы.

«Сеңелесе булса кирәк,— дип уйлады Илдар.— Ә тавышы Эляныкына охшаган». Трубкада:

— Тыңлыйм,— диделәр.

— Эля, исәнме,— диде Закиров, үзендә әчке бер киеренкелек сизеп.— Илдар борчый әле сине.

— Ә-ә-ә, Илдарчик, сәлам. Сабакташымның тавышын ишетүгә шатмын.

— Мин сиңа бер шалтыраткан идем. Командировкада, диделәр.

— Әйе шул. Кичә генә кайттым. Истә калырдай булды. Бу бит минем беренче командировкам.

— Димәк, ошады?

— Бик кызыклы сәяхәт,— диде кыз тыныч тавыш белән.— Шулай да өйдә әйбәтрәк.

Закиров Эляның аңа сабакташ итеп кенә каравын яхшы аңлый, шуңа күрә сөйләшүне үзе теләгән эздән җибәрергә курка иде. Бер кавымга тынлык урнашты.

— Ә сез... Ә син...— дип башлады ул тотлыгып,— шимбә көнне нишлисең? — Һәм кызның җавап бирүен дә көтмичә, әйтеп салды: — Әйдә, Эля, театрга барабыз.

— Безнең сабакташлардан тагын кем бара соң?

— Без икебез генә...

Эля бераз сүзсез торды.

— Кара әле, Илдар, бу бит һич көтмәгәндә... Аннары... шимбә һәм якшәмбе көнне минем вакытым юк.

— Бик кызганыч.. Ә сиңа тагын шалтыратырга мөмкинме?

— Әлбәттә, Илдар. Без сабакташлар ич. Теге атнада шалтырат...
— Рәхмәт, Эля. Һичшиксез шалтыратырмын.
Аларның сөйләшүе шуның белән тәмамланды.
«Ну бу каһәр суккан кыюсызлыкны! Әгәр мин кыюрак булсам, аның белән тугызынчы класста ук дуслашкан булыр идем инде. Ул бит мәктәптә үткәрелгән бер кичәдә үзе мине биергә чакырган иде. Ә мин нигәдер курыктым, үзем аны чакырырга базмадым... Нигә? Шикләнмичә әйтергә мөмкин: шул кыюсызлыгым мине бәхетемнән мәхрүм итте». Әгәр шул чакта Элеонора белән дуслашып киткән булсам, бу дуслык тора-бара мәхәббәткә әверелгән булыр иде, дип ышана иде ул.
Шундый күңелсез уйларга чумган хәлдә Закиров хезмәтенә, дөресрәге, торак контораларының берсенә юнәлде. Иртәдән үк көн сүрән иде. Ләкин төшкә таба болытлар таралды, кояш күренде, кыздыра башлады. Көннең беренче яртысында Закиров районның берничә кечкенә оешмасында булды. Ләкин бу файда китермәде.
Ул учреждение коридорына бик аз охшаган караңгы подвал бүлмәгә килеп керде һәм күзенә төшкән беренче ишекне төртеп ачты. Чехов әсәрләре битләреннән төшкәнгә охшаган, интеллигент кыяфәтле, пенсне кигән өлкән яшьтәге ханымнан сорашып, контора начальнигының кайда утыруын белде. Аның килүе начальник кешегә әллә ни тәэсир ясамады: әйтерсең НКВД кешеләрен кабул итү — аның көндәлек эше. Илдар бирегә килүенең сәбәбен аңлатты.
— Валерий Фролов дигән кешенең бездә эшләгәне юк,— дип җавап бирде начальник.— Һәрхәлдә соңгы өч елда эшләгәне юк.
— Әйтегезче, сезнең штатта урта буйлы, кара тутлы, кара сакаллы кешенең торганы юкмы? Әйтик, соңгы елда.
— Сакаллы, кара тутлы кеше дисеңме? — ул уйга калды.— Андый кеше бар иде бугай. Әйе, бар иде. Техник булып эшләде. Күптән түгел генә эшеннән чыкты.
Ул телефон трубкасын алды:
— Лидия Павловна, безгә НКВДдан бер иптәш килгән, аны работникларның личный делолары белән таныштырыгыз.— Ул каршысында утырган Закировка карап алды һәм битараф тавыш белән өстәде: — Уң якта икенче ишек.
Лидия Павловна, урта яшьләрдәге бер ханым, шунда ук техникның фамилиясен һәм исемен атады: Валериан Фроловский. Ул зур гына агач шкафның ишеген ачты да шәхси дело папкасын эзли башлады. Ләкин таба алмады.
Лидия Павловна, каушаудан кулларын җәеп:
— Шушында иде ләбаса. Мин аны бик яхшы хәтерлим,— диде.
Закиров өчен бар нәрсә ачык иде: әлеге техник кәгазьләрне үзе белән алып киткән. Эзен калдырмаска булган. Тәкъдим ителгән фоторәсемнәр арасыннан Лидия Павловна шунда ук Иөнтәсне танып алды:
— Менә ул Валериан Фроловский.
— Аңлашылды,— диде Закиров, иркен сулап.
Иөнтәс бу эштән моннан бер ай элек, ягъни Древцовның үтерелүе алдыннан ук киткән булып чыкты.
Закиров Лидия Павловнадан Древцов квартирында табылган хатны күчереп басуын үтенде. Бу эшләнгәч, Илдар машинка янына үзе утырды: «Фролов — профессионал түгел, димәк аның бармаклары машинка клавишына бүтәнчәрәк баскан булырга тиеш. Ә тикшерү өчен моны белү бик мөһим. Конторада машинка берәү генә бит».
Текстны басып бетергәч, ул Лидия Павловнадан монда булган сөйләшү турында беркемгә дә әйтмәвен үтенде.
Лидия Павловна көлемсерәп куйды:

— Сез, ягъни сезнең хезмәткәрләрегез, бар нәрсәне үз-үзегездән дә яшерәсез, шуңа күрә берегез ни эшләгәнне икенчегез белми.

Закиров сагая калды:

— Нигә алай дисез?

— Сезгә кадәр дә НКВДдан бер кеше килгән иде. Ул да беркемгә дә әйтмәскә кушып китте.

— Кайчан булды ул?

— Мөгаен, моннан ике атна, ә бәлки өч атна электер. Фроловский эштән киткәннән соң күп тә үтми.

— Ә ул кеше таныклыгын күрсәттеме?

— Юк. Миңа аның кирәге дә юк. Бездә кемнең дә булса эшләве яисә эшләмәве сер түгел ич.

Закиров ул кешенең тышкы кыяфәте турында озаклап сорашты. Лидия Павловна әйткәннәрне «Металлремонт» мастерскоенда ишеткәннәр белән чагыштырып карагач, Закиров Йөнтәсне эзләүчеләр арасында әллә ни уртаклык тапмады.

Бераз уйланып торганнан соң Илдар:

— Ә ул хезмәткәрегезнең фоторәсеме сакланмадымы? — дип сорады.

— Әлбәттә сакланды. Онытып торам икән.

Ханым картотеканы карап чыкты, ләкин рәсемне таба алмады.

— Бары да аңлашыла...— дип куйды Закиров уйчан гына.— Ә сез аның тору урынын белмисезме?

Документлары югалудан кәефе кырылган Лидия Павловна бер мәл фикерен туплый алмый торды.

— Хәзер, хәзер... уйлыйм әле... Ул кеше кайдадыр автовокзал тирәсендә тора иде бугай... Һәрхәлдә минем аны шул тирәдә күргәнем булды... Ә менә урамын, гафу итегез, искә төшерә алмыйм...

— Фроловскийның яшәү урынын кем белә икән?

— Әйтә алмыйм шул.

— Монда ул кем белән булса да дус идеме?

— Ничектер хәтеремдә калмаган. Ул һәрвакыт ялгыз иде. Безнең слесарьлар бәйрәмнәрне билгеләү өчен еш җыелалар. Ләкин Фроловский аларга катнашмый, өенә ашыга иде.

Закиров торак конторасының барлык хезмәткәрләре белән дә сөйләшеп чыгарга булды. Кичкә таба гына кайбер нәрсә ачыклана төште. Эшчеләрнең берсе Фроловскийны Нәриман урамындагы ике катлы өйдән чыгып барган чагында күргән булган. Шул кеше белән алар Нәриман урамына киттеләр. Әлеге өйне таптылар. Сораша торгач, Йөнтәснең пенсионерка Минкинада фатирда торганлыгы беленде. Аннары, Минкина сүзләренә караганда, ул компрессорлар заводының тулай торагына күчеп киткән. Шунда эшкә урнаштым, дип әйткән. Ләкин Закировның моңа ышанасы килмәде: Йөнтәс бик сак эш итүчән җинаятьче, алай эз калдырып йөрмәс.

Минкинадан сорау алу тагын шуны күрсәтте: Йөнтәс шимбә һәм якшәмбе көннәрендә еш кына шәһәр читенә китә торган булган. Кая икәнен хуҗабикәгә әйтмәгән. Автобуска утырып йөргән. Минкина аның берничә тапкыр тасма-тасма билетларын чүп чиләгенә ташлавын күргән. Шулкадәр билетның күпме торуы турындагы сорауга карчык: «Тасмада унбиш тиенлек җиделәп билет була торган иде,— дип җавап бирде.— Шул чак мин әле бер сумга мин көне бүе яшим, ә Валериан шулкадәр акчаны бер якка автобус билеты алу өчен генә туздыра, дип уйлап та алган идем».

Автовокзалда Закиров бер сум биш тиенгә Светловолжскидан якында булган дүрт торак пунктына, шул исәптән Святовск поселогына барып булганлыгын белде.

НКВД хезмәткәрләренең якындагы авылларга баруы нәтиҗә бир-

мәде. Бу торак пунктлар арасында Святовск — иң зурысы иде. Анда хәзер җирле оешмаларда эшләүчеләрнең личный делолары белән танышучы чекист яши иде.

Икенче көнне экспертлар Древцовны мәктәпкә чакырып язылган хатның Фролов эшләгән торак конторасындагы «Континенталь» маркалы машинкасында басылган булуын әйттеләр.

Шулай итеп, Йөнтәснең җинаять эшенә турыдан-туры катнашы барлыгы ачыкланды. Хәзер эшнең иң әһәмиятлесен башкарырга — Йөнтәсне кулга алырга кирәк иде. Аның фоторәсемен НКВДның барлык район бүлекләренә тараттылар.

Кичен Закиров Древцовның үтерелүе турындагы эшне тикшерүнең нәтиҗәләре турында Чурбановка һәм Галләмовка доклад ясады. Докладының азагында шундый тәкъдим кертте:

— Мин Древцовка карата террорлык акты ясалган, дигән версияне кире кагылган дип саныйм. Җыйналган материаллар шуны күрсәтә. Бу эшне тикшерүне милиция һәм прокуратура органнары тәмамларга тиеш, аларга тапшырырга кирәк.

— Алай. Аңлавымча, бу сезнең үз фикерегез? — дип сорады Галләмов.— Ә Тренькин бу хакта нинди фикердә тора?

— Ул хәзергә авыру, иптәш майор. Ләкин мин аның белән күптән түгел генә сөйләшкән идем. Ул үз позициясендә кала: бу җинаятьне совет работнигына каршы террорлык акты дип саный.

Закиров урындыкка утырды.

— Минемчә, Михаил Иванович,— диде Галләмов, Чурбановка мөрәҗәгать итеп,— эшне тапшырмый торырга кирәк. Җыйналган материаллар чыннан да тикшерүче Закировның фикерен раслыйлар. Ләкин тикшерүдә Жуков — Закиров версиясен шик астына куярга мәҗбүр итә торган ак таплар бар.

Һәм ул берничә дәлил китерде. Алар түбәндәгеләргә кайтып кала иде. Террорлык акты эшләргә җыенган кеше Йөнтәснең ярдәменнән файдаланырга була. Йөнтәс, Древцов квартирына керү юлларын табып, террорчының сигналын көтә. Ә тегесе, телеграмма турында белеп һәм Древцовның шул телеграмма буенча өенә кайту вакытын чамалап, Йөнтәс белән бергә, Древцов квартирына керә. Аларның берсе кыйммәтле әйберләр белән шөгыльләнә башлый, ә икенчесе хуҗаның кайтуын көтә. Алар, ике арада сугыш чыгарган булып, тәмәке савытын эшкә кушалар.

— Ничек кенә булмасын, шушы көнгә кадәр Йөнтәснең ялгызы гына эш иткән булуы расланмаган,— диде Галләмов.— Мин, җинаятьчеләр икәү булган, дип кистереп әйтмим, ләкин моның шулай булуы ихтимал. Ә бу хәл Йөнтәсне кулга алгач ачыкланачак.

Бүлек башлыгы эшне тапшыруны кичектереп торырга карар итте.

Докладтан соң берничә минут та үтмәгәндер, Закиров үз кабинетына кереп җитү белән, аны Галләмов чакырып алды.

— Иптәш өлкән лейтенант,— диде ул гадәттәгечә рәсми, коры тон белән,— без бүген бер аноним хат алдык. Танышыгыз. Бәлки ул сезгә нәрсә дә булса әйтер?

Закиров газетадан кисеп алынган хәрефләр ябыштырылган чирек бит кәгазьне кулына алды.

Республиканың ЧК НКВДсына.
Нәчәлник! Кәҗә тәкәсе-агентларыгызны минем бакчага — Кәрим авылына җибәрмәгез. Анда минем хатыннар көтүе (гарем). Анда керү сәламәтлек өчен зыянлы — суеп ташлаулары бар.

Дустың.

— Сәер хат бу,— диде Закиров уйчанланып.— Минемчә, исемсез автор безнең игътибарны Кәрим авылына юнәлтүне максат итеп куйган. Ни өчен? Әйтүе кыен.

— Шул шул менә. Ләкин сез хаклы.

Кабинетка Чурбанов килеп керде:

— Нәрсә, ребус чишәсезме?

Икесе дә аягүрә бастылар.

— Утырыгыз, утыр,— дип кулын изәде подполковник һәм өстәл янына килеп утырды.

— Михаил Иванович, без монда Закиров белән бер нәтиҗәгә килдек.— Ул мәсьәләнең асылын аңлатып бирде дә өстәп куйды:— Алар безнең игътибарны бүтән торак пунктларыннан читкә юнәлтергә маташмыйлармы?

Майор Галләмов республика картасы янына килде.

— Картага күз төшерик. Кәрим авылы белән янәшәдә генә — Макфирово, Ключищи, Святовск. Барысы да бер үк ераклыкта. Шулаймы? — Чурбанов белән Галләмов сүзсез генә картага карап тордылар.— Соңгы вакытта Святовск тирәсендә җитди вакыйгалар булып алуыннан чыгып карасак,— дип дәвам итте Галләмов,— безнең игътибарның нәкъ менә шунда тупланган булуы бик табигый.

— Сез нәрсә тәкъдим итәсез? — дип сорады Чурбанов, урындык артына аркасын терәп.— Исемсез хатны игътибарсыз калдырыргамы?

— Кәрим авылында өч меңгә якын кеше яши. Һәр яңа кешенең күренүе күзгә ташланмый калмый. Соңгы вакытта, әйтик, соңгы атнада анда нинди чит кеше күренгән — шуны белешергә кирәк...

— Марс Әхтәмович, минем аңлавымча, сез хатны ул авылда яшәүче кеше язмаган, димәкче буласыз?

— Әйе. Минемчә, анда даими яшәүче кеше, хат язып, кем әйтмешли, үзенә төбәп ут ачуларын теләмәс. Андый кеше икенче бер торак пунктын, әйтик, Макфировоны атар иде.

— Бик ихтимал,— дип подполковник аның сүзен җөпләде. Ул аягүрә басты, картага карап торды.— Димәк, язган нәрсәсен почта ящигына ташлар өчен ул кеше Кәрим авылына махсус килгән?

— Һәрхәлдә, почта штемпеле шул турыда сөйли,— диде Галләмов.

Чурбанов урынына барып утырды. Учы белән күзләрен каплады. Күпмедер вакыт сүзсез утырды. Аннары кинәт торды, телефон янына килде. Эчке эшләр халык комиссарының авыл җирләрендә милиция хезмәте белән шөгыльләнә торган урынбасарының телефон номерын җыйды.

— Николай Иванович? Исәнмесез. Чурбанов мәшәкатьли әле. Минем Кәрим авылындагы обстановканы беләсем килгән иде.

Трубкада бер мәл берни ишетелмәде. Комиссар урынбасары кем беләндер сөйләшә иде. «Җитди сөйләшүләрен бүлдердем ахрысы»,— дип уйлады Чурбанов.

— Гафу ит, Михаил Иванович, Кәрим авылында тынычмы, дип сорадың бугай... Тыныч иде...

Чурбанов сагая калды. Йөзе җитдиләнде.

— Ә кичә анда безнең работникны үтерделәр... Пычак белән кадап.

— Участковыйнымы?

— Юк. Совет район бүлегеннән лейтенант Севчукны.

— Җинаятьче кулга алынганмы?

— Качкан. Бар кешене аякка бастырдык. Ләкин хәзергә...— Яшенков йөткерә башлады. Аннары сорады:

— Нәрсә, әллә синең конторага да барып җиттеме?

— Безгә аноним хат килде. Үтерү белән куркыталар.

Алар очрашып сөйләшергә кирәк дигән нәтиҗәгә килделәр, һәм Чурбанов үзенең урынбасары белән полковник Яшенков янына китте.

Кабинетына кайткач, Закиров уйга калды. Йөнтәсне кулга алуны ничек тизләтергә? Тикшерү эшенең бүлектә калдырылуына ул эченнән

генә шатлана да иде — күп нәрсәгә ирешелгән бит, өстәвенә бу мәсьәлә аны чын-чынлап мавыктыра да. Закиров, эшне тиз көндә тәмамлап булыр, дип исәпли иде.

Аның уйларын көтмәгәндә Элеонора бүләп алды. Бүген дүшәмбе — яңа атна башланды. «Бәлки хәзер үк шалтыратыргадыр? Ничектер уңайсыз. Атна уртасында шалтыратырмын инде».

Берничә көн элек Закиров булып чыккан торак конторасыннан шалтыраттылар. Башта Илдар контора начальнигының ни сөйләвен аңламый торды. Хәер, аның уйлары эштән ерак иде шул. Ләкин ул шул ук мәлне сискәнеп киткәндәй булды:

— Алло, алло! Нәрсә дидегез? Кабатлагыз әле, зинһар! Нинди таныклык?

— Нинди дип... Моннан ярты сәгать элек безгә сез шалтыратмадыгызмыни?

— Кем? Кем шалтыратты? — дип кайтарып сорады Илдар, урыныннан ук торып.

— Миңа бер ир кеше шалтыратып әйтте: «Гафу итегез, НКВДдан шалтыраталар,— диде.— Мин шушы көннәрдә сезнең конторада булган идем, шунда таныклыгымны онытып калдырганмын». Ә мин сезгә кире кайтарып бирдем ич,— дидем. Һәм Лидия Павловнадан сорарга вәгъдә иттем. Ләкин аңарда да сезнең телефон номерыгыздан башка беркем бер нәрсә дә калдырмаган булып чыкты.

Закиров урындыгына лып итеп утырды. Ояларына таяк тыгылган кортлар кебек, аның фикерләре төрле якка сибелде. «Безнең җинаятьче эшенә төшкәнме-төшмәгәнме икәнебезне ничек җиңел белгәннәр. Димәк, кемдер Йөнтәсне саклый. Ә бәлки бу аның үз эшедер? Моңарчы ул андый нәрсәләр белән шөгыльләнми иде төсле. Ни генә булмасын, бер нәрсә бәхәссез — аны үз әшнәләре — җинаятьчеләр эзләгән».

Ул бер мәл ни эшләргә белми утырды.

Ул арада Рәхмәтуллин янына килергә кушып, Халык комиссарының секретариатыннан шалтыраттылар.

«Чыгып кына тора бит,— дип уйлады Закиров озын коридор буйлап атлаганда.— Комиссарның үзенә үк шулай ашыгыч нигә кирәк булдым икән? Һәрхәлдә рәхмәт әйтергә чакырмыйлардыр. Ни генә әйтмә, бүләкләгәндә ашыгычлык булмый».

Комиссар бүлмәсендә Чурбанов, Галләмов һәм Яшенков утыралар иде. Закировка да утырырга тәкъдим иттеләр.

— Древцовның үтерелүе хакында эш ничек бара? — диде комиссар Закировка игътибар белән карап.— Кайчан тәмамламакчы буласыз?

Закиров эшнең төп этапларын аңлатты.

— Озакка сузмагыз,— диде Рәхмәтуллин коры гына.— Юкса бандитлар тәмам котырындылар, инде сезнең адымнарыгызны контрольгә алганнар. Куркыныч янамаганын сизеп алганнар, күрәсең.

Халык комиссары урыныннан торды, кабинет буйлап йөренде һәм тәрәзә янына килеп туктады. Аннары, Яшенковка ымлап:

— Рәхим итегез, Николай Иванович, иптәшләрне таныштырыгыз,— диде.

Яшенков бер бит кәгазь алды да укый башлады: «Кичә, якшәмбе көнне өлкән лейтенант Севчук, Кәрим авылында туганнарында кунакка баргач, унтугыз сәгатьтә НКВД органнары эзли торган гражданинны күргән. Кино сеансы беткәч, әлеге кеше үзенең бер танышы белән клубтан чыккан да ашыгып урманга таба киткән. Севчук Галимҗан исемле малайны тиз генә участковый Зотов артыннан җибәргән. «Геннадий абый Йөнтәсне таныды, аның кай якка китәсен тикшерергә булды. Чистай тракты ягына, урманга таба китте. Коралын алсын да мине куып җитсен, дип әйтте»,— диярге кушкан. 19.25 тә сержант Зотов урманнан ерак түгел җирдә, коры елга төбендә хәрәкәтсез ятучы ке-

шене күргән һәм аның янына төшкән. Аркасына пычак кадап үтерелгән кеше Севчук булып чыккан».

Закиров шаккатты. Ул Геннадий Севчукны яхшы белә иде. Бу хәлгә ышанасы килми иде. Һәм тагын — Йөнтәс!

— Безнең эштә акрын кыймылдау менә нәрсәгә китерә,— диде комиссар.

Барысы да тын утырдылар.

Закиров башын күтәрде. Аның каршында Галләмов утыра иде. Аның бөтен кыяфәте: «Менә күрдеңме инде: әйттем бит мин сиңа, Йөнтәснең бер ялгызы гына эш йөртүенә күз йомарга ярамый, дидем. Синең версияң җимерелә түгелме?» — ди сыман иде. Әгәр биредә булмасалар, Галләмов бу сүзләрне кычкырып әйтәчәк иде.

Рәхмәтуллин, кайгылы кыяфәт белән, картларча авыр сулады:

— Кызганыч. Шундый яшь килеш! Нинди егет иде бит!

Тагын тынлык урнашты.

— Якын киләчәктә нәрсә эшләргә уйлыйсыз? — Арыган тавыш белән шыпырт кына сорады комиссар Чурбановтан.— Һәм гомумән бу үтерүдә безгә мәгълүм вакыйгалар белән үзара эчке бәйләнеш, уртак закончалык күрмисезме?

— Зариф Рәхмәтуллович (Халык комиссары мондый чакта үзенә хәрби званиесе белән мөрәҗәгать иткәнне яратмый иде), сез Древцовның үтерелүе һәм Севчукның һәлак булуы арасындагы элемтәне күздә тотасызмы?

— Монысы — тышкы элемтә, Михаил Иванович. Мин исә күренеп тормый торган эчке элемтә турында сорадым. Сүз уңаенда шуны да әйтим, безнең эштә күзгә ташланып тора торган нәрсәләр вакыйгаларның үзара бәйләнешен раслый алмый. Сез моны үзегез дә яхшы аңлыйсыз.

— Зариф Рәхмәтуллович, әгәр без сүзне нәкъ шул мәгънәдә алып барсак, минем фикеремнең буш хыял җимеше булып күренүе ихтимал.

— Кемгә? — дип сорады Рәхмәтуллин, аны бүлдереп. Без бер бүлектә эшләмәгәч, бер төрле фикер йөртүне онытканбыз, димәкче буласызмы? Ягез әле, Михаил Иванович, хыял җимешегезне уртага салыгыз әле,— дип елмайды ул.— Карап карыйк.

— Минем бу фикерем әле өлгереп җитмәде,— дип башлады Чурбанов.— Шуңа күрә аны алдан ук әйтергә теләмәгән идем. Севчукның үтерелүе, билгесез радистның пәйда булуы, Святовск поселогы янындагы хәлләр — болар барысы да бер үк чылбырның буыннары.

Үз фикерен аңлатуны дәвам итмәс борын, Чурбанов Халык комиссарына күз төшерде. Ул, аның йөзенә карап, әйтелгәннәрне ничек кабул итүен белергә теләгән иде. Рәхмәтуллинның күзендә шаян чаткылар күргәч, Чурбанов уйлап алды: аларның фикерләре элеккечә тәңгәл икән. «Әә Рәхмәтуллин — молодец, үткен фикер йөртү чослыгын югалтмаган»,— дип уйлады ул. Һәм шатланып куйды: димәк, версия дөрес!

— Беренчедән, Древцов белән Севчукның үтерелүе арасындагы элемтә — очраклы, аларны уртак бер максат берләштерми. Тик үтерүченең бер үк кеше — Йөнтәс булуы гына. Ә ул карак. Древцовны үтерүне алдан күздә тотмаган.— Шул чак Закиров Галләмовка күтәрелеп карады. Тегесе берни булмагандай утыра иде.— Бу фикер эштәге материаллар белән дә раслана.

Чурбанов кабинетта утыручыларга күз йөртеп чыкты — барысы да зур киеренкелек белән тыңлыйлар иде.

— Икенчедән: Йөнтәсне нииндидер шикле кешеләр эзләп йөргән...

— Үзләре шикле булса да, акыллары зирәк,— дип сүз кыстырып куйды полковник Яшенков.

— Ә менә бу соңгылары караклар белән дә, чит ил разведкасы белән дә элемтәдә булырга тиешләр. Шик юк, алар белән бик тә тәҗрибәле, акыллы һәм мондагы обстановканы яхшы белүче кеше җитәкчелек итә. Шулай итеп, Иөнтәсне берәр эштә җим итеп файдаланган булулары ихтимал. Табигый ки, шунда берьюлы аны кулы-аягы белән «юеш эш»кә [1]— Севчукны үтерү эшенә бәйләргә булганнар.

Чурбанов стаканнан су эчте, маңгаен сөртте һәм дәвам итте:

— Кемдер бар көченә безнең игътибарны бүтән торак пунктларыннан һәм, әлбәттә, беренче чиратта, Святовск поселогыннан читкә юнәлтергә тырыша. Безнең өчен дә, дошманнар өчен дә һич көтелмәгән булган вакыйгалар нәкъ менә шул поселок тирәсендә башланды ич. Без аларның эзләренә шулай тиз төшәрбез, дип алар һич көтмәгән. Әгәр без шул көтелмәгәнлектән тиешенчә файдалана алмаганбыз икән, монысы икенче мәсьәлә. Һәрхәлдә без, үзебез дә сизмәстән, Варев белән булган очрашудан соң аларны безнең игътибардан читкә юнәлтергә тиешле адым ясарга мәҗбүр иттек. Менә шуңа күрә алар аноним хатны милициягә түгел, куркынычсызлык органнарына язалар. Аннары иң ахыргы адымга — кеше үтерүгә баралар.

Чурбанов папкасыннан бер конверт чыгарды.

— Бу конверттагы почта штемпеле хатның шимбә көн җибәрелүе турында сөйли. Ә Севчукны якшәмбе көн үтерәләр. Без исә аларның хатын дүшәмбедә алабыз. Димәк, без шул көнне генә нидер эшли алабыз. Алар әлбәттә, хатның ничә көн барачагын белгәннәр. Димәк, шимбәдә һичкемнән курыкмыйча эш иткәннәр: авылда участковый милиционердан гайре беркем дә юк бит. Аларга кемне үтерсәләр дә барыбер булган. Төп максат: бу авылга безнең игътибарны җәлеп итү. Һәм менә бу кадәресен мин тагын бер тапкыр аеруча басым ясап әйтергә телэр идем.

Чурбанов бер кавым сүзсез торды һәм тыныч тавыш белән дәвам итте:

— Менә килеп туган хәлнең эскизы шундый...

Аннары Чурбанов аерым детальләргә күчте, аларның һәркайсын дәлилләп, тасвирлап бирде. Ул сөйләп бетергәч, Халык комиссары, җанлана төшеп, аның сүзен җөпләп куйды:

— Сезнең фикер бик ачык, Николай Иванович.

Чурбанов авырыксынып кына урынына утырды. Үз чыгышы аңа ошамады, дәлилләрне җитәрлек китерә алмадым, сүземдә эзлеклелек җитенкерәмәде, дип уйлады.

— Сораулар бармы? Тагын кем сүз әйтергә тели? — дип сорады Халык комиссары.

Сүз әйтүче булмады. Чурбановның фикерләре кабинетта утыручыларның күбесе өчен һич көтелмәгән булганлыктан, беркем дә яклап та, каршы килеп тә сүз әйтергә әзер түгел иде.

— Ярый, иптәшләр, сөйләргә теләүчеләр юк икән, минем үземә бернечә сүз әйтергә туры килер.

Ул өстәл тартмасыннан бер кәгазь чыгарды, аңа күз төшереп алды.

— Материаллар белән танышканда мин үзем өчен кайбер нәрсәләрне сызгалап утырган идем. Гөнаһ шомлыгына каршы, бирелә Михаил Иванович әйткән фикерләр, аныкы кебек үк ачык булмаса да, минем башта да уянган иде. Менә мин монда язып куйганмын: «Севчукның үтерелүе белән радистның эшләре арасында элемтә булуы турында уйланырга һәм бу версияне тикшереп карарга»,— дип язылган.— Комиссар кәгазен читкәрәк куеп, күзлек пыялаларын сөртте:

— Дөрес, Чурбанов алга сөргән версия әлеге дәлилләр белән расланмый. Шулай да ул иң җитди игътибарга лаек. Мин аның яклы. Та-

[1] «Юеш эш» — кеше үтерү белән бәйле булган җинаять.

гын кайбер фикерләремне әйтергә теләр идем: — Минемчә, Кәрим авылында алар, Йөнтәстән файдаланып, ике төрле максат куйганнар. Беренчедән, аның шик астында булу-булмавын белергә теләгәннәр. Бу нәрсә җинаятьчеләрнең торак конторасына телефоннан шалтыратулары белән раслана. Икенчедән, инде монда әйтелгәнчә, Йөнтәсне җим итеп файдалану да күздә тотылган. Моннан тагын икенче бер нәтиҗә ясау да сорала. Әгәр Йөнтәс чит ил разведкасы йогынтысына эләккән икән, тегеләр аны үз максатларында файдаланачаклар. Димәк, ул гади бер карак булудан туктый. Монда бер сорау туа: нигә соң әле алар Йөнтәс белән шул тикле мавыгалар? Бу хәл безне сак булырга мәҗбүр итә. Мөгаен, алар Йөнтәс кебек өй басучыдан башка булдырып булмый торган тагын бер зур җинаять эшләмәкче булалар. Әлбәттә, чит ил разведкасын өй басулар кызыксындырмый. Аларга яшерен информация һәм диверсия актлары кирәк. Менә шул әйткәннәрдән чыгып, безгә бик якын киләчәктә күп кенә чаралар күрергә кирәк.

Чурбановның һәм Рәхмәтуллинның чыгышларын Закиров тын да алмый тыңлады.

Киңәшмәдә Древцовның һәм Севчукның үтерелүе турындагы җинаять эшләрен хәзергә берләштермәскә, дигән карарга киленде.

## X бүлек

Кулга төшерелгән шифрны чишү өстендә белгечләр өч атна буе баш ваттылар. Ярдәм сорап, Мәскәүгә дә мөрәҗәгать итеп карадылар. Бәлки алар да шундыйрак шифрга юлыккандыр, дип өметләнгәннәр иде. Анда, чыннан да, ике урынлы саннар белән аралашучы биш урынлы саннардан торган бер шифр язып алынган булган. Ләкин әлегә кадәр «укылмаган» булып чыкты.

Стеклов көн саен бүлеккә килеп йөрде. Радио дулкыннарының ешлыгын һәм диапазонын үзгәртеп, безнең пеленгаторларга «эләкмичә», дошманның бер-ике тапшыру алып барган булуы бик ихтимал, дигән фикердә тора иде ул.

Шифрның сере очраклы рәвештә ачылды. Дөресрәге, шифрлар бүлеге хезмәткәре Старовойтовка нәкъ шул көнне кунакка килгән бер тарихчы-галим ярдәм итте. Николайның нәрсә турындадыр бик газапланып уйлавын да сизмичә, әлеге тарихчы Тимофей Денисов үзенең Идел буйлап югарыга сәяхәте турында мавыгып сөйләргә керешә. Ул үзе өчен бер ачыш ясаган булган: борынгы Болгар дәүләтенең вәкилләре — Идел буе татарларының бабалары — уникенче гасырда елга буйлап югарыга китә һәм анда бистәләр сала торган булганнар. Һәм алар биредәге төп халык булган руслар белән тыныч һәм дусларча элемтәдә яшәгәннәр. Андый бистә Кострома шәһәрендә дә сакланып калган. Бу шәһәрдә беренче татар зираты 1150 елда нигезләнгән булган.

Старовойтов, бу санны ишетү белән, үзе дә сизмәстән, аның ярдәмендә шифровканы үлчәргә керешә. Аннары көтмәгәндә китап шкафы янына ашыгып килә дә әбисеннән калган тәүратны эзләргә тотына. Православие чиркәвенең изге синоды тарафыннан 1896 елда бастырып чыгарылган бу зур китапны табып, аның битләрен кабаланып актара башлый. Дусты Николай аңа аптырап карап тора. Менә Старовойтовның түгәрәк йөзе кинәт бөтенләй үзгәрә, шаян кеше битлеге кигәндәй була. Ул Тимофей янына йөгереп килә дә аны кочаклап ала.

— Миңа нинди зур ярдәм иткәнеңне син күз алдыңа да китерә алмыйсың!— ди ул дулкынланып һәм, гафу үтенеп, хезмәт урынына ашыга.

Моңа тикле файдасыз кәгазьләр булып яткан шифровкаларны «укырга» менә шундый очраклы хәл ярдәм итә.

...Шифровальщик Стекловны бүлек башлыгы Чурбанов янында тапты һәм аларга үзенең ачышы турында сөйләп бирде. Һәм бер сәгатьтән «укылган» радиограммаларны китерергә вәгъдә итте.

Стеклов, кесәсеннән «Казбек» тартмасын чыгарып, папирос кабызды, тирән итеп суырды һәм иркен сулап куйды:

— Менә хәзер кайбер нәрсәләр ачыкланырга тиеш.

— Тиеш, тиеш,— диде Чурбанов та.— Болай да инде хуҗалар кыса башлады. Кичә өлкә комитетыннан шалтыраттылар.... Алар безгә бик зур өмет баглыйлар, Петр Прохорович... Ә без хәзергә куелган таләптән ерак торабыз — аз эшлибез.

— Менә монысы инде һәрхәлдә сиңа кагылмый,— дип каршы төште Стеклов.— Син, туганкай, болай да йөк атыдай тартасың. Һаман әле терелеп тә бетә алганың юк. Шулай ярыймы инде, я? Сиңа бераз ятып торырга кирәк иде. Юкса, ходай сакласын, өзлегеп китүең бар.

Чурбанов кулын гына селтәде:

— Җитәр инде, Прохорыч, син тагын мине үгетләргә тотындың, эш дигән нәрсә ул...

— Авыру ул синең эшеңнән куркып тормый,— Стеклов аның сүзен бүлдерде һәм өйдә сөйләшеп утыргандагыдай йомшак тавыш белән әкрен өстәп куйды: — Сәламәтлек белән алай шаярырга ярамый, Миша, ярамый. Ул сиңа кирәк булачак, әле ничек кенә кирәк булачак.

Чурбанов көлемсерәде.

— Әллә сез дәвалаучы врач белән сүз куештыгызмы? Анысы Халык комиссарына шалтыратам, дип куркыта. Менә бу төенне чишеп бетерсәк, дәвалана башлыйм, дөресрәге, ял алам да кая булса китәм.— Ул сәгатенә карап алды.

— Тиздән шифрны карарбыз, дошманнар нәрсә язалар икән.

— Алар, чекистлар тәүрат кебек дин китабын укып маташмый торганнардыр әле, дип уйлаганнар һәм шуңа исәп тотканнар. Җитмәсә тагын ачкычы да гадәти түгел, тәүратка бернинди катнашы булмаган төсле.

— Аларның эшләре дә тәүратта әйтелгәннәргә туры килми ич,— дип куйды Чурбанов. Әгәр тәүратның яшәеш турында сөйли торган «Борынгы васыять» дигән беренче китабын укып карасың, тәңре Адәмне, үзе килеп чыккан җирне эшкәртсен, дип Эдем бакчасына куып чыгара. Ә шул Адәмнең бүгенге балалары нишлиләр? Алар җир өстенә явызлык чәчәләр, кеше үтерәләр, аларга тыныч яшәргә бирмиләр.

Бүлмәгә ашыгып шифровальщик килеп керде.

Чурбанов радиограммаларны алды, кәгазьләрне селкеп:

— Менә алар, әле без түләмәгән векселләр,— дип укырга кереште.

Штольцка.
Кирәкле ике кеше таптым. Кушаматлары Үгез һәм Чмо. Алар ярдәмендә өченче кешене эзлим. Аның аша объектка да чыгарга тиешмен.

Мефодий.

Чурбанов укыган битне бер кырыйга куеп, икенчесен кулына алды:

Мефодийга.
Аларны эзләү эшенә уенчәнчеңә дә тартыгыз. Төп объектка Роза аша чыгарга тырышыгыз.

Штольц.

— Һәм менә соңгысы,— диде Чурбанов канәгатьсез тавыш белән.

Штольцка.
Хәзерлекне төгәллим. Үгез үтерелде. Өченчене кайда икәнен ачыкладым. Тиздән күзгә чалынырга тиеш. Роза елады. Эшләр алга китте.

Мефодий.

Шифровальщик чыгып киткәч, Стеклов радиограммаларны укып чыкты да:

— Хәзер монда кайбер нәрсәләр ачыклана,— диде.— Һәм никадәр яңа сораулар килеп туа...

— Берни дә эшләр хәл юк. Бәлки синең Мефодиең яңадан терелгәндер? Әллә бу очраклы туры килү генәме?

— Ул исән булса да үз исеме белән йөрмәс иде. Менә мин, Михаил Иванович, үземә калса, андый нәрсәгә бармас идем.

— Бәлки ул шулайдыр да, Петр Прохорович. Мин дә шулай дип саныйм. Ә бәлки алар безнең шулай дип уйлавыбызга исәп тотканнардыр?

— Аннан ни файда? Әллә дөньяда исем беткәнме? Хәер, бәлки алар шуның белән безне читкә юнәлтеп, моннан егерме ел элек булган вакыйгаларны тикшермәкчеләрдер? Без монда уйлап маташкан арада алар үз эшләрен башкарып та өлгерерләр.

Чурбанов бер кавым уйлап торды:

— Бәлки чыннан да шулайдыр. Шифрлары ачылган тәкъдирдә безне ялган юлдан җибәрү — алар өчен начар фикер түгел. Күп нәрсә ачык булмаганлыктан, безгә, Петр Прохорович, шик уята торган нәрсәләрнең барысын да тикшерергә кирәк. Тик бу турыда соңрак.

Алар шифровкаларның эчтәлегенә анализ ясап, аларны төрле детальләр, вакыйгалар белән чагыштырып шактый озак утырдылар. Һәм икәүләшеп шундый фикергә килделәр: радиограммаларда сүз Закиров белән бәрелешү вакытында үтерелгән Үгез кушаматлы җинаятьче турында бара. Ә бернинди шик уятмый торган икенче нәтиҗә радиограммаларның рацияне эзли башлауга кадәр җибәрелгән булуына кайтып кала иде. Аларда тагын шундый уй да туды: шифровкада телгә алынган «Өченче» — ул Йөнтәс түгел микән?

Ә кем соң ул Роза? Нигә ул «елаган»? Ә «эшләр алга китте» дигән сүзләр нәрсәне аңлата? «Төп объект» дигәннәре кайда? Ул чак әлеге «төп объект»тан тыш тагын бүтән объектлар да бар булып чыга бит? Бу сорауларга җавап хәзергә юк иде.

Шифровкалар белән эш беткәч, Чурбанов белән Стеклов рация яшерелгән чокыр тирәсендә засада оештыру мәсьәләсенә күчтеләр. Моннан элек Халык комиссары үткәргән киңәшмәдә ул төбәктәге «туристлар» палаткасын алырга карар ителгән иде. Кайберәүләр палатка урынына шул тирәгә махсус баржа китереп туктатырга һәм шуннан торып күзәтү алып барырга, дигән тәкъдим керттеләр. Ләкин бу тәкъдимнең үз кимчелекләре бар: баржадагылар яр читенә йөзеп чыкканчы җинаятьче качып өлгерәчәк. Өстәвенә төнге караңгыда баржадан күзәтү алып барырга гомумән мөмкин түгел. Шуннан соң Кәрим авылыннан ерак түгел җирдә табор корып җибәргән чегәннәрдән ярдәм сорарга карар иттеләр. Чыгышы белән чегән булган бер милиция работнигын таптылар. Аның аша таборның Идел буена күчеп урнашуын оештырдылар. Чегәннәр элек тә шул тирәдә тукталган булганлыктан, бу күчү шик уятырга тиеш түгел иде.

Чегән чатырларының янәшәсендә үк оперативникларның шундый ук чатырлары урнашты. Алар тышкы кыяфәтләре һәм кием-салымнары белән дә таборныкылардан аерылып тормыйлар иде. Чурбанов вакыйгаларның ничек дәвам итәчәген күз алдына китерергә тырышып карады. Бер карашка барысы да алдан күрелгән кебек иде. Ләкин ул бу операцияне күңеленнән кат-кат үткәрде, аның детальләре турында Галләмов һәм Стеклов белән киңәште.

Икенче көнне Чурбановны авыру тәмам аяктан екты. Аның урынына Галләмов калды.

Чокыр казылган урын өзлексез күзәтү астына алынганнан бирле дүрт көн узды, ләкин беркем дә күренмәде.

Табор исә үз тормышы белән яши бирде. Иртән үк хатын-кызлар Светловолжскига һәм тирә-юньдәге авылларга китәләр. Ирләр ат көтәләр, утын хәзерлиләр, йоклыйлар, карта уйныйлар. Кичкә таба табор җанлана: хатыннар кайта, алар белән бергә шук бала-чага кайта, куанып көлешкән тавышлар ишетелә. Ә төнлә табор, чатырлар, шулар тирәсендә утлап йөргән атлар караңгылыкка төренгәч, Идел өстенә чегән учакларының кызгылт чаткылары белән бергә ягымлы һәм дәртле моң тарала. Җырлар җитез биюләр белән алмашына. Аннары тагын җыр яңгырый.

Кичләр сизелмичә генә үтеп китә. Оперативникларга көндезләрен күпкә кыенрак: аларның палаткасы көн уртасында мунчаны хәтерләтер дәрәҗәгә җитеп кыза. Ә ике-өч кеше гел шунда булырга мәҗбүр, ә төннәрен алтысы да шунда.

Берәрсе килеп, чегәннәрдән үзенә кирәкле мәгълүматны ала алмасын өчен иртән оперативникларның өчесе табор кешеләре белән ат көтәргә китә. Чыннан да, тәҗрибәле агентка табордагы халыкның соңгы берничә атна эчедә артуын һәм кем хисабына артуын белү бик җиткән: ул шунда ук үзенә тиешле нәтиҗә ясаячак.

Чекистлар рация хуҗасын төрле кыяфәттә күз алдына китерделәр. Стеклов, мәсәлән, ул таборда чит кеше юклыгына ышану өчен, башта шунда сугылырга тиеш, дип уйлый иде. Аның фикеренчә, ул тоткан балыгын сатып йөрүче сыйфатында киләчәк. Галләмов исә, шпион яисә аның иярчене үзенә кирәкле мәгълүматны көндезләрен табордан китүче хатын-кызлардан алырга тырышачак, дигән карашта торды. Һәм, мондый хәл була-нитә калса дип кайбер чаралар да күрделәр.

Мәсьәлә табор Идел буена килеп урнашканнан соң алты көн үткәч ачыкланды. Ул көнне Наталья Большанинова һәм Рада Биленко, үтеп баручы машинага утырып, Светловолжскига килделәр. Шактый вакыт кибетләрдә, шәһәр базарында йөрделәр. Төштән соң, рәхимсез кыздырган кояштан качып, вокзал каршындагы бакчага керделәр һәм, үтеп-сүтеп йөрүчеләрне туктатып, күрәзәлек итә башладылар. Ләкин киләчәктә үзен нинди язмыш көтәсен белергә ашыгучылар аз иде. Большанинова, инде уңышка өметен өзгән булса да, акрын гына атлап килүче көрән тужуркалы, таза гәүдәле, урта яшьләрдәге бер ирне туктатты. Тегесе чегән хатынына бер мәл карап торды, елмайды һәм урындык янындагы агачка килеп сөялде. Большанинова карталарын күрсәтте, ә теге кеше биш сумлык акча чыгарды.

— Бирегә акча эшләр өчен бик ерактан килгәнсез, ахры,— дип шаяртты ир кеше.

— Нишлисең инде, чибәркәем? Гаилә бар, әнә күрәсез ич,— һәм чирәм өстендә нидер кимереп утыручы ике кызчыкка ымлады.— Менә алар аркасында шундый эссе көнне Святовскидан килергә туры килә. Шуңа күрә алтынлатсаң икән минем кулны, энҗе бөртегем.

Большанинова әлеге кешегә якын киләчәктә аны нинди шатлык-бәхетләр көтүен, аның нинди рәхәт көннәр кичерәчәген әйтеп бирде. Ир кеше, башын иеп, китмәкче булды, ләкин күрәзәче чегән хатыны аны болай гына ычкындырырга теләмәде, юлына аркылы төшеп, хатынының һәм балаларының да язмышын әйтеп бирергә теләвен әйтте.

Теге кеше иңбашын сикертеп куйды:

— Минем гаилә турында нәрсә әйтә аласың соң син,— үзеңнең таборың турында да җүнләп белмисеңдер әле!

— Кем белми? Минме?

Ул арада теге, акча эзләгән булып, кесәсен капшарга тотынды. Ләкин кулын кесәсеннән чыгарырга ашыкмады.

— Я, әйт, ничә кеше хәзер сезнең таборда? — диде ул, ниһаять, ун сумлык акча күрсәтеп.

— Җитмеш икә.

— Әгәр мин сезгә кунакка килсәм, җитмеш өченче буламы?

— Юк, нигә? Кадерле кунагыбыз буласың,— диде чегән хатыны, күзен акчадан ала алмыйча.

— Сездә хәзер кунаклар юкмыни?

— Бар. Алты кеше. Горький өлкәсеннән килгәннәр.

— Кунакның җынлесе өч көннән артык тормый. Ә алар сезнең сыйхөрмәттән симереп беткәннәрдер инде. Үзләре, баксаң-күрсәң, сезнең җырларны җынләп белмиләр дә булыр. Инде бию турында әйтеп тә тормыйм. Шулаймы?

— Дөрес сөйлисең, кадерлем. Йоклаудан башлары чыкмый. Гомумән, ул ирләрдән файда аз.

— Үз телләрендә сөйләшә беләләрме соң? Әллә онытып бетергәннәрме?

— Онытканнар, кадерлем. Берсе генә аз-маз ермачлый шунда,— чегән хатыны акча сорап кулын сузды.

— Ә бәлкем алар чегән дә түгелдер?

— Кем белә инде аларны?

— Алар сездә күптән яшиләрме соң?

— Иртәгә бер атна була, кыйммәтлем минем.

Ир кеше аңа унлык акча сузды:

— Әйдә тагын бер тарат әле карталарыңны: минем үземә дә, гаиләгә дә. Телең бик татлы.

Чегән хатыны кочак-кочак бәхет, санап бетергесез байлык вәгъдә итеп такылдый башлады.

Ләкин көрән тужуркалы сәгатенә күз төшереп алды:

— Фу, шайтан алгыры! Поездга соңга калам бит,— диң, йөгереп диярлек китеп барды.

Шуннан соңгы вакыйгаларның мәгънәсен Большанинова һич аңлый алмады. Ул урындыкка килеп утырырга да өлгермәде, аның янына кара костюм кигән егет килеп туктады һәм аңардан әле хәзер генә киткән кеше белән ни турында сөйләшүләрен сораштыра башлады. Чегән хатыны башта кул селтәп кенә котылмакчы иде, ләкин егет милициядән икәнен әйтте һәм таныклыгын күрсәтте; ә үзе көрән тужуркалыга әледән-әле борылып карады. Әлеге кеше табор һәм аның кунаклары турында сорашмадымы, дигән сорауга чегән хатыны уңай җавап биргәч, милиционер тегенең артыннан торып йөгерде.

Көрән тужуркалы инде ераклашып бара иде. Менә ул, куркыныч барын сизенепме, урам аркылы чыкканда артына әйләнеп карады һәм, аңа таба йөгерүче егетне күреп, тыкрыкка борылырга ашыкты, ләкин шул чак, аларның һәр икесе өчен һич көтмәгәндә, якындагы ишегалдыннан милиция сержанты килеп чыкты. Шунда арттан килүче егет:

— Туктагыз әле, гражданин! Туктагыз! — дип кычкырды.

Көрән тужуркалы теләр-теләмәс кенә туктады һәм сержантның килүен көтеп торды, аннары тиз генә артына борылды, күз ачып йомган арада уң кулы белән тегенең эченә китереп сукты да тыкрык буйлап йөгерде.

— Тукта! Юкса атам! — дип кычкырды әзәрләкләүче егет.

Көрән тужуркалы кеше күп йөри торган бу урамда атмаячакларын яхшы аңлап, кычкыручыга һич игътибар итмичә, бар көченә чатка таба йөгерде. Урамдагы кешеләр бу күренешкә гаҗәпсенеп карап тордылар. Менә пистолеттан аткан тавыш яңгырады. Егет тагын кычкырды:

— Тукта!

Урамдагы халык як-якка сибелде. Ниндидер бер ир кеше йөгерүчегә каршы төшмәкче иде, ләкин теге, туктап тормыйча гына, бер ая-

гын алга ташлады да, каршы чыгучыны аяктан екты. Егетнең һаман калышмавын күреп, җинаятьче каешына кыстырылган наганын тартып чыгарды һәм, тәзәп тормастан, атып җибәрде. Ләкин тидерә алмады.
Милиция хезмәткәре кирпеч бинаның стенасына елышты. Чылтырап пыяла ватылганы ишетелде. Якындагы тыкрыкка борылмас борын кәрән тужуркалы тагын ике тапкыр атты. Тавышлар, хатын-кызларның кычкыруы ишетелде. Нindидер бер ир кеше:
— Ярдәм итегез! Бандитлар! Үтерәләр! Ка-ра-ул — дип акырды.
Җинаятьче урамны аркылы чыкты да, ишегалдына кереп яшеренер өчен, якындагы өйгә таба йөгерде.
Милиционер, алдарак атлаучы егет белән кызны күреп:
— Тотыгыз бандитны! — дип кычкырды.
Алда баручыларның берсе Тренькин иде. Ул артына әйләнеп карады, аңа таба якынлашучы кораллы кешеләргә карап торды һәм шул ук мәлне коточкыч курку аның бөтен тәнен чиллә салкыныдай куырып алды. Ул акбурдай агарынды, стенага елышты. Җинаятьче Тренькинга җитәргә нибары ике адым кала тагын коралын күтәрде. Аның артыннан йөгерүче егет, теге атып җибәрмәс борын ук, өметсез саналган тупны тотарга тырышучы волейболчыдай, җиргә егылды һәм, дошман пулясы аңа тими калды.
Җинаятьче, тир исе бөркеп, Тренькинның яныннан ук йөгереп үтте һәм ишегалдына таба борылды. Эдуард, бу тирәдән тизрәк китәргә теләп, акны-караны күрмичә, үзе белән килгән кызга таба атлады, ләкин шунда ук аксый-аксый җинаятьче артыннан йөгерүче милиция хезмәткәренә килеп бәрелде. Тегесе Тренькинның йөзенә күз төшерде, «фу, шайтан», дип сүгенеп алды һәм ишегалдына йөгерде. Тренькин тәмам аптырап калды: бу егет шәһәр милиция идарәсендә эшләүче Юрий Герасимов иде. Лейтенант Герасимов, перспективалы хезмәткәр буларак, аларның резервына кертелгән һәм кайчак менә шундыйрак операцияләргә катнаштырыла иде.
Шул чак Тренькинны икенче бер курку биләп алды: «Әгәр аңа бернинди ярдәм күрсәтмәвемне эшләгән җирдә белеп алсалар?» Һәм бу курку аны Герасимов артыннан ишегалдына таба йөгерергә мәҗбүр итте. Ишегалды үтеп йөрмәле түгел иде. Анда да ату тавышлары яңгырады. Үлем куркынычы куркак исемен күтәрүдән, намусына тап төшүдән шүрләүгә караганда көчлерәк булып чыкты, һәм Тренькин кире борылды. Шулай да аның күңелендә: «Бу ыгы-зыгы арасында Герасимов мине танымагандыр әле»,— дигән өмет чаткысы уянды. Шулай үзен тынычландырып, ул әлеге урыннан ераграк китәргә ашыкты.
«Туры килеп торуын кара син. Ни пычагыма кирәк иде миңа монда килергә? — дип пошынды Тренькин.— Тиктомалга чебен урынына үтереп ташлый яздылар бит үземне. Барысы да шул Людка аркасында. «Әйдә, җаным, урам әйләнеп керик», имеш»,— һәм ул янында баручы кызга усал караш ташлады. Тизрәк котылырга кирәк моннан. Бар бит дөньяда үзләре белән гел мәшәкать һәм күңелсезлекләр генә алып килүче кешеләр.
Тренькин, күңелсез уйларыннан айнып, тизрәк кайтып киту ягын карады. Ә янындагы кызга, тиздән хатын өйгә кайтырга тиеш, дигән булды. Саубуллашу билгесе итеп кулын изәде дә урамдагы халык арасына кереп югалды.
Ул арада җинаятьче, аучылар куып килгән бүредәй, ишегалдында атылып-бәрелеп әйләнде. Менә ул ике катлы өй ишегенә кереп китте. Аның наганында патроннар беткән иде инде. Өйнең чормасына менде, аннан калай белән капланган түбәгә чыкты һәм, дыңгыр-даңгыр килеп, янгын баскычына таба йөгерде. Җинаятьчене тере килеш тотарга теләп, Герасимов атмады. Түбәгә чыгу белән ул җинаятьчене янгын баскычыннан аска төшә башлаганда куып җитәчәген аңлады. Моның




*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме*

шулай булачагын һәм үзенең уңайсыз хәлдә калачагын җинаятьче дә чамалады ахры. Шуңа күрә ул түбә уртасында туктап калды һәм, Герасимов аңа якынлашу белән, котырган эттәй, аңа ташланды. Герасимов аның йодрыгыннан читкә тайпылды, ләкин аны үзенә якын җибәрмичә булдыра алмады. Теге гаять көчле булып чыкты, оперативникны тимер кыршау белән кыскандай, кочаклап алды. Шулай да Герасимов терсәге белән тегенең янак сөягенә китереп сугарга өлгерде. Ул шунда ук аңа йодрыгы белән дә берне тондырырга теләгән иде, ләкин җинаятьче аның башына сукты. Герасимовның башы әйләнеп китте, һәм ул, егылып китмәс өчен, дошманына ташланды, аны бугазыннан эләктереп алмакчы булды. Менә шунда алар, бер-берсенә ябышкан хәлдә, түбә кыегыннан аска тәгәрәделәр һәм ике катлы өй биеклегеннән җиргә егылып төштеләр.



## XI бүлек

Закиров соңгы көннәрдә Идел буендагы бер торак пунктыннан икенчесенә йөреп чыкты, Кәрим, Макфирово авылларында, Святовск поселогында булды. Ләкин җинаятьчеләрнең эзенә төшә алмады. Бары шул нәрсә ачыкланды: шимбә көн кичкырын аларны Макфирово авылыннан ерак түгел җирдә бер көтүче, ә төнге сәгать унда Святовск поселогындагы агач склады каравылчысы үлгән. Сакаллы, попларныкы төсле озын кара чәчле, карсак буйлы бер кеше Макфирово ягыннан килүче ЗИС-5 маркалы йөк машинасыннан сикереп төшеп калды, диде ул. Закиров шул тирәдәге «Кызыл байрак» колхозыныкы булган бу машинаны эзләп тапты. Ләкин шофер берни әйтә алмады. Куаклык янындагы борылышта — ул, гадәттә, тизлекне киметә торган җир икән — сикереп менеп утырган булуы ихтимал, дип кенә котылды. Бу борылыш Макфирово авылыннан ярты чакрым чамасы.

Димәк, Йөнтәснең эзе Святовск поселогына килә. Ә Святовскидан Светловолжскига бары тик ике юл белән: автобуста яисә Идел буйлап су трамваенда барып була. Ләкин автобус станциясендә дә, пристаньда да Фролов-Йөнтәсне күрүче табылмады.

«Әгәр, Стеклов уйлаганча, Святовскида вакыйгаларның барышына йогынты ясый алырдай зур бер козгын оя корган булса,— дип уйлады Закиров,— ул Йөнтәскә бу тирәдә буталырга рөхсәт итмәс иде». Мондый нәтиҗә подполковник Чурбановның фикере белән дә тәңгәл килә. Димәк, Фроловны бу поселоктан эзләү файдасыз.

«Ә бәлки ул хуҗасының сүзен тыңламыйча, үз белдеге белән шунда калгандыр?» Менә шунда ул Йөнтәснең, чама белән бер сумлык билет алып, каядыр шәһәр читенә йөргәнлеген исенә төшерде. Андый билет белән дүрт торак пунктына, шул исәптән Святовскига барырга мөмкин, дигән нәтиҗә ясаган иде бит ул. Йөнтәс элек йорт басучы гына булган һәм чит ил разведкасы белән элемтәдә тормаган, шуңа күрә теләсә кайда яши алган. Хәзер исә, күрәсең, хәл үзгәргән: аның хәрәкәтләрен, ни эшләргә, кайда яшәргә тиешлеген шеф хәл итә булыр. Шул ук вакытта Фроловның элек тә Святовскига килеп йөргән булуын искә алсак, аның бирегә элекке гадәт буенча, хуҗасының рөхсәтеннән башка да килгән булуы ихтимал. Менә шуларны уйлап, Закиров җинаятьчене Святовскидан эзләргә кирәк, дигән фикергә килде. «Иртәгә үк шул поселокка күчеп киләм»,— диде ул эченнән.

Кичен, Светловолжскига кайткач, ул Бабанинага шалтыратты. Көне буе чабып арыганга күрәме, дулкынлануы басыла төшкән иде аның. «Дулкынланырлык көч калмаган»,— дип уйлады ул Эляның тавышын ишеткәч.

— Беләсеңме, Илдар,— трубкада кызның тавышы ерактан ишетелде,— минем бер тәкъдимем бар.

Илдар сагая калды. Көтелмәгән һәм гадәти булмаган бер нәрсә буласын сизү шатлыгы аның арыганлыгын тәмам юк итте.

— Хәзер сәгать 19.40. Шулаймы?

— Шулай,— диде Закиров, сәгатенә карап.

— Минем бер дус кызым бүген институтны тәмамлавын билгеләп үтмәкче була. Мине дә чакырды. Үзем генә барасым килмәгән иде. Әгәр теләсәң, бергәләп барабыз.

— Уңайсыз булыр инде ул. Мине чакырмадылар ич,— диде Илдар каушап, ләкин шунда ук ашыгып риза булды: — Дөресен әйткәндә, мин рәхәтләнеп риза...

Алар кайда һәм кайчан күрешәчәкләре турында сүз куештылар.

Илдар зур кыенлык белән чәчәк бәйләме тапты, бер тартма конфет алды. Бабанина көттермәде, тиешле вакытта килеп тә җитте. Ул өстенә кара панбәрхет күлмәк кигән, муенына Клеопатраның профиле төшерелгән алтын кулон таккан иде.

Илдар аңа чәчәк бәйләме тоттырды, һәм алар якындагы дүрт катлы кирпеч йортка таба киттеләр. Ишекне тантананың сәбәпчесе үзе — сары чәчле, озын керфекле, алсу битле кыз ачты.

— Ниһаять,— диде ул шатланып һәм Илдарга кызыксынып карап куйды. — Мин инде килмәссез дип уйлаган идем.

Ярым ачык ишектән алгы бүлмәдә сөйләшкән, көлешкән тавышлар ишетелә иде.

Хуҗабикә Закировка кулын сузды:

— Фәридә.

— Бик шатмын,— диде егет һәм, башын бераз ия төшеп, өстәде.— Илдар.

— Рәхим итегез,— кыз, яңа килгән кунакларны түргә узарга чакырып, ишекне киңрәк ачты. Озын өстәл тирәсендә кунаклар тезелешеп утыра иде.

Өстәл янына ике йомшак урындык китереп куйдылар да Илдар белән Элеоноралы рәттән утырттылар. Мондый урындыкларны Закиров театр сәхнәсендә, дворяннар тормышыннан алып язылган спектакльләрдә генә күргәне бар иде. Бу квартирдагы бар нәрсә: күпертмә бизәкле түшәм, стенадагы келәмнәр, алтынланган рамнарга куелган рәсемнәр,— хуҗаларның борынгы әйберләрне яратулары турында сөйли иде.

Шундый обстановкага эләккәч, Илдар, күпмедер вакыт, үзен уңайсыз сизеп, тартынып утырды. Нигәдер Эрмитажда беренче тапкыр булуын исенә төшерде. Анда күргән нәрсәләр аны тәмам шаккатырганнар һәм ул үзен ничектер кечкенә бөҗәк хәлендә итеп сизгән иде.

Шул вакыт ул өстәлнең аргы башында утырган Тренькинны күреп алды. Ул мыскыллы елмаю белән Закировка карап-карап ала иде: менә, янәсе, гомерендә беренче тапкыр адәм рәтле өйгә эләккән дә, хәйран калып, авызын ачып утыра, танышларын да күрми. Закиров, ияк кагып, аның белән исәнләште. Тренькин исә, күзләре белән ашардай булып, Элеонорага текәлгән иде.

Кунаклар Фәридәне өстәл янына чакырдылар, синнән башка күңелсез, диештеләр. Аннары тостлар башланды.

Закиров Фәридәнең аңа карап торуын сизде. Моны Эля да күреп алды:

— Дус кызымның сиңа күзе төште, ахрысы,— диде ул.

— Юк ла, Эля, сиңа гына шулай тоелгандыр.

— Син алай димә. Мин аны бик яхшы беләм, болай итеп берәүгә

дә караганын күргәнем юк иде. Шунысын да әйтим, аның хәзергә беркеме дә юк,— дип елмайды Эля.

Сүзне икенчегә бору өчен Закиров:

— Фәридә белән янәшә утыручы карт кем? — дип сорады.

— Ой, син мине гафу ит, Илдар. Онытып торам икән, без бит профессор Хәбибуллиннарда, дөресрәге, аның кызында кунакта.

Кунаклар аз эчтеләр, әмма өстәл янында иркенлек, самимилек хөкем сөрде. Аларга каршы утыручы юан гына бер кеше җор теле, тапкыр сүзе белән бөтен мәҗлес халкын үзенә каратты. Әкренләп Илдар да үзен иркен сизә башлады. Тиздән пластинкалар уйната башладылар, кайберәүләр биергә үк тотындылар. Эляның биисе килми иде, шуңа күрә Илдар, кызыклы хәлләр турында сөйләп, аның күңелен табарга тырышты. Әлеге юан кеше, кунаклар исеменнән, Фәридәнең скрипкада берәр көй уйнап күрсәтүен теләде. Тегесе ялындырып тормады. Ул инструментны тикшереп карады, аягүрә басты, сызгычын кылларга тидерде, һәм бүлмәгә нәфис моң таралды.

— Яруллинның «Шүрәле»сеннән бу вальсны мин һәрвакыт дулкынланып тыңлыйм,— дип пышылдады Илдар. — Ә Фәридә бик әйбәт уйный...

— Син, Илдар, молодец булып чыктың, боксны гына түгел, классик музыканы да беләсең икән...

Закиров дәшмәде. Эляның бу мактавы аңа ошамады. «Минем турыда әйбәт үк фикердә түгел икән бу кыз...»

Фәридә уйнап бетергәч, барысы да аягүрә басып кул чаптылар. Аның тагын нәрсә булса да уйнавын үтенә башладылар, әмма Марк Егорович — теге юан кешене шулай атыйлар иде — тавышын күтәрә төшеп әйтте:

— Кадерле кунаклар, бүген Фәридә — безнең күңелне, без аның күңелен ачарга тиеш, аңа бераз ял бирик.

Кунаклар өстәл яныннан кузгала башладылар. Бер почмакта Тренькин берәү белән музыка турында сөйләшеп тора иде. Аларга Илдар да килеп кушылды.

— Безнең кадерле коллегабыз Закиров җинаять эшләреннән ары китә алмый,— диде исерә төшкән Тренькин, әллә ни тәкәллеф саклап тормыйча. Аннары тагын өстәде: — Вакыт үтә, ә без синең белән, бөек идеяләр тудырасы, зур эшләр башкарасы урынга, шайтан белсен ни белән шөгыльләнәбез.

Закиров иңбашларын сикертеп куйды:

— Ә кем соң сиңа комачаулый? Тудыр, иҗат ит. Гомумән, вакыт турында сөйләшеп кенә калмыйлар, җырлыйлар да. Кайбер музыка әсәрләре вакытның тыелгысыз агышын сүзләргә караганда яхшырак тасвирлап бирә.

— Ә син конкретрак сөйләш,— диде Тренькин төмсәләнеп.

— Менә мисал өчен Массненың «Элегия»сен алыйк. Бу бит чиксез кадерле, мәңге кире кайтмас үткән вакыт турында йөрәк әрнеткеч кычкыру, кадерле үткән гомер турындагы газапларның апофеозы.

— Минемчә, музыка турында сөйләүгә караганда үзен тыңлау рәхәтрәк,— диде Тренькин. — Менә син безгә шул «Элегия»не уйнап күрсәт. Белгән кеше булып такылдарга барыбыз да булдырабыз.

Илдар Тренькинның аны уңайсыз хәлдә калдырырга тырышуын аңлады. Ул башта шундый ук тонда җавап бирергә теләгән иде, ләкин соңыннан, оятка калмас өчен, чыннан да уйнап күрсәтү хәерлерәк булыр, дигән карарга килде. Һәм шунда кулыннан тотып музыка мәктәбенә йөрткән әнисен рәхмәт хисе белән искә алды. Бүлмәдә кызыл агачтан эшләнгән, Бетховен барельефы төшерелгән, бронза шәмдәлләр куелган «Клингман» маркалы пианино тора иде.

— Кайчак бергә эшли торган иптәшеңнең киңәшенә колак салырга кирәк,— диде Илдар, елмаеп. Аннары, Фәридәгә мөрәҗәгать итеп, өстәп куйды: — Сез каршы түгелдер?

— Юк, юк, киресенчә. Үтенәбез...

«Буталмасам гына ярар иде»,— дип уйлады Илдар дулкынланып. Клавишлар буйлап бармакларын йөгертеп алды да баритон тавыш белән җырлап җибәрде. Илдар «Элегия»нең көен бөтен җаны-тәне белән тоя-сиземли иде. Ул бөтен күңелен биреп, рухланып уйнады һәм җырлады, ә уйнап бетергәч, аны мактарга тотындылар.

— Менә кайда яшеренеп ята икән талант! — диде Фәридә, аңа туры карап.

— Илдар,— диде Элеонора елмаеп,— ничек син үзеңнең шундый яхшы һөнәреңне еллар буе сабакташларыңнан яшереп йөри алдың?

— Яхшы сыйфатыңны яшерә белү — зирәклек ул,— диде Марк Егорович, хәйләкәр елмаеп: — Дошманнарда көнчелек уятмый.

Илдарны тагын уйнарга һәм җырларга мәҗбүр иттеләр. «Я встретил вас» романсын башкарганда, Илдар стенага сөялеп басып торган Элеонорага карап-карап алды. Кыз да аның бу карашын сизә иде.

Илдар янына Фәридә һәм тагын бер күзлекле кыз килеп утырдылар. Теге кыз күзлеген рәтләбрәк куйды да, биючеләргә кырын карап, әйтте:

— Борынгы Грециядә, антик эстетика үсә башлаган чорда, Еврипид: музыка яхшылыкка алып бармый гына түгел, киресенчә, кешене бозыклыкка илтә, аңарда хайвани теләкләр уята, дигән. Һәм ул хакыйкатькә якын килгән, минемчә.

Шул чак якында гына күңелсез кыяфәт белән утырган Марк Егорович җанланып китте:

— Менә ничек?! Кызык. Минем кайдадыр Платон белән Эпикурның да чат саен музыканы сүгүләре турында укыганым бар иде барын. Ләкин алар мондый ук катгый нәтиҗәгә килмәгәннәр бугай. Аңлавымча, Еврипидның фикеренә сез дә кушыласыз.

— Әлбәттә!

— Сез соң һәр төрле музыканы шулай кире кагасызмы? — диде Закиров.

— Нигә алай булсын? Классик музыканы кабул итәм. Ә менә мондыйны,— диде кыз, биючеләргә ымлап. — Амбар йозагы белән бикләргә кирәк.

Күзлекле кыз әйткән бу ахмак сүзләр, нәкъ афоризм кебек: алар икесе дә озак яшәүчән, дип уйлап алды Закиров.

— Монысы инде зәвык дигән нәрсәгә бәйле. We gustibus disputandum [1]. Кыскасы, кемгә нәрсә ошый бит,— диде ул һәм Фәридәгә мөрәҗәгать итте: — Ә сез ничек уйлыйсыз?

— Tempora mutantur [2]. Ошый икән, теләсә нинди музыканың яшәргә хакы бар, — диде Фәридә. Аның бөтен кыяфәте: «Без институтта латинчаны өйрәнмәсәк тә, аз-маз сукалыйбыз. Зинһар, борын чөймәгез»,— дия сыман иде.

«Менә син нинди икәнсең,— дип уйлады Илдар, Фәридәгә ихтирам белән карап. — Беркатлыга охшамаган бу, үзен-үзе яклый белә торганнардан». Нәкъ шул мәлне ул эшенә шалтыратырга кирәклеген исенә төшерде.

— Сездән шалтыратып алырга мөмкинме?

— Әлбәттә. Рәхим итегез. — Һәм кыз аны телефон янына алып килде.

---

[1] Зәвык турында бәхәсләшмиләр (латинча).
[2] Заманалар үзгәрә (латинча).

Трубканы Галләмов алды.

— Сез кайда югалдыгыз? — дип мыгырданды ул сәлам бирәсе урынга.— Без монда Тренькин белән сезне эзли-эзли арып беттек инде. Хәзер үк бирегә килегез.

— Иптәш майор, әллә берәр көтелмәгән нәрсә бармы? — дип сорады Закиров, башына кан йөгергәнне сизеп.

— Бар шул. Машинаны кая җибәрергә?

Закиров адресны әйтте.

— Машина хәзер чыга. Тренькинның кайда икәнен белмисезме?

— Ул да монда.

— Мена ничек? Аңа да әйт, бергәләп килегез.

Эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, Тренькин ачуыннан шартларга җитеште, Закировка әллә нәрсәләр әйтеп бетерде.

— Үзең генә бар, мин бармыйм! — диде ул, Бабанинадан күзен алмыйча. Аннары иелеп, Илдарның колагына: — Мин авыру, аңладыңмы шуны? Майорга шулай дип әйт,— дип пышылдады.

Закиров Элеонорага: «Безне бик ашыгыч чакыралар. Әгәр теләсәң, сине дә өенә илтеп куярга була»,— диде. Кыз берсүзсез ризалашты.

Элеонораның өенә кайтырга карар итүен белгәч, Эдуард та фикерен үзгәртте һәм алар белән бергә китәргә булды.

Машинага чыгып утыргач, Эля шыпыртлап:

— Пианинода уйнаганда син, миңа карап, нәрсә турында уйладың?

Илдар алгы утыргычта баручы Тренькин ишетмиме икән, дип, аңа карап алды һәм шулай ук шыпыртлап:

— Синең турыда, Эля. Мин инде күптән синең турыда уйлыйм, беренче күргәннән бирле. Тик бу турыда әйтергә генә кыймадым. Мин синсез яши алмыйм, Эля...

Кыз җитди-сагышлы күзләре белән Закировка озак карап торды, ләкин берни әйтмәде.

Элеонораны өенә кадәр илткәч, машина Халык комиссарлыгына таба ашыкты. Барышлый Тренькин Илдардан:

— Синең ул кыз белән мөнәсәбәтләрең ниндирәк, сер булмаса? — дип сорады.

— Эчкәнсең икән, буеңа сеңдер! — дип кызып китте Закиров. — Безнең арага тыгылма.

Ниһаять, машина Халык комиссарлыгының подъездына килеп туктады. Илдар белән Тренькин кергәндә майор Галләмов ниндидер кәгазьләр актарып маташа иде. Мена ул башын күтәрде, аның һәрвакыт ачулы йөзенә арыганлык билгеләре чыккан иде. «Чурбановсыз кыенга туры килә шул аңа»,— дип уйлады Закиров.

Галләмов аларга утырырга кушты.

— Бүген сәгать 18.30 да,— дип башлады ул, — бик әһәмиятле предприятиенең баш инженеры урынбасары Әхмәтов квартирындагы сейфны ачканнар. Квартирда сейф барын аның гаиләсе генә белгән булган. Конструктор кичләрен һәм төннәрен эшләгәнгә күрә, аның квартирында яшерен сейф җиһазлаган булганнар. Инде мәгълүм булганча, җинаятьчеләр нибары ун минут эчендә, ишек йозагын ватмыйча гына кереп, сейфның ачкычын табып ачканнар. Сейфта саклана торган кәгазьләр белән дошман агентурасы танышкан, дигән фикер бар. Ләкин ул турыда соңрак, тиешле экспертиза тәмамлангач, тәгаен белербез.

Галләмов, тикшерүчеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карый-карый, кәгазьдән укыган төсле сөйләп китте:

— Конструктор Әхмәтовның әнисе коридорда үле хәлендә табылган. Сугылган-бәрелгән урыннары юк. Врачлар да үлемнең сәбәбен әзеп кенә әйтергә кыенсыналар.

Майор карашын Закировка туктатты:

— Ә сезгә, өлкән лейтенант, икенче бер сюрприз. Мин әйткән вакыйгалар Древцов яшәгән өйдә үк булган, подъездлары гына икенче. Кыскасы, бу җинаять кайбер детальләре белән сез әле һаман очына чыга алмаган эшне хәтерләтә.

«Начальствоның шелтәләре бер-бер артлы сибелеп кенә тора, — дип уйлап алды Закиров. — Чыннан да Древцов эшен төгәлләргә вакыт. Бар нәрсә шул каһәр суккан Йөнтәскә килеп терәлә. Берни эшләр хәл юк,— тикшерүченең язмышы шундый инде аның».

— Менә шулай, иптәш Закиров, сез теге эштә артык озак казынасыз, шуңа күрә менә монысын да үзегезгә алыгыз. Ә хәзер, Треньҡин белән бергәләп, вакыйга булган урынга барыгыз. Безнең иптәшләр анда.

Егетләр китәргә җыендылар. Инде ишек бусагасына килеп җиткәч, Илдар майордан иртәгә өч-дүрт көнгә Святовскига барырга рөхсәт сорады. Фролов нәкъ менә шул поселокта яшеренеп ятарга тиеш, диде.

Галләмов кул гына селтәде:

— Анысы соңыннан, өлкән лейтенант, иртәгә хәл итәрбез. Әмма мин сезгә бу эштән тайчынмаска киңәш бирер идем. Заманында, әле мин тикшерүче булган чакта, безнең һәрберебезгә берьюлы унлап эш бирәләр иде. Һәм без шуларны ерып чыга идек.

— Соң мин тайчынмыйм ич...

— Я, ярар,— дип кырыс кына бүлдерде аны Галләмов. — Икегез дә хәзер үк шунда барыгыз... Хәер, бер генә минут. Әхмәтов квартирында булган хәлнең серен җинаятьчеләрнең ачкычны табу һәм сейфны ачу өчен бик аз вакыт сарыф иткән булуларыннан эзләргә кирәк, минемчә. Икенче төрле әйткәндә, бу эштә өйдәге хәлне бик яхшы белүче кеше катнашкан булырга тиеш. Сейфның ачкычы бүлмәдәге мәче башлы ябалак сыны аягының бер өлеше итеп эшләнгән булган. Баргач, үзегез күрерсез әле. Кыскасы, эшкә тотыныгыз.

## XII бүлек

— Фамилиягез, исемегез? — дип сорады Галләмов умрау сөяге марля белән бәйләнгән, таза гәүдәле, кара туткыл кешегә текәлеп. Ләкин теге кеше бу сорауның үзенә бернинди кагылышы булмагандай ята бирде.

— Сез нәрсә, чукракмы әллә? — дип сорады майор. Җинаятьче, телләр-теләмәс кенә, кырын күзе белән карап алды һәм, сүзен эченнән сыгып чыгаргандай, әйтте:

— Нәчәльник, мин авыру кеше. Бераз ял итәргә бирегез.

— Ял итәргә вакыт юк.

— Ә минем ашыгасым юк. Монда да сәндерә, тегендә дә сәндерә...

— Юк инде, гражданин... Исемегез ничек әле?..

— Бәйләнмә, нәчәльник. Исемсез кеше мин.

— Менә монысы инде бер дә юкка. Әйтергә туры килер, бүтәнчә чарагыз юк.

Җинаятьче исән кулы белән ишарә ясады, башын селекте һәм усал елмаеп куйды:

— Әйе, андагы хаза [1] тимер-бетоннан эшләнгән — беркая китәрлек түгел. — Аннары бөтен гәүдәсе белән алга талпынып куйды: — Сорауны тухты [2] алып барасың, нәчәльник: бернинди психологиясез. Турыдан ярасың. Криминалистика дәресендә сезгә башкача өйрәткәннәрдер әле. Беренче тапкыр өй баскан өчен сәндерәгә яткырыр алдыннан минем

[1] Хаза — караклар жаргонында — өй, җыелу урыны мәгънәсендә.
[2] Тухты — начар мәгънәсендә.

эшне бер начальник алып барган иде. Менә ичмасам эш! Әле төлкедәй койрыгын болгый, әле мәче булып мырлый, әле ишәктәй бакыра...

Галләмов түбәдән егылганнан соң аягы сынып һәм мие селкенеп хәзер шифаханәдә ятучы милиция оперуполномоченные Герасимовка бик нык каршылык күрсәткән бу җинаятьчене бүлдермәде. Куелган ятьмәгә нindirәк кош — гади бер каракмы яисә дошман агентымы эләккән булуын аңларга тели иде майор.

— Менә нәрсә, гражданин, сез урланган ыштан саткан өчен түгел, биредә шпион булганыгыз өчен утырасыз. Сәндерә белән рәшәткә турында сезгә уйлыйсы да юк. Ишетәсезме — уйлыйсы да юк! Сезне стена [1] көтә!

— Нинди стена ул тагын? Чегән хатыныннан бактырган өченме?! Ярый, кесәмдә наганым бар иде... куркытыр өчен генә, төзәп тормыйча гына аттым — төзәгән булсам — дөмегә иде. Минем эш ике статьяга туры килә: рөхсәтсез корал йөртү һәм, хулиганлык ясап, урамда ату.

— Юк. Сез, исемсез гражданин, үзегезгә бик җиңел тормыш сайлыйсыз. Ә чынлыкта карталар бүтәнчәрәк чыга шул: чит ил разведкасы өчен кирәкле мөһим мәгълүматларны җыярга, ягъни чегәннәр таборы янында, рация яшерелгән урын тирәсендә безнең засада бармы-юкмы икәнен белергә маташу. Бу бер. Милиция хезмәткәренә һөҗүм итү. Монысы ике. Боларның һәр икесе өчен дә җинаять кодексында җәза чарасы итеп атып үтерелү карала. Сезнеңчә әйтсәк — стена. Менә шулай.

Майор, җинаятьчедән күзен алмыйча, артсыз урындыкка барып утырды.

— Ә хәзер житди сөйләшүгә күчик. Чегәннән сорашып белгәннәреңне кемгә тапшырырга тиеш идең?

Авыру, башын мендәргә салган килеш, сүзсез ятты. Маңгаена тир бәреп чыккан иде.

— Мин арыдым, мин авыру кеше, начальник. Бүтән булдыра алмыйм.

— Син әле үгездәй таза. Түбәдән егылып төшкәч тә качып китмәкче идең.

— Сөйләүнең мәгънәсе юк, начальник. Үзең үк әйтеп торасың бит, атып үтерү каралган ике статья чәпәячәкләр, дип.

— Барысын да ачыклап сөйләп бирсәң, суд моны искә алачак. Бер үк эшнең кайчак күп яклы төсмере була. Ә менә бу — нәкъ шул очрак. Үзең уйлап кара: сине йомышчы итеп кенә тоталармы, әллә син үзең шпионмы. Күрәсең, барын да аңлатып бирү үзең өчен файдалы.

— Менә син кая борасың. Син миңа шпионлык чәпәмә, начальник. Үзең күреп торасың — блатной [2] мин

— Тәнеңә кадап ясалган сурәтләр, караклар жаргоны,— безнең өчен болар түгел, синең эшләгән эшләрең мөһим, без шулардан чыгып хөкем йөртәбез. Син моны үзең дә яхшы беләсең.

Галләмов папкасыннан бер бит кәгазь чыгарды.

— Үзең язасыңмы, әллә ярдәм итиммे? — диде ул, инде хәл ителгән нәрсә турында сөйләгәндәй, тыныч тавыш белән.

— Үзегез языгыз,— диде җинаятьче, «сез»гә күчеп.

Майор тумбочка янынарак килеп утырды.

— Горошкин Василий Сафонович, кушаматым Чалышаяк. Моннан ике ай элек, жиде еллык срокны тутырып, кояшлы Колымадан кайттым. Без жиде ел элек монда бер кибетне талаган идек. Идел буе район суды хөкем итте...

— Кем белән баскан идегез?

---

[1] Стена янына бастырып ату мәгънәсендә.
[2] Карак мәгънәсендә.

— Мин шухерда[1] гына тордым. Бүтәннәр хәл кылды.
— Я, шуннан, Горошкин?
— Колымада Үгез белән таныштым. Ул да бу яклардан.
— Аның фамилиясе? — дип сорады майор, сагая төшеп.
— Ивеев Бугуруслан. Ямаш урамында, егерме өченче йортта тора иде.
— Шуннан...— майор, җинаятьченең йөзе ап-ак булуны күреп, аны ашыктыра башлады.
— Аның аркылы Чмо белән таныштым. Ә ул миңа бер багана[2] бирде дә велик[3] табарга кушты. Светловолжскиның барыгасында[4] таптым. Кемнән алганымны әйтә алмыйм. Вак балыкка охшаган иде.
— Кайчан булды бу хәл?
— Май азагындамы әллә июнь башындамы — әйтә алмыйм, начальник.
— Шуннан, шуннан, Горошкин?
— Великны Чмога бирдем.
— Кем ул Чмо? Адресы?
— Белмим, миңа әйтмәде. Кайда яшәгәнемне белгәнгә, Чмо үзе мине таба иде. Моннан ике көн элек менә бу эшне кушты. Биш багана бәрабәренә. Өчесен алдан биреп куйды. Икесен соңрак, йомышны үтәгәч, диде. Ләкин, биллаһи дип әйтәм, мин аларга моның нәрсә өчен кирәклеген белмәдем. Рация турында ул миңа бер сүз дә әйтмәде. «Чегән хатыннарыннан сорашып бел, аларның таборы тирәсендә энкеведе кешеләре юк микән, булса кайчан килгәннәр?» — дип кенә әйтте. Чмо ул хатыннар белән ничек сөйләшергә икәнен дә өйрәтте. Чегән хатыны белән сөйләшкәндә мин ул әйткән сорауларны гына кабатладым...

Горошкин, майор аңа ышана микән, дип чиктән тыш киеренке көраш белән аның йөзенә текәлде. Моңа ул артык күп көч сарыф итте булса кирәк,— җинаятьче шабыр тиргә батты, сулышы ешайды. Ул күзен йомды.

Галләмов аңа бераз көч өстәп җибәрергә булды:
— Я, ярый, сез рация турында һәм бу мәгълүматларның нигә кирәк булуы турында белмәдегез, ди. — Майор тегеңә кружка белән су бирде. Горошкин кабалана-кабалана эчте. Хәзер Галләмов каршында тәмам җебеп төшкән кызганыч бер кеше утыра иде. Җинаятьченең дөресен сөйләп бирергә булганлыгы, моның бердәнбер котылу юлы икәнен аңлаганлыгы күренеп тора иде. Аның бу халәтен майор да сизде.
— Алган мәгълүматларыгызны сез кайда һәм кемгә тапшырырга тиеш идегез?
— Елга портына барырга тиеш идем. Анда икенче пристань янында 19.00 белән 19.30 арасында минем янга Чмо киләчәк иде.
— Аның белән ничәнче числода күрешергә сүз куешкан идегез?
— Шул ук көнне, өченче көн,— диде Горошкин ашыгып.— Ул бүтән вакыт билгеләмәде.
— Алайса, нигә соң сез пристаньга баручы трамвай тукталышына таба китмәдегез?
— Миңа Чмо, шунда бер очтан Серов урамындагы кибеткә кереп, кырык өченче размерлы галош алырга да кушкан иде.
— Нәрсә өчен?
— Белмим, начальник. Моны Чмо миңа әйтмәде.— Һәм Горошкин кибеткә нинди юллар белән барырга тиеш булуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

---

[1] Шухерда тору — сакта тору.
[2] Багана — мең сум акча.
[3] Велик — велосипед.
[4] Барыга — базар.

«Шул ишегалларының берсендә Горошкинны кемдер көтеп торган, күрәсең,— дип уйлады майор. — Юкса, шундый катлаулы маршрут билгеләүнең ни хаҗәте булган?»

Горошкин җим ролен генә үтәгән булырга тиеш: әгәр ул кибеткә янсә пристаньга бару юлында юкка чыкса,— димәк, җимне каптырдылар, димәк, засада турындагы хәбәр читкә китмәсен өчен табор халкын күзәтү астында тоталар.

Галләмов, бу уйларыннан аерылып:

— Горошкин, сез наганны кайдан алдыгыз? — дип сорады.

— Бу эшкә китәр алдыннан Чмо бирде.

— Аның әшнәләреннән кемне беләсез?

— Беркемне дә белмим. Ул үзе турында берни сөйләми иде.

— Ә Үгез аны кайдан белгән?

— Бу кадәресен дә белмим. Бездә артык сораулар бирү гадәте юк. «Чмо — танылган карак, ул бик хәйләкәр һәм бик куркыныч. Бер-бер хәл булдымы — янтавыңа кыпты, җеназа укымый да калырлар»,— диде миңа Үгез.

— Ә сез аңардан курка идегезме?

— Мин теләсә кайсы шпананы дөмектерәм. Ике бармагым белән көмеш тәңкәне бөгә алам. Кирәк булса, аның танавын ертырга да күп сорамам.

— Ләкин эш көчтә генә түгел, Горошкин. Ничек кенә булмасын, ул сине шухерда тоткан һәм һәлакәтле статья астына үзе урынына сине китереп тыккан.

— Иреккә чыккач, мин аңа ул бурычны кайтарам әле. Миннән калмас.

— Аңа кадәр ерак әле, син көтеп торма — хәзер үк кайтар.

— Ә син өйрәт, начальник, ничек кайтарыйм?

— Үгез кая китте? — Сорауга сорау белән җавап бирде Галләмов.

— Чмо миңа, аны майда ук сезнекеләр дөмектерде, диде. Мин үзем аны егермеләрендә күргән идем. Үгез белән Чмо икәүләп Ключищидагы бер кибетне басканнар иде бугай. Аннары алар Ивановский тыкрыгындагы бер малинага [1] килеп йөргәннәр. Миңа бу турыда Үгез ычкындырды. Мине дә алып барырга вәгъдә иткән иде.

— Ул Ивеев тагын кайларда була иде соң?

— Вахитов урамында бер хазасы бар иде бугай. Анда Наталка-хваталка дигән бер хатын янында еш кунгалый, имеш. Бөкре май башларында мәтәлгәнче үк, бу турыда мин аңардан ишеткән идем. Теге мәткә Бөкрене дә сыендыра торган булган. Фартовый хатын диләр үзен, әмма бик хәтәр комсыз: бүлмәсен һәм үзен коточкыч кыйммәткә сата икән. Ә минем андый җиргә барырлык чама юк: сукыр бер тиен сәмәнсез [2] утырам, кесә тишек. Кемгә дә булса өлешкә керергә теләмәдем. Эшкә урнашырга иде исәп.

Майор «коточкыч кыйммәткә» дигән сүзләрне тегенең нинди ачу белән әйтүенә каршы үзалдына көлемсерәп куйды.

— Мескен караклар һәм талаучылар, мескен җинаятьчеләр! Аларның үзләрен талаучы кешеләр дә табыла икән дөньяда! — диде Галләмов. — Начар кешеләр алар, шулай бит, Горошкин?

Тегесе дәшмәде.

— Эх, Горошкин, Горошкин, аңлыйсыңмы син шуны: син һәм синең ишеләр кешеләргә тыныч яшәргә һәм эшләргә комачаулыйлар бит! Менә син күз алдыңа китер: әйтик, синең әнисең, сеңелең янсә энең намуслы хезмәт белән күпмедер акча тапты, ди, шуннан чыгып,

---

[1] Малина — караклар җыела торган урын.

[2] Сәмән — акча.

үзләренә ниндидер план кордылар, ди. Һәм кинәт кайдандыр ниндидер бер мөртәте килеп чыга да, аларның бу хәләл акчаларын тартып ала, үзләрен кыйный, ә кайчакта үтерә дә. Без, Горошкин, мондый гаделсезлек белән килешеп тора алмыйбыз. Әтиләребез һәм абыйларыбыз егерме ел элек революцияне моның өчен дип ясамадылар.

Галләмов урыныннан торды һәм гасабиланып камера буйлап йөренә башлады. Бераз тынычлангач кына утырды һәм сорау алуын дәвам итте.

Горошкин, Йөнтәснең һаман шул элекке стиль белән, ялгызы гына «эшләвен» ишеткән булса да, аның кайда икәнен белми иде. Аның каравы ул Дюдя турында кайбер нәрсәләр сөйләде.

— Дюдя, производство теле белән әйткәндә, — күп станокта эшләүче. Үзе гаҗәп оста фармагончы: кешене күз дә йоммый алдый бит. Уртакул йорт басучы, юеш эштә[1] йөрүчеләр белән дә дус. Бер тапкыр мин аны Бөкре белән дә күргәнем бар. Алар дуслар. Бөкренең әйтүенчә, Дюдяның кыз-хатынга хиресе бик зур. Шәһәрнең малиналарында аны теләп кабул итәләр. Акча туздырырга бик оста — ә кыз-хатынга бу нәрсә ошый.

— Ә ул Чмоны беләме?

— Бу турыда берни әйтә алмыйм, нәчальник. Белгән булырга тиеш. Чыннан да белгән: Чмо да бит Иран шаһы сараенда хәрәм агасы түгел. Ул да мәткәләр тирәсендә фыртланырга бик ярата. Хәзер генә исемә төште: бервакыт Үгез мине кабакка чакырды. Менә шунда сөйләгән иде.

— Минем белән Чмо да бара, дидеме?

— Шулай бугай.

— Ә син нигә бармадың?

— Әйттем бит инде, нәчальник: сәмән юк чак иде. Ә мин кеше хисабына эчәргә яратмыйм. Аннары шунысы да бар: бәйдәге көчектәй юеш эшкә өстерәүләреннән курыктым. Менә шулай, нәчальник, алардан башка гына йөрим.

— Син инде кеше үтергәнем юк, димәкче буласың?

— Нәчальник, мин сине алдамыйм. Юеш эшкә барганым юк. Әнием белән ант итәм. Бер генә фрайер да моны әйтмәс.

Соңрак Горошкин әйткәннәрнең күбесе расланачак. Чемизов велосипедын нәкъ менә Чалышаякка саткан булуын әйтер. Җинаятьче үзе дә аның сүзен раслар. Шулай итеп, радист файдаланган велосипед белән булган вакыйга өлешчә ачыкланыр.

Сорау алу вакытында шул ук Чалышаяк биргән мәгълүматлар буенча каты режимлы колониядә утырган Бөкрене дә эзләп таптылар. Ул Ивановский тыкрыгында һәм Ярославский урамындагы җыелып эчү урыннарының адресын, шулай ук квартирында җыен карак-угры җыела торган Наталка-хваталканың тору урынын әйтеп бирде. Бөкренең сүзенә караганда, Дюдя кушаматлы Ленарис Абдулловны Чмо үзе эшкә катнаштыра торган булган. Ул биргән мәгълүматлардан шул ачыклары: Дюдяның даими яши торган урыны юк, ул җил-үлән төсле, теләсә кайда кунып-түнеп йөри, төрле хатыннар белән тора, ешрак Наталка-хваталка тирәсендә бөтерелә, имеш. Ә менә Йөнтәс турында ул берни дә белми булып чыкты.

Оперативниклар типтерү урыннарын һәм Наталка-хваталка — Наталья Хватова квартирын күзәтү астына алдылар. Милициянең район бүлегендә Ивановский тыкрыгындагы караклар оясының моннан ике атна элек туздырылган булуы беленде. Ләкин өйнең хуҗабикәсен генә кулга алганнар булып чыкты.

---

[1] Җинаятьчеләр жаргонында «юеш эш» — кеше үтерү.

Ике атна буе күзәтү алып бару нәтиҗә бирмәде. Чмо да, Дюдя да күренмәделәр. Икенче атнаның азагында Ярославский урамыннан, участок милиционерыннан шундый хәбәр алынды: урамның иң аргы башындагы агач баракта районнардан килгән күп кенә туристлар урнаша икән. Бу баракның аерым керү юлы булган берничә бүлмәсен шушы тирәдәге бер предприятие читтән килгән кешеләр өчен гостиница итеп файдалана, әмма еш кына ул бүлмәләр буш була икән. Ул көнне дежур торган лейтенант Зарипов килгән кешеләрне тикшереп карарга булган. Баракның тәрәзә капкачларындагы ярыклары аша яктылык урамда җыелып торган яңгыр суына төшә. Эчтә ни барын аерырлык түгел, ниндидер шау-шулар гына ишетелә. Килүчеләр өчен билгеләнгән бүлмәләргә коридор аша үтеп булмый — ишек эчтән бикле. Лейтенант икенче подъезд аша коммуналь квартирның коридорына керә һәм агач баскычтан баракның чормасына менә. Электр фонарен кабыза, саклык белән генә тулай торакның коридорына төшә торган люк янына килә. Ләкин люк металл эшермә белән бикләнгән булып чыга. Бикнең эшермәсен гади пәке белән дә күчерергә мөмкин, дип уйлый Зарипов. Лейтенант ярыкка колагын куеп тыңлап карый. Уң яктан исерек ирләр һәм хатын-кызлар тавышы, ә якындагы бүлмәдән кемдер җыр суза. Күп эчүдән карлыккан тавыш:

— Ох, кыен да соң бу дөньяда нагансыз... — дип акырып җырлап җибәрә. Аста, нәкъ люк турысында, ике бәндә якага-яка килгәннәр дә иң азгын җинаятьчеләрнең жаргон сүзләрен оятсыз сүгенү белән аралаштырып, үзара мөнәсәбәтләрен ачыклап маташалар. Ул арада, бер хатын-кыз чыгып, аларны аермакчы була. Шул мәлне бик тә ачулы тавыш:

— Ша, падлалар! Нәрсә әтәчләнәсез, фрайерлар! Үз кодлаңдагы дусларыңны түгел, җыен чүп-чарны бугазларга кирәк! — дип акыра.

«Шәһәрнең культура памятниклары белән танышу өчен колхозлардан килгән кешеләргә охшамаганнар болар,— дип уйлый Зарипов. — Кичекмәстән оператив группа чакыртырга кирәк».

Ярты сәгатьтән баракны камап алдылар. Фонарьлар янмый, һәм милиция, дәүләт куркынычсызлыгы хезмәткәрләренең сыннары төн карангылыгында эреп югала иде. Группа белән майор Галләмов үзе житәкчелек итте.

Коридорга чарлактагы люк аша үтеп керделәр, тышкы ишекне ачтылар, һәм берничә сотрудник бүлмәләр янына ашыкты. Ишеге ярым ачылган почмак бүлмәдә карлыккан нәзек тавышлы берәүнең гитарага кушылып җырлаганы ишетелә иде. Шул чак тузган чәчле берәү ишектән башын тыгып карады һәм, суярга дип тотылган дуңгыз баласыдай чинап:

— Легавыйлар, легавыйлар [1], җәмәгать! Качыгыз! — дип кычкырды.

Шунда ук коридор һәм бүлмәләр кая барып бәрелергә белмәгән кешеләрнең аяк тавышлары һәм кычкыруларыннан гөр килеп башлады. Кинәт бар бүлмәләрдә дә ут сүнде, ату тавышлары ишетелде. Кайдадыр гөрселдәп шкаф ауды, тәрәзә пыялалары ватылды. Почмак бүлмәгә якын килерлек тә түгел иде: аннан бертуктаусыз атып тордылар. Наган тавышлары урамда да ишетелде.

Төнге караңгылыктан файдаланып берәү дә кача алмасын өчен, бирегә машиналар китерергә һәм барак тирәләрен фара белән яктыртырга карар ителгән иде. Бандитлар тәрәзәдән сикерешеп чыга башлагач, фараларны чыннан да кабыздылар.

— Тукта! — дип кычкырды Галләмов.— Коралларыгызны ташлагыз! Юкса атабыз!

[1] Легавый — җинаятьчеләр милиционерларны шулай атыйлар.

Бандитлар башта кинәт кабынган уттан каушап калдылар, ләкин шунда ук, караңгыга качучы тараканнар төсле, төрлесе төрле якка сибелделәр. Ике бандит атыш вакытында үтерелде. Өчесен тоттылар. Алар арасында Дюдя да бар иде. Ләкин Чмо да, Йөнтәс тә күренмәде.

Дюдядан (Ленарис Абдулловтан) шунда ук сорау алдылар. Сорау алу иртәнге дүрткә кадәр дәвам итте. Дюдяның күрсәтүенә караганда, Чмо (фамилиясен белми) май башларында мехлар белән сату итә торган комиссия кибетен басуны оештыра һәм бу эшкә аны да ала. Май ахырында шул ук Чмо аңа Древцов квартирын басканнан соң төпкә яткан[1] Йөнтәсне эзләп табарга куша. Абдуллов Йөнтәснең соңгы эш урынын ничек табуын аерата горурланып сөйләде. Дөрес, Чмо аңа башта ук Йөнтәсне эзләүнең юлларын өйрәткән була. Аның әйтүенчә, Фролов торак конторасыннан ул килгәнче үк китәргә өлгергән. Абдуллов чекистларның, Йөнтәсне эзләүдә Чмо үзе дә катнашкан булырга тиеш, дигән фикерләрен раслады. Аерым алганда, Чмо телефон үзәгендә, металл әйберләр мастерскоенда булган һәм, һәр очракта, Йөнтәснең нәкъ үзе булып киенгән, битенә, аныкына охшатып, сакал һәм мыек ябыштырган. Шулай итеп, Чмо оперативникларны ялгыш юлдан җибәрергә теләгән. Ул Абдулловка Йөнтәснең йозаклар буенча зур белгеч булуын һәм бик четерекле бер эш өчен кирәк икәнлеген әйткән. Ләкин бу эшнең нәрсәдән гыйбарәт булачагын ачыклап тормаган. Йөнтәсне эзләгәне өчен Чмо аңа җиде мең сум акча биргән һәм, әгәр таба алса, тагын бирергә вәгъдә иткән. Шуннан соң Абдуллов милиция работнигы исеме астында торак конторасында булган, анда эшләп киткән бер ханым белән сөйләшкән һәм аңардан Йөнтәснең йөргән хатыны турында сорашып белгән. Ул бу турыда Чмога әйткән, һәм шуннан соң Чмо суга төшкәндәй юк булган. Шул чак Абдуллов Чмоның әлеге хатын аша Йөнтәсне тапкан булуын аңлаган.

Сорау алу вакытында шунда утырган Закиров Фроловны эзләгәндә бер хата җибәрүен: торак конторасында эшләп киткән кешеләр белән сөйләшмәвен аңлады. Галләмовның күз карашы да аңа, гүя: «Җинаятьче сезгә караганда зирәгрәк булып чыккан»,— дип әйтә сыман тоелды.

Комиссия кибетен басканнан соң, Чмо аю кебек бер елга йокыга талырга исәпләде, диде Абдуллов, әмма аның ни өчен мондый карарга килгәнлеген әйтә алмады. Аның сүзенә караганда, Чмо ифрат сак эш йөртә башлаган: очрашуларны бик сирәк билгели, үзе һич көтмәгәндә килеп чыга, ә кайчак телефоннан гына шалтырата икән. Шуңа күрә Абдуллов аның кайда яшәгәнлеген белми иде.

— Әйтегез әле, Абдуллов, Древцовның квартирын басу — Йөнтәс эше икәнлекне Чмо белдеме? — дип сорады Галләмов.

— Моны белү читен эш түгел. Йөнтәс бары тик өй басу белән генә шөгыльләнә һәм гел берьялгызы гына эшли. Әгәр кайдадыр әйбәт кенә бер фатирны бассалар һәм ул турыда безнең агай-эне берни белмәсә, димәк бу Йөнтәс эше. Тагын шунысы да бар: ул бер вакытта да йозакны ватмый.

— Йөнтәснең кеше үтерүе мөмкинме?

— Юк. Тик берәрсе аны тоткарларга теләгәндә генә. Төрмәне бер дә яратмый ул.

Галләмов көлемсерәде:

— Ә кем ярата соң аны? Бәлки сездер?

— Шулай да бүтәннәр аңа ничектер тынычрак карыйлар. Минем үземнең артык исем китми: аңа яраклашырга өйрәндем инде. Анда ичмасам бернәрсә турында да уйламыйсың.

[1] Төпкә яту — качып яту.

Абдуллов Фроловның йөргән хатыны — Зеленодольская урамындагы азык-төлек кибетендә эшләүче Косовская турында да сөйләде.

— Димәк, сез, Абдуллов, Йөнтәсне күреп белмисез? — дип сорады Галләмов, тегеңә игътибар белән карап. — Алайса, бәлки аның туганнарын беләсездер?

— Минем аны, гражданин начальник, берничә тапкыр күргәнем бар: төксе чырайлы, кыяфәтсез генә, попка тартым, тик рясасы гына юк. Ә менә аның сеңелесен чәчәктәй чибәр нәрсә диләр. Бәлки шуңа күрәдер, исемен дә Роза кушканнар.

Галләмов шунда ук ниндидер Роза турында сүз барган шифровканы исенә төшерде. Аның башыннан: «Бәлки Фроловны шул сеңелесе аркасында эзләгәннәрдер?» — дигән уй йөгереп үтте. Һәм майор, бөтен барлыгын биләп алган дулкынлануны яшерергә тырышып, тыныч тавыш белән икенче сорауны бирде:

— Ул аның бертуган сеңлесеме?

— Әйе.

— Кияүгә чыкканмы?

— Нәрсә, начальник, әллә сыланырга исәпме?

Галләмов, тегенең сүзләрен ишетмәгәндәй, тыныч кына кабат сорады:

— Кияүдәме, юкмы?

— Кияүдә бугай.

— Каян беләсез?

Абдуллов тагын шуларны сөйләде. Көннәрдән бер көнне, моннан ике еллап элек, Йөнтәс, янәсе, Наталка-хваталка янына лаякыл исереп килә. Моны ишеткәч Абдуллов гаҗәпләнә, чөнки Фролов аракыны авызына да алмый торган кеше. Менә шул чак Йөнтәс, имеш, әйтеп сала: туйда бертуган сеңелемне сатып эчтем, ди.

Абдуллов Фроловның сеңелесе турында аңа кем сөйләгәнен тәгаен генә хәтерли алмады. Чмо булырга тиеш, дип кенә әйтте, чөнки Чмо белән Фроловның кайчандыр уртак эшләре булган, ләкин соңрак араларыннан кара мәче үткән, диләр.

Абдулловтан бүтән бернинди файдалы нәрсә дә ишетеп булмады.

Сәгать тугызда кибет ачылуга Зеленодольская урамына Галләмов белән участок милиционеры килеп төштеләр. Ләкин сатучы Косовская эшендә юк иде. Ялга китте, диделәр, ләкин кая киткәнен тәгаен белүче табылмады. Наталья Хватова да сорау алу вакытында Абдуллов сөйләгәннәрдән гайре берни дә әйтә алмады.

«Хәзер инде һич шикләнүсез әйтергә мөмкин,— дип уйлады Галләмов: — Чмо чит ил разведкасы кушуы буенча эш итә. Аны никадәр тизрәк кулга алсак, радистны табуны да шулкадәр тизләтәчәкбез. Димәк, алар Фроловны тапканнар, һәм ул да хәзер алар кушканны эшли. Шулай да безнең өчен кем әһәмиятлерәк? Фроловтыр, мөгаен. Алай булмаса, җинаятьчеләр шул тикле тырышып аны эзләмәсләр иде. Өстәвенә хәзер, сеңелесе барлыгы беленгәч, безнең өчен аны табуның әһәмияте аеруча арта. Ниндидер төп объектка агентлар нәкъ әнә шул Роза аша чыгарга уйламыйлармы? Бик ихтимал. Моны Фролов үзе генә әйтеп бирә ала. Шулай итеп, Фролов-Йөнтәс күп нәрсәгә безнең күзне ача алачак. Мөгаен, монда бик кирәк булса да, Закировның үтенечен канәгатьләндерергә һәм Святовск поселогына җибәрергә кирәк. Җинаятьченең шунда яшеренеп ятуы бик ихтимал»

Галләмов шәһәрнең барлык предприятиеләрендә Роза исемле яшь хатынны эзләү турында тиешле күрсәтмәләр бирде.

## XIII бүлек

Конструктор Әхмәтовның квартиры — икенче катта. Куе булып үскән тупыл ябалдашлары яшел стена хасыйл иткәннәр дә тәрәзәләрне машиналар йөри торган юлдан һәм киң урамның каршы ягындагы биш катлы биналардан аерып торалар. Закиров, тәрәзә янына баскан килеш, яфраклар аша урамда ниләр барын күрергә тырышты. Үз-үзенә һаман бер үк сорауны бирде: «Ничек итеп җинаятьчеләр тәрәзә аша сейфны күрә алганнар соң? Куе яфрак бар нәрсәне каплаган бит».

Җинаятьчеләр урамнан торып күзәтү алып барганнар, дигән уй Әхмәтовлар квартирын караганнан бирле аңа тынгылык бирми иде. Чыннан да сейф турында өйдәгеләрдән башка бер генә чит кеше дә белмәгән. Сейфны куючылар — барысы да ышанычлы кешеләр. Гаилә әгъзаларыннан берәрсе әйткәнме әллә? Әхмәтов сүзләренә караганда, аның энисе беркая да чыгып йөрми торган күрше карчык белән генә аралаша торган булган. Өстәвенә, ул күп сөйләшүчән кеше дә түгел. Хатыны Нина Васильевнага килгәндә, хезмәт урынында аның үзенә яшерен информация белән эш итәргә туры килә, шуңа күрә ул тел яшерә белә. Ә өч яшьлек Альберт бөтенләй исәпкә керми. Әхмәтовның чит кеше барында беркайчан да сейфны ачканы булмаган.

Сейф — тәрәзәгә каршы. Аның нәкъ стенадагы төсле обой ябыштырылган ишеге берни белән дә аерылып тормый. Өстәвенә аны зур рамлы рәсем каплап тора. Ә инде сейфның ачкычын табу — чит кешенең кулыннан һич килмәстәй эш.

Закиров тыныч иде. Менә шул эчке тынычлык аңарда серне ача алачагына ышаныч уята иде. Хәлбуки, ул хәзергә тынычланыр өчен бернинди нигез юклыгын да аңлый. Дөрестән дә, бүгенгәчә әле ачылмаган Древцов эшенә бик охшамаган авыр җинаять эшләнгән. Димәк, бу эшнең дә һавада асылынып калуы ихтимал. Җинаятьләр чыннан да охшаш: квартирларның һәр икесенә, хуҗалар өйдә юк чакта, йозакны ватмыйча гына кергәннәр. Кичке алтыларда Әхмәтовның энисе, күрше карчыгы белән бергәләп, бакчадан оныгын алырга киткән. Юлда кибеткә кергәннәр. Ләкин Әхмәтова акча алырга оныткан булган. Ул ашыгып квартирына кайткан (кибет шул ук бинаның беренче катында) һәм анда чит кешеләр барын күрүгә, йөрәген тотып егылган. Һәрхәлдә, мәетне ярганнан соң врачлар йөрәге ярылган дигән нәтиҗәгә килгәннәр.

Әхмәтова көтеп-көтеп тә килмәгәч, күрше карчыгы да кире кайткан. Квартирның ишеге ачык булган. Алгы бүлмәдә ул хәрәкәтсез яткан Әхмәтованы күреп алган. Идәндә зур-зур аяк киеме эзләрен дә искәртә ул (подъездда ремонт бара икән). Карчык ашыгыч ярдәм станциясенә һәм милициягә шалтыраткан.

Башта бу вакыйганы квартир басарга маташу дип санылар. Ләкин Әхмәтов үзе кайтып, сейфны тикшергәч һәм андагы кәгазьләрнең кузгатылган булуын күргәч, эш бөтенләй икенче юнәлеш ала. Җинаять урынына чекистларны чакыралар.

Алгы бүлмәдәге аяк киеме эзен үлчәп карадылар. Ул кырык өченче размерлы булып чыкты. «Бик сәер туры килү бу,— дип уйга калды Закиров. — Чмо да Горошкинга шундый ук үлчәүдәге галошлар алырга кушкан бит. Бәлки шушы эш өчендер? Ләкин биредә нәкъ менә шул җинаятьче булганлыкны раслый торган дәлилләр кайда соң?» Алар хәзергә юк иде...

Криминалистлар квартир хуҗасының өйдә кия торган тапочкаларының эче известькә буялган булуга игътибар иттеләр: әйтерсең, кемдер аларны аяк киемен салмыйча гына кигән. Бу шулай булып чыкты да: аларны идәндә эз калмасын өчен шулай кигәннәр. Тапочкаларны

дактилоскопия[1] күзлегеннән чыгып та тикшерделәр һәм аларда квартир хуҗасының бармак эзләреннән башка... Валерий Фроловның имән бармагы эзен дә таптылар. Тикшерүчеләр өчен көтелмәгән зур уңыш иде бу. Закиров, җинаятьчеләр Фроловны конструктор Әхмәтовның квартирына керү һәм аның сейфын ачу өчен эзләгән булганнар, дигән нәтиҗәгә килде. Ләкин бу бит әле, алар ачкычтан файдаланганнар, дигән сүз түгел иде.

Илдар Әхмәтов янына килде:

— Вагыйз Әхмәрович, сез кайтканда сейф ачкычы кайда иде?

— Ничек кайда? Мәче башлы ябалак тәпие эчендә,— диде ул башын күтәреп.

Закиров шкаф янына килде һәм ябалак сынын тикшерергә тотынды. Очып китәргә җыенгандай, канатларын җәйгән ябалак сыны саргылт-яшел зур күзләре белән аңа карап тора иде. Тәпиләре бер-берсеннән һич тә аерылып тормый. «Ачкычның монда икәнен алдан белмәсәң, һич башыңа киләчәк түгел,— дип уйлады ул. Моны чит ил агентурасы да белмәгән булса кирәк. Аларның Йөнтәсне бик тырышып эзләүләре шуның аркасында булмады микән?»

Илдар Әхмәтовка карап алды. Ул, битен учлары белән каплап, диванда утыра, иңбашлары калтырый. «Әнисен кызгана,— дип уйлады Закиров. — Беләсе иде, исән чагында да шулай кызгана иде микән ул аны?» Ул Геннадий Севчукны күмгән вакытны исенә төшерде. Мәрхүмнең хатыны, кычкырып елый-елый, аның каберенә бер кочак чәчәк китереп салды. Бу ханымның иренә исән чактагы мөнәсәбәтен белгән Рәфкать Измайлов әйткән иде шунда: «Кешене үлгәч түгел, исән чагында ихтирам итәргә кирәк»,— дигән иде.

Закиров карашын Әхмәтовтан тәрәзәгә күчерде. «Тукта әле,— диде ул үз-үзенә,— сейфның ачкычы йокы бүлмәсендә, ә сейф үзе — кабинетта. Димәк, җинаятьчеләр кабинет тәрәзәсеннән күзәтү алып барганнар, дип фараз итсәк, табигый ки, ачкычның кайда яшерелүен алар белмәскә тиешләр иде. Ишегалды ягыннан күзәтү алып барырга мөмкин, дип саныйк. Әгәр бередә бу квартирга килеп йөри торган кеше булган, дип уйласак, ул кеше сейф турында гына түгел, аның ачкычын кайда яшерүләре турында да белергә тиеш. Ләкин моны белгән кешегә йозаклар буенча белгечнең кирәге юк. Алайса, Йөнтәс нигә кирәк булган? Квартир ишеген теләсә кайсы йорт карагы да ача алган булыр иде. Шулай килеп чыга: бередә квартирны тышкы яктан күзәтеп торган чит кеше эш иткән».

Закиров конструктор кабинетына әйләнеп керде һәм карашы белән тәрәзәнең тышкы ягындагы куе яфракларга текәлде. Агачка менеп күзәтмәгән ләбаса инде алар?! Андый кешене шунда ук күргән булырлар иде. Өстәвенә аста кибет, халык йөреп тора. «Тукта әле, тукта! — диде ул эченнән. — Алар бит бу өйне бер-ике көн генә түгел, атналар, айлар буе күзәткәннәрдер? Чыннан да шулай? Алар күзәтүне бу агачларда әле яфраклар юк чакта ук башлаганнар! Ничек соң бу фикер башына элегрәк килмәде?»

Хәзер июль башы. Димәк, Әхмәтовны һәм аның квартирын апрель-май айларында күзәтә башлаганнар. «Ә кайдан торып күзәткәннәр? — дип сорады ул үз-үзеннән. — Урамның теге ягыннанмы? Ләкин аннан караганда, квартирда нәрсә барлыгын чамалап булмый бит. Өстәвенә тәрәзә тюль белән капланган. Димәк, барыбер агачка менәргә кирәк? Ләкин бу мөмкин түгел! Алайса, ничек соң?»

Һәм яңа бер уй аның аңын яктыртып җибәргәндәй булды: «Бинокльдән файдаланганнар! Әлбәттә шулай! Янсә труба! Ә андый приборларны кеше күзе алдында кулланып булмаганлыктан, алар күзәтүне каршыдагы өйнең тәрәзәсеннән янсә чормасыннан алып барганнар».

[1] Дактилоскопия — бармак эзенә карап кешене табу.

Ул, стенага таба чигенеп, сейф янына ук килеп басты да, каршыдагы бинадан торып нәрсә күреп булуын чамаларга теләде, ләкин һаман шул агачлар комачаулый иде. Шул чак бүлмәгә Тренькин килеп керде һәм, Закировка гаҗәпсенеп карап:

— Син нәрсә унлыкка тидерергә теләгән укчы кебек бастың? — диде.

— Син дөрес әйттең, Эдик: мин нәкъ менә унлыкка тидерергә телим. Тик менә мишеньны күрергә агачлар комачаулый.

— Ә-ә,— диде Тренькин. — Андый фикер минем башка да килгән иде. Ләкин ул, нәкъ борчак төсле, әнә теге яшел стенага килеп бәрелә дә кире сикерә,— һәм ул каршыдагы агачларга ымлады.

— Шулай булгач, комачауламасыннар өчен, ул агачларның ябалдашын кыркырга кирәк.

— Әллә син шпионнар да шулай эшләгән дип уйлыйсыңмы? — дип көлемсерәде Тренькин.

— Аларга болай эшләп торуның кирәге булмаган.

— Аңламадым.

— Кем белә, бәлки алар күзәтүне кышын яисә язын алып барганнардыр.

— Тукта әле, әйбәт фикер бит бу! — диде Тренькин. — Әлбәттә, алар озак хәзерләнгәннәр. Шулай булгач, аларның бу квартирга күп тапкырлар кергән булулары да ихтимал. Яисә тагын бер тапкыр керергә чамалаганнар. Юкса аларга, сейфны кире бикләп, вакыт әрәм итеп тору ниемә кирәк булыр иде.

Тренькинның бу фикере Закиров өчен көтелмәгәнрәк булды.

— Син, мөгаен, хаклысыңдыр, Эдик. Моны тикшерергә кирәк. Бу эшкә син үзең тотын,— диде ул уйчанланып.

Закиров үтенече буенча Эчке эшләр халык комиссарлыгының район бүлегеннән торак конторасына шалтыраттылар, һәм тиздән өй каршында агачларның очлары киселде.

Чама белән билгеләп, каршыдагы өйнең икенче катыннан башлап дүртенчесенә кадәр урнашкан кырый тәрәзәләрдән, оптик приборлар ярдәмендә, сейфны күреп була, дигән фикергә килделәр. Закиров майор Галләмовка шалтыратты, аңа үзенең фикерләрен әйтте һәм хезмәткәрләренең берәрсенә әлеге тәрәзәгә караган квартирларны тикшереп чыгарга кушуын үтенде. Майор бер кавым сүзсез торды, аннары, хәзергә буш кешеләр юк, диде. Шуңа күрә бу эшне лейтенант Тренькинга кушачагын әйтте. Майорның тавышыннан ук Илдар шуны аңлады: квартирны каршыдагы өйдән торып күзәткәннәр, дигән фикер белән ул килешеп бетми иде бугай.

Әхмәтовның сызымнарын тикшерү шуны күрсәтте: берничәсенең почмагында гади күз белән күреп булмый торган язу карасы таплары калган. Экспертлар, бу сызымнарның почмагына кара савыты куйганнар, дигән нәтиҗәгә килделәр. Әхмәтов шулай аңлатты: аның эш өстәлендә чыннан да язу карасы тутырылган шешә тора, ләкин сызым өстендә эшләгәндә ул аны бервакытта да кәгазь почмагына куймаган. Кайчандыр Әхмәтовның улы аударганнан соң шешә карага манчылган килеш бер кырыйда тора биргән. Квартирда саклана торган сызымнарны фотога төшергәндә агент, артык кабаланып, шушы шешәдән файдаланган, дигән фикер туды. Шулай итеп, Тренькинның фараз кылуы раслана башлады: димәк, җинаятьчеләр сейфтагы сызымнар белән моңа кадәр дә файдалана килгәннәр. Ләкин ничә тапкыр файдаланганнар? Кайчан алар Әхмәтов сейфын ача башлаганнар? Бу сорауларга җавапны Тренькин конструкторның үзе ярдәмендә табарга тырышты.

— Вагыйз Әхмәрович, бу сызымнар һәм исәп-хисаплар өстендә кайчанрак утырган идегез, хәтерли алмыйсызмы? — диде ул, Әхмәтовка кара савыты эзләре калган сызымнарны сузып.

Әхмәтов аларга игътибар белән карап чыкты да, авыр сулап:

— Гомумән, мин сезгә шуны әйтергә тиешмен: эшләнеп беткән нәрсәләрне мин өйдә ике-өч көннән артык тотмыйм. Менә боларны мин егерме сигезенче июньдә, җомга көн эшләп бетердем, иртәгесе көнне заводка алып барырга исәпләгән идем. Ләкин соңыннан аларны тагын бер тапкыр тикшереп чыгасым, якшәмбе көнне дә эшләп аласым килде.

— Димәк, сез бу сызымнарны егерме сигезендә эшләп бетергән булуыгызны тәгаен хәтерлисез?

— Әйе, моны тикшерүгә кыен түгел: без исәпләүләрне изделиенең һәрбер узелы буенча алып барабыз. Ә изделиеләрне эшләү шундый ук эзлеклелек белән бара.

— Ә менә бу исәпләүләр кайчан төгәлләнгән иде? — диде Тренькин, математика формулалары төшерелгән берничә бит кәгазьне күрсәтеп.

— Моннан ике көн элек.

— Икенче июльдә, сишәмбе көнме?

— Әйе.

— Ә заводка кайчан илттегез?

— Кичә.

— Аларны кайчан эшли башлаган идегез?

— Менә шушы сызымнар белән бер үк вакытта,— диде конструктор, кәгазьләр төргәгенә күрсәтеп.

— Ә кайчан?

Әхмәтов кашларын җыерды:

— Бу узелны булдыру турындагы уй минем башта күптән түгел, моннан ике атна чамасы элек кенә туды. Шуннан соң әле бер-ике көн уйланып йөрдем. Кыскасы, эшкә моннан ун көн чамасы элек керештем,— диде Әхмәтов, аннары тикшерүченең фикерен укыгандай, өстәп куйды. — Өйдә мин сызымнарның караламасын гына эшләдем һәм исәпләүләрне башкарганга кадәр үк заводка илтеп куйдым. Сызымнарны анда эшләп бетерергә тиешләр иде...

— Әйтегезче, Вагыйз Әхмәрович, сезнең каралама сызымнар һәм исәпләүләр буенча дошман агентурасы конструкторлык бюросының нәрсә өстендә эшләвен белә аламы?

— Заводның нәрсә чыгаруын, минемчә, шәһәрдә һәркем белә. Без ул продукцияне инде ун елдан артык чыгарабыз. Ә менә изделиенең техник-экономик күрсәткечләре — аның икенче мәсьәлә. Дөресен әйткәндә, аерым узелларга карап кына изделиенең сыйфатын белергә мөмкин түгел. Ләкин шунысы әһәмиятле: бу узелда техник яңалыклар, ягъни уйлап табу элементлары бар.

Әхтәмовның сызымнары һәм исәпләүләре буенча үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре белән танышканнан соң, Галләмов бик ашыгыч рәвештә бүлекнең киңәшмәсен җыйды. Анда атаман Мефодийның нидән үлүе турында мәгълүматлар җыю өчен Әстерханга киткән майор Стеклов кына юк иде. Галләмов бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты, гасабиланып, бер мәл тәрәзә белән өстәл арасында арлы-бирле йөрде, аннары сәгатенә карап алды да, Тренькинга мөрәҗәгать итте:

— Я, лейтенант, тикшерүнең барышы турында сөйләгез. Сезгә биш минут,— диде.

Тренькин экспертиза нәтиҗәләре турында, конструктор Әхмәтов әйткәннәр турында сөйләде һәм ахырда:

— Минем фикеремчә, дошман агентлары, җинаятьче Пөнтәс ярдәмендә, Әхмәтов квартирына кереп, аның сейфындагы кәгазьләр белән танышуны үткән якшәмбедән, ягъни 30 июньнән башлаган. Һәрхәлдә, экспертиза конструктор үз өендә эшләгән документларның дошман кулында булганлыгын раслый торган эзләрне таба алмады. Бу бер. Ә икенчедән, Әхмәтов квартирына керү өчен реаль мөмкинлек 30 июньдә генә туган — ул көнне алар бөтен гаиләләре белән туганнарына ку-

накка китәләр һәм төнге уннарда гына кайталар. Нәкъ шул арада Йөнтәс сейф механизмын тикшерергә өлгерә. Ә икенче тапкыр алар квартирга дүшәмбе көн, 2 июльдә кергәннәр. Аларга, элек уйлаганча, егерме минут җиткән дә булыр иде, ләкин көтмәгәндә кайтып, теге карчык эшне бозган.

— Иптәш лейтенант, сез дә, Закиров кебек, Әхмәтов квартирын тәрәзә аша күзәткәннәр, дигән фикердә торасызмы? — дип сорады майор. Аның сүзләрендә шикләнү ноталары бар иде.

Тренькин икеләнеп калды:

— Кистереп әйтә алмыйм... Әлбәттә, тикшереп карарга ярый...

«Аңлашыла,— дип уйлады Закиров Тренькин турында. — Начальникларда ризасызлык уятасы килми моның».

— Алайса, чит ил разведкасы Әхмәтов квартирында сейф барын каян белгән? — дип сорады майор Тренькиннан.

Ләкин ул, Закиров фикереннән баш тарткан булса да, бу сорауга үз җавабын бирергә әзер түгел иде.

— ... минем уйлавымча... монда хатын-кыз гаепле... алар күп сөйләшүчән булалар... менә шулар аркасында... Алар аралашкан кешеләрне тикшерергә кирәк...

Галләмов ияк какты һәм, утырырга мөмкин икәнне белдереп, кулы белән ишарә ясады.

— Тренькинга сораулар бармы? — дип сорады Галләмов кырыс тавыш белән. Аннары бер мәл сүзсез торды да, өстәп куйды: — Бәлки бүтән фикерләр бардыр?

— Миңа мөмкинме, иптәш майор? — дип аваз салды ишек янында почмакта утырган Закиров.

— Сөйләгез!

— Лейтенант Тренькинның фикере нигездә дөрес,— дип башлады Илдар.

Майор аңа таба борылды да җирән кашларын күтәрде. Аның маңгае гармун күреге төсле җыерылып килде. Бу исә, бүлек кешеләре белгәнчә, гаҗәпләнүне яисә ризасызлыкны аңлата иде.

Ләкин бу хәл Закировны каушатмады, ул сүзен дәвам итте:

— ... бу фикерне тагын шуның белән раслап була: Чмо белән Дюдя ачкычлар буенча белгеч саналган Фроловны моннан ике атна элек тапканнар. Бу хәл үзебезнең эзләнү нәтиҗәләре белән дә, Дюдяның әйткәннәре белән дә раслана. Димәк, дошман агентлары Әхмәтовның сейфына Тренькин әйткән вакыттан элек якын килә алмаганнар. Фроловны тапканнан соң да әле шпионнар квартирга керү өчен уңай вакытны көтеп торганнар. Сейфтан күп тапкырлар файдаланырга теләгәнлектән, алар ачыктан-ачык эш итүне кулай күрмәгәннәр. Һәм менә андый көн килгән: 30 июньдә, якшәмбе көн төштән соң, Әхмәтовлар гаиләсе кунакка киткәч...

— Без бу турыда ишеттек инде,— диде Галләмов, аны бүлдереп. — Берәр яңа нәрсә әйтә аласызмы, юкмы?

Закиров хәзер дошман эзен яшерергә маташачак, дигән фикер әйтте.

— Әгәр шифровкада телгә алынган Роза Фроловның сеңелесе булмаса, ул хәзер алар өчен кирәкмәс бер йөк кенә, һәм алар Йөнтәстән котылу ягын караячаклар. Гомумән, ул артык күзгә чалына торган кеше, һәм алар моны бик яхшы аңлыйлар. Безнең бурыч ничек кенә булса да Фроловны кулга төшерү. Ә аны Святовск поселогыннан эзләргә кирәк.

— Ярый, аны табарга тырышып карагыз. Сезгә иртәгә үк Святовскига китәргә рөхсәт. — Галләмов өстәлендәге календарьның битләрен актарды: — Бүген атна кич, ә киләсе дүшәмбедә сезне бирeдә көтәм.

— Аңладым, иптәш майор.

— Ләкин сезнең белән сөйләшәсе сүз бетмәде әле, иптәш Закиров.— Майор аркасы белән креслога терәлде. — Сезнең сүзләрегездә элек әйткәннәрегез белән чагыштырганда каршылык бар. Сезнеңчә, конструктор Әхмәтов сейфы белән бәйле булган вакыйгада уңышка ирешүдә чит ил агентларына җинаятьче Фролов ярдәм иткән. Шулаймы?

— Әйе, мин моңа ышанам.

— Алайса, нигә Фролов Древцов квартирына ачкыч ярату өчен шул кадәр вакыт әрәм иткән? Әллә ишек йозагы катлаулыракмы? Алай түгел ләбаса! Әгәр Фролов тышкы ишекне ача алмаган икән, сейфны ачу аның кулыннан килми дә килми бит инде!

— Монда, әлбәттә, уйланырлык нәрсә бар. Ләкин, минем фикеремчә, монда менә нәрсәне истә тотарга кирәк: Древцовларның ишек йозагы индивидуаль заказ буенча эшләнгән, һәм аңа ачкыч ярату мөмкин түгел. Кыскасы, монда отмычкасыз берни эшләп булмый. Ә көне буе кеше йөреп тора торган подъездда отмычка белән маташу бик кыен, вакыт күп кирәк. Мондый шартларда чит кеше квартирына сиздермичә кереп булмый. Тагын шуны да истә тотарга кирәк: каршыдагы квартирның ишегенә «күз» куелган, кем белә — бәлки аннан күзәтеп тора торганнардыр. Димәк, квартир ишеге төбендә бер минуттан артык тоткарланырга ярамый, ә моның өчен үз ачкычың булу кирәк.

Закиров нидер язып маташкан майорга күз төшерде һәм, пәрдә белән капланган зур тәрәзәгә таба борылды да, ашыга төшеп:

— Ә Әхмәтов квартирында — кибеттән алынган стандарт йозаклар, һәм аларга ачкыч ярату Фролов кебек оста карак өчен — көнбагыш ашау белән бер... Ә инде сейфка килгәндә, ул да Фролов өчен зур каршылык түгел, җиде сәгать җитеп ашкан...

Галләмов кул селтәде:

— Җинаять турындагы хокук фәне бүтән фәннәрдән бернәрсәсе белән дә аерылмый, өлкән лейтенант, анда да теләсәң нинди теорияне уйлап чыгарырга, капма-каршы булган күп нәрсәләрне аңлатырга мөмкин.

Бүлмә хуҗасы, җәйге бөркүлекне бераз киметү өчен, вентиляторны эшләтә башлады, тәрәзәнең ак пәрдәсен төшерде.

— Менә сезгә икенче сорау: әгәр Әхмәтов квартирын тәрәзәләрне яфрак капламаган вакытта, ягъни кышын янсә язын күзәткән булсалар, ул чагында күзәтүне җәй көннәрендә ничек алып барганнар? Ә бит алар бу эшләрен туктатмаганнар. Ял көнне Әхмәтовлар гаиләсенең кунакка китүен белгәннәр ич. Айлар буе подъездда янсә ишек алдында тормаганнардыр бит инде. Минемчә, агент кайдадыр якында гына булырга тиеш, бәлки шул ук өйдә яши һәм Әхмәтов гаиләсеннән берәрсе белән янсә аларга кереп йөри торган кеше белән элемтә тота торгандыр.

Закиров бер кавым эндәшми торды, аннары әкрен генә:

— Монысы инде икенче операдан ария, иптәш майор... — дип куйды. — Һәм аның мөстәкыйль яшәргә хакы бар.

— Белгечләр теле белән әйтсәк, монда арияләр чыннан да төрле, ләкин алар бер үк музыкаль нигезгә корылганнар. Бербөтен музыкаль әсәрдән үзгә буларак, аларның кайсысы безнең өчен әһәмиятлерәк икәнен әйтүе кыен.

— Һәрхәлдә мин аларны капма-каршы куймас идем: икесенең дә әһәмиятле булуы бар. Минем бер нәрсәдә шигем юк — һәр ике версияне кичектермәстән тикшерергә кирәк.

Майор көлемсерәде:

— Сезнеңчә, бирелә шпионнарның бөтен бер шайкасы оя корган булып чыга. Шпиономаниягә бирелмик, дип әйтүем. Әлбәттә, һәр ике версия җентекләп тикшереләчәк.

— Иптәш майор, сезгә бер үтенечем бар: каршыдагы өйдә, дөресрәге, тәрәзәләреннән күзәтү алып барырга мөмкин булган квартирларда торучылардан сораштырырга рөхсәт итегез.

Майор Тренькинга таба борылды:

— Ишетәсезме, лейтенант, бу сезгә кагыла.

Тренькин урыныннан торды:

— Эшләнер, иптәш майор.

Майор Тренькинга шулай ук Әхмәтовлар гаиләсенең хатын-кызлары белән аралашкан кешеләргә аеруча зур игътибар итәргә кушты.

Икенче көнне сәгать җидедә Закиров су трамвае белән Святовскига китте. Ә Тренькин иртән үк майор кушканнарны үтәүгә кереште. Әхмәтов квартирындагы хәлләрне беренче булып күргән карчык белән бер сәгатьләп сөйләште. Аннардан яңа бер нәрсә дә ишетә алмагач, подъездлардагы җыештыручылар белән танышты. Алар да соңгы вакытларда шик уятырдай бер нәрсә дә күрмәүләрен әйттеләр. Ишегалды себерүче дә шуны ук кабатлады.

Көндез, кояш төшлеккә менеп бик хәтәр кыздыра башлагач, кирпеч йортның подъездына кергән Тренькин салкынча һавада бераз хәл алып торды. Ул биредәге алты квартирда булырга тиеш иде. Торак конторасына кереп, бу квартирларда кемнәр яшәвен белеп чыккан иде инде ул. Алар барысы да диярлек күптәннән яшәүчеләр иде. Соңгы ике елда бары тик бер кешенең — тау инженерының гына пропискага кергән булуы беленде. Вакытлыча яисә пропискасыз яшәүчеләр бөтенләй юк, диделәр.

Ул унҗиденче квартирның ишек төбендә тукталып звонокка басты. Тиздән эчтә лыштыр-лыштыр атлаган аяк тавышы ишетелде. Ишек бераз ачыла төште һәм ачулы хатын-кыз тавышы:

— Манька янынамы? Җаныгызга төкерим! — дип мыгырданды.

Мондый нәрсәне көтмәгән Тренькин каушап калды.

— Кертмим,— диде әлеге тавыш, һәм ишек шапылдап ябылды.

Тренькин тагын звонокка басты.

— Әйттем бит инде,— дип кычкырды шул ук хатын.— Әллә милиция чакырганны көтәсеңме?

Тренькин ишеккә якын ук килде дә үзенең НКВДдан булуын әйтте.

Ниһаять, ишек ачылды. Тренькин таныклыгын күрсәтте. Өлкән яшьтәге ханым аны карашы белән баштанаяк капшап чыкты. Шуннан соң гына теләр-теләмәс артка чигенде һәм лейтенантны коммуналь квартирның коридорына кертте. Коридорны тузан белән капланган тоныкы лампочка яктырта иде. Гомуми кухнядан керосин, тозлаган кәбестә исе, тагын әллә нинди әче исләр килә иде.

— Нәрсә кирәк? — диде карчык тәкәллефсез генә.

«Гомуми квартирда шундый күрше белән торсаң, күңелсезлектән интекмәссең»,— дип уйлады Тренькин, бәрәңге саклана торган әрҗә өстенә утырып.

— Сезнең квартирда вакытлыча яшәүчеләр юкмы?

— Без барыбыз да бу фани дөньяда вакытлы гына. Син соң кем турында сорыйсың, фатирчылар турындамы?

— Әйе, шулар турында.

— Күптән шулай диләр аны,— дип мыгырданды кортка. — Бездә андыйлар юк.

— Сез, гражданка, ашыкмагыз әле. Миңа торак конторасында шушы адрес белән ике ел буена Матюгов дигән кеше яшәгән иде, диделәр. Шулаймы?

— Яшәде бугай.

— Кайчан һәм кая китте?

— Аның пропискадан төшкәненә бер айлап булды инде, наныкай. Ә кая киткәнен алла белсен, миңа әйтмәде.

— Ә квартиры?

— Монда аның хатыны калды. Теге аның икенче ире иде. Беренчесе белән күптән аерылышкан... Бозык, исерек бер нәмәстә иде. Иреннән аерылгач бу хатын Воркутага китте... Ә анда, үзең беләсең, шахталар. Менә ул анда шушы тау инженерын казып чыгарган. Монда алып кайтты. Ә ул кеше чыннан да бер хәзинә булып чыкты: эчми, тартмый, кыйнашмый, хатын-кызлар белән йөрми. Безнең заманда андый ирне табып кара син: кая карама — ата мәчеләр дә исерек башлар.

Тренькин көлемсерәде:

— Сезнеңчә, бөтен кеше бозык булып чыга,— диде ул һәм, кортка624 тагын нидер әйтергә җыенуын күрмәмешкә салышып, кырыс тавыш белән: — Ата мәчеләрнең дә төрлесе була... Я, ярый соң, шуннан теге кеше?..

— Петр Петрович,— диде хуҗабикә.

— Әйе, Петр Петрович, сезнең канатлы фәрештәгез, күрше хатын янынннан кире очып киттеме?

— Кем белә инде аларны? Каядыр язылып китте бугай. Ә монысының китәсе килмәде: салкын анда, ди.

— Бәлки ул язылып китмәгәндер, төрмәгә эләккәндер?

— Анысын мин белмим инде, наныкай. Менә кичен Клашка кайтыр, үзеннән сорарсың.

Тренькин кемнең тәрәзәсе урамга каравын белеште. Берсе Сыркина фамилияле хатынның квартирыныкы булып чыкты.

— Ә Сыркинаның фатирчы тотканы юкмы?

— Манькаңыңмы? — һәм кортка җавап урынына иңбашын гына сикертеп куйды.

— Ә хәзер кайда соң ул?

— Булмаганны сөйләп гөнаһлы булыр хәлем юк, ә булганы шул...

— Кыскарак тот,— диде Тренькин, аны бүлдереп.

Кортка почмак бүлмәгә таба баш изәде һәм шыпыртлап:

— Татлы уеннарны бик ярата шул, куркып тормый... Менә хәзер балалар тудыру йортында... Әйттем мин аңа... Җүнлегә илтми...

— Аңлашыла. Йөргән ирләре монда пропискасыз торалар идеме?

— Юк, берсе дә атнадан артык тоткарланмады. Мин дә монда бардак оештырырга рөхсәт бирмәдем. «Я язылышып кешечә тор, яисә монда килеп идән таптап йөрмәсеннәр, милициягә барып әйтәм»,— дидем. Ә кайберләрен бөтенләй кертми идем.

Тренькин корткадан күршеләре турында сораша башлады. Тегесе күпне белә торган булып чыкты һәм кемнең кемгә, күпмегә килүен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Аның әйтүенчә, өченче катта, нәкъ аның өстендәге квартирда командировкага килгән бер кеше шактый озак вакыт яши икән. Кыш көне үк фатирга кергән булган.

— Ул кеше безгә дә кермәкче иде,— диде кортка, — ләкин мин аның тәртәсен кире бордым — күзләре бик уйнаклый иде: берәр нәрсәне чәлдермәгәе дип курыктым.

Тренькин өченче катка менеп китте. Анда, Метелева квартирында, кортканың әйтүенә караганда, теге фатирчы яшәргә тиеш иде. Хуҗабикә үзе өйдә юк иде: шифаханәдә ята, диделәр. Тренькинны авыру апасын карар өчен бүтән шәһәрдән килгән бер ханым каршы алды. Әмма ул фатирчы турында берни әйтә алмады.

Метелева яши торган бүлмәләрнең икесенең дә тәрәзәләре урамга карый, һәм алардан Әхмәтовлар квартирының тәрәзәсе яхшы күренә иде. Тренькин Метелеваның кайсы шифаханәдә ятуын сорашып белде дә шунда китте. Метелева урология бүлегендә бөере белән ята иде. Тренькин авыруга үзен танытты да фатирчысы турында сораштыра башлады. Аның әйтүенчә, фатирчысы Анатолий Сергеевич Постнов —

төпле, интеллигент кеше. Февраль аенда җәйгә кадәр торырга дип кергән һәм фатир хакын ярты елга алдан биреп куйган. Магнитогорскидагы металлургия заводыннан командировкага килгән икән. Бүлмәдә даими яшәми, озак вакытка югалып торгалый икән. Мин тәэминат эшендә, шуңа күрә еш кына кайтып-килеп йөрергә туры килә, дип аңлаткан. Фатирчысын вакытлыча пропискага кертү турында Метелева һичектер уйламаган. Постнов яши торган бүлмәдә элек Метелеваның фин сугышында үлеп калган улы яшәгән икән.

— Квартир буенча күршем Шамил Искәндәр улы Нигъмәтуллин — геолог кеше. Ул еллар буе палаткада яши. Өенә елына бер-ике генә тапкыр, анда да азга гына кайта. Шуңа күрә мин, гел ялгыз тормас өчен, фатирчы кертергә булдым,— диде ул.

— Ә хәзер фатирчыгыз кайда? — дип сорады Тренькин.

Метелева иреннәрен кысты, йөзенә кайгы билгесе йөгерде.

— Үлде шул ул.

— Үлде?

— Моннан ике атна элек Магнитогорскига кайтып киткән иде...

— Димәк, июнь урталарыннан ул сездә яшәми.

— Шулай бугай. Көнен тәгаен хәтерләмим...

— Ә үлгән булуын каян беләсез?

— Хат алдым мин, иптәш тикшерүче,— диде Метелева һәм тумбочкасына сузылды. — Менә ул.

Тренькин конвертны әйләндергәләп карады, почта штемпеленә игътибар итте.

— Ал-а-а-й... егерме сигезенче июньдә җибәрелгән... беренче июльдә килгән. — Ул хатны чыгарды да укырга кереште:

Кадерле Мария Петровна! Сезгә күршебез хөрмәтле Анатолий Сергеевич Постновның 26 июньдә вафат булуын хәбәр итәбез. Без барыбыз да якын иптәшебезнең вакытсыз үлүе уңае белән тирән кайгы кичерәбез.

Буровлар гаиләсе

— Ә мин Магнитогорскига барырга һәм Анатолий Сергеевичларда туктарга җыенып йөри идем,— диде авыру хатын зәгыйфь тавыш белән. — Минем ирем шунда күмелгән, гражданнар сугышы вакытында тифтән үлгән иде... Менә күрәсезме, нинди кеше ул, үләр алдыннан да минем турында кайгыртырга онытмаган. Баргач, кайда тукталырга белми аптырап йөрмәсен, дип, үзе тәкъдим иткән иде. Анда минем беркемем дә юк бит...

Ә Тренькин ул арада икенче нәрсә турында уйлады: «Хат егерме сигезендә җибәрелгән, ә Әхмәтовлар квартирына утызында керәләр. Димәк, хатны җибәрүче ул көнне монда булмаган. Исән булса да, бер тәүлек эчендә бирегә килеп җитә алмас иде. Постнов исән һәм хатны Метелева килеп йөрмәсен өчен җибәргән булырга тиеш. Авыру карчык белән кемнең мәшәкатьләнәсе килсен?»

Эдуард, хатны үзем белән алыргамы-юкмы дип, бер мәл икеләнеп торды. Ахырда, аның Әхмәтов квартирындагы вакыйгага бернинди кагылышы булмаганлыгына ышанса да, алырга булды.

«Версиянең сабын куыгыдай юкка чыгуын белгәч, Закировның чырае сытылыр инде»,— дип уйлады Тренькин. Ул сәгатенә карады: эш көне тәмамланганга бер сәгать үткән иде инде. «Оһо, ә мин, тиле, әле һаман эштә», — диде ул үз-үзенә.

Ул тагын Закировны исенә төшерде. «Беләсе иде, минем Эляга шалтыраткалавым турында ишетсә, нишләр иде икән? Ә бөтенләй тартып алсам, ни әйтер? — Тренькин елмайды. — Һуштан язар».

Элеонора турындагы уй аңа көч өстәп җибәрде, кичке бөркү аркасында туган хәлсезлек юкка чыкты. Ул кинәт тәнендә җиңеллек сизде,

күнеле күтәрелде. Кыз белән тиздән очрашу шатлыгына алдан хәзерләнүдән аның йөрәге кытыкланып куйды.

Ни өчендер ул күптән түгел Юра Герасимовның җинаятьчене куып баруын, ә үзенең, чит кешедәй, аңа ярдәм итмәвен исенә төшерде. Куркаклыгымны бүтәннәр дә беләчәк, дигән күңелсез уй аның бөтен барлыгын биләп алды. Күңел күтәренкелеге юкка чыкты. «Шул кадәр начар итеп яратылган бу кеше дигәнең,— дип уйлады Эдуард. — Гүзәл нәрсә турында уйлый башларга, аның тәмен татырга да өлгермисең, синең күңелгә шунда ук ямьсез уй килә дә төшә: хәтернең бер почмагыннан килеп чыга да, синең аңыңны агулый, күңелеңдәге матур уйларны пычрата».

Икенче көнне Метелева ята торган дүртенче шәһәр шифаханәсеннән урология бүлегендә ятучы Тараткина исемле бер авыру хатынның колбаса белән агулануын хәбәр иттеләр. Билгесез кеше шифаханәнең кабул итү пунктына азык-төлек салынган пакет китергән һәм аны Метелевага бирергә кушкан. Палатада Тараткина Метелевадан колбаса сорап алган булган. Ә Метелеваның бу вакытта ашыйсы килмәгән. Озак та үтми Тараткина үлгән.

## XIV бүлек

Гурьевта майор Стеклов чон[1] отрядында бергә хезмәт иткән күптәнге танышы Сергей Бажановны эзләп тапты. Сергей шәһәр азык-төлек торагында эшли иде. Алар аерылганнан соң үткән алты ай эчендә ул бик нык үзгәргән: кайчандыр куе булган чәче коелып беткән, үзе юанайган, олыгайган, җитдиләнгән иде. Ул үз өендә, тыныч шартларда, Каспий буе төбәгендә күптән булган вакыйгалар турында сөйләп бирде. 1924 елның көзендә, армиядә хезмәт итеп кайткач, Бажанов Әстерхан ОГПУсының Гурьев шәһәре буенча уполномоченные булып эшли. Тынгысыз заман: шәһәр читләренә әледән-әле бандитлар килеп чыга, төннәрен атышлар булып тора. Шәһәрдә Кутеповның эмиссарлары — монархияне торгызу турында хыялланучы элекке патша офицерлары күренгәли. Аларны тоту буенча үткәрелгән бер операция вакытында чекистлар кулына элекке патша армиясе поручигы — Идел буендагы монархистлар белән элемтәдә торган Шергин дигән кеше эләгә. Атаман Мефодий — Александр Викентьевич Волковский турында әнә шул кеше сөйләп бирә. Элекке атаман бу вакытта инде тыныч урында — Әстерханга күчеп урнашкан һәм ни өчендер әледән-әле Гурьевка килеп йөри икән. Аксөяк алпавытлар ыруы вәкиле поручик Шергин кайчандыр Волковский белән бергә гимназиядә укыган була. Алар эти-әниләренең дуслыгын дәвам итәләр. Шергиннар өендә, Викентий-ата Россиянең иң бай кешеләреннән бер дә калышмый, дип, Идел-Кама банкында гына да аның миллион сумнан артыграк акчасы саклана, дип сөйли торган булалар.

— Поручик Шергин,— дип сөйләп китте Бажанов, каты итеп пешерелгән чәйне чокырларга агыза-агыза, — атаман Мефодийның кулында авырлыгы илле караттан да ким булмаган бриллиантлы гаҗәеп матур йөзек күргән булуы турында сөйләгән иде. Бриллиантның астында кандай кызыл төстәге тәре сурәте дә булган. Атаман Мефодий, йөзек — ул йөз еллар буе күп кеше эзләп таба алмаган серне белү өчен ачкыч кына, дип, ә үзе аның ярдәмендә табарга мөмкин булган хәзинә белән чагыштырганда бернигә дә тормый, дип мактана торган булган. Волковский әлеге байлыкларны үзе белән алып, чит илгә качарга җыенып йөргән. Шергинны да бу эшкә катнаштырырга вәгъдә иткән. Поручик-

[1] Чон — части особого назначения — махсус билгеләнгән частьлар.

ның сүзләренә караганда, аның дусты соңгы вакытта монархия режимын торгызу турында уйлаудан битәр, исән-имин чит илгә качып котылу турында кайгырткан, шуңа күрә җинаять акцияләрендә дә аз катнашкан.

Бажанов чәйле чокырны майорга таба этәрде, аннары үзенекен кулына алып, бераз өреп торды, ашыкмый гына бер йотым эчте һәм шактый арыган кыяфәт белән утыручы Стекловка күз төшерде дә:

— Әйдә, Петя, чәйне эчеп бетерик тә, бераз йоклап алыйк. Бүген ял көне бит. Аннары мин ул атаман турында сөйләп бетерермен, ярыймы?

Стеклов риза булды. Ләкин аның күзенә йокы кермәде, көндезге бөркүлек аны тәмам әлсерәткән иде. Ләкин төштән соң коры, эссе җил бераз басылды, ә сәгать бишләрдә Каспий ягыннан салкынча дымлы җил исә башлады. Стеклов, кич җитеп, өйдә җиләсләнә төшкәч кенә хәл алды.

— Тыңла әле, Серега, көн саен шундый мунчада ничек түзәсең син, ә? Мин менә икенче генә көн торам, анда да аяк сузар хәлгә җиттем.

Тегесе, аңа җавап итеп, елмайды гына. Кичке аштан соң өй хуҗасы сүзен дәвам иттерде:

— Шергин сөйләгәннәрдән чыгып, без күптәнге танышыбыз атаман Мефодийның эзенә төштек. Бу тирәләрдә ул инде бүтән исем астында йөри иде. Ниһаять, ул килеп йөри торган яшерен квартирларның берсендә без аның өстенә үк барып чыктык. Ләкин ул бирелергә теләмәде һәм атыш вакытында үтерелде. Шергин аны таныды. Яшерен квартир хуҗабикәсе дә үтерелгән кешенең атаман Мефодий-Волковский икәнен әйтте. Сине кызыксындыра торган нәрсәләр турында минем белгәнем менә шул.

— Ә теге серле йөзек атаманның үзе белән идеме соң?

— Ә-ә! Әйтергә онытканмын икән: йөзек үтерелгән атаман кулында табылмады. Бар киемнәрен, кем әйтмешли, соңгы җөенә тикле тикшереп чыктык, яшерен квартирның астын өскә китердек, ләкин бу бернинди дә файда бирмәде.

— Бәлки квартир хуҗабикәсе берәр кая яшергән булгандыр?

— Юк, ул андый йөзекне атаман кулында беркайчан да күргәнем булмады, диде.

Икесе дә берара сүзсез утырдылар. Бажанов ут кабызды һәм тәрәзәләрне япты.

— Черки кереп тулыр да, йокларга бирмәс,— диде ул.

Бераз уйланып утырганнан соң, Светлов:

— Ә атаман белән кемнең элемтәдә булуын, аның якыннарын ачыклый алмадыгызмы?

— Ул чак игътибарга лаеклы берни дә белә алмадык... Тик менә әлеге хуҗабикә генә атаман янына кыяфәте белән аңа охшашлы хатын-кыз чырайлырак чибәр бер егетнең килеп йөрүен әйткән иде. Аның сүзенә караганда, атаман бу егет белән бик җылы мөгамәләдә булган.

— Ә ул егетне тота алмадыгызмы?

— Юк. Аның кем икәнлеге ачыкланмыйча калды.

— Волковский белән Шергин кайда бергә укыганнар?

— Тукта әле, тукта... — Бажанов маңгаен җыерды. — Әллә Ярославльда, әллә Костромада. Кайдадыр Югары Идел буенда икәнлеген генә хәтерлим... Ул тагын ниндидер Ипатий монастыре турында да әйткән иде. Шергинның сүзләренә караганда, Романовлар династиясенең беренче вәкиле патша итеп шул монастырьда игълан ителгән. Оят булса да әйтим, ул монастырьның кайсы шәһәрдә икәнен мин белмим...

— Кострома да,— диде Петр Прохорович, нәрсә турындадыр уйлаган җиреннән. — Боярин Михаил Романов Россия дәүләтенең патшасы итеп шунда игълан ителгән.

— Димәк, алар Костромада бергә укыган булганнар,— диде Бажанов.

— Ә теге яшь егет атаман Мефодийның энесе булмаганмы соң?

— Бу турыда берни әйтә алмыйм, Петя. Бу фикер минем уема килмәгән.

«Балалары гимназиядә укыганнар икән, ата-аналары да шунда, Костромада яшәгән булырга тиешләр. Атаманның этисе дин әһеле булганлыктан, җепнең очын, мөгаен, чиркәү архивларыннан эзләргә кирәктер. Викентий-ата ниндидер мәхәлләнең башында торган булырга тиеш,— дип фикер йөртте Стеклов. — Әгәр теге егет атаманның энесе булса, бүген Мефодий өрәгенең яңадан калкуын һәм хәзер бу исем астында кем яшеренгән булуын ничектер аңлатырга мөмкин. Архивларда Викентий-атаның шәҗәрәсен ачыкларга туры килер».

Дуслар, элекке көрәштәшләрен һәм һәр икесен дә дулкынландырган сугышчан вакыйгаларны искә төшереп, төн уртасына кадәр сөйләшеп утырдылар.

Стеклов кайту белән командировкасының нәтиҗәләре турында бүлек җитәкчеләренә сөйләп бирде.

Галләмов, бу командировка инде мәгълүм булган нәрсәләргә бернәрсә дә өстәмәде, диде һәм, бер хезмәткәрне Костромага җибәрергә кирәк, дигән тәкъдимне хупламады.

— Ул мәгълүматларны без болай да ала алабыз,— диде ул. — Өстәвенә, мин чит ил разведкасы шифровкаларында телгә алына торган Мефодий белән атаман Мефодий арасында туганлык җебе булуына бик нык шикләнәм. Разведка эшендә мондый туганлык традициясен саклау гадәте юк. Аның ахыры начар булып бетүе бар. Әгәр инде дошман моңа бара икән, ул моны фәкать контрразведканы ялгыш эздән җибәрү максаты белән генә эшли.

— Шулаен шулай, Марс Әхмәтович,— диде Стеклов, — ләкин вакыйгаларның һәм фактларның үзара туры килүен дә искә алырга кирәк: шифрның ачкычы Костроманың тарихы белән бәйле, ә хәзер Волковскийларның да шул ук шәһәрдә яшәгән булулары ачыклана. Атаманның якыннарыннан берсенең аңа бик нык охшаган булуын кая куясың? Әгәр ул егет чыннан да атаманның энесе булса, аның абыйсы «тормышын» дәвам итәргә теләве дә психологик яктан аклана.

— Дәлилләрегез уйланырга мәҗбүр итсә дә, монысы инде уйдырмалар өлкәсеннән,— диде Галләмов, Стекловны бүлдереп. — Мин хәзер үзеп кенә берни әйтергә дә җыенмыйм, Петр Прохорович. Чыннан да башта тикшерергә кирәк. Шушы көннәрдә Жуков эшкә чыгарга тиеш. Мин кичә аның янында булдым. Менә аны җибәрербез. Ә хәзергә «бик ашыгыч» дип Костромага сорау җибәрегез.

Галләмов хәзер бүлектә эшнең муеннан булуына, кешеләрнең җитешмәвенә зарланып алды. Җитмәсә тагын көтелмәгән бер хәл килеп чыкты, диде ул. Милиция хезмәткәре Герасимов җинаятьчене куып килгәндә лейтенант Треньккинның да шул тирәдә булуы һәм аның, куркаклык күрсәтеп, аңа ярдәмгә килмичә, күздән югалуы мәгълүм булды.

Стеклов башын селкеде:

— Әгәр расланса, бөтен бүлеккә тап төшәчәк.

Шул вакыт безнекеләр кулга төшергән радиограмманы китерделәр.

Мефодийга.
Нигә эндәшмисез? Элемтәнең икенче вариантыннан файдаланыгыз. Очрашу урыны: 3-М, өч парашют гөмбәзе астында, һәр пәнҗешәмбе, 11.00. Дашкова.

Штольц

— Менә укып карагыз, Петр Прохорович. — Галләмов шифрны майорга бирде, тегенең укып бетергәнен көтеп торды да, өстәде: —

Табышмак артыннан табышмак. Һәрхәлдә, «З-М» — шартлы очрашу урыны булырга тиеш. Ә менә «өч парашют гөмбәзе астында» дигәне нәрсә аңлата?

Стеклов иңбашын җыерды:

— Сүз парашюттан сикерү турында булырга тиеш түгел, дип уйлыйм. Алайса, бу нәрсәне аңлата — башыма сыйдыра алмыйм.

— Монысын инде расшифровкага биреп булмый. Хәзер төп белгечләр — без үзебез. — Галләмов шифровканы тагын бер кат укып чыкты. — «Дашкова»сы — пароль булса кирәк. Тик шунысы ачык түгел: бу сүзне телдән әйтергә тиешләрме, әллә... Тукта әле, — майор кулын маңгаена куйды. — Дашкова дигән авторның китабы бар бугай. Ул ханым, әгәр хәтерем ялгышмаса, әби патша заманында Россия Фәннәр академиясенең президенты булган. Ә менә китапның исемен хәтерләмим.

— Бәлки сүз икенче бер Дашкова турында бара торгандыр? — дип шик белдерде Стеклов. — Безнең илдә язучылар яисә галимнәр арасында Дашковалар азмыни? Хәер, моны тикшереп белеп була. Республика китапханәсенең картотекасында казынырга кирәк.

Очрашу урыны билгесез булганлыктан, моның бернәрсә дә бирмәячәген аңласа да, Галләмов бу фикерне хуплады.

Соңгы көннәрдә Стеклов Идел-Кама банкының архивларында керем-чыгым кенәгәсеннән Викентий Волковский салган суммалар турындагы мәгълүматларны эзләде. Кенәгәне, ниһаять, тапты. Саргаеп беткән кәгазьләрдән күренгәнчә, 1914 елның 1 августына Волковскийның банкка салган акчасы алтын белән ике миллион сигез йөз илле мең сум булган. Бу гаять зур сумма Стекловны таңга калдырды, һәм ул Бажанов сөйләгәннәрне исенә төшерде. «Поручик Шергинның әтисе Викентий-атаның байлыгы бик зур булу турында тикмәгә генә сөйләмәгән икән». Тик менә кая киткән бу акчалар? Чыгымнар графасында барлык сумманың 1914 елның 1 августында, ягъни беренче бөтендөнья сугышы башланган көнне, алынуы турында язылган. Викентий-атаның акчасын банктан алуы тикмәгә генә булмаган: сугышның төрле борылышлары аны бар булган байлыгыннан мәхрүм итәчәген яхшы аңлаган ул. Бик зур инфляция башланыр да, шул уңай белән хөкүмәт банктагы акчаларны вакытлыча бирми тору яисә алтын урынына кәгазь акчалата кире кайтару турында карар чыгарыр, дип курыккан. Ә сугыш вакытында алтынны кәгазь акчага алмаштыру — ул бөлгенлеккә төшү, дигән сүз.

«Әйе, хәйләкәр кеше булган, шайтан,— дип уйлады Стеклов. — Ләкин бу кадәр сумманы кайда яшереп тотарга мөмкин?» Алтын акчалар берничә йөз килограмм тәшкил итәргә тиеш булган лабаса! Нинди зур яшерү урыны кирәк аларга! Бу кадәр йөкне ул берьялгызы гына ничек күчерсен дә, ничек яшерсен? Аннары бу серне кемгә ышанып әйтә алган ул? Ихтимал, үз балаларына гына. Атаман Мефодий Шергинга йөзекнең сере турында сөйләгәндә нәкъ менә ул хәзинәне күздә тотмады микән? Йөзек белән яшерелгән хәзинә арасында нинди бәйләнеш бар? Ә бәлки Викентий-ата алтынын чит илгә озатырга өлгергәндер?

«Викентий поп үзенең мәхәлләсендәге кешеләрне рәхимсез талаган. Юкса, аңа шулкадәр күп акча кайдан килсен? — дип уйлады Стеклов. — Ул яшергән алтын алданган меңнәрчә гади кешеләрнең күз яше белән сугарылган. Димәк ул — халыкныкы». Шунда ул монастырь хуҗасының колак ишетмәгәнчә комсыз булуы турында бабасы сөйләгәннәрне исенә төшерде. Ул хәтта монахларны да талаган, аларны ачлы-туклы тотып, акчасын янга калдырган. «Ә шул урланган акчаны,— ди иде аның бабасы,— алла сараенда — гыйбадәтханәдә яшереп саклый, гөнаһыннан да курыкмый бит, мөртәт».

«Ә бәлки поп урлап җыйган миллионнарын шунда, монастырьга яшергәндер,— дип уйлап алды Стеклов.— Моннан да уңайлырак урыны эзлисе дә юк бит». Һәм янадан аның фикерләү юлына, биек таудай, үтә алмаслык булып, тагын шул Идел буе монастыре килеп басты. «Монастырь булмады бу, чишә алмастай бер төен булды. Ләкин ул монастырьга бер-бер юл табылырга тиеш бит инде. Гомере беткәнче шул юлны таба алмас микәнни соң ул? Экскаватор алырга да шундагы бар җирне казып чыгарга иде. Юк, ярамый: архитектура памятнигы. Димәк, кадерле Петр Прохорович,— диде ул үз-үзенә,— бүтән юл эзләргә кирәк. Ләкин нинди юл соң ул?»

## XV бүлек

Святовскига килү белән Закиров туры поселок Советына керде. Ул анда оперуполномоченный Денисов һәм күптән түгел милициядән аларга күчкән Измайлов белән очрашырга тиеш иде. Бу ике кеше берничә көн инде поселокта яшиләр. Алар бирердәге кирпеч заводы эшчеләренең делоларын карап чыктылар, тегү ательесында, кибетләрдә булдылар, җәза срокларын тутырып кайткан кешеләрнең документларын тикшерделәр, Йөнтәс ашарына алырга кибеткә килми калмас, дип анда дежур тордылар. Ләкин Фролов анда күренмәде. Бәлки аның ашарына бүтән берәү алып кайта булыр? Ә кем? Иллә мәгәр аларның бер нәрсәдә шикләре юк: Йөнтәс ниндидер бер хатын-кызда яши. Паспорт өстәле биргән белешмәдән күренүенчә, поселокта ике йөзләп ялгыз хатын бар, аларның кырыктан түбәнрәк яшьтәге һәм үз өйләрендә янсә аерым бүлмәдә яши торганнары — ике дистә чамасы. Шул ук көнне НКВД хезмәткәрләре, янгын инспекторлары исеме астында, поселок Советы рәисе белән бергәләп, үзләрен кызыксындырган өйләрдә булдылар. Ләкин бу да нәтиҗә бирмәде.

— Ә бәлки ул,— дип шикләнүен белдерде Измайлов,— бөтенләй бүтән җирдә яши һәм түшәмгә төкереп ята торгандыр?

Денисов та аны яклады.

— Бирердә ул, егетләр, бирердә,— диде Закиров.— Автобус билетлары шул турыда сөйли. Севчукны үтергәч тә, бирегә чумган. Әхмәтов өенә кергәч, шулай ук бирегә кайткан. Шуны да истә тотыгыз: ул кабәхәтне тотканчыга кадәр бирердә каравыллаячакбыз! — Аннары гасабиланып өстәде:— Уйлагыз, уйлагыз, шайтан алгырлары!

Икенче көнне контрразведчиклар тагын кибетләрне күзәтә башладылар. Закиров автобус тукталышы белән пристань арасында йөренде.

Төшкә таба күк йөзе болытлар белән капланды. Төньяктан салкын җил күтәрелде; дулкыннар, текә ярга еш-еш бәрелеп, шаулый башладылар. Вак янгыр сибәләргә тотынды. Пристаньның буш залында Закиров тәрәзә янына барып басты. «Кайдан гына эзләргә соң бу Фроловны? — дигән уй башыннан китмәде.— Бер генә нәрсә эшлисе кала: җинаятьченең фоторәсемен кибеттә һәм ательеда эшләүчеләргә күрсәтергә». Ләкин моның да уңыш китерәчәгенә өмет аз — җиде ел элек төшерелгән фоторәсемдә Йөнтәс чәче китәртелгән килеш, ә бу инде кешенең тышкы кыяфәтен бик нык үзгәртә. Бары бер юл: көтәргә генә кала. «Үзе генә яши микәнни соң ул? Юк, моның булуы мөмкин түгел: кибет тирәсендә күренми калмас иде... Димәк, монда хатын-кыз катнашкан... Аларның да ялгыз яшәүчеләрен тикшереп чыктык. Әллә ирле булып та, каядыр озакка киткән берәр хатын янына сыенганмы? Тукта әле, әйбәт фикер бит бу! — Янгыр тугәрәкләре белән капланган су өстенә карап торган Закиров сискәнеп киткәндәй булды.— Мондый хәл сирәк булса да очраштыргалый бит».

Поселокта ирләре төрмәдә утыручы хатыннар яшиме икәнлеген ачыкларга ниятләнеп, ул, ашыга-ашыга, милиция бүлегенә таба атлады. Барышлый кибеткә сугылды. Лейтенант Денисов янына килде. Тегенең чыраена карап, яңалык юклыгын аңлады.

— Иптәш өлкән лейтенант,— диде Денисов.— Ә Йөнтәс тәмәке тартамы?

— Тарта иде. Хәзер белмим.

— Ташламагандыр әле. Минем башта бер фикер туды.

— Әйт, тизрәк, Коля,— диде Илдар түземсезләнеп.

— Кибетчедән сорашып белергә кирәк: хатын-кызлардан кайсысы папирос сатып ала икән?

— Шуннан,— диде Закиров, һаман үз уйларыннан аерыла алмыйча.— Шуннан нәрсә?

— Мондый кечкенә торак пунктында тәмәке тартучы хатын-кызлар аз була бит...

— Анысы шулай, ләкин яраткан ирләре өчен тәмәке сатып алучы хатыннар да җитәрлек була. Хәер...— Закиров уйларыннан аерылды...— Хәер, дөрес фикер бу! Монда яшәүчеләр бер-берсен яхшы беләләр. Кем дә булса тәмәке яисә аракы сатып ала башласа,— бу нәрсә күзгә ташланмый калмый. Әгәр сатып алучысы ирсез яисә ире каядыр киткән хатын булса,— бигрәк тә...

Лейтенант, фикерен яклаучы табылуга шатланып:

— Менә мин дә шулай уйлаган идем шул,— диде.

— Кыскасы, Измайлов белән икәүләп тикшерегез, ә мин тиз генә милициягә барып киләм, бер нәрсәне ачыкламакчы булам.

Денисов ашыгып кибеткә таба китмәкче иде, Закиров аны туктатты.

— Тагын бер нәрсә. Барып чыкмаса, кибетчегә Фроловның фоторәсемен күрсәт. Аңладыңмы?

— Аңладым.

— Алайса, бар.

Дүрт кеше эшли торган милиция бүлеге кибеттән ерак түгел генә урнашкан иде. Өлкән яшьтәге, карачкы шикелле чандыр сержанттан ул моннан бер ел элек кирпеч заводында эшләгән ике кешенең хулиганлык өчен төрмәгә утыртылган булуларын белде. Аларның берсе — Вася Топтыгин — төрмәгә эләгүеннән берничә ай гына элек өйләнгән булган икән. Хәзер ул Воркута тирәләрендә. Хатыны Гражданская урамында, җиденче йортта яши. Сержантның сүзләренә караганда, аңа егерме биш яшь тирәсе, үзе чибәр генә, исеме Зинаида. Закиров сержанттан бу хатынны ничек шулай яхшы белүен сорады.

— Әллә ул сезнең танышыгызмы?

— Аны кем генә белми икән? Кибеттә сату итә ич.

— Менә ничек?!— Контрразведчик урыныннан ук сикереп торды.— Кайсы кибеттә?

— Әнә генә ич,— диде сержант, тәрәзәгә таба ымлап.

Закиров ашыгып ишеккә ташланды. Сержант, берни аңламыйча, аның артыннан карап калды.

Сәгать нәкъ бер иде. Закиров соңга калуыннан курыкты: кибет төшкелеккә ябылырга тиеш иде. Ничек кенә булса да кибетче Топтыгинаны күздән ычкындырмаска кирәк иде. Денисов белән Измайловның кибеттән берни дә белә алмыйча киткән булуларына ул шикләнми иде. Аның исәпләвенчә, әгәр Фролов чыннан да шул хатын өендә яшеренеп яткан булса, Топтыгина хәзер үк өенә ашыгырга тиеш. Ә Фролов — тәҗрибәле җинаятьче, эшнең нәрсәдә икәнен шунда ук чамалаячак. Аннары тотарсың аның койрыгын.

Закиров кибет янына йөгереп килде. Ишеккә йозак эленгән иде. Як-ягына каранды: кибетче дә, егетләр дә күренми. Якындагы тыкрыкка

таба йөгерде. «Кайда соң бу шайтан алган урам?» Тирә-юньдә җан әсәре юк. Закиров якындагы өйнең тәрәзәсен какты. Аннан башын тыккан җирән чәчле кыздан Гражданский урамының кайда икәнен сорашты.

Ул, аяк астына җыелган яңгыр суына да игътибар итмичә, урамдагы үрдәк-тавыкларны пычратып, бар көченә йөгерде. Бакчалары яшеллеккә күмелгән тар гына урамга борылгач, коймага кагылган фанер тактага игътибар итте: «Гражданский урамы».

Аңардан ике йөз метр чамасы алдарак таза гына гәүдәле бер хатын ашыгып атлый иде. Дранча түбәле өйгә таба иелеп үскән зур гына каен агачы янына җиткәч, әлеге хатын туктады, як-ягына каранды һәм ашыгып өйалды бакчасына үтте. Хатын кыяфәткә бик чибәр иде.

«Шул булса кирәк,— дип уйлады Закиров.— Мине күрде! Хәер, хәзер моның әһәмияте юк инде. Фролов, әгәр ул анда булса, куркыныч турындагы сигналны барыбер соңарып алачак. Бу юлы ычкына алмас».

Закиров каенлы өй яныннан үтеп китте. Өй җиденче номерлы иде.

«Тизрәк егетләргә хәбәр итәсе иде,— дип уйлады Илдар.— Тик моны ничек эшләргә? Миңа моннан китәргә ярамый бит!» Фролов ишегалдыннан кача алмасын өчен, Закиров койма аша эчкә үтте һәм Топтыгина өен әйләнеп чыкты. Өйалды ишеге күренеп торырлык итеп, мунча почмагына барып басты. Дөрес, болай эшләүнең бер кимчелеге бар: Йөнтәснең тәрәзәдән урамга сикерүе ихтимал. Хәер, җинаятьче көпәкөндез тәрәзәдән йөрмәс, дип уйлады Закиров. Ул бит әле өйнең күзәтү астында икәнлеген хәзергә уена да китермидер.

«Әгәр хуҗабикә чыгып, өй тирәсендә чит кеше юкмы икән, дип тикшеренә башласа, Фролов биредә булып чыга»,— дип уйлады Закиров.

Яңгыр туктады. Ләкин мунча түбәсеннән тамчылар һаман тама иде әле. Һава чиста һәм хуш исле. Ярты сәгатьтән өйалдында әкрен генә баскан аяк тавышлары ишетелде. Закиров стенага елыша төште, коралын чыгарды. Болдырда хуҗабикә күренде. Ул, ишегалдына карап та тормастан, ишекне бикләде дә, берни булмагандай, урамга чыкты. Янкапка янында бер кавымга туктап, яулыгын рәтләде һәм поселокның үзәгенә таба атлады.

Закиров чарасыз калды. Баягы ышанычның эзе дә калмады. «Йөнтәс биредә түгел микәнни соң?».

Шул вакыт урам яктан:

— Ярдәм итегез!.. Үтерә-әә!— дип чыелдап кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде. Закиров шул тавышка таба йөгермәкче булган иде, ләкин шунда ук аңына килде һәм өйалды турысында туктап калды. Җан әрнеткеч кычкыру тагын кабатланды. Күрше ишегалдыннан ниндидер хатын-кыз икенче берәүгә:

— Федька үзенең Танькасын кыйный... Самогон чөмергәндер әле... Бар, ярдәм ит...— диде.

Кычкыру-каргаулар бераздан тынды. Закиров, сагаеп кына, өйне әйләнеп үтте дә, койма ярыгыннан урамга күз төшерде. Анда ике ир кеше җирдә ятучы өченче берәүне бәйләп азапланалар. Шунда ук чәче-башы тузган бер хатын басып тора. Алар янына милиция сержанты килеп туктады. Закиров аны күргәч шатланып китте. Ул, сагаеп кына, кулына асылынып күтәрелде дә, койма аша урамга карады. Аның карашы Измайловныкы белән очрашты.

— Сез монда ничек килеп эләктегез?— дип пышылдады Измайлов.

— Соңыннан, лейтенант. Сержантны чакыр.

Аннары Денисовка:

— Койма аша монда кер. Тизрәк!— дип боерды.

Закиров лейтенантка бурычын аңлатты. Ул урам як тәрәзәне каравылларга тиеш иде. Ә Измайловка Топтыгинаны чакырып китерергә кушты. Үзе өйалды почмагына басты. Аның янына Денисов килде:

— Безгә Галләмов шалтыратты. Косовскаядан сорау алганнар. Ул күптән түгел генә кайтып төшкән. Аңардан Фроловның бу поселокта нинди дер Зинкага фатирга кереп торуын белгәннәр... Сержант безгә сезнең Зинаида Топтыгина белән кызыксынуыгызны әйтте. Һәм без тизрәк бирегә...

Ул арада куркынган Топтыгина күренде. Измайлов аның артыннан иярде. Закиров бер кавым күтәп торды да баскычтан күтәрелә башлады. Нәкъ шул мәлне аның каршында, җир астыннан калкынып чыккандай, Йөнтәс пәйда булды. Җинаятьче, туктап тормастан, күз ачып йомганчы аңа китереп сукты һәм күршеләрнең коймасына таба йөгерде. Закиров баскычтан тәгәрәп төшеп китте. Денисов Йөнтәсне койма аша сикерергә җыенганда куып житте. Алар арасында көрәш башланды. Фролов лейтенантны җиргә екты һәм шашкан кешедәй коймага ташланды, ләкин ул арада Денисовка ярдәмгә Закиров килеп өлгерде. Икәүләп алар Йөнтәсне егып салдылар.

Менә Фролов, куллары бәйле килеш, Топтыгина өендә утыра, сорауларга җавап бирергә теләми. Тентү вакытында Древцов өеннән урланган кыйммәтле әйберләрнең кайберләре табылды. Слесарь тартмасыннан яңа гына игәүләнгәне күренеп үк тора торган катлаулы конфигурацияле бер ачкыч килеп чыкты. Аның сейф йозагын ачар өчен ясалган булуында шик юк иде. Шунда ук пластилин кисәге дә ята.

Денисов пластилинны һәм ачкычны Фролов алдына куйды да:

— Бу ачкычны пластилинга төшерелгән эз буенча кем өчен эшләдегез, гражданин Фролов? — дип сорады.

Әмма җинаятьче, телсез кешедәй, сүзсез утыра бирде.

— Чәнчелеп китсен, эндәшмәсен,— диде Закиров мич артыннан.— Чмоны кулга төшергәч теле ачылыр әле. Хәер, без болай да барысын да беләбез инде.

Чмо исеме телгә алынгач, Фролов кыбырсый башлады.

Измайлов пүнәтәйләрдән:

— Сез, күршеләр буларак, боларга кемнәр килеп йөргәнне күрмәдегезме?— дип сорады.

Уңып беткән яулык бәйләгән бер кортка тешсез авызы белән:

— Әнекәем, барышын да күреп бетереп буламы соң? Өйдә савытсаба юып, кәҗәне савып бетерә алмыйшың, караңгы төшкән була. Тәрәзәдән карарга вакыт та калмый,— дип пышылдады.

Янәшәсендә утырган карт та аның сүзен җөпләде:

— Эшсез бәндә генә бар нәрсәне күреп, белеп тора, ә эш кешесенең вакыты калмый.

Закиров Топтыгина янына килде:

— Әйтегезче, Зинаида Семеновна. Бу... фатирчыгыз әлеге ачкычны сезнең күз алдында эшләдеме?

Хуҗабикә кызарынып башын түбән иде:

— Әйе...

— Монда аның әшнәләре килеп йөри идеме?

— Бер ир кеше дүрт-биш тапкыр килде.

— Аның тышкы кыяфәте нинди иде рәк?

Хуҗабикә сөйләп бирде.

— Минем аңлавымча,— диде Закиров, Фроловка таба борылып.— Бирегә Чмо килгәли булса кирәк. Симез кош ул. Без аны күтәп алырга да иренмәбез.

Топтыгина утырды һәм, гасабиланып, яулык читен бөтерә башлады.

— Сез яраткан бу кешегезнең нәрсә белән шөгыльләнгәнен белә идегезме?— дип сорады аңардан Закиров.

— Белмәдем. Ул миңа, геолог булып эшлим, ә хәзер озак вакытка ял алдым, диде.

Хуҗабикәдән сорашып, 30 июньдә, якшәмбе көн, Фроловның өйдә кунмавын, дүшәмбе генә кайтуын, аннары яңадан юкка чыгуын беләләр.

— Димәк, сезнең Валерочкагыз сишәмбедә, ягъни, икенче июльдә юкка чыкты,— диде Закиров.— Шулай бит?

— Шулай бугай. Әйе, шулай.

— Теге көннәрне ул, геолог буларак, квартирлар тикшерү белән шөгыльләнде,— диде Илдар, җинаятьчедән күзен алмыйча.

Тегесе өметсез бер кыяфәт белән кулын селтәде:

— Я, ярый, начальник. Ул чүпрәк белән мәтәшмәгез. Үзем сөйлим. Тик шуны искә алыгыз — үз теләгем белән...

— Килештек,— дип риза булды Закиров һәм үзен күптән борчып килгән сорауларны бирергә ашыкты:

— Чмоның фамилиясе ничек?

— Моратов Марат Минаевич. Бу ачкычны мин аның өчен... кичә күчермәсен китергән иде... иртәгә килергә булды.

— Сезнең сеңелегез бармы?

Фролов бер мәл сүзсез торды, аннары:

— Әйе, бар,— диде.

— Аның исеме ничек? Кайда эшли?

— Исеме Роза... Роза Полыханова... Заводта эшли... инженер...

— Древцов квартирына үзегез генә кердегезме?

Фролов тәрәзәгә таба борылды: аның сул күз кабагы тартыша башлады. Ул эндәшмәде.

— Ә Кәрим авылында милиционерны кем үтерде. Сезме?

— Юк. Мин үтермәдем.— Җинаятьченең бөтен гәүдәсе тартышып куйды, башын Закировка таба борды: — Чмо... Моратов эше...

— Ә Әхмәтовлар квартирында карчыкны кем үтерде?

Фролов куырылып килде. Аның көчле гәүдәсе йомшарып киткәндәй булды.

— Ул үзе... куркуыннан,— диде ул, сүзен кысып чыгаргандай.

— Конструктор өендә сейфны сез ачтыгызмы?

— Мин.

— Кайчан?

— Утызында, якшәмбе көн.

— Тагын кем бар иде?

— Мин ул кешене белмим. Картрак кына бер нәрсә, бераз аксый, ләкин үзе бик хәтәр җитез. Мине аның белән Чмо таныштырды. Ә Моратов үзе шухерда торды.

— Ул картлач кәкре борынлымы?

— Әйе.

Закиров авыз суын йотты: «Әллә тәҗрибәле шпион һәм кеше үтерүче Варев тагын калкып чыктымы?»

— Күрсәтеп торучы кем иде?

— Шул картлач булса кирәк.

— Конструктор квартирында аңа нәрсә кирәк иде?

Фролов картның ниндидер сызымнарны фотога төшерүен сөйләде. Ә ул үзе ишек һәм сейф йозаклары белән маташкан. Моның өчен аңа өч багана төрткәннәр.

Закиров яңадан Древцов квартиры турында сораштыра башлады. Ләкин җинаятьче бу вакыйганы үз өстенә алырга теләмәде. Соңыннан, кире кагып булмаслык дәлилләр китергәч кенә, ул Древцовның кинәт

кайтып керүен, аны тотарга маташуын һәм шулчак үтерелүен танырга мәҗбүр булды.

...Аннары Закиров Йөнтәсне тотулары турында Галләмовка хәбәр итәргә йөгерде. Галләмов аны уңышы белән тәбрик итте һәм аларга машина җибәрде. Топтыгина өендә засада калдырдылар.

Алар Йөнтәснең сеңелесе Полыханованың конструкторлык бюросында эшләүче, бик купшы киенеп йөрүче тәкәббер хатын Роза Зеленская белән якын элемтәдә булуын ачыкладылар. Зеленскаяның ире — теш технигы, «сул» эшләр белән күп акча таба һәм шул сәбәпле милиция һәм финанс бүлекләренең кәгазьләрендә телгә алына башлаган иде инде.

«Ике билгесезле мәсьәлә булды бит бу,— дип уйлады Закиров.— Дошман шифровкасында нинди Роза турында сүз бара икән соң? Бәлки бу ханымнардан берсенең дә аңа катнашы юктыр?»

Авырып терелгәннән соң эшкә чыккан подполковник Чурбанов Йөнтәс ясаган ачкычның Полыханова белән Зеленская эшли торган заводтагы сейфларның берсенә ярамыймы икәнлеген бик тиз генә тикшереп белергә кушты. Заводка Закиров китте. Бүлек начальнигы, пинжәгенең кайтармасына Кызыл байрак ордены беркетелгән юантык гәүдәле, пеләш башлы кеше, Закировның таныклыгын бик җентекләп тикшергәннән соң, пичәтләп куелган зур гына сейфтан бер бәйләм ачкыч чыгарды һәм Закиров алдына куйды.

Закиров үз кесәсендәге ачкычны алды, һәм алар икәүләп аны әлеге бәйләмдәге ачкычлар белән чагыштыра башладылар.

— Мәгъсүм Нәҗметдинович,— диде Закиров, бүлек башлыгына мөрәҗәгать итеп,— сездә ачкыч югалту очраклары булдымы?

Тегесе сүзсез генә урыныннан торды, сейфтан ниндидер журнал алды һәм:

«1938 елның 19 октябренда цех начальнигы Гәрәев 27 номерлы сейфның ачкычын югалтты. Ул ачкыч 20 октябрьда, ягъни бер тәүлектән соң цехта табылды»,— дип укып китте дә, үзеннән өстәп куйды:— Бүтән мондый очракның булганы юк. Ә теге сейфны без алыштырдык.

— Димәк, моннан ике ел чамасы элек... Ә ул ачкыч хәзер кайда, шушы бәйләмдәме?

Бүлек башлыгы кирәкле ачкычны тиз генә табып бирде. Закиров аны үзендәге ачкыч белән чагыштырып карады. Туры килмәде. Инде дүртенче дистә ачкычларны карый башлаганда Закировка 19 номерлы сейфның ачкычы аныкына бик охшаган төсле тоелды. Моңа кадәр күздән кичерелгән ачкычларның номерларын бик тыныч кына язып утырган бүлек башлыгы урыныннан торды һәм, каушап, калтыранган куллары белән ачкычларны алды да тонык тавыш белән:

— Болай охшаган төсле, ләкин мин безнең заводта андый хәлнең булуына...

— Кайда ул сейф?..

— Барлык сызымнар җыела торган җирдә... җыю цехында...— диде тәмам каушап төшкән бүлек башлыгы.

Төшке ял вакытында икесе дә җыю цехына киттеләр. Анда, махсус бүлмәдә әлеге 19 номерлы сейф тора иде. Башта аны цех начальнигы күз алдында бүлектә саклана торган запас ачкыч белән ачтылар. Закиров, йозакка «үз» ачкычын кертеп, әкрен генә боруга сейф ишеге ачылып киткәч, бүлек башлыгының маңгаена тир тамчылары бәреп чыкты, ә цех начальнигы бу хәлгә бер могҗиза күргәндәй карап тора башлады.

Закиров Роза Полыханованың шушы җыю цехында эшләвен һәм изделиеләрнең сызымнарына кагылышлы булуын ачыклады. Цех начальнигыннан тыш сейфны тагын аның урынбасары һәм смена начальниклары ача ала икән. Ачкычның күчермәсен заводта эшләүчеләрнең генә ала алуына шик калмады: һәркем ачкычны кул куйдырып тапшырыр-

га тиеш, һәм ул пичәтләнә торган махсус сейфта саклана. Чит кешенең җыю цехына керергә һәм, бигрәк тә, ачкычтан файдаланырга мөмкинлеге юк. Шушылардан чыгып, ачкычның күчермәсен телгә алынган дүрт җаваплы работник турыдан-туры аралаша торган һәм, ул ачкыч белән шушы ук цехта эшләүче кеше яисә бу цехка кереп йөрергә хаклы булган икенче бер кеше файдаланырга теләгән, дигән нәтиҗә ясарга Закировның нигезе бар иде.

Закировка җыю цехына кереп йөрүче кешеләрнең исемлеген бирделәр. Алар арасында Полыхановның дус хатыны Роза Зеленская да бар иде. Алар урта мәктәптә бергә укыган булганнар.

Закиров сейфны ачарга хакы булган хезмәткәрләр белән якыннан аралашкан кешеләрне, аларның да җыю цехында эшләүчеләрен һәм цехка кереп йөрергә хакы булганнарын тикшерергә тотынды. Ул Федорукның цех партия оешмасына биргән гаризасына игътибар итте. Бу хатын иренең Роза Зеленская белән очрашуы турында яза һәм иренә карата чара күрелүне таләп итә иде. Федорук смена начальнигы булып эшли, һәм аның сейфны ачарга хакы бар.

Партоешма секретаре бу гаризаның чыннан да нигезле булуын: Зеленскаяның һич кирәксезгә Федорук кабинетына кереп йөрүен раслады.

Подполковник Чурбановка тикшерү нәтиҗәләре турында сөйләгәндә, Закиров Зеленскаяны бик нык күзәтү астына алу кирәклеге турында басым ясап әйтте. Ә менә Федоруктан сорау алу белән хәзергә ашыкмаска кирәк, дип саныйм, диде. Подполковник аны тыңлаганда элек алынган шифровкаларны, карта ачкандагы төсле, алдына таратып салды. Аларга бер мәл карап торды да:

— Федорук турында... аңардан сорау алсак, бу ачкычтан күчермә алган кешегә мәгълүм булачак, димәкче буласызмы?— Һәм, Закировның җавап бирүен дә көтмичә, өстәде:— Әйе, мондый куркыныч бар...

Чурбановның уенда тагын нәрсәдер булуы күренеп тора иде.

— Иптәш подполковник, әгәр Зеленская шифровкада телгә алынган Роза булса, хуҗалары аны эшсез тотмаячаклар...

— Һәм Йөнтәстә табылган ачкычның нәкъ аның өчен эшләнгән булуы да ихтимал,— дип өстәде подполковник.

— Нәкъ шулай,— диде Закиров, аның белән килешеп.— Ул хуҗаларына үз кулы астында булган информацияне генә булса да җиткереп торачак. Әлбәттә, аның кулында булган нәрсәләр 19 номерлы сейфта саклана торган информациягә караганда чүп кенә. Дошман агентурасы яңа изделие турындагы информацияне, кем әйтмешли, бер чумыруда алмакчы булган. Хәзер безгә шуны белү бик кирәк: Зеленская информация тапшырамы, әгәр тапшырса — кемгә һәм ничек?

Закиров Чурбановка күз төшерде. Тегесе, аңа нидер әйтергә җыенып, алдындагы кәгазьләрен бер якка этеп куйды.

— Илдар Мәхмүтович, мин хәзер генә менә нәрсә турында уйлап алдым: Фроловның кулга алынуы ачкычны көтеп торучыны сагайтмасмы икән? Һәм ул кеше хәл ачыкланганга тикле шыпырт кына ятмасмы?

— Алай булуы мөмкин. Ләкин, икенче яктан, бу нәрсә Йөнтәсне ачкычтан файдаланырга тиешле кеше белән тоташтыручы «буын»нан бәйле.

— Ягъни?

— Без бит хәзергә Моратовның заводта эшләүче агент белән турыдан-туры бәйләнеше бармы, яисә алар арасында тагын кем дә булса бармы икәнен тәгаен генә белмибез бит әле. Агентның, әйтик, Розаның, нәрсә эшләячәген нәкъ менә шул «кем дә булса» хәл итмиме икән?

— Сез Моратов белән, әйтик, Роза арасындагы «буын»ның Варев булуы ихтимал, дип уйлыйсызмы?

— Әйе, иптәш подполковник.

— Варев,— диде Чурбанов,— бик хәйләкәр, карт төлке, заводта эшли торган агентның контрразведчиклар күзәтүе астына эләгүенә тәмам ышанмый торып, ул аны шунда тотачак һәм аңардан үзенә кирәкле информацияне ала торачак.

— Эзембә төштеләр, дип сагаю өчен нинди нигезе бар аның? — дип дәвам итте подполковник.— Фроловның һәм, хәтта, әгәр эләктерә алсак,— Моратовның да кулга алынуы, аның күзлегеннән чыгып караганда, әле Розаны куркыныч астына куймый. Варев, шифровкалар — безнең өчен әле чишелмәгән табышмак, дип уйлый. Димәк, аныңча, без әле Роза турында бер нәрсә дә белмибез. Шулаймы?.. Шуңа күрә игътибар итегез: Моратовның кайда яшеренеп ятуын Фролов белми. Ә үзләренә кирәк чакта алар Фроловны шунда ук табалар. Күрүебезчә, бердә элемтә бер яклы гына. Мин ышанам: Моратов белән аның хуҗасы арасында да шундый ук элемтә. Мондый хәлнең бер кимчелеге бар барын: ул тиз аралашуны кыенлаштыра. Аның каравы югарыдагы буыннарның фаш ителү куркынычы кими. Моның шулаймы-юкмы икәнен без Моратовтан белербез, дип уйлыйм.

Ләкин Святовск поселогында вакыйгалар алар уйлаган сценарий буенча бармады. Фролов кулга алынганнан соң икенче көнне кичен Топтыгинаның ишеген шакыдылар. Зинаида ишекне барып ачты — аның каршысында ниндидер малай басып тора иде. Малай Валя абыйны чакырырга кушты.

— Ә син өйгә кер, энем,— диде аптырашта калган Топтыгина. Ләкин малай, мин урамда гына көтеп торам, диде. Топтыгина, Валя абыйны чакырырга дип, өйалдына кереп китте. Тиздән ишектә лейтенант Денисов күренде.

— Нәрсә кирәк, малай?

— Анда, кое янында,— диде малай, кулы белән шул якка күрсәтеп,— сине Марат абый көтеп тора. Миңа шулай дип әйтергә кушты.

Моратовның бу адымын оперативниклар көтмәгәннәр иде. Денисов югалып калды. Аның башыннан: «Нәрсә эшләргә?— дигән уй йөгереп үтте. Чыксаң, засада барын сиздерү була. Юк, миңа чыгарга ярамый. Топтыгинаны җибәрергә кирәк, ә без, тегеңә күренмичә, арттан барырбыз».

— Хәзер синең белән менә бу апаң барыр. Ә мин чыга алмыйм, аягымны тайдырдым,— диде ул малайга.

Топтыгина белән малай ашыкмый гына коега таба киттеләр. Анда беркем дә юк иде. Топтыгина, бераз көтеп торды да, кире борылды. Коелы тыкрыктан ике йорт үткәч, кемдер аңа шыпыртлап кына дәште. Топтыгина туктады.

Капкадан Моратов килеп чыкты.

— Ә Валерка кайда?— дип сорады ул, як-ягына каранып.

— Ул аягын тайдырган,— диде малай ашыгып.

— Ә бәлки ул сакалын да югалткандыр?— дип малайга таба борылды җинаятьче.— Ник дәшмисең? Ул абый сакаллы идеме?

— Караңгы иде анда... тик сакалы юк иде төсле...

— Ә син ни әйтерсең? — дип ысылдады ул Зинаидага һәм кесәсеннән фин пычагы чыгарды.

Топтыгина куркуыннан телдән язды. Ул караңгыда ялтырап киткән пычактан күзен ала алмас хәлгә килде һәм, ни әйтергә белми, башын селкеде дә артка чигенмәкче булды. Ләкин Моратов аны чәченнән тотып алды һәм пычагын аның бугазына ук китерде.

— Сатлык кәнтәй, энкеведечыларны җылытып ятасыңмы?! Я, әйт, алдасаң — кадыйм...— Җинаятьче бик иләмсез итеп сүгенде.

Малай куркуыннан башта артка чигенде, аннары Топтыгиналар өенә таба йөгерде.

— Син кая? — дип акырды аңа Чмо.— Тукта хәзер үк! Падла!

Шул чак күрше ишегалдыннан бер кеше килеп чыкты, үзе артыннан янкапканы япты да тротуардан аларга таба килә башлады.

Моратов бармакларын Зинаиданың чәченнән алды, аның кулыннан кысып тотты һәм пычагын хатынның янтыгына китереп терәде.

— Тавышың чыкмасын — үтерәм,— диде ул.

Читтән карауучыга ике гашыйк басып тора төсле иде. Шуннан соң көтелмәгән хәл булды. Теге кеше кинәт кенә борылды да тегенең башына китереп сукты. Чмо башы белән капкага килеп бәрелде, пычагын кулыннан төшереп җибәрде. Зинаида, үз-үзен белештермичә, алга ташланды һәм җинаятьче белән әлеге кеше арасында калды. Бу хәл тегенә,— ә ул Денисов иде,— тагын берничә тапкыр сугарга комачаулады. Ул арада Моратов аңына килде, капкага таба ыргылды һәм кесәсеннән пистолетын чыгарырга теләде. Ләкин Денисов, йөгереп килеп, Чмоның кулыннан тотарга өлгерде, әмма шул чак төнге тынлыкны ату тавышы бозды: Чмо, пистолетын кесәсеннән чыгармыйча гына, атып тидермәкче булган иде.

Поселокның төрле очында берьюлы этләр өрә башлады. Топтыгина ачыргаланып кычкырып җибәрде:

— Үтерәлә-ә-р!! Ой, үтерәлә-ә-р!!

Денисов җинаятьчене коралсызландыра алмады. Ул Моратовны коймага китереп кысты һәм аның пистолет тоткан кулын читкә каерды. Шул чак караңгылык эченнән Измайлов килеп чыкты. Моратов, аны күргәч, аңлап алды: «Засада!». Ул коточкыч көч белән капкага таба ыргылды, ә сул терсәге белән Денисовның яңак сөягенә китереп сукты. Лейтенант бер мәлгә хәлсез калды. Шуннан файдаланып, Чмо уң кулын да ычкындырды һәм аның өстенә килгән икенче оперативникка туп-туры атарга ниятләде. Ләкин Денисов, инде егылып барган килеш, соңгы секундта йодрыгы белән аның уң кулына бәрде, һәм шуның аркасында пуля Измайловка зыян китерә алмады.

Моратов исә янкапкадан ишегалдына кереп китте. Измайлов, Чмоның хәзер капкага төбәп атачагын аңлап, җиргә иелде. Ул капка астыннан йортка күз йөртеп чыкты: җинаятьче инде ишегалды уртасына житкән һәм, артына борылып тормыйча гына, капкага таба ата иде. Чмо хәзер йөгереп кача икән, аны бу караңгыда табып булмаячагын оперативник яхшы аңлый иде. Җинаятьченең кара шәүләсе борылышта күмелә дигәндә генә, Измайлов бер-бер артлы ике тапкыр атып өлгерде. Моратов алпан-тилпән килеп берничә адым ясады да өйнең нәкъ почмагына килеп сөялде һәм әкрен генә җиргә шуып төште.

Соңыннан Измайлов, мин аның аягына төзәп аткан идем, умырткалыгына ялгыш тигән, дип акланачак... Ничек кенә булмасын, Моратовны коткарып кала алмадылар. Һәм Варевка таба сузылган җеп тагын өзелде.

*Ахыры киләсе санда*

# МАРС ШАБАЕВКА 50 ЯШЬ



*Марс Шабаев иҗатын иңләп узган төп образ-мотивларның берсе — аның туган ягындагы Ык елгасы. Ул — шагыйрьнең илһам чыганагы, туган җирне сөю тойгысы, ул — аның тормыш учагы. Шагыйрьнең гражданлык хисләре әнә шул конкрет учактан ут ала, аның кешелек язмышы һәм кешелеклелек турындагы фәлсәфи уйлары әнә шул уттан үрләп китә.*

*М. Шабаев әсәрләрендә туган як елгасы — табигать һәм Ватан-ана алдындагы изге җаваплылык тойгысын, шагыйрь язмышының ил, халык, дөнья язмышына кушылуын гәүдәләндерә: «Озатның син мине Чулман аша, үрләп кара, диеп, Иделдән...» Җаваплылык һәм бурыч тойгысы әдипне бүгенге көннең актуаль мәсьәләләренә, замандашларыбызны сөендергән һәм борчыган күренешләргә алып чыга, аңардан фикердә, хистә олылык, кыюлык, тирәнлек таләп итә...*

*Табигатькә кешелекле мөнәсәбәтне һәм кешенең гүзәл табигатен яклап язган әсәрләрендә М. Шабаев беренчел нигезләргә, үз буынының сугыш утында көйгән балачагына кайта.*

*«Җирән Конрад», «Татар хатыны», «Сине эзлим», «Артист», «Әби-апа»... Бу поэмалардагы конкрет образлылыкка, психологик чынлыкка, шигъри буяулар җетелегенә омтылуның нигезендә шагыйрьнең үз биографиясе, язмышы, шәхси тетрәнүләре... Тормышчан рухы, ихлас кичерешләре, ил тарихын тудырышкан кешеләр хакында җырлавы белән әлеге әсәрләр бер-берсен дәвам итеп, тулыландырып та килә. Ләкин аларның һәркайсы үз агышы, ритм-интонацияләре, үз аһәңе белән аерылып тора. Шушы әсәрләре белән, М. Шабаев бүгенге татар поэмалары үсешенә үзенчәлекле өлеш кертте.*

*М. Шабаев иҗаты жанрлар төрлелеге, эзләнүләр тынгысызлыгы җәһәтеннән дә игътибарга лаек. Аның Ык буйлары турындагы шигъри әсәрләре белән авазлаш «Салда сәяхәт» повестен, балалар өчен язылган «Мич башында биш мәче» исемле китабын укучылар яратып кабул иттеләр. Бөек демократ шагыйрь Уолт Уитмен әсәрләрен тәрҗемә итүе М. Шабаевның кызыклы эзләнүләренә һәм иҗади үсеш мөмкинлекләренә янә бер дәлил булды.*

*1976 елда «Җикән камыш», «Онытма» һәм «Сине эзлим» дигән җыентыклары өчен Марс Шабаев Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде. Бу — шагыйрьнең халыкка хезмәт итүен тану, шул хезмәтенең югары бәяләнүе иде. Ул үзе дә, тормыш һәм иҗат максатын билгеләп, бер шигырендә болай дип язды:*

*Җирем үзе җырлый!*
*Җир булмаса,*
*Халкым да юк минем, җыр да юк.*

*Ык суларыннан көч-илһам алган шагыйрьнең иҗат чишмәсе бүген яңа көч белән чылтырый, аның җыры поэзиябезнең уртак Иделенә кушыла.*

# Марс Шабаев

## ШИГЫРЬ УТЫМ АЛГА ДӘШӘ МИНЕ

### Килдем

*Кайдан килдегез сез безгә,*
*Батмаенча диңгезгә?*

Минзәләдән килдем.
Минзәләдә
Ак күбеккә баткан чияләр,
Ботакларын җиргә кадәр иеп:
«Бер кайтырсың, танымабыз...» — диеп,
Шаулап калды...
Кызлар-гүзәлләр дә
Танымаслар, борын чөярләр!

Ык буеннан килдем.
Ык буенда
Калды мин чуммаган чоңгыллар...
Калды төнбоеклар, бер төш булып...
Калды мин яраткан сары комлык:
«Нәрсә икән, бала, һай, уеңда?...—
Дигән төсле, моңга чумды да.

Урманнардан килдем.
Урманнарда
Мин эзләгән зелпе тамыры,
Мин кисәсе чабаталык юкә,—
Азга түгел, гомерлеккә, күпкә!—
Эреде дә зәңгәр томаннарда,
Балачакны җуеп калдырды.

Болыннардан килдем.
Болыннарда
Мин өзәсе юа-балтырган,
Мин кабасы сусып алсу җиләк,
Мин иснисе чәчәк, нидер көйләп,
Хыял-теләкләрне күп елларга
Чит күзләрдән саклап калдырган.

Мин таңнардан килдем.
Шул таңнарда
Каеннардан төшкән аклыклар...
Калды мин эчәсе каен суы,
Калды талчыбыктай таң сылуы,
Үбелмичә калды...— Үкенечкә!—
Кичерелмичә калды шатлыклар...

Мин кичләрдән килдем.
Кичләрендә

Салкын сулы сиртмә коега
Кызлар су алырга киләләр дә,
Егет куеныма керәләр дә,
Эреп бетә... Сөю җилләрендә
Шул коега йолдыз коела...

Килдем Минзәләдән, Ык буеннан,
Урманнардан, яшел болыннан...
Ал таңнардан килдем, тын кичләрдән...
Авылдагы олы-кечеләрдән,
Күрше-күлән, кардәш-ырудан
Хәер-фатихаләр алып килдем...

Ярты җаным шунда калды минем!
Шунда калды...
Тагын сезгә нәрсә әйтим инде?!

*1981*

## Авыр...

Авыр —
Егылганны күтәрүе,
Авыр —
Чөелгәнне төшерүе,
Авыр —
Канатсызга канат кую...
Җиңелрәктер таулар күчерүе.

Авыр —
Өстен булу ваклыклардан,
Авыр —
Олуг эшләр калдыруы,
Авыр —
Күтәрергә шөһрәт һәм дан...
Җиңелрәктер диңгез яндыруы.

Авыр —
Яхшы гына булып яшәү,
Авыр —
Һәрчак уйнап-көлеп йөрү,
Авыр —
Һәркемне дә тигез күрү...
Җиңелрәктер кояшны сүндерү.

Авыр,
Авыр —
Үз-үзеңне җиңү,
Авыр —
Табу сүз җилемен-җимен...
Кул кушырып, берни эшләмичә,
«Авыр» диеп сөйләү генә җиңел!

*1981*

## Алсу таңда, шәһәр урамында...

Әллә инде илаһилык иңә?
Әллә кайдан, мәңгелектән гүя,
Өнме, моңмы —
Сүзсез бер җыр килә...
Адымымны көйләп шул җырга,
Кушылмакчы булам... Чыкмый барып!
Таш диварлар көлә кубарылып,
Чыңлый гүя еллар-зынҗырлар!

Кара инде: бу нинди тамаша?! —
Әллә мең ел, әллә йөз ел аша
Ташлар җырлый икән, ташлар ласа —

Телен бел дә, тыңлый бел генә.
Тыгыз итеп тэрэп иңне-иңгә.
Тигез сафта таш урамнар килә,
Җырлап килә гүя ил белән!

Ул моң-җырда — Сөембикә сылу,
Ул моң-җырда — Кабан-Болак суы,
Ул моң-җырда — халык үч-ярсуы,
Ерак калган чорлар авазы.
Унҗиденең Октябре анда
Яна һаман, яна алсу таңда —
Кандай кызыл Казан һавасы.

Атлар чаба,
Чак-чок чакма чага:
Тояк асларыннан чаткы чыга!
Казан шулай чаба...
Килер чорга
Ашкыналар урам ташлары.
Даһиларың һәйкәллэрдән карый,
Һәрбер ташың, Казан, моңлы тарих —
Тыңласыннар заман яшьләре.

Мин һәйкәлләр өмет итмим, шәһәр!
Дан-шөһрәт көтмим һич ул кадәр...
Сәгать суккач, мөмкин булса әгәр,
Тик бер ташың булыр идем, дим.
Төннәрендә ташлар җырлаганда,
Урыным белеп кенә, мин һаман да
Өн-моң булып торыр идем, дим...

*1981*

## Карап торам да мин...

Карап торам да мин урамдагы
Хәрәкәткә, ыгы-зыгыга,
Бер нәтиҗә ясыйм: Казан да бит
Идел кебек җанлы, зур елга.

Ага...
    ага...
        ага...
Халык ага —
Эшләпәләр ага, яулыклар...
Халык төрле: тик бер генә мөһер
Сугып куеп булмый халыкка.

Тышкы кием-салым, елмаюлар,
Ресторанда акча түгүләр,
Машиналы һәм дачалы булу —
Юк, берсе дә артык түгел лә!

Артык түгел адәм баласына
Сөю-сөелү, кайгы-шатлыклар...

Җанның тынычлыгы, ихлас көлү
Толкучкада булмый сатлыкка.

Беркемнең дә хакы юк дөньяда
Кеше хыялларын ватарга.
Һәрберебез — Илнең гражданины,
Бурычлы без уртак Ватанга.

Кирәк түгел эшләгәнне сынау,
Кемнәрнеңдер җырын тыюлар,
Гашыйклардан төнне кызганулар,
Ай-кояшны каплап куюлар.

Бардыр, бардыр — мең нән берәүдерме? —
Әшәкеләр бардыр әле дә.
Тик ул хакта түгел минем сүзем —
Керә белик кеше хәленә.

Уртак максатларга бергә-бергә
Нинди мавыктыргыч атлавы!
Өмет белән яши кеше җирдә,
Бер карасаң — бәхет катлаулы,
Бер карасаң — гади генә кебек:
Яшә,
    эшлә,
        гомер итә бел.
Бу мәңгелек тормыш елгасының
Тере тамчылары икән без...

*1982*

## Шагыйрь монологы

Күңелем пакь.
Кулым, буялса да,
Язу карасына буяла.
Максатларым ачык: хакны сөйләү...
Хаклык аша карыйм дөньяга.

Пегастырмы — канатлы аттырмы
Шагыйрьләрнең илһам юлдашы?—
Укып беләм, ләкин күргәнем юк...
Мин шигырьдә үзем —
Эш аты.

Өмет итмим һич тә үлемсезлек,
Булдыралган кадәр җырлыймын.
Кырыс шагыйрь дигән исем алдым —
Җырладым бит кырыс чорны мин.

Һәр чорның да үзенең шагыйрьләре —
Яңа җимеш шигъри агачта.
Башкалардан аерылып тора
Затлылары, өзеп алгач та.

Минем эш сәгатем чикләнмәгән,
График төзеп булмый хисләргә.
Кешелекнең кайгы-шатлыкларын
Мөмкин түгел аны чикләргә.

Кайчак дәшми күңел. Ул бикләнә,
Ят күзләрдән кача эчкәрәк.
Ә ят күзләр, симез һәм тук йөзләр
Тормый алар бер дә нечкәләп.

Асыл шагыйрь һәрчак бер бөтен ул:
Сүзе, үзе — барысы бергәдер.
Сүз бәһасе шигырьләрдә арта —
Сез түләгез аңа бермә-бер!

Юк, артыгын һич тә сорамыйм мин —
Бары күңелемә тимәгез.
Мин шигырьдә — эшче.
Эш хакымны
Тиыренчә генә түләгез.

*1982*

## Шулай, дуслар...

Шулай, дуслар,
Тормыш — матур бер җыр.
Һәм без аны матур җырладык.
Тын җитмәгән чакта сынатмадык,
Дан-мактаулар күтәп тормадык.

Ә кемнәрдер безне алкышлады,
Ә кемнәрдер безгә табынды.
Түр башында булдык без һәрвакыт
Тормыш дигән ямьле табында.

Хәзер инде яшьлек юлларыннан
Җилеп узган бәхет тулпары
Бер сызгыру белән чабып килми...
Шатлык сараеның утлары

Тоныграк яна, сүрәнрәк...
Кадерлерәк безгә алкышлар...
Башкаларны күбрәк ымсындыра
Офыктагы алсу балкышлар.

Хәзер инде безнең җырга иңә
Югалтулар моңы, сагышлар...
Борчылулар анда, шомланулар...
Сирәгрәк безнең табышлар.

Ә шулай да, дуслар, тормыш
җырын
Җырлап бетерергә ашыкмыйк.
Якты кояш белән ант итик без:
Тормышка без үлеп гашыйк бит!

*1982*

## Гомер утым алга дәшә мине...

Әткәм-әнкәм кабызып китеп барган
Яктысында гомер утымның
Тормыш китабының мин әлегә
Илле битен генә укыдым.

Бүген күңелемдә — хәтерләүләр...
Хәтерләүләр гомерем юлларын.

Хәтер-кинокадр, ни өчендер
Тәртипләрен бозып елларның,
Сүтә...
сүтә...
сүтә...
Иң кирәкле,
Әйтелергә тиеш уйларның
Күплегеннән гаҗиз булгангадыр —
Бер еракка китә, бер кайта.
«Үткән еллар — аккан сулар...» — диеп,
Җырлата да, аннан моңайта.
Онытылып кабат актарсам да
Хәтер дәфтәрләрен мин бүген —
Күңелдәге кичереш-табышларның
Еллар юып киткән бик күбен...
Сокланып та, кайчак шукланып та
Йөрелгәндер: чөнки яшь идем.
Киткәннәрнең ачы тәҗрибәсен
Мирас итеп хәзер яшимен.
Мин бурычлы якты дөньяларга,
Мин бурычлы Айга-Кояшка.
Мин бурычлы сезгә, аксакаллар,—
Нинди байлык булса бу башта,
Мин аларны сездән үзләштергән,
Сезнең газапларны күрмичә.
Юк, хакым юк, миннән соңгыларга
Бу әҗәтне кире бирмичә,
Еллар тузанына күмелергә!
Мин бурычлы очкан кошларга —
Гомерем күкләрендә талпынганда,
Мин тырыштым кошка охшарга.
Бу тормышта барысы бер тамырда:
Кайгы-шатлык, яхшы-яманы.
Кешелекнең парадоксларда
Кайнап яши торган заманы.
Илле елым миңа набат кага!
Мин ишетәм шушы набатта:
Без яшибез икән кешелекнең
Үткән сабакларын кабатлап.
Буын арты буын килә-китә —
Кире какмыйм, еллар, мин сезне.
Буын алмашында, ярышта
Кешелекнең үлемсезлеге.
Тормыш китабымның соңгы бите
Язылмаган... Безнең дәвамнар
Оныкларда булыр...
Ә хәзергә —
Көнем якты, зәңгәр һавалар!
Гомер китабымның илле битен
Тапшырам да сезнең кулларга,
Алга атлыйм — иң кызыгы алда,
Кичерелмәгән әле,
Юлларда...

Гомер утым алга дәшә мине!

*1982*

## Рәдиф Гатауллин

# ГОМЕР УРТАСЫННАН ХАТЛАР

Цикл-поэма

## Багышлау

*март 1983*

*Яшьтәшләрем, сезгә бу җырларым —*
*бу багышлау, мөрәҗәгатьләрем —*
*сезгә, илдәшләремә!*
*Сезгә иде минем һәр китабым*
*(Һәр китабым — ихлас бер хисабым!)—*
*хистәшләремә, фикердәшләремә,*
*сезгә —*
*минем егерме ел янып, җан атканым —*
*шигырьләрем,*
*һаман дәвам иткән бу хатларым!*

*Сезгә, туган төбәк малайлары!*
*Сезгә, безнең мәктәп принцессалары,*
*авылда бер булган горур кызлар —*
*еллар аша сезгә барсын*
*элек әйтелмәгән сүзләр.*
*Бу хатларым — сиңа, минем буын!—*
*Сезгә:*
*соңгы тапкыр, бәлки, яланаяк —*
*урам чирәмендә үскәннәргә,*
*әтиеләр, әтисезләргә,*
*катык тәмен онытмаганнарга,*
*авыр елларда да*
*гел шат булганнарга,*
*чабата үрә белгәннәргә,*
*шуны киеп, кичке уенда биеп, җырлап,*
*иң дәртле җан булып йөргәннәргә!*
*Сезгә, яшьтәшләрем:*
*авыл ае, йолдызлары тулы*
*якты хыял белән*
*чынбарлыкка горур килгәннәргә,*
*Күкрәк ачып, тормыш давыла кергән*
*пакь, беркатлы, сабый күңелләргә!*
*Һаман оптимист кыз, егетләргә!*

*Инде күптән дөнья йөген тарткан*
*сафташларыма,*
*сабырлана барган хезмәттәшләремә,*
*кыр батырларына, райком секретарьларына,*
*гади эшчеләргә —*
*барлык яшьтәшләремә!*
*Инде чал чәчлеләр, яки пеләшләргә,*
*карьера өчен түгел,*
*идеал өчен көрәшүчеләргә —*
*ахыргача бергә!— дигән теләк белән*
*янган фикердәшләремә...*
*Сезгә, сезгә минем мәхәббәтем!—*
*Бәлки,*
*күңелегездә туган сүзләр*
*әйләнгәндер минем сүзгә?!*
*Минем хисләр*
*әйләнсә иде сезнең хискә!*
*Шуңа —*
*алып кайтсын сезне*
*шигъри мөрәҗәгатем*
*туган елыбызга —*
*(Дуңгыз елымы ул, эт елымы?*
*Әллә елан елы булды?)*
*Кырык бергә!*

*Бу җырларым — еллар буе язган,*
*әле ахыры юк бу хатларым —*
*сезгә, кырык беренче елгылар!*
*Яшьтәшләрем, сезгә!*

## Егерме яшьтә бер уй-хат

*март 1961*

Мин туганда дөнья тын булган.
Башта —
давыл булган, буран-кар торган.
Аннан тынган.
Мартта
аязган да көннәр — мин туганмын...
Әнкәй раслый ала
мин туганда дөнья тын булганын.

Мин туганда дөнья тын булган...
Ләкин күрдем мин дә
давылны да, салкын, карын да —
барын да!
Тудым — кырык бердә.
Үстем — ак чәүкәләр булып кара хәбәр —
сугыш хатлары очкан авылда,
димәк, давылда...

Мин давылның ни икәнен беләм,
ахры шуңа аяз көннәрне
сөя минем җаным!

Җырларым да —
аяз көннәр, кояш бүләге —
тыныч таңнар,
сөю гөлләре!
Әйе, аяз күңел чәчәкләре!
Ахыргача — ышанам —
минем җырлар
аязлыгын яклар көннәрнең.

Ә давылның ни икәнен беләм...

## Мәхәббәт турында баллада

*апрель 1963*

Урманда кыргый алмагач
Ялгызы үсте.
Язын чәчәк койды, көзен
Алмасы пеште.
Яратып ачы алмасын,
Аның янына
Килеп йөрде бер малай, кыз —
Якын авылдан.
Җыр суздылар алма өзгән,
Бүлгән чагында...
Үсеп җиткәч аерылдылар —
Чор юлларында

Яңгырый җырлары Ватанның
Төрле ягында...
Кыз беркөнне туган җирен
Төшендә күрде...
Гүя ул иң газиз моңын
Югалткан иде...
Гафу сорап, алмагачы
Янына килде:
Искә төште якын көйләр!—
Шатланды, көлде...
...Шушы ук төш шул ук төндә
Егеткә керде.

## Яшьлегемә хат

*ноябрь 1964*

Мин күрергә телим сине —
мине
аңламаганнарның беренчесен —
аңламаганын да яшермичә,
алдамаганнарның беренчесен!

Ә ни өчен?
Җанда яра булып калгансыңмы?
Сызлап, һаман сагындырасыңмы?
Күңел моңнарымны тик син
сабый йокысыннан
уяталгангамы?
Әллә
үзең шул моңнарда калгангамы?
Минем ялгышларны, кыен язмышымны
әллә каян,
алдан күрә алгангамы?
Шуңа, качып, юл башында калгангамы?

Мин күрергә телим —
мине,
ахры, аңлый алганнарның беренчесен.

Тыныч бәхетеңә кагылмыйча,
сиңа рәхмәт әйтеп бары,
кире китү өчен,—
мин күрергә телим сине...

## Бәхет турында хат

*август 1969*

Ахры, кызыгасың булыр:
— «Янып үтә һәрбер көнең,
нинди бәхетле син!» — дисең,
дустым минем.

Әй, ул бәхетем —
пәрдә япкан тәрәзәле
серле күңел йортым минем!
Беләсеңме, шул бәхетне —
җанны баскан уйлар,
мәшәкатьләр йөген,
бәгырь өзеп туган җырның үзен —
кызыгам кайчак!—
кемгәдер мин бирер идем.
Иңенә салыр идем берәрсенең,
качар идем — экияттәге кебек,
«Хәзер алма алып киләм,
көт»,— дип китеп;
әй торса иде,
тирләп, арып, сабыры бетеп.

Мөмкин түгел бу эш!
Өлешемә тигән көмеш —
булса да авыр,
зарланмый, мин күтәрергә тиеш!

Бары да монда: шатлык, газап,
көлү, яшем —
белми тудым, инде барысын күреп яшим.
Әмма кайчак уйлап куям: бәхетемне мин
көнләүчегә тик беразга,
күтәреп карарга гына бирер идем.

Ә югыйсә, гомер әлегә матур уза:
мин язмыштан, бәхетемнән —
исән чакта үзем куйган,
үз җиремә үзем үк утырткан
көмеш баганамнан риза...

## Марс авылы малайларына

*октябрь 1975*

Сагынам сезне, Марс малайлары,
яшьтәшләрем, димен,
үстек тә без таралдыкмы — төрле
тарафына илнең?

Авыл — сабыр, каргамый ул үзен
ташлап киткәннәрне.
Тик, каены төштә — кара, моңсу...
үпкәләгәнгәме?
Ә имәннәр? Безнең «ахирәтләр»
алар исәннәрме?
Шаулап үсәләрме?
Балачакның авыр истәлеге:
давыл узган төштә,
яу ирләре кебек, нык имәннәр
егылганы истә...
Гаҗәпләндек: шул урында азак
яшь имәннәр үсте!
Орлыктанмы алар? — үсентеләр
тамырданмы китте?!
Яңа урман үсте!
Яшь имәннәрне мин искә алам
сагынганда сезне;
әтиләргә алмашка без үстек!—
Тамыр — җирдән безнең!
Күптән ирләр булдык... «Ахирәт»ләр —
имәннәр дә — ирдәй!
Яңа буын — җиргә!
Урман — ныклы терәк, ышык безгә,
ә без терәк — илгә!

Шушы чагыштыру (яңа димим!)
егерме ел инде уйда минем:
күңелемә килә...
Ул, үзенә бер поэма сорап,
шакый күңелемә...
Яшь имәннәр тамыр җибәргәндәй,
җырлар туа килә...
Алар үсәр... Каты салкында тик
нык имән дә үлә!

Имән кебек нык дусларым минем!
инде арада юк яшьтәшләр бар...
Ә яшәрбез, димен!
Төрле тарафларда үтибез без
вазифасын илнең!
Нинди уйлар, нинди гамьнәр сездә?
Я, сөйлә әле, Рәис, сөйлә, Илфир?
Сез соң — Илмар, Вилмир?!
(Сагынуым, бу исемнәргә син
үзең шигърилек бир!)
Хыялларны, куркып кына, яшьтән
сезгә ача идем...
Сез һәрвакыт хупладыгыз мине,
яшьтәшләрем минем!
Бер көн, кайтып Марс урамына,
җырлап йөрсәк имәннәр янында
чал чәчле биш егет —
яшьтәшләрем, акларсызмы мине?
Аңларсызмы бу хат-шигыремне?

Тик сезгә баш иеп,
бары сезнең сүзгә, хак тәнкыйтькә
ышанырмын кебек...

Сагынам сезне, Марс малайлары...

## Сержант улы

*17 март 1983*

Кайта-кайта өйрәнсәм дә
утыз икедә өзелгән
бик кыска гомер юлың,
яуда ятып калган әткәм,
(иңемдә һаман кулың)
кырык яшемдә белдем тик:
сержант булгансың икән бит!—
Мин, димәк, сержант улы...

Солдаттан маршалларгача
сынады сугыш юлы
ирләрне — сайлап тормады,
юл иде ялкын тулы...
Атакага иң-иң алдан
барганын беләм сержантның,
мин — шундый сержант улы!

Фронтовик гаиләсе дип, әткәй,
әнкәйне, өч улыңны
юккамы кайгыртты Ватан?
Сыйпады баштан, кулын
йөрәктә тойдык: җылы...

Нигә генерал булмасын
яуда үлгән ир баласы —
солдат, я сержант улы?
Батырлар тыныч йокласын,
шикләнмәсен: балалары
ата юлына тугры!—
барсы да — Ватан улы!

Без дә үстек, ирләр булдык,
юл, максат — ачык, туры...
Өчебезнең дә улы бар,
уларның горур җыры:
— Бабай батыр сержант булган,
әтиләр — сержант улы...

Хәрби киемнәнме, юкмы,
без — илнең терәк-кулы,
Шәһәрдә, авыл, походта —
һәр җирдә кирәк кулы.
Әткәйләр үрнәге — изге,
без — мәңге сержант улы!
...Мин илнең шагыйрь солдаты,
юл — бөек Ватан юлы.
Илледә, йөздә дә яшәр
горур хис — күкрәк тулы;
безнең дә яшәү — атака!
Әйтермен гомер буе:
— Бул, җырым — солдат җыры!
Минем әткәй сержант булган —
һөҗүмгә барганда үлгән...
Мин, дуслар, сержант улы!

## Яшьтәшләремә — татар шагыйрьләренә

*март 1981*

Кырыкберенчеләр, әй яшьтәшләр!
Күрегез: җиттек ләса кырык яшькә;
Ераклаша елга башланган җир,
Ярлар бер-берсеннән еракклаша.

Ашмый йолдызларга —
Җыр да
Җиргә төшкән инде — гадиләшә.

Кырыкбереңчеләр, без дә кырык яшьтә!

Ә бит
Әле дә сискәнәләр кебек кешеләр:
— Без — кырык беренче елгы,— дисәк,—
кырыкберенчеләр...
Үсеп җитә инде безнең уллар,
Шундый матур алар туган еллар,
Моңсулыкны белмәс
Алар язган җырлар!

Ә без кешелек хәтере өчен
Һаман тере яра төсләләр.
Түгел ләкин бәхетсезләр:
Тормыш шундый матур ләса, яшьтәшләрем!
Улларыбыз — әтиләләр,
Кырык яшьтә без дә, кырыкберенчеләр!

## Атлар турында уйлану-хат

*февраль 1982*

Яшьтәшләрем! Кайда икән безнең
балачакта менгән очкын-атлар?
Болыннардан эзлим, кайтсам,
күренмиләр. Кайда алар?
Адреслары бармы, язсам хатлар?
Әй, кайда сез, «Сандугачлар»,
«Буян», «Красавец»лар?!
Кай тарафта аерылдык без сездән, атлар?
Котылгысыз: сез китәсез,
юк, бетәсез... Кемнәр яклар?
Безнең буынгамы кала
«Гамьсез» дигән яманатлар?
Ә бит әле бездә исән —
яши атка мәхәббәтләр!
Улларыбыз менә нишләр? —
Атсыз нинди ир булыр соң,
нинди батыр булыр Салаватлар?

Ир канаты булган тугры юлдаш — атлар!—
Шигъриятькә дә бит
алып килде безне шул «канатлар»! —
Әкияткә әллә күчеп бетәрсезме?
Без канатсыз гомер итәрбезме?
«Соңгы мамонт» урынына —
бәлки хәзер «соңгы атлар»?!
Сезне алып киткән көчләр
суймасмы соң Пегасны да?!
Аны роботлардан кемнәр яклар?
Шигырьдә дә сирәк образ хәзер атлар —
әйе, азлар...
Корыч атлар анда — МАЗ, КамАЗлар...
Кичер мине, балачакның тугры аты,
ир канаты, тагын бер кат!

Мин хат язам бүген тагын...—
сиңа түгел инде ансы:
— КамАЗга хат!

## КамАЗга мөрәҗәгать-хат

*февраль 1982*

Безнең буын гомерендә син —
бөек сынау, КамАЗ!
Бездә — синең чакыру, оран, аваз,
КамАЗ!
Әйт син: шефлыкка алса сине җырыбыз,
иң зур сәнгать күгенәчә без
чөйдекме әле чорга тиң шатлыкны?
Күрсәттекме, тиңсез сурәт итеп,
Татарстан, синең горурлыкны?!
Шигырь юлы аша — йөрәк аша —
үткәрдекме аны,
күтәрдекме синең авыр колонналар —
«КамАЗ»ларны?!
Син уяттың күпме шагыйрь, җырны!
Тик, әйт: булдыкмы без шигъри сүзнең,
Мавликовтай, илгә данлы бригадиры?!
Каләмдәшләр — камаздашлар, әйтегез:
җырыбыз
«КамАЗ ударнигы» саналырмы?!
Яза алдыкмы аңа лаек поэманы?!
Чын гражданлык белән сугардыкмы
интим лириканы?!

КамАЗ! Магниткалар,
Маяковскийлар җыры — җанда, исән...
Әтиләрнең, өлкәннәрнең сүзе — истә...
Заман, ышан: кырыкберенчеләр шигыре
түгел синнән читтә.
Ул — көрәштә, эштә!

Ахыргача, КамАЗ, син — зур сорау безгә,
Олы оран, наказ.
Ахры, үзең
син шефлыкка алдың бу яшьлекне!—
Әйдә, чакыр безне, юнәлт чорга җырны,
сугышчан ит, КамАЗ!

Уңышлар да булыр, син әйт һаман:
— Бу — аз...
КамАЗчылар кебек эшлә, тулы көчкә!
Шагыйрь!
Чорга лаек җыр яз!

# Игенчеләр иленә хат

*март 1982*

Кичерегез мине,
        яшьлегемдә калган яшьтәшләрем!—
Мәктәп белән саубуллашкан көнне,
елап, миңа
олы юл теләгән классташларым!
Сез күрергә теләгәнчә,
        яңа Такташ — бунтарь Гаташ була алмадым.
Кичерегез, юл башында озатып калган
        якты күзле кызлар — сүнмәс йолдызларым!
Ахры, ул чактагы садәлекне
        бүгенгәчә сакламадым.
Гафу итегез,
        миңа зур өметләр баглаганнар!
Сезнең ышанычның күбесен,
        беләм, акламадым.
Мин — җырымда Мәҗнүн тарафдары —
тулы көчкә мәхәббәтне
        бәлки якламадым?!
Дөньяны да — башта вәгъдә биргәнемчә —
тәмам камил, матур итә алмамын.
Кичерегез, авылымдагы аксакаллар!—
«Үз авылымның акыллысы» булалмадым,
сез уйлаганча, «зур кеше»
        булып та тиз кайталмамын.
Бөек гаебем сезнең алда, якташларым:
мин әлегә авылым Марс данын
Кырлай, Сыркыдылар,
Кармәт, Күлле Кимеләр,
Келәш, Минештеләр
        биеклегенә илтә алмадым!
Ләкин, ышаныгыз, яшьтәшләрем!—
Марс — сугыш алласына
баш июче булмадым мин.
Кешелеккә каршы коралга
        дан җырламадым!
Зевсның һәр әмеренә буйсынып, юк,
        намус мин җуймадым.
Яңа Геростратларга кушылмадым —
мин һәлакәт теләмәдем җиремә.
Прометейга табындым мин һәрчак!
Кешелексез фикер —
        юк шигыремдә!
Әнкәй чәчкән,
ил фатихасы белән үскән
яхшылык булды күңелемдә!
Кояш исе, тир, тоз тәме
        җырда — икмәгемдә!

Әле язылмаган иң шәп җырым —
ул, авылдашларым, сезгә!
Әле әйтелмәгән матур мәдхияләр —
якташларым, сезгә!

Сезгә, игенчеләр, аңлашылсын бар иҗатым...
Игенчеләр иленә — ватаныма булсын
соңгы шигырем минем —
соңгы хатым!

## Җирдәшләремә мөрәҗәгать

*март 1982*

Туганнан бирле мин сезгә дәштем,
гел киңәштем,
сезнең белән яшәдем мин, яшьтәшләрем!
Сезне чакырдым ярдәмгә һәр эшемдә,
илдәшләрем, җирдәшләрем!
Тугры булды җырым сезгә мәхәббәттә!
Бүген дә шигырем — сезнең хакта.
Сезнең хакта уйладым мин
Уфа, Казанымда, Иделемдә.
Парижда, Лондонда
сезнең белән гаплаштем — уйларымда:
Чит җирләрдән уздым
Ватан тулы күңелем белән —
булдым анда да, димәк, сезнең белән.
Бүген дә уйларым — сезнең турыда:
дөньядагы барлык яшьтәшләрем
берләшә алырмы җырымда?!
Ни аңлата соң аларга без туган ел —
мең тугыз йөз кырык бер — ул?!
Яшьтәшләремнән, күрсеннәр,
Җирдә күпме президентлар инде,
Министрлар...
Ә күпме атаклы шагыйрьләр?
Ниләр уйлый әле
Җирнең барлык кырыкберенчеләре?
Тарих сабакларын ничек аңлый алар?
Алар өчен,
дөнья өчен кирәк бүген
нинди җырлар?
Сөйләшә алырбызмы
гомумкешелек телендә без, дуслар?
Аңлаша алырмы
халыкара хистә безнең йөрәк?
Их, кешеләр,
бүген
уртак Җирнең иминлеге —
булсын безнең бөек уртак теләк!

## Эпилог

*март 1983*

*Ишетәсезме безне, әй, лириклар —*
*бездән элгәреләр — ерак тарихлардан*
*бүгенгегә дәшкән йөрәкләр — бөекләр!*

*Бездә бүген — сезнең мирасыгыз,*
*гасырлардан хатлар,*
*ялкыннардан чыккан утлы китаплар,*
*«пәйгамбәр сүзедәй» хак хитаплар...*

*Беләбез, сез*
*тиңсез ораторлар, Тукташ кебекләр...*
*Ишетелде безгә сезнең сүзләр!*
*Яд итела җанда сезнең хатлар,*
*сезнең мөрәҗәгатьләр —*
*түгел анонимнар, донос, шикаятьләр!—*
*сездән килде бөек аманәтләр!*
*Безгә ирешге сезнең антлар, мәхәббәтләр!*

*Сүзләрегез — тарих кайтавазы,*
*алар — бездә!*
*«Син кайтавазыңда яшисең!»—*
*бездә сез яшисез кабатланып,*
*дәвамыгыз — бүгенгедә!*

*Сезне дәвам итсен минем хатлар,*
*сезгә булсын — безнең буыннан җавап,*
*киләчәккә — яңа мөрәҗәгатьләр!*
*Үз чорыбыз — үз җырыбыз,*
*сөйләсеннәр алар:*
*кырык елга якын тынычта без,*
*шундый бәхет бирде илебез!—*
*Килер буыннарга*
*илтсен алар безнең горурлыкны —*
*тәҗрибәләр сүзен илтсен хатлар!*

*Барсын хатларымда — яуда үлгәннәрдән ядкярь,*
*исәннәргә бездән хөрмәт һәм дан,*
*партиягә рәхмәтләр!*
*Омтылышлар, безнең мәхәббәтләр...*
*Егерменче гасыр ахырыннан яңа йөзгә*
*Җирнең имин баруына ышаныч, антлар!*
*Алар —*
*бары безнең заман яза алган хатлар!*
*Шул ук адрес:*
*йөрәкләргә йөрәк сүзе барсын,*
*юлда югалмасын! Дошман угы алмасын!*

*Хәере белән, өмет тулы җырлар,—*
*төш җиткәндә*
*аяз күккә без очырган кошлар!*
*Ышанам: кешеләргә кирәк сүзегез бар,*
*ак юл сезгә,*
*гомер уртасыннан хатлар!*

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

*Фаҗигале төстә һәлак булган рәссам Константин Алексеевич Васильев истәлегенә багышлыйм*

# ӨЧЕНЧЕ ВАГОН

хикәя



Кайчандыр, кемдер әйткән иде Алсуга: тимер юлда аварияләр булганда өченче вагон һәрчак исән кала. Ни өчен нәкъ менә өченче вагон — Алсу белми иде. Әмма шул турыда ишеткәннән бирле гел өченче вагонга утырырга тырышты. Бу хәл үзеннән-үзе килеп чыкты: йөгереп, пыяла бинага керде, Казан-Васильево электричкасына автомат кассадан билет алды һәм өченче вагонга юнәлде.

Шунысы гаҗәп, өченче вагонда һәр көнне диярлек Пугачевныкы кебек сакаллы, саргылт йөзле бер кеше дә кайта иде. Башта Алсу аңа игътибар итмәде, әмма «Пугачев сакал» һәр көн күзенә чалына башлагач, үзалдына көлемсерәп куйды. Әллә соң бу сакалбай да аварияләрдә өченче вагонның исән калуын беләме? Янә сәере шул иде: сакалбай һәрчак эскәмия аша аңа каршы утыра. Әй, утырмагае! Күргәне юктыр шул каратут йөзле, зур кара күзле, кыйгачланып килгән, карлыгач канатыдай җилпенергә торган кашлы яшь хатыннарны. Бер сабакташ егет аңа: «Алсу, синең кашларың кош канатыдай җилпенергә генә торалар»,— ди торган иде. Ә инде сул битендәге миңе турында сөйли башласа, оялтып бетерер иде: «Бу миң сиңа, Алсу, мәхәббәт алласы тарафыннан бирелгәндер, юкса үзеңә бу хәтле килешеп тормас иде. Мин синең урыныңда булсам, әллә кайчан Голливудтагы чибәрләр конкурсына барган булыр идем»,— дип, кәефе китеп йөргән чакларда, кызга тәмам канат үстереп җибәрер иде.

Әйе, әле кайчан гына унынчы класста укып йөри иде Алсу. Һәм кайда диген? Башкортстанның Күгәрчен районында. Бүген исә Алсу — КАИ студенткасы. Башта ул Казан авиация институтына керергә теләмәгән иде — ир-егетләр институты диделәр. Казанга килгәч, ишетеп белде: стюардессалар да хәзерлиләр икән анда. Әлбәттә, стюардесса булам дип кермәде югары уку йортына Алсу, радист булу иде теләге. Һәм булыр да! Мәктәптә әйбәт укыды, керү имтиханнарын да начар бирмәде, укуын да начар укымый. Кайдадыр дөнья читендә югалып калган Күгәрчен районында туып-үскән кызга, Казан кадәр Казанга килеп, зур уку йортларының берсенә укырга керү үзе бер җиңү иде. Кием мәсьәләсенә килгәндә, Алсу беркайчан да күзгә бәрелердәй артык ялтыравыклы киемнәр кимәде. Яхшы укыган өчен, аннары үскәч кирәге чыгар дип, әтисе аңа сигезенче класста ук тегү машинасы алып биргән иде. Буйга җиткәч, ярап куйды — Казанга ук алып килде: үзе тегә киемнәрне Алсу, ничек тели, шулай тегә. Һәм начар да текми. Ялтыравык киенмәсә дә, курсташ егетләрнең күзләре гел аңарда. Сизә-

тоя бит ул егетләрнең карашын. Бер тапкыр аңа укытучылары Светлана Михайловна да игътибар итте. Яшьлеге, чибәрлеге белән башка укытучылардан аерылып торган Светлана Михайловна аны коридорда туктатты да, бер читкә дәшеп алды.

— Муртазина, җәен стюардесса булып эшләргә телисеңме? Вакытлыча. Мин үзем шуннан да әйбәт ялны күз алдыма да китерә алмыйм.

— Светлана Михайловна,— дип гаҗәпләнде Алсу. Гаҗәпләнмәслек тә түгел: чибәр, яшь укытучыны һәрчак ыспай, купшы киенгән шәһәр кызлары уратып алган булыр. Светлана Михайловна үзе дә гади булса да зәвыклы киенә иде.

— Туктатуыма гаҗәпләнмә. Гүзәл кыз син, Алсу.

Алсу колакларына кадәр кызарып чыкты.

— Ну-ну, гаҗәп матур килеп чыга синең бу елмаюың. Сокланырлык. Ә бит, дускаем, безнең күбебезгә әнә шул сихри елмаю, хатын-кызга гына хас, ир-атны магнит кебек тартып тора торган серле елмаю җитми. Аннары йөрү дә.— Светлана Михайловна ирләрчә атлап узган студентканы карашы белән озатып калды.— Ирләрчә киенәбез, ирләрчә селкенеп йөрибез. Нәфислек югала бара кебек безнең затта. Ә бит, дускаем, хатын-кыз — гүзәлләрнең дә гүзәле. Мин быел җәен бер авылга бәрәңге алырга бардым. Шунда бер яшь киленнең көянтә-чиләк белән чишмәдән кайтканын күрдем. Күрдем дә таңга калдым. Мин үземне матур йөрим дип белә идем. Сизәм-күрәм, ир-ат теге киленгә әйләнеп карый. Монда, дускаем, мин дә югалып калдым. Мин аны судан кайтканда гына шулай матур йөри дип торам, бер тапкыр тегенен урамнан үткәнен күрдем. Беләсең килсә, көнләшүемнән үлепләр китә яздым. Матур йөри дию генә аз булыр, аккоштай йөзә менә, йөрми, гүя йөрүе белән бер укыганда ятлардай шигырь яза. Бөтен гәүдәсесыны, килеш-килбәте елмая-көлә. Синдә дә, Муртазина, шул килендәге хәрәкәтләр бар. Беләсеңме, кил әле син безнең тулай торакка. Без анда «Гүзәллек» дигән түгәрәк оештырып ятабыз. Килерсеңме?..

«Рәссаммы әллә бу кеше, әллә мине ясыймы?»— дип, Алсу тагын эскәмия аша утырган сакалбайга карап алды. Ул да карый икән бит, әллә Алсудан күзен дә алмый инде? Алсуның битләренә гүя гөлләр кунды, йөзенең алсуланып китүен сизде ул — бер мәлгә генә аларның күзләре очрашты. Алсу оялудан түбән карады, ә ул алмый карашын, һаман карап бара. «Белә микән бу сакаллы адәм минем кияүдә икәнемне?.. Белсә соң! Ә ул миңа гашыйк булган булса?.. Һи-и, җүләр дә соң үзем...»

Алсу өченче курста укыганда ук кияүгә чыкты. Менә бер ел инде ул Насыйр белән яши. Хәзер инде Насыйр — Алсуның ире. Ире-ире дә, әллә нигә иләшеп кенә китә алмый Алсу үзенә. Бер караса ярата кебек, бер караса, ят кебек. Шулай иләшәләрдер инде. Кияүгә укып бетергәч чыгарга кирәк булган да бит. Әллә нигә ашыга төште шул. Ыспай, оялчан табигатьле Насыйрны күрде дә, егет көннән-көн күңеленә якыная барды, ә инде өйләнәм дигәч, няк кагудан ары китә алмады. Начармы, яхшымы, Насыйрның өе бар, әнисе белән генә тора. Тулай торакта да яшәп туйган иде инде. Танышулары Идел буенда булды. Атна саен Алсулар Идел буена коенырга киләләр иде, шунда таныштыул Насыйр белән.

Насыйр Алсуны күтәреп кенә йөртмәде. Хәер, күтәреп тә йөртте. Һәр көн вокзалга кадәр озата килде, кич белән кайтканда каршы алды. Озата иде дә, үзе тизрәк эшенә чаба иде. Насыйрның эше әйбәт, пыяла өрүче булып эшли ул. Яхшы хезмәт хакы ала. Бер тапкыр электричка тимер юлдан чыкты, тимер юлчылар өч сәгатькә якын поездны юлга төшерә алмый җәфаландылар. Насыйр аны көтеп торган икән. Электричка килеп туктауга, мәйданда Насыйрны күргәч, Алсу аны кызганудан гаҗизләнеп калды.

— Җүләрем, шулай ярыймы инде. Ашамагансындыр да әле үзең.
— Син дә ашамаган бит,— дигән иде Насыйр, Алсуның болай да нечкәреп киткән күңелен тәмам җилкендереп.
Кыскасы, Насыйр әйбәт ир иде. Кияүгә чыккан кызларның барысына да шундый ир тисә, тоташ тату гаиләләр генә яшәр иде бу дөньяда. Ә бүгенгә йөз гаиләдән алтмышы аерылыша. Статистика! Алсу белән Насыйр яшәрләр. Насыйр аңа хезмәт хакын тиененә кадәр кайтарып бирә. Дөрес, ул акча көне-сәгате белән Насыйрның әнисенә күчә, ләкин эш андамыни, иң мөһиме, ул аны башта хатынына кайтарып бирә.
Әйе, канәгать иде Алсу иреннән. Канәгать иде — кичәге көнгә чаклы. Кичә әнә шул түгәрәк сакал блокнотын онытып калдырды. Ул бик ашыгып чыгып китте. Шунда бер ир-ат онытылып калган блокнотны күреп алды да, ачып карады һәм Алсуга таба борылып:
— Сез бит бу. Танышыгызмы әллә? Мәгез, үзенә бирерсез,— дип, җавап көтмәстән, блокнотны аңа сузды.
Беренче биттә үк ул үзенең рәсемен күрде. Рәссам аны шул хәтле охшатып ясаган иде, үз сурәтен күрүгә, кып-кызыл булды Алсу.
Электричкадан чыккач, ул гадәттәгечә бер читтәрәк басып, халык үткәнне көтеп торды. Бары тик мәйдан бушап калгач кына фонарь астынарак килде, блокнотны ачып карады — аның йөрәге дөп-дөп тибә башлады.
Күр әле моны, икенче биттә дә, өченчесендә дә Алсу. Һәм төрле күренештә, төрле кыяфәттә, төрле киемдә. Менә ул көзге кара пальтодан, бәрхет кепкадан. Менә ул елмая, көлә, моңсуланып утыра. Менә ул электричкадан төшә, менә ул китап укый, журнал актара, каерылып, ишектән кереп килүче берәүгә карый...
Алсу блокнотны күкрәгенә кысты. Шушы минуттан салам чәчле, түгәрәк сакаллы, сары йөзле рәссам аның күз алдыннан китмәде.
Өйгә ул гаепле кеше сыман кайтып керде. Насыйр аны ишек төбендә каршы алды:
— Кайттыңмы? — Гадәти хәл буларак, ул җавап көтмәде, борылып китәргә итте, әмма ниндидер бер мәлдә ирнең карашы хатынының күзләренә тукталды.— Сиңа ни булды?
— Берни дә булмады.
— Күзләрең көлә, йөзең балкый. Бер-бер имтиханың алдан бирдеңме әллә?
— Әйе,— диде Алсу, гомерендә беренче тапкыр ирен алдап.
Алсу пальтосын салды, шкафка элде, ишек янындагы көзгегә күз төшереп алды. Барысы да тәртиптә кебек иде, тик менә күзләре генә чынлап та елтыр-елтыр килә шикелле.
Блокнотны Алсу дипломатына яшерде, иң аска, конспект дәфтәрләре астына салды.
— Менә, күр, нәрсә ясадым,— дип килеп чыкты түр яктан Насыйр.
— Ни бу? Ой! Әллә исәннәр инде?
— Юк, ләкин исән кебек. Балык та балык, алар да балык, копия.
— Аһа. Чынлап та охшаганнар. Карале, тач тере сыман йөзәләр.
Алсуга Насыйр ясаган әйбер ул хәтле ошамады, әмма юри исе киткән булып кыланды ул. Хикмәт шунда: аның мондый сувенирны базарда да күргәне бар иде. Графинга охшаган пыяла эчендә балыклар йөзә, алар төрле төстә һәм, җентекләбрәк карамасаң, гел тереләр сыман.
— Матурмы? Базарда биш сум тора. Биш сум,— диде Насыйр горур төстә.
— Матур. Әни кайттымы?
— Юк. Мин аш салдым инде.
Хәзер нәрсә эшлисен белә иде Алсу. Әйе, хәзер ул бәрәңге әрчеп салыр, ит пешкәч, бәрәңге белән итне алыр да токмач өстәр, суган турар,

кипкән укроп сибәр. Һәм аш әзер. Бүләсе дә ишегалдында нидер эшләп йөрүче Насыйрны чакырасы гына кала. Аш өлгерде, тик Алсуның Насыйрны чакырасы килмәде. Ул дипломатын ачты, дәфтәрләр астыннан блокнотны тартып чыгарды.

Әгәр дә мәгәр Алсу үзен шушы рәсемнәрдә күрмәсә, кичәле-бүгенле үлеп киткән булса, никадәр чибәр, соклангыч сылу булганын белми үлгән булыр иде. Тикмәгә генә аны рәссам күреп алмагандыр шул. Ул чынлап та матур икән бит. Күр әле моны, баскычтан төшеп килүен, ничек оста тотып алган.

Аяк тавышлары ишетелде, Алсу тиз генә блокнотны дипломатына яшерде һәм аш бүлә башлады. Насыйр керде, фуфайкасын салып, кулын юды, өстәл янына килеп утырды.

— У-у, исе син пешергән ашның! Телең йотмалы.

— Аша. Әни нигә кайтмый икән инде?

— Икенче сменага калды ул.

Ни сәбәпледер, кыен иде Алсуга Насыйр белән икәүдән-икәү генә калуы. Риясыз җан Насыйр моны аңламый иде. Бүген Алсуның бигрәк тә берүзе каласы килде. Ни өчен? Белми. Ичмасам әнисе дә юк. Ул булганда, килен белән каенана нинди дә булса гыйбрәтле хәл турында сөйләшәләр. Насыйр телендә эш тә аш.

— Тавыклар кетәгенең сәндерәсе җимерелеп төшкән икән. Ясап куйдым әле. Теге чуар тавык әтәчне сихерләгәндер, билләһи, яныннан да китми, юньсез. Кайберләрен суярга да вакыттыр инде, тавык симерсә, күкәй салмый башлый, диләр бит.

Алсу дәшми, ашавын белә. Насыйрның әңгәмәсен куәтләп сүз әйттеңме, соңыннан һич туктатам димә, качып котылып булмый башлый, лекцияләреңне кабатларга бирми йөдәтә.

— Иртәгә якшәмбе, бездә яшьләр кичәсе була, барабызмы?

Алсу, башын күтәреп, иренә карый, аны ни өчендер таныш булмаган рәссам белән чагыштыра. Рәссамга кимендә утыз, утыз биш яшь булыр, ә Насыйрга нибарысы егерме биш, Алсуга егерме ике яшь тулды.

Исендә, Насыйр үзләренә бик чакыргач, барырга риза булды. Аларны Насыйрның әнисе каршы алды. Әтиләре ике ел элек үпкә рагыннан үлеп киткән икән.

— Мәрфуга атлы мин, элек Латыйп Мәрфугасы идем, хәзер әнә Мәрфуга булып кына калдым,— диде ул, Алсуны күзәтә-күзәтә. Насыйр болай да кыз янында бөтерчектәй бөтерелә иде, шуңа карамастан, әнисе аңа:

— Я, нигә катып торасың, түр өйгә алып кер кунагыңны, күрсәт бүлмәңне,— диде.

Анасы хуплагач, Насыйр кыз янында тагын да өтәләнә башлады. Әле Алсуга чүәк китерде, әле китап, әле журналлар — чәй өлгергәнче караштыра тор, янәсе.

Ана белән ул шул хәтле тату, бер-берсен аңлап яшиләр кебек күренде аңа, хәтта көнләшеп куйды кыз. Дөресрәге, үзе дә сизмәстән, егеткә булачак ир итеп карады. Алты почмаклы өй, кош-корт. «Ява» мотоциклы, алтын куллы Насыйр. Ул арада Насыйр пыяладан үзе ясаган хикмәтле «сәнгать әсәрләрен» күрсәтә башлаган иде инде. Менә Шүрәле, менә су анасы, ә менә бусы — Пушкин әкиятендәге Балда.

Кара чәчле, уртача буйлы, күрәктәй зур куллы, күк күзле, төз борынлы, чылгыйланып торган мыеклы эшче егет үз өендә тагын да якынрак булып киткән иде Алсуга. Хәер, үз әнкәсе әйтмешли, нигә ул ир-атка матурлык та сиртмә буй, иң мөһиме — сине хөрмәт итсен, яратсын, итагатьле, тыйнак, тыңлаучыл булсын, тагын шуңа өстәп — эчмәсә, тартмаса... Ә бит Насыйр — тәмәке дә тартмый, артыгын эчми дә торган егет. Кыскасы, Насыйр кебек ир турында хыялланмаган кызлар бик

аздыр, булса да, бик аздыр. Насыйр исә аны бүген үк өрмәгән җиргә генә утыртмый.

Табын янына утырышкач, чәй көйли-көйли, Мәрфуга апа сорап куйды:

— Атаң-анаң кай якларда яшиләр инде, балакай?

— Башкортстанда, Күгәрчен районында. Үз көннәрен болай үзләре көтәләр инде шунда.

— Семьягыз ишлеме соң?

— Мин — дүртенче бала. Миннән башка тагын ике сеңелем бар. Бер апам Уфада, университетта укыта.

— Атаң кайда эшли?

— Гади эшче ул. РТСта трактор, комбайннар ремонтлый.

— Мал-туарыгыз да бармы?

— Район үзәге саналса де, зур авыл кебек ул безнең Күгәрчен. Сыер, сарык-кәҗә асрыйлар. Кәҗә мамыгыннан инәки шәл бәйли.

— Шул кәҗә мамыгыннан бәйләгән шәлне ничә тапкыр алам-алам дидем, гомер үтә, алып булмый да булмый. Латыйп мәрхүм дә алам дип йөргән булды, алалмады.

— Мин сиңа, әнием, үзем алып бирәм мамык шәлне,— диде моңа кадәр сүзгә кушылмый гына утырган Насыйр.

— Амин. Ярый, улым, шулай итәрсең,— Мәрфуга апа Алсуга текәлебрәк карады, аннары улына:— Әүвәл башлы-күзле бул, балакай,— диде.

Мәрфуга апа Алсуны күргәч тә якын итте, күргәч тә ошатты булачак киленне, моны Алсу аның «син» дип сөйләшә башлавыннан ук сизеп алды. Әнисе «башлы-күзле» бул дигәнгә тәмам оялып, кызарынып утырган Насыйр, үҗәтләнә төшеп, әнисенә үртәлеп карады, алай да аңлатмагач, тамак кырды: бу нишләвең инде, әни, күрмисеңмени улың оялып утыра янәсе.

— Ярар, ярар, колакларыңа хәтле кызарынып утырма. Үзең өйләнәм дә өйләнәм дип йөдәтә идең түгелме соң. Күп сайланма, менә сиңа кәләш. Алсу акыллым, чык әле шуңа кияүгә. Әйбәт ул үзе, кулыннан килмәгән эш юк. Бераз оялчанрак болай. Анысы үтәр, баштарак атасымәрхүм дә шулайрак иде. Гел кулга өйрәтелгән мал иде инде, соңыннан, малакаем, ир ирлеген итте, яратты шундый итеп... Һәй, аларны искә төшерсәңме... Пар күгәрченнәр кебек яшәгән идек... Күр әле моны, комачаулап торам ласа... Түгелме? Бик әйбәт. Сез дә шулай яшәрсез, пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп. Укуың кайда инде, балакай? Насыйр укыйсың, дип сөйләгәнгә генә әйтүем...

— КАИда.

— Ир-ат һөнәре икән дә. Ярый, хәзер инде барысы да буталды. Хатын-кызлар ир-ат эшен башкара, ир-ат — хатын-кызларныкын дигәндәй. Мин үзем дә әнә цехком булып торам. Төп эшем исә — формалар ясау. Җиңел түгел эшем, авыр дип тә әйтәсем килми. Ир-атның ниндие юк та, хатын-кызның — ниндие. Оялып утырмагыз сана, кайбер аналар кебек арагызга кысылып йөрмәм, менә әйтте диярсез. Ничек телисез, шулай яшәрсез. Ничәнче курсны тәмамладың әле?

— Өченчедә укыйм.

— Укы. Бер сүзем дә юк. Насыйр эшләгәч, шул бик җиткән. Я, ярый, оялттым да ахырысы үзегезне. Мин күршеләргә чыгам, утырыгыз, гөрләшегез, музыка тыңлагыз әнә...

— Син, Алсу, ачуланма тагын аңа,— диде Насыйр, әнисе чыгып киткәч, җиңелчә генә Алсуга кагылып.

Алсу кулын алмады, Насыйр аңа якыная төште.

— Алсу, син әнигә ачулана күрмә тагын, дим. Ул шундый инде, күзгә бәрә дә әйтә.

Насыйр аны кочакларга да үрелә иде инде, кыз кисәк тайпылгач кына тыелып калды.

— Миңа китәргә вакыт инде, Насыйр. Кызлар көтәләрдер.

— Кемнәр?

Чынлап та, кем көтсен аны? Беркем дә көтми. Барысы да күрде бит, үзе теләп китте Насыйр белән. Җитмәсә курсташы Маринка: «Насыйр, бер рәттән ЗАГСка да кереп чыгыгыз инде»,— дип, артларыннан кычкырып калды.

*

* *

Кияүгә чыгуны бу хәтле җиңел булыр дип уйламаган иде Алсу. Әтиләренә ул озын итеп, тәфсилләп хат язды. Тегеләре ризалыкларын белдереп тормадылар, икәүләшеп килеп тә төштеләр. Моны һич тә көтмәгән Алсу каушый калды.

— Кияүгә чыгасың, өстеңә рәтле пальтоң да юк,— диде әтисе.

Әтисе белән әнисе гостиницада торырга булдылар, Алсу көн дә алар янына чапты; лекцияләрдән соң туй өчен әйбер-кара алырга кирәк иде. Әтисе аңа:

— Син, кызыкай, оялма, нәрсә кирәк, әйт, әтиең тикмәгә генә бирергә килмәде, кесәсендә мең ярым акча, әниең дә буш килмәде. Ул үз акчасына апайларыңа кием-салым алыр, мин — сиңа. Кем соң ул, буласы кияү диюем?

— Эшче.

— Эшче булса, әйбәт. Бик әйбәт. Дөнья тоткасы хәзер эшче кулында.

Алсу диванда утыра, әнисе белән әтисе — караватта. Гостиницаны ата-ана ошатты. Казанга беренче килүләре иде, ашыкмадылар. Әнисе:

— Торыйк әле, карт, бераз, әллә яңадан килеп була бу Казанга, әллә юк,— дип сөйләнде.

— Иртәгә Насыйрларга барабыз. Сөйләшергә. Үзе чакырды,— диде Алсу.

— Казаннан читтәрәк тора икән дә... Ярар, без әзер, алмага керерсең.— Әтисе кулына шөгыль таба алмыйча ишекле-түрле йөренә башлады.— Җәй танышалар, көз өйләнешәләр. Өлгерер идең әле институтны тәмамлагач та. Әнә Садрый Тәгъзимәсе...

Әтисе тагын бик күп мисаллар китерде, ләкин Алсу белә — ул болай гына сукрана, кызының өченче курста ук кияүгә чыгуын бик үк хупламаса да, каршы түгел иде. Монда килгәч кенә түгел, өйдә дә: «Кыз бала ул чәчкә кебек, вакыты җиттеме — өзсеннәр. Юкса корый, кибә, салкын тия башлый»,— ди торган иде.

Әтисе Уфада институтта укытучы булып эшләүче апалары Рита турында сөйләде. Ритага утыз яшь инде, һаман кияүгә чыкмый, аспирантурага керде, аны бетерде, менә хәзер доктор булмакчы. «Кияүгә чыксам,— ди торган иде апалары,— мин хыялыма ирешә алмаячакмын».

«Хатын-кызның хыялы — бала табу, әйбәт кияү табу. Ату хыял да хыял»,— дип тузынган иде әтисе шунда. Әнә өченче кызы Алсу тотты да кияүгә чыгарга булды. Кияү — эшче, төшеп калганнардан булмас, тулай торакта кефир эчеп гомер итми, үз йорты, үз хуҗалыгы, дигәндәй. Кыскасы, китте атаның кайгысы өченче кыздан. Хәерле булсын.

— Рита апаң да акча салам диде әле. Холодильник алырлар, ди.

Әнисе дә каршы түгел иде Алсуның кияүгә чыгуына. Шулай булгач...

* * *

Әнә шулай кияүгә чыкты да куйды Алсу. Хәзер менә дөнья көтәләр. Алсу бәхетле иде. Насыйр аның өчен үләргә әзер, каенанасы Мәрфуга апа (ул аңа хәзер әни, ди) киленгә куанып бетә алмады. Кырык яшендә ирдән ялгыз калган бу хатынга Алсудан битәр, аның ата-анасы, димәк ки, кода-кодагые ошаган иде. Эшчеләр, дөнья күргәннәр, әйбер кадерен беләләр. Килене дә әнисенә охшаса, бер дә ким-хур булмаслар. Һәрхәлдә алма агачыннан ерак төшми, диләр.

Тикмәгә генә ана күңеле сизгер була димиләр икән шул. Көннәрдән бер көнне ана кеше килене́ндә үзгәреш күрде. Артык чәчрәмичә генә, бәрелми-сугылмый гына эш башкарган килен бер ноктага текәлә дә, үз-үзенә бикләнеп уйга кала. Насыйр, әлбәттә, берни дә белми, ә менә каенана килене́ндәге бу үзгәрешне шундук күреп алды. Алай да сүз әйтергә базмады, ачуланышканнардыр, килешерләр, дип уйлады. Ләкин күрде-күзәтте дә улын, аңлады: ачуланышмаганнар. Насыйр һични булмаган кебек яши бирә, әллә ниткән сувенирлар ясый, базарга чыкмаса да, янәшәдәге санаторийда ял итүчеләргә илтеп сата.

Ана улының бу шөгылен күрде дә күрмәде дә. Кеше буш вакытын кая булса да куярга тиештер бит инде. Ә менә киленгә ирнең бу шөгыле ошамады кебек, һәрхәлдә куанмады ул ир алып кайткан акчага. Насыйр хәзер көненә бишәр, ә кайчак егермешәр сум да алып кайткалый иде.

Акчасын алган саен Алсу аңа үртәлеп карый. Хатыны күзләрендә хуплау күрмәгәч, Насыйр, акланганда й:

— Алалар бит. Ну, теләмисең икән, ясамыйм,— дигән булды.

Алсу дәшмәде.

Лекцияләрен кабатлап чыккач, ул Насыйр янына килеп ятты. Ире йоклый иде инде, Алсу аның тыныч кына мышнавын тыңлап ятты-ятты да, үзе дә сизмәстән көрсенеп куйды. Аның күз алдында салам чәчле, түгәрәк сакаллы рәссам хасил булды. Бүген дә шул ук өченче вагондагы үз эскәмиясендә, үз урынында утырып кайтты ул, үзе һаман рәсем ясый. «Һаман мине ясый микән?»— дип уйлады Алсу.

Вагонга шул арада ике ревизор килеп керде. Рәссам аларны гүя күрмәде, ул бөтен барлыгы белән рәсем ясауга бирелгән иде.

— Гражданин, ваш билет?

Ул аларны ишетмәде.

— Гражданин, кемгә әйтәләр!— дип кабатлады ревизор. Ревизорның ишелеп төшкән корсагын хәтта формасы да яшерә алмый иде.

«Аның билеты бар,— дип уйлады Алсу.— Бар. Ул хәзер аны табар».

Рәссам, ниһаять, башын күтәрде, кем әле сез дигәндәй, аптырап, ревизорга карады.

— Да, да, билет!— диде ревизор. Ул хәзер елмая, куанып елмая иде. Менә, ниһаять, билетсыз берәүне булса да эләктерде.

Рәссам кесәләрен актарды, әллә ниткән кәгазьләр тартып чыгарды, әмма билет чыкмады да чыкмады. Ахырда ул сүзсез генә чалбар кесәсенә керде, бөтәрләнеп беткән өч-дүрт өчлек чыгарды, берсен ревизорга сузды.

— Надо же,— дигән булды ревизор.— Эзләп маташкан була тагын, күз буяп.

Рәссам аңа тагын өч сум акча сузды.

— Бусы нәрсәгә тагын?

— Күп сөйләшмәс өчен,— диде рәссам әкрен генә.

— Ну бу яшьләрне...

Ревизор рәссамның кәефен бозды, ул блокнотын япты да тәрәзәгә карап кайта башлады. Яннан караганда аның йөзе ниндидер артистны хәтерләтә иде, бик якын, бик танылган артистны.

Электричкадан алар бергә төштеләр.

Алсу юри әкрен генә атлады. Куып житсен иде дә, һич югы бер сүз әйтсен иде. Мәгәр ул аны куып та житте, узып та китте, газета киоскысына туктап, газета алды, шунда аның кесәсеннән бер кәгазь кисәге төште.

Рәссам киткәч, Алсу юри шул кәгазьне күтәрде. Билет иде бу, бүгенге билет. Димәк, ревизор аны бөтенләй юкка рәнжетте. Алсу рәссамны куа китте, әмма аңа сүз катарга кодрәте житмәде. Алсу аңа һич югы рәхмәт әйтергә тиеш. Никадәр рәсем ясаган, әле һаман ясый. Кайда гына күрмәгән ул аны. Димәк, гел Алсуны күзәтеп йөргән. Нигә соң үзе кача, артына әйләнеп бер сүз булса да әйтми? Ни өчен Алсуны күзәтеп йөргән? Нигә соң үзе кача, артына әйләнеп бер сүз булса да әйтми? Ни өчен Алсуны котыртып йөри?

— Мин сезне күрәм. Күрәм,— диде рәссам, әйләнмичә генә. Рәссам Алсу белән тигезләште, дөресрәге, аны көтеп алды.— Мин сезне төшемдә дә, өнемдә дә күрәм. Әгәр бу дөньяда гүзәллек идеалы бар икән, ул — сез. Зинһар, дәшмәгез. Каршы әйтә күрмәгез. Минем сездәй сылу, гүзәл хатын-кызны беренче тапкыр күрүем. Сез...

Ул ниндидер сүз эзләде, тапмады, төсләр белән эш итә торган кеше бәлки әйтер сүзләрен әүвәл төсләрдә күрәдер. Ул Алсуга текәлеп карады.

— Сез минем мастерскойга килерсезме? Мин сездән ерак тормыйм. Мин сезне көн дә көтәрмен. Ишетәсезме, көн дә,— ул башын түбән иде, бер мәл аяк астына карап торды.— Сезнең арттан йөри-йөри, менә өченче пар туфли туздырам инде, тагын ничәне туздырасын хода үзе белсен.

Аннан үз-үзенә елмайды. Алсуны култыгыннан алды. Алсу китеп тә бара ала иде, кая инде ул ят кешедән култыклату, янәшә атлау да оят иде аңа. Берәр танышы күрсә, ни күзе белән әнисенә, Насыйрга күренер. Ләкин үзе белән һични кыла алмады, ул аны гүя сихерләде, гипнозлады, аны өйдә көтсәләр дә, баруын белде. Ярый әле Насыйр соңгы вакытта каршы алырга килми башлаган иде.

— Күз, төсләр ае,— диде рәссам.— Яратам көзге көннәрне, табигатьнең төрле төсләргә керә-керә чишенүен яратам. Әнә чаган, җәйләрен күзгә дә чагылмый, көз життеме, гүя чәчкә ата, күз алмалы түгел үзеннән. Күрәбезме?.. Мин сезнең портретыгызны ясар идем. Бик тә, бик тә ясарга телим мин сезнең портретыгызны.

Нигә гафу үтенә инде, бара бит Алсу, тәүге куркуы да каядыр китеп югалды, әйтерсең, ул ире белән атлый иде. Әйе, ул аның бик якын кешесе икән бит. Ул аны моңа кадәр күрми генә йөргән, ә менә хәзер, хәзер ул аны үзе эзләп тапты.

Ишегалды аша уздылар, рәссам кебек үк сары чәчле кыз тәрәзәдән карады, ул да түгел, мастерской ягыннан ак муенлы эт килеп чыкты. Алсу дерт итеп китте.

— Рекс, бар урыныңа. Ишетәсеңме, ни әйттем, Рекс! — диде рәссам.

Хуҗасы катгый төстә боерык бирсә дә, эт этлеген итте, килеп, Алсуны иснәде һәм әкрен генә, күптәнге таныш икән дигәндәй, китеп барды.

— Мин сезнең исемегезне дә беләм. Элек сезне ирегез исемегез белән дәшеп каршы ала иде. Алсу бит сез?..

— Алсу,— диде яшь хатын, беренче тапкыр телгә килеп.

— Әйдәгез, узыгыз менә монда.

Ишегалдының аргы башында сарай сыман зур гына нәрсә бар иде, шунда узды Алсу. Ишекне Алсу артыннан рәссам үзе япты.

Тыштан артык зур күренмәгән сарайның сарай булмавы, бүрәнәдән буралган зур гына өй икәне беленде. Өйнең уртасында ук диярлек зур мич, мич башында ятак.

— Кыш көннәрендә бик туңсам, шунда менеп җылынам,— диде ул, аклангандай, җыймаган урынын калын юрган белән каплады.— Салыгыз өстегезне, рәхим итеп, өйдәгечә хис итегез үзегезне. Зинһар, оялмагыз. Телисезме, мин сезнең алдыгызга тезләнәм. Мин сезнең гүзәллегегезгә әсир. Һәм мин сезнең сурәтегезне ясарга телим. Аннан үлсәм дә үкенмәс идем.

— Кирәкми. Мин күрәм бит, сез — талант. Сез — зур талант. Әнә теге картинагыз, Идел буе... Бусы кем? Су буендагы нәни кыз...

Алсу, шиңә башлаган чәчкәгә су сипкәндәй, ачылып терелеп китте, һәр картина янына туктап, соклануын яшермичә рәссамны мактады.

— Мин сезне беләм, сезнең картиналарыгызны күргәзмәдә күргәнем бар...

Рәссам гүзәл хатынның бу сүзләренә каршы тыенкы гына елмайды, һәр талантка хас булган кебек, аның да бу хатынга сер булып каласы килде. Яшь чакта кеше юк кына әйберен дә зур итеп күрсәтәсе килә, ә инде халык тарафыннан танылa башлагач, талант иясе көндәлек шау-шудан, ыгы-зыгыдан читтәрәк калырга тели. Нурмөхәммәттә бу хатын әллә ниткән, моңа кадәр үзе дә аңлап бетермәгән хисләр уятты; иң гаҗәбе — бу гүзәл аны болай ук яхшы беләдер дип, күз алдына да китермәгән иде ул.

Алсуның рәсемен ясау өч сәгатькә сузылды. Алсу белә иде: аны Насыйр көтә, борчыла, үз-үзенә урын тапмый, капка янына чыгып, зарыгып көтеп тора. Ләкин шулай булуын белсә дә, ул ашыкмады. Рәссамның салмак хәрәкәтләренә карап торуы рәхәт иде аңа. Ул, үз-үзен онытып, сурәт ясый, күзләре Алсуда, ә пумала тоткан кулы...

— Бүгенгә җитеп торыр,— диде рәссам, ниһаять, башын күтәреп.— Киенегез. Туңмадыгызмы?.. Киләсе килүегездә мичне кызурак ягып куярмын. Тышта яңгыр, зонтыгыз бармы?

— Бар.

— Рәхмәт сезгә, сүз тыңлап килүегез өчен рәхмәт.

Ул, якын килеп, Алсуны кулыннан алды, туры итеп күзләренә карады. Алсу курка калды, бу күзләрдә ниндидер көч бар иде, ул үзе дә сизмәстән аңа тартылды, туктый, үзе белән һични кыла алмады. Моны һич тә көтмәгән Нурмөхәммәт каушый калды, ләкин икенче мәлдә ул инде йомшак кына итеп Алсуның битеннән үбеп алды.

— Хуш, иртәгә кадәр...

— Хушыгыз... Өченче вагонда...

Һәм алар икесе берьюлы елмаештылар.

*

* *

Иң мөһиме — Насыйр алдында каушамау иде. Ни әйтер ул аңа? Ни дип ялганласа да, Насыйрның белүе бар: деканатка шалтыратыр, станциягә. Ул шундый. Әллә курсташ кызның туган көнен уздырырга тулай торакка кереп чыктым дияргәме?..

Алсу, йөгерә-атлый, үз урамнарына борылды, очраган бер кеше аннан: «Нишләп болай соңга калып йөрисең, чибәркәй, беләбез кемдә булганыңны!»— дияр сыман иде.

Капканы сак кына ачты, Насыйр аны кече капка артында посып көтеп тора икән, ул: «Һайт!»— диюгә, тәмам өнсез калды. Куркуы, шомлануы, шикләнүе — барысы бергә җыелган иде, үзе үк ир кочагына сеңде.

— Ай, Насыйр, нишләвең инде бу, котымны ала яздың бит...
«Юк, ул миңа бер дә ят түгел, тоелган гына. Насыйр минем ирем».
...Бер көн соңга калып кайту — бер хәл, ә менә бу хәл көн дә кабатлана башласа, нишләр микән ир?

Алсу еш кына ике-өч сәгатькә соңга калып кайта башлады. Башта хатынының бу кыланышын уенга, янсә изге ялганга кайтарып калдырырга теләде Насыйр — дәшмәде, күрмәгәнгә салышты, ә инде бу хәл һәр көнне кабатлана башлагач (күрәсең, каравыллап торгандыр), Алсу Нурмөхәммәт капкасыннан чыгуга, аның терсәгеннән эләктереп алды.

— Привет!— диде ир, исе китмәгәнгә сабышып.
— Сәлам,— дигән булды Алсу.
Алсу терсәген ычкындырды да тиз-тиз атлап китеп барды.
— Тукта, Алсу!
— Кайтсаң, әйдә,— диде Алсу борылмый гына.
Насыйр аны куып житте, янә терсәгеннән кысып тотты.
— Син нишләп монда?
— Рәсememне ясый ул минем.
— Әһә, рәсемең ясый, димәк... Һәм күптән ясый башладымы ул сине?

Алсу жилкәсен жыерды, кабат терсәген тартып алмакчы итте, әмма терсәкне Насыйр нык тоткан иде.

— Зато мин беләм,— диде Насыйр теш арасыннан.— Уникенче октябрь көнне ясый башлады ул.

Әйе, чынлап та шулай бит әле, ул көнне яфраклар коела иде, күзгә манзара. Нурмөхәммәт табигатьнең әнә шул күзгә бизәкләренә игътибар итте. Шул көнне ул аның беренче тапкыр битеннән үпте, кыяр-кыймас кына, Алсуның күңелен рәнжетүдән сагаеп кына.

— Беләсеңме синдәй күпме чибәрләр булганын бу мастерскойда?
— Ничек миндәйләр?
— Беләсеңме күпме узганын аның кулыннан синдәйләр дим.
— Белмим, белергә дә теләмим. Минем бары тик рәсememне генә ясый ул.
— Әлбәттә, ник ясамаска?!

Ирнең «беләсеңме күпме узганын аның кулыннан синдәй чибәрләрнең» дигән сүзе Алсуны тетрәндереп жибәрде, ирнең һәр сүзе йөрәгенә ук булып кадалды. Чынлап та, аңа кимендә утыз-утыз биш яшьләр булыр, шул елларда кемнәрнең генә сурәтләрен ясамагандыр бу рәссам. Һәммәсен үбеп озаткандыр, күзләреннән үбеп каршы алгандыр, һәммәсенә дә, бер аңа гына әйткәндәй, матур-матур сүзләр әйткәндер. Ә мин аңа ышана калдым.

«Әйе, әйткәндер»,— диясе килде Алсуның, әмма әллә нигә теле әйләнмәде. Кисәк кенә бу аңа чыннан да шулай булгандыр кебек тоела башлады. Ләкин бит ул аны үзе дә яшермәде. «Ялган сөйлисең, Насыйр. Аның миннән башка беркеме дә юк. Ул ялгыз. Ул бәхетсез. Мин кирәк Нурмөхәммәткә, мин — Алсу...»

Алсу сүз таба алмады. Нишли алыр иде ул аның өчен?.. Бернәрсәне яхшы белә иде Алсу: аның янында үзен аңлый торган, һәр даим хәленә кереп, йөрәк тибешенә кадәр тоеп яшәүче яраткан кешесе булырга тиеш. Ул — ялгыз. Бәлкем, Алсу — аның бердәбер куанычы, юанычыдыр. Ул аны гүзәлләрнең гүзәле итеп күрә, аннан илһам ала, ижатына дәрт таба. Көтмәгәндә тормышына килеп кергән Алсу — аңа алла да, алиһә дә, иң гүзәл хатын-кыз да. Алсудан соң ул берәүне дә ул хәтле камил һәм гүзәл итеп ясый алмас. Алсу аның янына илһам бирер өчен килде, чөнки чын талантка ялган гүзәллек кирәкми. Нурмөхәммәтнең нинди талантка ия булуын аңласа, бер Алсу гына аңлыйдыр. Рәссам беркөнне аңа: «Картиналарыма игътибар итсеннәр, талантымны танысыннар өчен, миңа үлеп карарга кирәк»,— диде. Әйе, әллә шаяртып,

әллә уенын-чынын бергә кушып, «үлеп карарга кирәк»,— диде. «Юк-юк, син яшәргә тиеш, кадерлем Нурмөхәммәт абый, яшәргә! Синең янында мин дә үземне кеше итеп сизә башладым. Ихтимал, мин ялгышамдыр, ләкин сизәм, тоям, миндә үзем дә аңлап бетермәгән үзгәреш булды, мин үз-үземне тантым. Моңарчы мин үз дөньяма бикләнеп яшәгәнмен, сукыр булганмын. Ә хәзер әйләнә-тирәмә — бөтен дөньяга башка күзлектән карый башладым. Искиткеч гүзәл икән бу дөнья! Һәм син ачтың минем өчен бу гүзәллекне, син, Нурмөхәммәт абый».

Хыялында ул мәһабәт күргәзмә залында йөри, төркем-төркем кеше бер картина яныннан икенчесенә күчә, сокланып, картиналардагы төсләр уенын читкәрәк китеп карап, күзәтеп тора. Алсу да, халык агымына ияреп, бер секциядән икенчесенә күчә, күңелгә шул тиклем якын булган бу таныш картиналарда моңа кадәр күрелмәгән яңа бизәкләр таба. Күргәзмәнең түрендә рәссамның соңгы иҗат җимеше — Алсуның сурәте. Һәммәсен — олысын-кечесен магниттай үзенә тартып торган күз карашы, сихри елмаюы... Таң кала халык. Сүз кирәкми, төсләр, буяулар гына аңлата ала аның гүзәллеген. Ул да түгел, портрет каршына рәссам үзе килеп баса, тынып калган күргәзмә залы кисәк көчле алкышка күмелә. «Искиткеч уңыш!»— диешәләр чал чәчле агайлар. «Талант!»— дип көнләшәләр яшь рәссамнар. Нурмөхәммәт тыенкы гына елмая, шатлыгын уртаклашучыларның кулларын кыса, ә күзләре Алсуны эзли...

— Ник дәшмисең, һич югы бер сүз әйт.

Алсу сискәнеп китте, иренең җимерек кашларына, чаткылар уйнап торган күзләренә, аның беләген шатырдатып тоткан кулына карап куйды.

— Ни дисәм дә, син мине аңламассың, Насыйр.

— Кая инде безгә — каткан тезгә,— диде Насыйр, көлемсерәп, әмма күз карашында тетрәндергеч утлар биешә иде.

Алсуның Насыйрга Нурмөхәммәттәге талант турында сөйлисе килде, әмма иренең мыскыллы елмаюы аны бу уеннан тыеп калды.

— Синең каршыңда минем һичнинди гаебем юк, Насыйр. Карама миңа шул тиклем ачулы күзләрең белән, һичнинди гаебем юк, Насыйркаем.

— Ярый-ярый, әйдә, сөйләп кара, намус, әдәп турында да онытма.

Ниһаять, Насыйр кулын ычкындырды, янәшә атлап киттеләр.

— Нигә телең йоттың?— диде Насыйр.

— Мин сиңа бүтән бер сүз дә әйтмим, Насыйр. Мин синең белән бер дә ачуланышырга теләмим. Рәнҗим мин синең бу кыланышыңа.

Иренең кәефе юклыгын, юл буе сөмсере коелып кайтуын күреп, Алсу аңлашуны артык дип тапты — ул барыбер ышанмас.

— Насыйр! Ишетәсеңме, Насыйр дим!— кайтып җитәрәк Алсу туктапып калды, үрелеп, иренең борчулы күзләренә карады.— Карале, Насыйр, бу турыда әнигә әйтмә, яме?

— Ни турында?

— Минем рәссам янында булуым турында.

Моны ничек аңламак кирәк? Ир тәмам аптырап калды. Әйтерсең, алар арасында берни дә булмаган, әйтерсең, ир аны ят кеше яныннан табып алып кайтып та килми.

Насыйр да туктады, Алсуны үзенәрәк тартып, хатынының күзләренә карады.

— Ул сине ярата мы?

— Җүләр. Менә җүләр дисәң дә җүләр инде.

— Әйе, мин җүләр,— дип килеште ир.— Тиле мин, тиле. Көн-төн эшләп, мин аны укытам, ә ул художник белән кети-кети уйный. Әйе, мин җүләр!

— Тимә аңа, Насыйр. Ул болай да бәхетсез кеше.
— Һәм син ул бәхетсез кешене бәхетле итәргә булдыңмы?!
— Насыйр,— дип ялварды Алсу.— Житте бу турыда. Әйдә, кайтыйк, әни көтәдер...

Алсуның күңелен үкенечле сагыш талкый иде. Рәссам аңа тагын азрак утырырга кушты, әллә шаярып, әллә чынлап бөтенләй кал дип тә ялварды. Алсу якын да килмәде, имеш, ире бар, көтәдер, борчыладыр. Аңлардай кешеме Насыйр Алсуның уен-теләген, хыялын?! Юк. Нурмөхәммәт аны аңлар иде.

— Әйе, ул талант,— дип, һаман тынычлана алмады Насыйр.— Ә синең ирең бездарь, чүп-чәләмә, шулаймы?
— Мин сиңа алай дип әйтмәдем.

Алсуның Насыйр белән талашасы килми иде. Гомумән, ул бүген бәхетле иде. Ә менә Насыйр моны күрми, белми, аңламый.

— Ул миңа акча да түләргә вәгъдә итте, рәсемгә төшкәнем өчен, натурщица булганым өчен. Минем сурәтемне Мәскәүгә күргәзмәгә жибәрергә исәбе, тиздән аның башкалада күргәзмәсе ачылачак.

Менә күр инде хәзер синең хатының нинди кеше дигәндәй, Алсу иягең чөя төшеп, иренә карады. Ире аны һәр көнне күрә, Алсу — Алсу инде, һичнинди үзгәреш юк. Шул ук чөенке борын, шул ук кара күзләр, дугаланып киткән кыйгач кашлар, чак кына күперебрәк торган нәни баланыкыдай нәфис иреннәр.

— Йә-йә, алай бик кәпрәймә. Подумаешь, красавица...

Әйе, красавица, беләсең килсә, Насыйркаем, син генә күрергә теләмисең. Ләкин шулай дип уйласа да, үз-үзендә ят кыланыш күреп, Алсу кечерәеп калгандай булды, баягы тәкәбберлегенең, ваемсызлыгының әсәре дә калмады. Насыйр аңа мыскыл катыш елмаю белән карап тора иде.

— Бүгеннән ул йортка аяк та басмыйсың, ишеттеңме!— диде ир, кече капканы ачып, хатынны алдан жибәрде.— Картинасы тәмамланмаса, күңеленнән ясап бетерер. Талантлы булгач, фантазиягә байдыр әле.

Алар болдырдан күтәреләләр иде инде. Әниләре каршы чыкты.
— Кая болай югалдыгыз? Ашым күптән суынып бетте.
— Һавада йөрдек,— диде Насыйр, әнисенең күзләренә карамаска тырышып, Алсуны алдан уздырып, ишекне япты.

*
* *

Өченче вагон, өченче эскәмия, тәрәзә янындагы урын. Нурмөхәммәт үз урынында иде. Алсу килеп утыруга, алар күзгә-күз карашып алдылар. Алсу теләр-теләмәс кенә елмайды. Ләкин елмаюы бик сәер килеп чыкты, Нурмөхәммәт нидер сизеп, аның янына күчеп утырды. Күчеп утырды да Алсуның кулыннан алды:
— Ул-бу булдымы әллә, нигә болай боексың?..

Нурмөхәммәт бу көнне бик сүзчән иде, Алсуга ул гомер ишетмәгән матур-матур сүзләр сөйләде. Алсу андый сүзләргә өйрәнеп килә иде инде, юл буе дәшмәде, аңа татлы сүзләрне тыңлавы рәхәт иде.

Әле электричка туктамас борын ук, Алсу мәйданда аны көтеп торучы Насыйрны күрде. Күрде дә, йөрәгенә дерт итеп китте. «Нишләргә тиеш ул, нишләргә?..»

Нурмөхәммәт тә Насыйрны күрде һәм Алсуга нелә төшеп:
— Алсу, кадерлем, курыкма, кыю бул. Мин синең кыю булуыңны телим,— диде.

Күңелен юл буена ныгытып кайтса да, электричка ишегеннән чыгуга, Алсуның аяклары Насыйрга таба атладылар, гүя аны кемдер култыклап алып бара иде. Ул чамалады: ирнең бөтен кеше алдында рәссамга бәйләнеп җәнҗал чыгаруы бар иде. Алсу моны теләми, аның күңелендә рәссамның изге кеше булып калуын тели ул.

— Һаман шуның белән бер вагонда кайтасың икән әле,— диде аңа Насыйр, янына килеп туктауга.— Тагын бер күрсәм, беләсеңме, нишләтәм мин аны?

— Син аны берни дә эшләтә алмыйсың, Насыйр. Ул көчле кеше, ихтыяры көчле аның, сиңа гына бирешерлек түгел. Әйдә кайтабыз. Җитте сиңа, кеше көлдереп йөрмә.

Алсу ирен култыклап алды, һәм алар баскычка юнәлделәр. Шул хәтле әйләнеп карыйсы килде Алсуның артына, шул хәтле күрәсе килде Нурмөхәммәтне тагын бер тапкыр. Аның артыннан карап тора микән? Әмма кодрәте җитмәде.

Өйгә кайткач, Алсу үз-үзенә урын табалмый йөдәде. Насыйрның да кулы эшкә бармый, диванга утырган да каш астыннан гына хатынның һәр хәрәкәтен күзәтә, гүя ни турында уйлаганын белергә тели иде. Ирнең авыр күз карашы Алсуны чарасыз итә, ул үзен пыяла сувенир эчендәге балык кебек хис итә башлый: әле бер эшкә, әле икенчесенә тотына, әмма ни эшләргә генә керешмәсен, ирнең стенадай каты күз карашына барып төртелә.

Салмак кына, һич ни булмаган гамьсез бер кыяфәттә Алсу киштәдәге сувенирларны урыныннан күчерә-күчерә тузаннарын сөртә. Алар барысы да — бер фасонда, бер формада эшләнгән пыяла сувенир-уенчыклар. Кайчандыр Алсу исе китеп карый иде пыяла савыт эчендәге су дөньясына. «Балыкларын, балыкларын кара, Насыйр, тере диярсең, чын әгәр!»— ди торган иде. Тора-бара мондый сувенирларга күнегә башлады, аларның күбесе, игезәк балалар сыман, бер-берсен кабатлыйлар. «Копия, штамп»,— дия башлады Алсу эченнән генә. Ә инде Нурмөхәммәт ачкан дөньяның гүзәллегенә инангач, бу пыяла әйберләргә Алсу тыныч кына карый алмый башлады. Рәссам ясаган картиналарда җанны кузгатырлык сәнгатьчә дөреслек, чынлык күрсә, аның рәсемнәрен караган саен карыйсы килеп торса һәм күргән саен, бәхет кошы тоткандай, йөрәгең уйнавын тойсаң,— Насыйр ясаган әйберләр алар янында югалып, уңып калалар, күзгә бәрелеп торган фальшь, зәгыйфьлек күңелне биздерә иде.

Сувенирларны урыныннан күчергәндә, аларның берсе кулыннан төшеп китеп челпәрәмә килүен сизми дә калды Алсу. Хатынның һәр хәрәкәтен күреп-күзәтеп торган Насыйр бер сүз дә әйтмәде. Алай да эченнән генә: «Их, син, җебегән, әрәм иттең әйберне»,— дигән кебек Алсуга карап алды. Шулай да сиздермәскә тырышты, берни булмагандай утыра бирде. Ә Алсу? Юк, ул курыкмады, җәлләмәде дә. Фальшь әйберне ватудан аның кәефе бозылмады. Ул битараф бер рәвештә салмак кына хәрәкәтләр белән идәндәге пыяла ватыкларын җыеп алды, чүп чиләгенә илтеп түкте.

Ватык графин эченнән чыккан балык — тере җан түгел шул, ә Алсу — җан иясе. Ул да шулай гомергә графин эчендәге балык кебек яшәр микәнни? Юк инде, хәзер дөнья аңа бөтенләй башка яктан ачылды.

* *

«Нигә ул бүген юк, кайда ул?» Алсу вагонга кергән бер кешене күзеннән кичерә торды. Ике якка эшерелеп ачыла торган ишектән бер-

туктаусыз кешеләр керәләр. Ә Нурмөхәммәт юк та юк. «Хөрмәтлем Нурмөхәммәт абый, кайда сез, кайларда йөрисез? Мин сезне көтәм. Сезгә бүген бер сүз әйтергә булдым. Яратам мин сезне, яратам».

Ишекләр ачылды да ябылды, ә Нурмөхәммәт кермәде дә, күренмәде дә. Менә вагон дерт итеп китте, шулвакыт Алсуның да йөрәге кысылып куйды. Вагон кузгалды, пассажирлар утырыштылар. Алсу бөтенләй өметен өзде. Кинәт аның зиһене ачылып киткәндәй булды. Ул соңга калгандыр да арттагы вагоннарның берсенә утыргандыр, утыргандыр да, вагоннан күчә-күчә, Алсу янына киләдер. Белә бит ул Алсуның өченче вагонда икәнен...

Шулай бер тукталышны үтте электричка, икенчесендә тукталды, ә Нурмөхәммәт күренмәде дә күренмәде.

Алсуның йөрәген үкенү, үртәлү тойгысы биләп алды. Нигә, нигә ул теге вакытта аңа ияреп китмәде! Ә бит киткән булса, болай ук үкенмәс, үртәлмәс, өзгәләнмәс иде. Алсуның гәүдәсе кичерәйгәннән-кичерәя барды, гүя ул утырган урындыгына сеңәргә тели иде. Ул беркемне дә күрмәде, беркемгә дә күтәрелеп карамады. Дөнья аңа караңгы-караңгы булып киткән шикелле тоелды. Әле бит кайчан гына күңеле канатланып оча торган иде. Янәшәсендә Нурмөхәммәт кайта, Алсуның кулын учына алган, күзләре белән генә нидер сөйли, нидер аңлата.

Васильево тукталышы. Электричка туктар-туктамас, халык, дәррәү кубып, ишеккә юнәлде. Нурмөхәммәт белән кайтканда, Алсуның күңеле рәхәттә тирбәлә иде, гүя язгы көннәрнең берендә зәңгәр күктән, чылтыр-чылтыр килеп, әллә ниткән сихри аһәңнәр, тыңлап туймастай моңнар агыла. Рәссам янәшәсендә булганда, Алсу үзе дә, кош булып, күккә ашар сыман, канатлы, күтәренке иде күңеле.

Юк инде, вагоннардан төшкән кешеләр арасында да күренми ул. Инде нишләргә? Мәйдан бушады, бар халык таралып бетте. Ичмасам, Насыйр да каршы алырга килмәгән.

Алсу әкрен генә баскычка таба атлады. Шунда баскыч янында басып торган ике хатын әңгәмәсенә колак салды.

— И-и, ходаем, мескенкәй, өлгерермен дип уйлады микәнни...

— Өлгерә алмаган шул. Яшь-яшь кеше... баланы коткарган әнә, ә үзе...

Алсу алар яныннан үтеп китте. Кинәт аның йөрәге кысылып куйды. «Кемгә ни булган?»— дигән шомлы уй зиһенен телеп узды, кире борылып, сорыйсы килде, әмма җөрьәт итмәде.

Алай да Насыйр каршы алырга килгән икән. Вокзал бинасы янында Алсуны көтеп тора. Хатыны килеп җитүгә, ул аны култыклап алды.

— Нигә инде мәшәкатьләнеп йөрисең?— дип куйды Алсу. «Күрәсең, бүген юк ул, тынычлан. Берүзем кайтуыма үлеп шат инде син».— дип өстисе килгән иде, тыелып калды.

Ләкин шатлык күрми Алсу ирнең йөзендә, чырае агарынып киткән, никтер күзләрен яшерә. Авырып китмәгәе...

«Нурмөхәммәт абый, кадерлем, кая булдыгыз сез, нигә Алсуыгыз белән кайтмадыгыз?.. Ә мин сезне зарыгып көттем, керфек какмый, ишеккә карап бардым...»

Насыйр аңардан нидер сорады кебек, ләкин Алсу аны ишетмәде, аның күңеле Нурмөхәммәттә иде. «Ярый, Нурмөхәммәт абый, бүген сезнең эшегез булгандыр. Иртәгә без янә бергә, бер вагонда кайта башларбыз. Мин сезгә иртәгә бер сүз әйтермен. Мин аны сезгә бик күптән әйтергә җыенып йөрим... Аны әле минем беркемгә дә әйткәнем булмады, хәтта Насыйрга да...»

...Ләкин икенче көнне дә, өченче, дүртенче көнне дә Нурмөхәммәт күренмәде. Алсу йокыдан калды, ул гел аның турында уйлады, хәтта төшләрендә күреп, уянып-уянып китәләде. Өйдә дә күп сөйләшмәде,

кушсалар — эшләде, кушмасалар, китап ачты да, укыган булып, уйланып утырды.

Юк инде, бүтән болай яши алмый. Бүген ул аларга үзе барачак, Насыйр сагалап торса торыр. Ул аңардан курыкмый, Нурмөхәммәт абыйсы аны көтәдер... Мөгаен, ул чирләгәндер, урында ятадыр һәм өзелеп Алсуны көтәдер...

Очрашу теләге, Нурмөхәммәт белән күрешү теләге күңелен шул дәрәҗәдә ашкындырды Алсуның, ул кайту юлында ук аңа кереп чыгарга булды. Вагоннан төшүгә, бөтенләй икенче якка китте. Насыйрның каршы алуы бар иде. Бүген ул, ниһаять, тәвәккәлләде. Насыйр түгел, каенанасы үзе килсә дә, барачак иде ул Нурмөхәммәт абыйсы янына.

Алсу йөгерә-атлый алар урамына ашыкты. Менә аларның кече капкалары ачык. Бигрәк әйбәт, келә шалтыратып торасы юк. Батыраеп, ишегалдына кереп китте, туп-туры мастерскойга юнәлде. Мастерской янәшәсендәге бакчада таралып миләш үсеп утыра: тәлгәшләре ихата аша үрелгән. Миләш моңсуланып калган кебек тоелды Алсуга. Әллә соң чынлап та бер-бер хәл булдымы Нурмөхәммәт абыйга? Тизрәк атла, Алсу! Баскыч астыннан Рекс килеп чыкты. Алсуны иснәде дә, күзләренә карап, койрыгын селкеп куйды һәм мастерской ягына башын борды да, еламсырап, шыңшып алды.

«Бу ни бу, ни булды сиңа, Рекс? Хуҗаң чынлап та авырып ятамы әллә? Керәм, керәм, кадерлем. Әйе, әйе, ул мине көтәдер».

Мастерской ишеген ачуга, Алсуның йөзенә дымсу салкынча һава килеп бәрелде. Һәрвакыт күлмәкчән йөрерлек мастерскойда нык ук салкын иде. Алсуның йөрәге жу-у итеп китте. Мастерскойның җан өшеткеч салкын булуы, әллә ниткән ят исләр белән тулуы Алсу күңеленә әллә ниткән шом салды. Нигәдер пәрдәләр тартылган, мич башындагы ятак әйберләре дә юк. Алсу сак кына түр якка узды, марля япкан картинаны ачты. Бу — Алсуның сурәте. Ясап бетерә язган. «Нурмөхәммәт абый, кадерлем, мин менә килдем. Синең каршыңда мин сәгатьләр буена утырырга да риза. Күр әле, никадәр гүзәл икән бит Алсуың! Күзләрен, күзләрен генә күрче, ничекләр охшаткан, ничекләр килештергән! Ә серле итеп елмаюын ничек итеп тотып алган. Бу елмаюда моңсулык та, мөлаемлек тә, серлелек тә бар...»

Нурмөхәммәт кагылган һәр нәрсәгә бармаклары белән тиеп-тиеп алды Алсу. Шунда карашы мич янындагы өстәлгә куелган кара тасмалы фоторәсемгә төште.

Кинәт Алсуның тез буыннары бушап китте, аяк астындагы идән убылды. Кара тасма үрелгән фотодан Нурмөхәммәт абыйсы карап тора иде. Бөтен тәне буйлап тетрәнү узды.

Мөмкин хәлме? Алсу бер мәлгә өнсез-телсез калды. Күкрәк төрендәге ташны ярып, күзләренә яшь бәреп чыкты.

Юк, юк, бу мөмкин түгел!

Ишегалдында Рекс шыңшый, ул ишекне тырный, ачмакчы була. Шунда гына Алсу исенә килде. Ишекне ачты. Ишегалдында рәссамның кара шәл бөркәнгән әнисе басып тора иде, аны күрүгә, бөтенләй өмете өзелде.

— Әминә апа! — бары тик шулай гына дия алды, ул барысын да аңлады, барысына да төшенде. Ана иңенә төшкән кайгы-хәсрәт аның кайгысыннан күп тапкыр авыррак, хәвефлерәк иде.

— Әми-и-нә ап-па!..

Алсу тотлыга, әйтер сүзен әйтә алмый, үксүдән, иңнәре калтыраудан чарасыз калып, ананың күкрәгенә капланды. Газиз башына ишелеп төшкән хәсрәттән ананың гәүдәсе тагы да кечерәеп калган кебек иде. Ана калтыранган бармаклары белән Алсуның чәчләреннән сыйпый, кайгысын уртаклашырга килгән яшь хатынның ике битеннән ала, күз-

ләренә карый. Карый да, чарасыздан, әлегә кадәр үзенә ят булган яшь хатынның башын күкрәгенә кыса.

— Нәрсә булды, Әминә апа?

— Поезд астында калды ул, балакай. Бер баланы коткарган, ә үзе...

*
* *

Өченче вагон Алсу өчен истәлекле иде. Ул элеккечә һәркөн өченче вагонда кайтты. Вагонга кергәч, гадәттә, рәссам утырып кайта торган эскәмиягә күз ташлый, урын я буш була, я анда кем дә булса утырып тора. Ир-ат, җитмәсә Нурмөхәммәткә охшаганрак ир кеше утырса, Алсуның йөрәге жу-у итеп китә.

Ул юк инде. Ул һичкайчан әйләнеп кайтмас. Ләкин аның картиналары яши.

Бүген ул вагонга кереп утыруга, киосктан алган газеталарны караштыра башлады. Кисәк аның «Идел буе рәссамнары күргәзмәсе» дигән белдерүгә күзе төште. Ул анда барыр, үзе белән Насыйрны да алып барыр. Картиналарны бергәләп карарлар...

Насыйр аны электричка туктаган мәйданда көтеп тора иде һәм нәкъ өченче вагон туктый торган төштә.

«Насыйр, Насыйр,— диде Алсу үзалдына.— Насыйр, җүләрем, яхшы кеше бит син...».

Ишектән чыгуга, Насыйр аңа кулын сузды, Алсу үзе дә иренә бик теләп тагылды.

— Килеп яхшы иткәнсең, Насыйр.

— Беләсеңме, Алсу, мин теге пыяла әйберләрне бүтән ясамыйм инде.

Алсу сул кулы белән ирнең ышанычлы һәм нык беләген кысты, елмаеп күзләренә карады. Насыйр да, күңеле булып, хатынына ныграк елышты.

*Казан—Васильево,*
*1982 ел.*

# Галимҗан Латыйп

## Муса дисәм

Муса дисәм, берәм-берәм чыгып,
Көрәшчеләр баса сафларга.
Әзер алар дошман сипкән утны
Күкрәкләре белән капларга.

Муса дисәм, кан калтырый төсле
Күсе җанлы, шыпырт адәмнәр —
Аларның бит җаны әвәләнгән
Мәкер кушылмалы хәрамнан.

Муса дисәм, үткән буыннарның
Батырлыгы килә аңыма.
Балкып кабына кызыл ромашкалар,
Йолдыз арты йолдыз кабына.

Муса дисәм, нәсел-нәсәбемнең
Киләчәген күрәм үрләрдә.
Олы җанлы ирләр бар чагында
Төшмәс җиргә кара күләгә:

Үлем алдында да шаһбатырлар
Үлемсезлек җырын җырлады.
Бәла-казалардан, баскыннардан
Саклап калыр өчен дөньяны.

## Сыерчык бураннары

Әллә дөрес килә инде
Әбинең юраганы:
— Быел бит үзенә башка
Сыерчык бураннары.

Күрерсең менә үзең дә,
Кар гөжләп китмәячәк:
Шифалы дымнан кырларны
Һич мәхрүм итмәячәк.

...Юш килсен, дөрескә чыксын
Әбинең юраганы.
Бәхетле итсен кырларны
Сыерчык бураннары.

## Укучы сүзе

Дымга сусаган кырларга
Рәхәтләнеп яуган кебек
Җылы яңгыр шыбыр-шыбыр —
Язылгыз әле, шагыйрьләр,
Дарулардан көчле шигырь:
Шифа булсын йөрәкләргә,
Көч өстәсен беләкләргә!..
Язылгыз әле шигырьләр —
Дарулардан көчле шигырь.

●

Урманнарга керсәм яңарам мин,
Җаным, тәнем белән яңарам.
Әйтерсең лә мин әйләнеп кайтам,
Малай чакларыма яңадан.
Кошлар җыры, урман әкиятләре
Сеңгән канга, кергән күңелгә.
Алар мине ерак үткәннәргә
Алып кереп китә бүген дә.

Сирәгәеп калган кошлар җыры,
Аларда да сагыш, зар икән —
Урманның да шатлык, кайгылары,
Үз югалтулары бар икән.

«Бары безгә җитәр әле»,— диеп
Яшәүчеләр дә бар, билгеле.

Кая инде андый бәндәләрнең
Сөргән кыры, чәчкән игене!..

Яратырга кирәк җир-суларны,
Мирас бездән ярлы калмасын.
Каралмасын оныкларның күге,
Алар безне дөрес аңласын.

## Исәннәргә чәчәк бирегез

Озаталар аны речьләр сөйләп,
Табутына чәчәк салалар.
Нинди генә яхшы сүзләр әйтмик,
Күрешүләр юк инде яңадан.

Гомер кыска, гомер шундый кыска,
Кич була да янә таң ата.

Җир-әнкәбез үзенең балаларын
Тик мизгелгә гүя ярата.

Исәннәргә күбрәк әйтегез сез,—
Яхшы сүзне! Бирегез чәчәкләр.
Көеп барган үләннәрне дә бит
Яңгыр тамчылары яшәрткән.
Соңармагыз,
Исәннәргә бирегез чәчәкләр...

●

Берәү килә, берәү китә,
Буыннар алышына.
Нинди җилләр кагылмыйлар
Кешеләр язмышына.

Кала ул кояш, йолдызлар,
Теләсә кемнән кала.

Берәүнең үзеннән соң да
Йолдызы балкый ала.

Яна ул исәннәр өчен,
Киләчәк өчен яна.
Яшәде — яшьнәмәде, дип
Кем әйтер икән аңа!

●

Ай чыккан диңгез өстенә,
Яктырып, балкып тора.
Дулкыннар нурга төренеп
Ял итеп, ятып тора.

Ихтыяр көче җитәрлек,
Дулкыннар тыйнак алар.

Дельфиннар ай яктысында
Бәйрәмгә җыйналалар.

Чумалар, өскә чыгалар,
Чөяләр борыннарын.
Шатланып хәбәр итәләр
Диңгезнең җылынганын.

## Кешеләрнең язмышында уйнамагыз

Кешеләрнең язмышында уйнамагыз,
Рәнҗетүләр тотмый ул дип уйламагыз.
Беләм, ачмыйм әллә нинди бер яңалык,
«Ни чәчсәң, шуны урырсың»,— ди бит халык.
Яманнан яман туасы көндәй ачык.—
Гөнаһлардан беркайчан да булмый качып.
Мәкерле җан хәтер йөртмәс, мәкер йөртер,
Утларга да үзе кермәс — сине кертер.
Рәнҗетүләр тотмый ул дип уйламагыз,
Кеше язмышлары белән уйнамагыз.

●

Бу дөньяда яратудан көчле
Башка бирәр бәхет бар микән.
Җир бәхете, Ил бәхете өчен
Мәхәббәт бит безне бар иткән.

## Кил яныма

Йөз ел күрмәгәндәй булдым,
Сагындым тавышыңны.
Төшләрдә күреп уянам
Беренче танышуны.

Кырларда йөргән чакта да,
Үрләргә менгәндә дә,
Елмайганда, көлгәндә дә
Ишетәм тавышыңны...
Басалмыйм сагышымны.

Бар икән юләр, диярсең,
Кешеләр көләр, диярсең,
Әллә ни сөйләр, диярсең,—
Исең китмәсен аларга,
Телләре кычытканнары
Сөйләсен, әйдә сөйләсен.

Бар дөньяңны оныт та кил,
Эшләреңне ташла да кил,
Бу дөньяда кем бар тагын,
Минем мәхәббәтемә тиң!..
Кил тизрәк, кил яныма,
Минем кебек сине тагын
Я әйт әле, кем сагына?

●

Күңелләрне ярып чыккан җырлар
Хрусталь кебек зыңлый колакта.
Яктылыгы йолдызларга җитә,
Кайтавазы китә еракка.

●

Берәүләрнең җаны — зәңгәр чәчәк,
Кызыл чәчәк аткан бакчада.
Ә берәүләр гаме — хәрам малда,
Булса — ярый... керле акча да.

●

Гуманлыкны башлык итеп куйсаң,
Күмәр иде җирне ак чәчәккә.
Кара шәүлә йөрмәс иде янап
Атом белән — бөек киләчәккә.

Гел хәвефтә яши әле дөнья,
Гамьсезлеккә беркем хаклы түгел.
Үз сүзеңне ярып әйтү кирәк,
Якты булсын дисәң әгәр күгем.

Тыныч яшәү өчен көрәш бара
Җирдә, күктә, океан төпләрендә.

Кирәк безгә кешелеклелек фәнен
Байрак итеп биек күтәрергә.

Гафил булып калмыйк, вакыт безне
Көтеп тормый, һаман ашыктыра.
Җай чыкканын көтеп, явыз мәкер
Куләгәдә посып басып тора.

Мәңгелек бер нәрсә юк дөньяда,
Матдәләрнең гомерләре чикле...
Хәзер минә Кызыл кенәгәгә
Җирнең үзен кертер вакыт җитте!

●

Сагындырып килде быелгы кыш,
Сагындырып яуды карлары.
Аңлашыла иде игенченең
Борчылуы, аның аһ-зары.

Басуларга озак кар ятмаса,
Ужымнарның хәле аяныч.
Мондый чакта күзгә йокы керми,
Мондый чакта кирәк таяныч.

Кайчак башка төрле уйлар килә:
Нәрсә булды соң бу елларга?

Билдән яуган карны ера-ера,
Бер йөрисе килә кырларда.

Явар, явар, бер яумыйча калмас,
Киләчәктә безнең өмет бар.
Чаңгыларын тагып, бияләйдән,
Кар яуганын көтә оныклар.

Явым-төшем җаен, кышын кирәк,
Вакытында кирәк һәр нәрсә.
...Шатлыклары, борчулары да бит
Безнең белән һаман янәшә!

## Тирәкләр

Юл буенда тирәкләр,
Кыш димиләр, җәй димиләр,
Бабайлардан отып алган
Үз көйләрен көйлиләр.

Бер истәлек булсын диеп,
Көч бар чакта кулларда,
Утыртты безне бабайлар
Тезеп олы юлларга.

Бу якларның яме булып
Ерактан күренәбез.
Яктылыкны ярате:анга,
Кояшка үреләбез.

Юл йөрүләр берни түгел,
Сау-сәламәт кешегә,
Юлаучылар бабайларны
Һаман искә төшерә.

Үзе китсә, төсе кала
Изге җанлы кешенең.
Беркайда да онытмыйлар
Андыйларның исемен.

Көн арты — көн, ел арты — ел,
Юл буенда без — сакта.
Юлчыларга юл багабыз,
Тирәк кенә булсак та.

## Дуслар җыелган җирдә

Бер биеп аласы килә
Дуслар җыелган җирдә.
Килешер микән соң бу эш,
Алтмыштан үткән иргә?

Имән иданнәрне сыгып,
Бии яшьләр уртада.
Шайтаны да, гармуны да
Йөрәгемә ут яга:

Әйдә, имеш, яшьлегеңне
Бер искә төшер әле.
Төкер картлык дигәнеңә,
Бие, килешер әле...


Тыпыр, тыпыр, тыпыр, тыпыр
Килә минем аяклар.
Әллә инде бер үземә
Биш-алты пар аяк бар.

Кул чабалар, көч бирәләр,
Менә, диләр, молодец.
Йөрәк димен махы бирсә,
Минем эшләр харап ич.

Бер яшьлектә, бер картлыкта,
Барыбер бер үләсе.
Без күрәсен кеше күрмәс,
Без үзебез күрәсе.

Җан теләгән кеше, диләр,
Елан ите ашаган.
Ничек итеп калыйм инде
Кызыктан, тамашадан.

Алай-болай була калса,
Дуслар гафу күрсеннәр,
Чирләп түгел, ятып түгел,
Биеп үлде дисеннәр.



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*




## Роберт Батулла

# ЧАБАК-ТАУ

ОЧЕРК

Зичә инеше — Зәй елгасының бер тармагы. Инешнең башланган җиреннән үк диярлек мәһабәт Чабак-Тау күтәрелә. Урман белән капланган тауның башына менеп карасаң, бөтен тирә-як уч төбендәге кебек күренә. Бистәбашы авылы артында — карурман, Ашыт белән Шыкмай болыннарында мал утлап йөри. Колхоз үзәге Бишавылы аяк очында гына кебек. Тукай исемендәге колхоз җирләре болар.

1962 елның җәе... Чабак-Тау түбәсендә ике кеше басып тора. Аларның олы яшьтәгесе — күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган язучы Сөббух ага Рафиков. Икенчесе, яшьрәге — әле күптән түгел генә шушы колхозга җитәкче итеп куелган Исмәгыйль Сәгытдинов.

Зәй каласында яшәүче Сөббух ага шушы төбәкнең баш агрономы Исмәгыйль Сәгытдинов белән тиз арада дуслашып, якынаеп киткән. Егетне яңа эшкә, Тукай исемендәге колхозга күчергәч тә, Сөббух ага болай дигән иде:

— Әйдә, Исмәгыйль энекәш, күрсәт әле колхозыңны!

— Мактанырлык эшләр юк бит әле, Сөббух абый! — диде Исмәгыйль шул чакта.

Чыннан да, урманы-суы, болыны-басуы белән алты мең гектар җире булса да, ул елларда колхозның эшләре күкләргә чөярлекләрдән түгел иде.

— Шулай да, Сөббух абый, мин сезне Чабак-Тауга алып менә алам! — диде Исмәгыйль.

Чабак-Тау Кавказ-Кырым таулары кебек данлыклы түгел түгелен, шулай да түбәсенә менеп баскач, тирә-якның матурлыгын күреп, кеше я тынып кала, я сокланубын яшерә алмый.

Өлкән язучы белән яшь председатель «ай-вай»сыз гына тынып калды. Алар дәшмичә озак басып тордылар тау башында. Ул вакытта аларның нәрсә уйлаганын тәгаен генә әйтеп бирү кыен, ләкин шушы як кешеләренең язмышы турында кайгыртулары шиксез. Киләчәктә язучы Сөббух Рафиковның мәкаләләрендә, әсәрләрендә шушы Зәй төбәгендә яшәүче фидакарь, эшчән, көр күңелле хезмәтчәннәр лаек урын алыр. Ихтимал, Сөббух ага язылачак каһарманнары турында уйлангандыр. Артта калган бу хуҗалыкның киләчәге ничек булыр, яшь дусты бу авыр эшне тарта алырмы, дип борчылгандыр.

Колхозның яңа председателе Исмәгыйль Сәгытдиновны тынгысыз, читен хезмәт көтә. Хуҗалыкны урталар, алдынгылар рәтенә ничек итеп күтәрергә? Меңләгән кешеләр белән ничек уртак тел табарга?

Барысы да ал да гөл булмас: күңелең дә төшәр, табышлар, уңышлар да очрар, ялгышмый да калмассың... Ни генә булса да, Тукай исемендәге колхоз алдынгы хуҗалыклар рәтенә басарга тиеш! Ләкин моның өчен чирек гасыр вакыт кирәк булган икән.

— Ул елларны искә төшергәндә, хәзер дә авыр сулап куям! — дип сөйли Исмәгыйль Сәгытдинов.— 1958 елның декабрендә Зәй райкомы утырышыннан чыккач та аптырап калдым: гаилә дә корып өлгермәгән егет идем әле мин ул чакта. Экономик яктан йомшак дүрт авылны берләштергән зур колхоз белән җитәкчелек итү өчен шактый кыюлык, тәвәккәллек кирәк булгандыр инде. Терлекчелек артта, маллар ябык, биналар читәннән дә киртәдән, саман кирпеченнән салынган. Колхозчыларга түләү аз, кешеләр, тормыш алып бару өчен, мунчаладан кап сугу кәсебенә керешкәннәр, ир-атлар, чит якларга чыгып, балта эшендә йөри. Авылда юллар юк, радио юк, электр юк, клублар иске.

Эш торышы белән танышканнан соң тиз арада яшь председатель колхоз активын, коммунистлар һәм идарә членнарын җыеп, озак кына киңәшмә уздырырга булды. Киңәшкәннән соң карар кабул ителде.

Беренче: терлек биналары төзүне алга сөрергә, маллар санын арттырырга, иген уңышы өчен көрәш башларга.

Икенче: колхозчылар белән мәсьәләне уртага салып сөйләшергә, түләүне арттырырга.

Ләкин һаман авылдан китә торалар. Ни өчен? Сәбәп нәрсәдә? Туган җиреннән нигә кача кеше? Авылыннан нигә бизә кеше?..

Ул көннәрдән соң егерме биш еллап вакыт узган. Тукай исемендәге колхоз — районда алдынгыларның берсе. Байтак сулар аккан, күпме тир түгелгән. Гаять олы эшләр башкарылган. Колхозның дүрт авылы арасында юллар күтәртелгән, кышын да, җәен дә өзлексез машиналар йөреп тора. Электр инде күптән даими рәвештә колхозчыларга хезмәт итә. Куыклы керосин лампалары, сукыр лампалар мәктәп музейларында гына саклана. Һәр йортта радио, һәр авылның үз клубы бар, колхоз үзәгендә — культура йорты. Телефон кертелгән өйләр дә шактый. Үткән ел бөртекле культураларның бөтен тармакларыннан да район хуҗалыклары арасында бу колхоз җиңүче булып чыкты һәм «Алтын башак» вымпелын яулап алды. Ашлык тапшыру планы йөз егерме биш процентка үтәлгән. Шикәр чөгендере сатып, колхоз акча янчыгын шактый тулыландырды.

Ләкин кешеләр авылдан һаман китә тора. Элек яшьләр киткән булса, хәзер дә бик теләп калмыйлар шикелле. Ни өчен?

Председатель: Башта әйттеләр, авылларда культура хезмәте юк дәрәҗәсендә, шуңа күрә кеше шәһәргә омтыла, диделәр.

Сорау: Күп колхозларда — шул исәптән сезнең колхозда да — клублар, культура йортлары бар. Һәр кешедә телевизор, көн саен кино күрсәтелә. Яшьләр барыбер шәһәргә карый. Димәк, сәбәп культурада гына түгел?

Председатель: Шуннан соң уйлаштык. Юллар начар, шәһәргә барсаң, кайтып булмый, кирәк-ярак өчен авылдан чыгып булмый, шуңа күрә халык бизә, диде кайберәүләр.

Зәй ягында юллар начар түгел хәзер. Асфальт та бетон. Ун минутта — Зәйгә, ярты сәгатьтә Түбән Камага, Брежнев шәһәренә барып җитәсең, көнендә әйләнеп кайтасың.

Сорау: Димәк, сәбәп юлларда гына микән? Ни өчен унынчыны бетергәннәр генә түгел, хәтта байтак гомерен колхозда эшләп уздырган олы яшьтәгеләр дә нигезеннән китәргә күп сорамый?

Председатель: Хикмәт, бәлки, яшәү шартларындадыр? Мал-туар карау, утын әзерләү, су китерү кебек эшләр шактый вакытны ала. Су, газ, кайнар су кебек мөһим нәрсәләрнең кул астында булуы кирәк. Болары әле хыялда гына. Шулай да без, белгечләр, яшьләр өчен махсус йортлар төзүне планлаштырдык. Бөтен уңайлыклары булган шул йортларда, бәлки, яшьләр озаграк тоткарланыр?!

Һич шик юк ки, алда саналганнар — әлбәттә, җитди сәбәпләр. Рухи азык, культура, юллар, торак шартлар — һәммәсе дә бик кирәк. Минемчә, сәбәпләрнең берсе колхозчының буш вакыты булмаудыр. Әйтик, колхоз тракторчысы, вакыты-вакыты белән тәүлегенә уналтышар, егермешәр сәгать эшли. Шәһәр тракторчысы сигез сәгать эшли дә ял итә, яраткан шөгыле белән мавыга: балыкка китә, футбол-хоккейга йөри, бала-чагасы белән уйный, театрга бара. Яшерен-батырын

түгел, авыл шартларында андый иркенлекне механизатор күрә алмый. Китүенә аклану эзләгән кешегә бусы да — сәбәп.

Ләкин колхозның төп терәге — үз эшен югары сыйфатлы итеп, матур итеп, җиренә җиткереп, яратып башкара торган кешеләр. Алар сигез сәгатьлек эшкә, атнага ике тапкыр ялга гына кызыгып, җирне ташлый торганнардан түгел. Яшьләр бит Шыкмай авылында Хәниф Биккинин, Хәниф Хисмәтуллин, Амур Йомаголов, Бистебашында — Әлмөхәммәт Гыйльметдинов, Гандәлиф Гайнуллина... Бишавылында — Мөнәвир Вәлиуллин, Мәкчем Кузнецов... Алар умырып эшли, матур яши белә. Мондыйлар белән теләсә нинди авыр эшкә алынырга була. Болар сине дә, җирне дә ташлый торганнардан түгел.

**Сорау:** Эшче куллар мәсьәләсендә колхозның эшләре өметсез түгел, алайса?

**Председатель:** Шөкер хәзергә! Алда саналганнар янында тагын бик күп терлекчеләр, игенчеләр бар, шундыйларга таяна колхоз, алар — колхозның төп хуҗалары.

**Сорау:** Сез — җитәкче, сез — колхоздан үз теләгегез белән китә торганнардан түгел. Сез шушы кешеләр белән туганлашып беткән. Әйтик, менә яхшы гына механизатор авылдан калага китүе турында гариза тотып сезнең янга керде, ди. Сез ничек кабул итәсез андыйларны? Ачуланасызмы, үгетлисезме, нәфрәт белән карыйсызмы, дигәндәй...

**Председатель:** Әлбәттә, син җитәкли торган колхоздан кеше кача икән, бу — матур күренеш түгел. Мин андый кешеләрне кочак җәеп каршы алмыйм. Коммунист булса, аның белән иң беренче партия комитеты вәкиле сөйләшә. Инде тәкате калмаган икән, нигә кешене ирексезләп тотарга? Китсен. Шәһәргә дә эшче көч кирәк бит. Юк! Минем андыйларга үпкәм юк. Шәһәргә китүчеләргә ачу да сакламыйм. Артист буласың килә икән, сәләтең бар икән — рәхим ит, сәхнә йолдызы бул. Мәсәлән, Бишавылы мәктәбен тәмамлаган егетебез, Татарстанның халык артисты Наил Дунаев белән без горурланабыз. Әгәр шагыйрь икәнсең, шигырь яз, алла хакы өчен укы, кеше бул! Мәсәлән, Бистебашы егете, безнең колхоздан чыккан шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов — безнең мактанычыбыз. Ләкин бит шәһәргә киткән һәр кеше бәхетле түгел. Хәтта кунар урын таба алмаганнары да булгалый. Азмыни калага китеп, матур гаилә кора алмаганнар? Әгәр дә ул колхозда калса, ихтимал, кеше булыр иде, илгә файда китерер иде. Димәк, калада эш пешерә алмаган кеше җирдән китеп ялгышкан, авылын ташлап, үзенә үк хыянәт иткән. Шуңа күрә аның эше дә, ашы да юк. Ул һәрвакыт зарланып йөрүчән бер бичарага әверелә. Андыйлар турында халыкта җыр да бар:

> **Чия пеште, чия өздең,**
> **Алмасын өзәлмадың;**
> **Авылыңны ташлап киттең,**
> **Калага җитәлмадың.**

Уңганнар калада да, авылда да югалмый. Бар шундыйлар, шәһәргә китсә дә, умырып эшләгән булырлар иде. Ләкин алар авылда калды. Һәм кем-хур булмадылар. Әйтик, тимергә кулы тисә, тимер җырлый, агачка тотынса, агач җырлый торган алтын куллы механизатор Нәҗип Низамов шәһәрдә тамак туйдыра алмас идемени? Ул авылны ташламады, туган җирендә калды...

Күп андый кешеләр... Колхозның беренче шоферы мәрхүм Хәсән абый Мәүләвиевнең улы Нурәһит та атасы һөнәренә хыянәт итмәде. Ул — колхозның мышаныччлы шоферы. Гаиләсе дә шәп. Хатыны Нурдидә белән өй тутырып балалар үстерә. Биш баладан төпчек малай:

— Мин дә үскәч, эти кебек шуфир булам,— ди.

— Төпчек түгел әле ул! — дип көлә Нурдидә ханым, иренә карап.

Ире Нурәһит тә аны хуплагандай, әлмая:

— Төпчек түгел, тагын бер-икәү планлаштырылган...

Рәхәт шундыйларга карап тору. Сокланасың аларны күреп, хәтта көнләшеп тә куясың. Димәк, Хәсән абыйның гадәтләрен улы Нурәһит дәвам итә. Нурәһиттән рульне аның улы алыр.

...Зәкия апа Гыйлфанова йортына кайгы иңде: үлем кәгазе. Ләкин күрше хатын-кызлар бу турыда Зәкия апага әйтмәскә булдылар. Ярамый! Әле яңа гына ул баладан котылды. Малай тапты ул. Зәкия апа савыккач кына әйтергә булдылар: ирең батырларча һәлак булган, диделәр. Зәкия апа күңеленә юшкын урнашса да, тамагына әче таш килеп тыгылса да, ачыргаланмады. Һич ни белми, кул-аякларын бутап яткан улына карады. Туганда ук ятим булырга язган икән кечкенә Мәсгутка, бичарага. Ата кеше вафат, улы үсәр. Ялгышмады Зәкия апа, Мәсгут ятим калса да, ким-хур булмады. Яхшы укыды, эшкә өйрәнде һәм туган авылында калды. Атасы исән булса, улы белән мактана алыр иде: Мәсгут Гыйлфанов — ике тапкыр Дан ордены кавалеры, атаклы механизатор, бөтен Татарстанга даны таралган чөгендер игүче кеше. Ул бригадир да, парторг та булды, ул механизатор да, ул игенче дә, ул артист та. Мәсгут җырлаганда, бөтен якташлар, эш туктатып, аның моңын тыңлыйлар. Бәхетле, бик бәхетле Гыйлфановлар гаиләсе, бала-чага, матур-тигез ата-ана, әбиләре Зәкия апа да сау-сәламәт.

— Уч төбендә генә йөртерлек кешеләр алар! — ди председатель андыйлар турында.

Ерак басу ягыннан тузан өермәсе куптарып, трактор идарә ягына таба килә. Бу — техникага гашыйк Хәйрулла Ярмөхәммәтов. Уттай эш өстендә тракторга атланып ни эшләп йөри ул? дип уйлады председатель.

Трактор килеп җитте, Хәйрулла сикереп төште дә агрономга кычкыра:

— Ашлама бетте, тәк торам, тизрәк ашлама китерегез! — ди.

Председатель, эчендә кабынган ачуын тыярга тырышып, агрономга әйтте:

— Кочаклап үп Хәйрулланы! Башка бер кеше булса, ашлама бетте, дип кайтып китәр иде дә мунча керер иде, я булмаса, күләгәгә кереп йоклар иде. Синең эшне эшләп йөри кеше. Рәхмәт әйт тә Хәйруллага, тиз генә ашлама чыгар!

Иртәнге сәгать биш тулып килә. Идарәгә звено башлыклары җыела. Алар арасында мәктәп директоры Лев Ермолаев та бар. Иртән таңнан торып, нишләп йөри, дисәң, ул да «нәрәт»кә төшкән икән. Бу колхоз чөгендер белән дан тота. Ә ул чөгендерне тулысы белән диярлек мәктәп коллективы эшкәртә, һәр елны гаять мул уңыш ала.

Тукай колхозы якын шәһәрләр белән чиктәш: Зәй, Түбән Кама, Брежнев, Минзәлә, Әлмәт... Шәһәрләр күбәя, шәһәр авылдагы яшь кадрларны гына түгел, хәтта төпләнеп өлгергән урта яшьтәге кешеләрне дә үзенә суырып ала. Бу табигый хәл, әлбәттә. Ләкин бу җитәкчеләрне борчымый калмый.

— Шәһәрләр арта, дип, кул кушырып утырып булмый,— ди Сәгытдинов.— Кадрларны әзерләргә кирәк. Колхозда күпчелек үзебезнең урта мәктәпне тәмамлаган кешеләр эшли. Киләчәктә дә үзебезнең кадрларга өмет багланган. Аларны саклау өчен колхозчыларның эш шартларын яхшыртырга, хезмәтне җиңеләйтү чараларын күрергә кирәк. Әйтик, тиздән колхозга К-700 тракторы кайтартылачак. Бу машина механизаторның эшен шактый җиңеләйтә. Сменага 20—25 гектар җир сөрергә була. Элек савымчы башына 15—20 сыер тия иде, механизмнарны көйләгәндә, бер кеше 80 баш сыерны тәрбияли ала, 300 баш дуңгыз симертергә мөмкинлек бирә. Шикәр чөгендере монда 420 гектарда игелә һәм тотрыклы уңыш китерә. Мәгълүм ки, чөгендер эше — кул көче таләп итә торган катлаулы процесс. Бигрәк тә хатын-кызларның авыр хезмәтен җиңеләйтү кирәк. Бу процессны механикалаштыру, комбайннар белән тәэмин итү, кул көчен киметү — менә нәрсә борчый колхозны бүгенге көндә.

Теге елны Чабак-Таудан төшкәч, Сөббух ага Рафиков председатель Исмәгыйл Сәгытдиновка «Беренче яз» исемле романын бүләк иткән иде. Китапның беренче битенә:

«Кадерле Исмәгыйл һәм Рәмзия ханым Сәгытдиновларга, иң яхшы теләкләр теләп, Сөббух Рафиков, 8 май, 1962 ел»,— дип, истәлекле имзасын куйган.

Сөббух аганың теләкләре изге сәгатьтә әйтелгән. Үзе исән булса, менә кемнәр, менә нәрсәләр турында сөйләгән булыр иде аңа Сәгытдинов. Аны тагын Чабак-Тауга чакырыр иде: язучы кукуруз басуларын, чөгендер плантацияләрен, терлек йөри торган көтүлекләрне, яңа мәктәп һәм культура йорты биналарын күреп сөенер иде. Тукай исемендәге колхоз председателе, Татарстанның атказанган

агрономы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденына ия Исмәгыйл Сәгытдинов коллективның еллык планны барлык күрсәткечләрдә дә арттырып үтәгәнен сөйләр иде.

Алар — бу җиргә кендекләре белән береккән кешеләр: берсе — колхоз председателе Исмәгыйл Сәгытдинов, икенчесе — мәктәп директоры Лев Ермолаев. Профессияләре аерым булса да, аларның хезмәте бер үк ноктага җыела. Кадрлар әзерләү, җир өчен, Ватан өчен ышанычлы алмаш үстерү.

Мәктәп директоры да эшләгән эше белән горур. Колхозның мактаулы эшләрендә аның да өлеше зур һәм мактауга лаек. Шушы мәктәпне тәмамлаган шагыйрьләр Мөдәррис Әгъләмов һәм Хәйдәр Гайнетдинов, Татарстанның халык артисты Наил Дунаев, Олимпия уеннары чемпионы, атаклы спортчы Федор Симашов, математика фәннәре кандидаты доцент Гамбир Закиров һәм авылның бүгенге таянычлары, атаклы терлекчеләр, механизаторлар бар да шушы мәктәптән чыккан. Алар Азык-төлек программасын үтәүгә зур өлеш кертә.

Сәгать иртәнге биш.

Чабак-Тау артыннан кояш күтәрелә. Яңа хезмәт көне туып килә. Звено башлыклары идарәгә җыела...

*Зәй районы*

*1982 ел*

## Бер сорауга—бер җавап

**Сорау:** *Безнең проза әсәрләребез әлегә Союз күләмендә киң яңгыраш таба алмый. Моңа иң төп сәбәп итеп Сез нәрсәне саныйсыз?*

**Рафаэль Мостафин:**

*— Бу сорауга — зур талант кирәк, дип кенә котылып булыр иде. Әмма бу төшенчәнең үзен бераз аңлатып китәргә кирәк. Зур талант — ул, табигый сәләттән тыш, чорны, халык күңелен, замандашның уйтойгыларын тирәнтен белү дигән сүз. Заманча фикерләү, заман кузгаткан проблемаларны сиземләү, көннең кадагына суга белү... Зур талант бөтендөнья әдәбиятының иң күркәм традицияләрен үзләштергән булырга тиеш һәм шул ук вакытта — беркемне дә кабатламаска, үз сүзен әйтергә... Ул әдәбиятта җитди яңа сүз әйтергә тиеш. Нинди сүз? Моны әлегә беркем дә белми, талант аны үзе табарга, үзе әйтергә тиеш...*

## Марат Бибишев,

«Камгэсэнергострой» берләшмәсенең йортлар салу комбинаты начальнигы, Татарстанның атказанган төзүчесе

# «ИСТӘЛЕККӘ ШӘҺӘР БҮЛӘК ИТӘМ»



*Баш өстендә түбәсе булмаган кеше үзен бәхетле тоя алмый. Өйсез кешегә якты кояш нуры да — көйдергеч афәт кенә, таң җилләренең назы да үзәккә үтүчән салкын гына өрә, ләйсән яңгырының шифасы да җан өшеткеч юешлектән генә гыйбарәт. Һәркем борын-борыннан, йорт-кура өлгертеп кергәч кенә үзен мөстәкыйль саный алган, бәхет өмет итә башлаган.*

*Бәхетлеләрнең дә төрлесе була: иң көчлеләре башкаларны бәхетле итүдән күбрәк ләззәтләнәләр. Аларның шатлык-куанычы бәхетле иткән кешеләре санынча арта бара. Әгәр шулай икән, төзүчеләрдән, кешеләрнең иң беренче ихтыяҗы булган торак белән тәэмин итүчеләрдән дә бәхетлерәк кемне табарсың?!*

*Үзәге Татарстанның Брежнев шәһәренә урнашкан «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең йортлар салу комбинаты начальнигы Марат Бибишев әлеге игелекле хезмәткә утыз елдан артык гомерен багышлаган. Соңгы вакытларда ул Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр өчен яңа шәһәр иҗат итү белән мәшгуль. Без шул бәхетле кешегә журнал укучыларын кызыксындырырдай сораулар белән мөрәҗәгать иттек.*

**Сорау:** **Сездәй төзүче инженерларның фидакарь иҗаты аркасында Татарстан киң колачлы корылмаларны башкарып чыгарга сәләтле өлкәләр сафына басты. Берничә дистә ел эчендә республикабызда өр-яңа шәһәрләр салынды. Хәзер аларда нефтьчеләр, энергетиклар, химиклар, машина төзүчеләр рәхәт гомер кичерәләр. Ул калалар — сезнең иҗатыгызның аерым баскычлары. Сез, үз эшегезгә бәя биргәндә, аларга карап фикер йөртәсездер: кайда, нинди уңышлы яңалык кертелгән, кайчан хата җибәрелгән; яңа төзелешләргә тотынганда, үткәндәгеләр сезгә, билгеле бер дәрәҗәдә, өлге ролен үтидер, мөгаен.**

**Инде сезнең комбинат төзүчеләре Татарстан атом электр станциясе энергетиклары яшәячәк шәһәргә нигез салды. Шул уңайдан ачыклыйсы килә: торак**

йортлар, яңа калалар төзүдә иң мөһиме нәрсә? Яңа шәһәрләрне, төзүчеләр башкарып чыккан эшне бәяләгәндә, аның кай ягына игътибар итәргә кирәк?

**Марат Бибишев:** Бу сорауга өзеп җавап бирүе шактый кыен, чөнки мин ничек кенә уйласам да, һәркем шәһәрләрне, өйләрне үз аршины белән үлчәячәк. Берәүләргә — аның тирәлегенең табигый шартлары, башкаларга — анда нинди предприятиеләр булуы, өченчеләренә исә өйләренең архитектурасы, уңайлыклары, хәтта кибетләрендә ниләр сатылуы яки тагын да, минем карашымча, әһәмияте кечкенәрәк тоелган яклары мөһим санала. Кыскасы, бу — кешеләрнең шәхси сыйфатларына, дөньяга карашларына, эрудицияләренә бәйле. Шунлыктан мин дә бу очракта бары тик шәхси карашым, үзем инанган хакыйкать турында гына әйтә алам һәм аны расларга тырышачакмын.

Миңа калса, йорт салучыларга, шәһәр төзүчеләргә генә түгел, һәр һөнәр иясе өчен, үз эшен бәяләүдә, төп бер үлчәм бар: синең кылганың кеше табигатенә, аның көткәненә, теләкләренә ни дәрәҗәдә җавап бирә?! Син салган йортта яшәгәндә, ул үзен бәхетле хис итәме, рәхәтме аңа? Минем бу кагыйдәм кайбер коллегаларымда ризасызлык та тудыра. Архитекторларның Бөтенсоюз киңәшмәсендә, шушы фикерне алга сөреп ясалган минем бер чыгышым шактый четерекле бәхәс тә кузгатып җибәргән иде. Күпләр, заман төзелеше, архитектурадагы яңалыклар, ягъни мода, кешене тәрбияләргә, аны шул шартларга буйсындырып, яраклаштырырга, өйрәтергә тиеш, дип кенә уйлыйлар. Чакрымнарга сузылган төп-төз киң урамнар, күк гөмбәзен тишеп үтәрдәй биек ташпулатлар... Өсләренә карасаң, баш әйләнә. Тольятти шәһәрендә булучылар беләләрдер: андагы урамнарның киңлегеннән зиһенең чуалырлык. Иксез-чиксез мәйдан, өйләренең бинибая биеклеге сине бөтенләй кечерәйтеп, куркытып калдыра. Брежнев шәһәрен салганда, без бу хәлне истә тоттык. Монда урамнар да чамадан тыш киң түгел, күпкатлы йортлар тәбәнәкләре белән аралаштырылды. Сезнең чамалап караганыгыз бар микән: бинибая биек бинаны төрле ысуллар белән бүлгәләргә, җанга җылы бирә торган кыяфәткә кертергә була. Ян-якларына тәбәнәгрәк өстәмәләр куясың, балконнарын башка төскә буйыйсың, гомум күренеш үзгәреп китә. Брежнев шәһәре — күркәм рәсем шикелле.

Миннән еш кына: «Ну, Бибишев, син биш катлы йортлар салудан кайчан туктыйсың инде?» — дип сорыйлар. Тавышларында ук канәгатьсезлек сизәм. Тик дөресен әйтми булдыра алмыйм. «Беркайчан да! — дим.— Әгәр Җир өслеге чикләнмәгән булса, мин әле бер катлыларны гына салыр идем». Чыннан да, кешегә гөлбакчага күмелгән, бер катлы аерым йортларда яшәү мең-миллион тапкыр рәхәтрәк булыр иде. Уйлагыз әле: ни өчен без, юк вакытны бар итеп, урман куеннарына, су буйларына ашыгабыз. Учак ягарга яратабыз. Аның ялкынында пешкән шулпаның, шунда кайнаган чәйнең тәме айлар буе безне сагындырып тора. Хикмәт нәрсәдә? Мин моңа үземчә җавап табам шикелле. Кеше миллионнарча еллар буе табигать куенына сыенып яшәгән. Аның цивилизацияле тормышка ирешүенә, бөтен формалашу дәверен исәпләгәндә, бик аз вакыт үткән. Димәк, безнең җан, үзебез дә аңламаган әчке кагыйдәләр нигезендә, табигать хозурлыгына тартыла һәм, шул теләгенә ирешкәндә, кеше аеруча рәхәтлек тоя.

Шәһәрләребезне без мөмкин кадәр кеше рухына туры килерлек итәргә тырышабыз. Кайчак урам ягына кечкенә генә бер бизәк төшереп куйсаң да, йорт көләп җибәрә сыман. Брежнев шәһәрендә 62 ишекле бер өй бар. Үзе бер кала! Тоташтан туп-турыга бастырып куйсаң, кешенең котын алыр иде. Без аны шундый итеп бормаладык ки, берничә ишеккә аерым ишегаллары булдырдык, хәзер күрсәгез... Әйтерсең лә анда берничә генә гаилә гөрләтеп яшәп ята.

**Сорау:** Атом электр станциясен төзүчеләр һәм энергетиклар өчен салыначак шәһәрдә сезнең бу принцип ничегрәк тормышка ашырылачак?

**Марат Бибишев:** Монда без булачак шәһәрнең урынын сайлаганда ук кеше күңеленең омтылышларын алга куеп эш иттек. Кама буендагы иң күркәм тирәлек алынды: суы да, урманы да, таулары да бар. Шәһәрне, һичнинди өстәмә мәшакатьләр тудырмыйча гына, тип-тигез җирдә төзи башларга да мөмкин иде. Минем күзләр әлеге билгеләнгән урыннан аска, таулар ышыгына елышкан бо-

рынгы авылга текәлеп калды. Үзем: «Кеше никадәр акыллы,— дип уйлыйм.— Бездәй төзүче инженерларга алардагы акылга ирешергә күпме кирәк әле! — дим.— Әнә бит, алар нинди җайлы урынга утырган, бөтен уңайлыкны табигатьнең үзеннән алган!» Янымда проект төзиячәк оешма вәкилләре дә бар иде, фикеремне аларга да әйттем.

— Юк! — дим.— Яңа шәһәрне бу тау башы шәрәлегенә салырга ярамый!

— Үз тәкъдимеңне керт алайса! — диләр.

— Әнә ул! — Мин борынгы Кама Аланы авылына төртеп күрсәттем.— Яңа шәһәр шунда утырырга тиеш!

— Ну, Бибишев! Үз өстеңә күпме өстәмә мәшәкать аласың!..

Дөрес, эше дә, чыгымнары да артыграк булачак. Тик төзүче инженер иң әүвәл кешеләр мәнфәгатен күз алдында тотарга тиеш. Әгәр өстенә шәһәр корып куйсак, карт-коры гына яшәп калган ул авыл да бөтенләй харап булачак иде. Шәһәр аны таптап, изеп китәчәк. Без исә аларны бик әйбәт өйләргә урнаштырачакбыз. Бусы — бер. Икенчедән, яңа шәһәребез җилләр генә уйнап торган шәрәлектән котыла, атомчыларыбыз әкияттәгедәй матур шәһәрдә яшәячәкләр.

Сорау: Станция эшли башлагач, сезне сокландырган тирәлекнең күркәмлеге кимемәсме?

Марат Бибишев: Барысы да — кеше кулында. Станция салынмас борын, табигатьне саклау чаралары күреләчәк. Файдалануда булган суны чистарту өчен көчле фильтрлар куелачак. Без табигатьтән хуҗалык өчен кирәкне ала да бёлергә тиешбез. Әйтик, әлеге очракта, илгә энергия җиткерү максат итеп куелган. Моңа ирешү юлында нинди дер каршылыклар туа икән, аны җиңәргә туры килә. Нәкъ шундый ук станция Башкортстанда да салына. Аларга без дә булышабыз. Андагы шәһәрне салырга тип-тигез яңа урын сайланган. Эш өчен рәхәт, әлбәттә. Безнең өйләр таулар-калкулыклар арасына төзеләчәген ишеткәч, алар да миннән көлде! «Их, син, Бибишев, җүләр, үзеңә күпме мәшәкать уйлап чыгаргансың!» — диләр. Шаяруга каршы шаяру белән җавап бирергә туры килде: «Әйдә, көлегез, дим, бик бeлэсегез килсә, дөньяның иң зур кыенлыкларын шул «җүләрләр» күтәреп тора да инде!»

Табигать шартларының иминлеген саклау да кыенлыклар, өстәмә чыгымнар таләп итәчәк. Мондагы тирәлекнең гүзәллегенә хилафлык китерсәк, безне үз вөҗданыбыз ук кичермәячәк.

Сорау: Марат ага, Сез башкаларның эшчәнлегенә бик таләпчән. Күңелегезгә ошамаган якларын күрсәгез, хезмәткәрләрегезне бик каты ачуланасыз: чыдасаң, чыда, чыдамасаң... да чыда. Тәнкыйтькә үзегез ничек карыйсыз?

Марат Бибишев: Тәнкыйть төшенчәсе гаять киң мәгънәле. Максатыңны кемнедер тәнкыйть итүгә генә юнәлдерсәң, иң кирәкле эшне дә эттән алып этккә салырга була. Мин үзем кешеләрнең пошмаслыгын, ялкаулыгын яки, миннән киткәнче — иясенә җиткәнче, дип, кушылганны астан-өстән генә үтәп, күз буяп йөрүчеләрне кичерә алмыйм.

Әйтик, әлеге Кама Аланына салына башлаган беренче йортларның идәнен җәйгәндә, түшәүчеләрне ачуланырга туры килде, тиешле әзерлеген күрмичә, тиз генә матурлап, шомартып куймакчылар. Каерып карадым да егылып китә яздым. Бу рәвешле ябылган ленолиум бераздан купшакланып чыгачак, идән коточкыч салкын булачак. «Кемне алдыйсыз?», «Ни йөзегез белән өр-яңа шәһәргә брак кертергә җыендыгыз?» кебек сүзләр телгә үзеннән-үзе килә инде. Анысы — бер хәл, син күрмәгәндә дә, өйнең ямен-тәмен җибәрердәй шундый кимчелекләрне кабатламаслык итәргә иде! Җитәкче даим саен тикшереп тора алмый, намуска каравыл куеп булмый...

Инде мине тәнкыйтьләүләренә килсәк, турысын әйтим, авыр кичерәм. Бигрәк тә, урынсыз икәнен сизсәм, җан кыйнала. Инде, эшең барып чыкмавына пошынып йөргәндә, ачуланып булса да, берәрсе этәргеч бирердәй тәнкыйть фикере әйтсә, нәтиҗәсенең куанычын алдан күреп, тынычланасың. Иң ачу китергәне — сүз юктан сүз табып, өйрәтергә азапланган кеше белән эш итү.

Без Кама Аланында беренче эш итеп өч катлы йорт төзүне билгеләдек. Аны иске мәктәп урынына салырга кирәк иде. Минем фикергә каршы чыктылар.

«Иске мәктәпкә, яңасын салмыйча, тотынасы түгел! — диләр.— Балаларны укудан мәхрүм итмәкче буласыңмы әллә?..» Бу төр бәхәсләргә игътибар итсә, төзүче бер нәрсә дә эшли алмас иде. Мин Рәис Сәләхов егетләре белән киңәштем дә тәвәккәлләргә булдым. Шунсыз ярамый. Кыю тәкъдим кешегә җаваплылык хаматы да кидерә бит ул, аны аңлый белергә кирәк. Җиңел булмады, ике ай эчендә, ял көнсез эшләделәр, мәктәп өлгерде. 40—50 бала карамагына зур шәһәрләрдәге кебек үк әйбәт бина тапшырылды. Уку елын да, 1983 елның чыршы бәйрәмен дә балалар шунда каршыладылар.

Тагын да җитдирәк бәхәс Брежнев шәһәрендәге спорт комплексын сала башлаганда куерган иде. Бәхәсләштек, кычкырыштык, уртак фикергә килә алмадык. Нинди генә сүзләр ишетмәдем: «үзсүзле», «башбаштак», «киребеткән»... Минемчә, инженер — иҗат кешесе ул, аның уй-теләкләрен кырт кисеп куелган кысаларга кертергә тырышу — ахмаклык. Мин дә тәвәккәлләдем. Ярдәмчем Фәрит Сөләйманов белән сөйләштем.

— Мин бик аңлыйм да бит, Марат Шакирович,— ди бу,— сарайга диган җирнең геодезистлар билгеләп биргән документы да, проектыбыз да юк.

Миндә боларның барысы да әзер иде инде. Проектны үзем төзедем, урынның ниндилеген дә ачыкладым, аның ничә квадрат метры нинди авырлык тотып тора алачагын яттан беләм, хәтта төзелеш материалларын кайдан, ничек алырга икәнен дә чамалап куйган идем.

Зуррак җитәкчеләр сизгәләгәнче, спорт комплексының төп заллары әзер дә булды. Ул шактый арзанга төште, чөнки проект үзебезнеке, төп материаллар — зур заводлар төзелешеннән калган-поскан нәрсәләр. Башка чыгымнар планда каралганнан тыш экономияләнгән мөмкинлекләрдән ясалды. Спорт сараен тантаналы рәвештә ачарга чакыру билетлары тараткач, минем беренче теләккә каршы төшкән тәнкыйтьчем аптырап калды.

Юк, мин иң мөһим җиңүне аның агарып чыккан ачулы йөзен күрүдә булды дип санаудан ерак торам. Безнең тәвәккәллекнең иң файдалы нәтиҗәсе шул: хәзер һәр көнне сигез йөз бала спорт комплексының мәрмәр баскычларыннан йөгерә-йөгерә менеп-төшеп йөри. Спорт белән мавыкмасалар, алар урамда ялгыш юлга кереп китү куркынычы алдында калырлар иде. Егерме биш метрлы төзү бассейныбызның сикерү җайланмалары да бар. Брежнев шәһәре спортчыларына мин зур ышанычлар баглыйм. Кеше гомере бик кыска. Аның һәр мизгеле алдан ук билгеләнгән файдалы шөгыль белән узарга тиеш. Без Кама Аланында да спорт комплексына урын билгеләдек инде...

**Сорау:** Бу кадәр мавыгып китәрлек булгач, сез, мөгаен, үзегез дә физкультура белән шөгыльләнәсездер?

**Марат Бибишев:** Хәзер минем спортка бүлер вакытым азайганнан-азая бара. Яшь чакта классик көрәш белән «җенләнгән» идем, хәзер ныгытып торып күнегүләр ясарга ара юк. Шулай да кышын, кичке сигезләрдә, чаңгы киеп, Кама буйларын уратып узам, тимераякта йөгерергә яратам. Шугалакка улым белән бергә барабыз. Дөрес, ул минем киемнәрне кочаклап, читтән карап кына тора. Шуарга кыстасам: «Миннән җитәр, әтием, икенче курста зачет биргән идем инде!» — ди. Мин аңардан көләм, ул — миннән. Җәен су керергә йөрим. Вакыт чикле, тик мин физкультурага багышланган сәгатьләрне кызганмаска кирәк, дим, чөнки ул сиңа, кыймылдарга куркып утыручы адәмгә караганда, икеләтә-өчләтә артыграк эшләргә куәт өсти. Гомернең пешмәгән, булдыксыз, ялкау кешеләрне тикшереп, аларга вәгазь укып узган минутлары кызганыч.

**Сорау:** Атом станциясен төзергә килүче яңа кадрларда ниндирәк сыйфатлар күрергә теләр идегез? Сез, әлбәттә, тәҗрибәлеләрне хуплыйсыздыр, тик яңа төзелешкә берни белмәгән яшьләр дә килергә мөмкин бит.

**Марат Бибишев:** Бу төзелешкә әллә ни күп кеше кирәкми. Дөрес, әлегә безнең көчләр җитми һәм яңаларны чакырудан, сайлап алудан котылып булмаячак. Моңарчы катнашкан төзелешләрем тарихыннан чыгып әйтә алам: һәрьяклап син теләгән сыйфатларга гына ия хезмәткәрләрне көтеп торырга ярамый. КамАЗны сала башлаганда да без үзе оста, холкы күндәм, гаиләсе бөтен булган төзүчеләрне генә кабул итәргә теләгән идек — андыен гына каян табып бетерә-

МАРАТ БИБИШЕВ • «ИСТӘЛЕККӘ ШӘҺӘР БҮЛӘК ИТӘМ»

сең аның? Сайладык, кайберсенең күзгә күренеп торган начар яклары сизелсә дә, кире борырга ашыкмадык. Тора-бара ышанычлы коллектив тупланды. Минем кулдан да меңнәрчә гаризалар, автобиографияләр узды. Бер вакыйга хәтердә аеруча нык саклана. Эш көне азагы иде инде, бүлмәмә унбиш-егерме егет килеп керде, төзүче булырга телиләр. Тазалар, чибәрләр.

— Һөнәрегез нинди? — дим.

Эндәшмиләр, төзелешкә яраклы осталыклары юк, күрәсең. Арадан берсе:

— Мин төзелеш училищесында укыган идем,— дип куйды.— Ташчылыкка өйрәнгән идем.

Аптырабрак калдым. Эш белмиләр, дип, мондыйларны да кире борып утырсаң, ул йортларны, моңарчы дөнья үзе дә күрмәгән ул заводларны кем салыр?

— Бөтенегезне бер бригадага кабул итсәк, кайсыгызны бригадир ясарсыз? — дим.

— Әнә, ул булдырыр! — дип, теге училище белемле егеткә күрсәттеләр.

Килештек. Дөньяларыбызны онытып, кирпеч түшәүнең элементар кагыйдәләрен кабатлап чыктык. Мин үз белгәннәремне күрсәтеп-күрсәтеп бирдем. Алар һәр сүзне йотып алырдай булып тыңладылар. Шунда мин гел тәҗрибәлеләр белән генә мавыгуның дөрес түгеллеген аңладым. Андыйлар ялгышларга да, бракка да иялəнгән була бит. Яшьләрне үз һөнәреңә өйрәтүнең икенче төрле ләззәте бар. Әлеге егетләр янында мин шуны тойдым.

**Сорау**: Аннары, аннары?

**Марат Бибишев**: «Аннары»сының азагы юк әле. Егетләрем, ышанычны аклап, объект арты объектны өлгертеп кенә торалар. Ул көнне бригадирлыкка тәвәккәлләгәне — Социалистик Хезмәт Герое Вазыйх Мәүликов. Әле күптән түгел Вазыйх белән шул беренче көннәр турында сөйләшкән идек. «Без, сезнең бүлмәгә барып ирешкәнче, җиде оешманың ишегеннән кире борылган идек инде,— дип тасвирлап торды Вазыйх.— Безнең белән юньләп сөйләшүче дә булмады. Сез безгә сәгать ярым вакытыгызны бүлдегез»... Кешеләр үзара сөйләшеп аңлашырга тиеш, тел безгә шуның өчен бирелгән. Атом электр станциясе янында яңа шәһәр салучы участок начальнигы Рәис Сәләхов та — минем шәкерт. КамАЗ төзелеше егетнең сәләтен төрле яклап ачты: аны СССР Верховный Советына депутат итеп сайладылар. Ул бригадасын комплекслы итеп оештырды, төзелешкә кирәкле барлык һөнәр кешеләрен туплаган җитмеш кешелек бригадада бердәм наряд белән эшли башладылар. Рәис Злобин методын камилләштерде, һәм моңа ул үз эзләнүләре аша килде. Кешеләр тапканны кабатларга бик үк өнәп бетерми ул...

**Сорау**: «Минем кебек» дип өстәрсез шикелле тоелды. Сезнең үзегез турында да, кеше кушканга аның бик исе китми, Бибишевның үз сиксәне сиксән аның, дип сөйлиләр. Сез хәтта Мәскәү проект төзү институты директоры академик Борис Рубаненко фикерләренә дә каршы төшкәлисез икән. Алардан проект килеп өлгермәс борын, үз белдегегез белән йортлар салгалагансыз. Рационализаторлык тәкъдимнәрегез дә артык кыю икән. Мондый каршылыклар күбәеп китеп, көннәрдән бер көнне бу постны бушатырга кушмаслармы?..

**Марат Бибишев**: Гаҗәп тә тоелыр, бәлки, әмма мин үзем хакында ишетелгән әлеге сүзләрнең күбесен дөрес дип табам. Кеше кушканны яки гадәтине генә башкарып утырырга яратмыйм. Кайчак күңелгә гаҗәеп төрле яңа бер өйнең проекты кереп оялый, исәпли башлыйсың, сызасың. Бу нәрсә шәһәргә, кешеләргә кирәк булганга бөреләнгән икән — шуны да аңлыйсың. Берсендә мин яшь гаиләләр өчен бик уңайлы йорт проекты иҗат иттем. Коллегаларым да яңа проектны хупладылар. Мәскәүгә, Борис Рафаэлович Рубаненко институтына расларга җибәрдек. Шактый вакыттан соң академикның безгә киләчәген хәбәр иттеләр. Каршы алдык. Аңа шәһәрне күрсәтеп йөрим. Яратты ул безнең шәһәр урамнарын, йортларыбызга соклануын да яшермәде. Аннары: «И-и, кара инде, онытып торам, мин бит сезнең теге проектны раслатып алып килдем»,— ди. Мин көлеп җибәрдем: «Рәхмәт, Борис Рафаэлович! — дим.— Безнең андый типтагы йортларда моннан ике ел элек рәхәтләнеп яшәп яталар инде!» Шоферым ул арада безне нәкъ шул йортлар янына илтеп туктаткан иде. Урам ягындагы бизәкләр йортны гаҗәп күркәм итте, лоджияларының башка төстә булуы да аңа аеруча килешә

иде. Академигым мине, алардан рөхсәт алмый торып, үз белдегем белән мондый эш башкарган өчен ачуланасы урынга, котларга мәҗбүр булды.

Яңалык ачу беркайчан да, берәүгә дә җиңел түгел. Бигрәк тә төзелешнең элекке гадәтләренә бераз каршы төшүчән яңалыкны тормышка ашырганчы (ай-һай), чәчләрең агара. Әмма инженерның фикере төзүче хезмәтен җиңеләйтүчән, шәһәрләрне матурлатучан, чыгымнарны киметүчән эзләнүләрдән тукталмаска тиеш. Минемчә, андый ачышка омтылыш кеше җанына табигать тарафыннан ук салынган. Үземнән чыгып әйтәм. Мине, әле малай чакта, әни бәрәңге төбенә өяргә чыгара иде. Тиешлесен бүлеп бирә дә әйтә: «Шул эшеңне бетермичә, бер кая да китмисең!» — ди. Мин чамалап карыйм: малайларның су кирәргә җыелган вакытына өлгерерлек түгел. Ни дисәң дә, вак эш бит. Мең мәртәбә иелеп, бәрәңгенең һәр төбе тирәли биеп торырга кирәк. Кызурак селтәнгәләп тә карыйм, эш үрчеми. Уйлап тордым да, башта бураэнаның бер ягын өеп буеннан-буена барырга булдым, аннары икенче ягын өеп менәм. Эш күзгә күренеп тизләште... Бу да — үзенә күрә, рациональ ачыш булган. Һәр эшнең камилрәк ысулын табарга мөмкин, кеше акылының чиге юк. Ачышының язмышы нинди кешегә барып бәйләнә: яңалыкны хуплаучыгамы, әллә киребеткән бер юньсезгәме — шунысын гына алдан белеп булмый.

Соңгы вакытта мин төзелеш темпларына сизелерлек этәргеч булырдай яңалыклар белән хыялланып йөрим. Беренчесе — иң зур тоткарлык тудыра торган агач материалларны алыштырырдай бетон детальләрне заводта коеп чыгару теләге. Минемчә, агачны өлешчә алыштырырга мөмкин булачак.

Мине тагын йортларның нигезен ныгытуга сарыф ителә торган вакыт һәм чыгымнар борчый. Өйләрнең стенасын өеп менгезү — берни түгел, фундаментның өлгерүен көтеп, тәмам саргаябыз. Дөрес, моннан берничә еллар элек бераз алга китеш булды. Ныгытылган нигез ысулы тәкъдим ителде. Биек йортларның нигезенә субай батыру өчен бик көчле механизмнар чыкты. Мин шул алымны һәръяклап камилләштермәкче булам.

Әйтик, безнең оешма «Азык-төлек программасы»н тормышка ашыру җәһәтеннән авылларда да йортлар сала. Без авылдагы өйләрнең алтмыш-җитмеш процентлабы бер гаиләгә бирелә торган, бакчалы, аерым йортлар булуын телибез. Шул ук вакытта күп катлылар да салынсын. Аларында белгечләр, интеллигенция вәкилләре, авыл тормышына әле тирән тамыр җибәреп өлгермәгәнрәк яшь гаиләләр торып тора ала. Инде гомергә шунда калырга, төпләнергә ниятлиләр икән, акрынлап аларын да аерым өйләргә күчерергә мөмкин.

Аерым өйләрнең ике метрлап тирәнлектәге идән аслары булырга тиеш. Нигезне ныгытмый ярамый. Теге мәһабәт ташпулатлар нигезен ныгытучы механизмнар артык зур. Мин шуның авыл өйләре нигезен ясаучы кечерәйтелгән вариантын уйладым. Сызымын-фәләнен ясадым инде, машина тиздән өлгерәчәк. Без аны иске-москы механизмнардан гына оештырырга булдык.

Мондый яңалыклар тыныч кына, иләнелгән гадәт буенча эшләп ятучыларга ошамый. Өстәмә борчу, мәшәкать. Тик, минемчә, мәсьәләнең бу ягы — вак нәрсә. Тәндә — җан, күңелдә — дәрт, башта фикер барында, төзелеш инженеры уйланырга тиеш. Аның нинди постта утыруы, аннан төшерүләре — формаль нәрсәләр. Урыннан алып кына талант иясенең сәләтен бетереп булмый. Төзелеш инженерының чын кыйммәтен аңлаган кешеләр, шул исәптән академик Рубаненко да, мине алай «киребеткән кеше»гә түгел, ә «үз фикерен яклый белүче инженер»га саныйлар. Үзеңә булган мөнәсәбәтне дә объектив бәяли белергә кирәк бит әле.

**Сорау:** Сезнең хезмәтләрегез Татарстан җирендә барган зур төзелешләргә кушылган. Алар сезгә дә дан китергән: Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь Революциясе орденнары белән бүләкләнгәнсез. Ничек уйлыйсыз: сезнең катнаш белән салынган ул корылмалар шәһәрләр төзү тарихының ерак киләчәгендә үз эзләрен саклап калырлармы?

**Марат Бибишев:** Билгеле булганча, шәһәрләр тик томалга гына төзелми. Алар кешенең ихтыяҗына бәйле рәвештә туалар. Татарстанны дөнья мәйданына чыгарган нефть, Европада иң куәтледән саналган ГРЭС, АКШ автомобиль производ-

ствосы магнатларын шаккаттырган КамАЗ, продукциясен дистәләгән чит илләргә озатучы нефть-химиясе берләшмәсе — безнең шәһәрләр берсеннән-берсе кыйммәтлерәк әнә шундый предприятиеләр таләбеннән туды. Бу коллективлар исә елдан-ел колачлырак була бара. Татарстанның, СССРның гына түгел, дөньяның ихтыяҗын канәгатьләндерүгә зурдан-зур өлеш кертәләр. Алар белән бергә без салган калаларның да абруе күтәрелә.

Сорау: Сез — зур эшләргә чумган, бик мәшгуль кеше. Сезне Мәскәүдә дә, Казанда да күпләр белә, Брежнев шәһәрендә сезгә йөзләрчә кешеләрнең йомышы төшә. Үзегез шуларның кайсының язмышы белән якыннан таныш, кемнәрне яхшы беләсез?

Марат Бибишев: Төзүче инженерларның гомум гадәте — кеше ярату. Безнең хезмәтнең төп максатыннан киләдер инде бу. Кеше әйбәт шартларда яшәсен, дип тырышабыз. Әйбәтлекнең исә чиге юк. Инженерлык сәләтен үстерүгә бер этәргеч бу. Әмма без нинди генә затлы сарайларның проектын сызып бирсәк тә, никадәр җайлы материаллар тапсак та, әгәр терсәктән — измәгә, тездән балчыкка батып, баштанаяк буяуга чумып эшләүче гади төзүчеләр: ташчылар, монтажчылар, слесарьлар, кранчылар, буяучы-сылаучылар булмаса, безнең хыяллар, ак калалар рәвешендә, җир өстенә калкып чыга алмас иде. Минем иң якын дусларым, кадерле кешеләрем дә — алар. Тәмам өлгереп җитәр алдыннан өйгә буяучылар керә. Разия Шагазина, Галия Вәлиева, алар өйрәткән уннарча кызлар... Разияны мин күптән беләм. КамАЗ салырга ерактан яшьләр агыла башлагач, алар, без моңарчы гомердә ишетмәгәнчә: «Истәлеккә... шәһәр бүләк итәм!» — кебек матур максатлар куеп, җиң сызганып, гайрәт орып эшләргә дә тотынгач, Разиябыз, инде без нишләрбез, дигән кебегрәк, шүрләп тә калган иде. Янәсе укымышлы яшь җилкенчәк җыела да, элекке буяучылар артыкка чыга. Яшьләрне төзүче итәр өчен, нәкъ Разия кебекләр кирәк иде. Без аны училищены яңа гына тәмамлаган кызларга бригадир итеп билгеләдек. Депутат булды Шагазинабыз, орденнар алды. Аның дусты Галия Вәлиева — «Камгэсэнергострой»да бердәнбер «РСФСРның атказанган төзүчесе»...

Сорау: Меңнәрчә төзүчеләре булган берләшмәдәге иң якын кешеләрегезне әйтүне үтенгәч, сез, һич көтелмәгәнчә, кызлар турында сөйләп җибәрдегез. Шул уңайдан аларга булган шәхси мөнәсәбәтегезне дә аңлатсагыз иде! Сезнеңчә, кыз-хатынның тормыштагы һәм гаиләдәге урыны нинди? Һәм Татарстан АЭСен салганда, алар нинди роль уйнар?

Марат Бибишев: Бу очракта мин халыктан уздырып әйтә алмам: ир — баш, хатын — муен. Кайберәүләр моңа хатыннарны кимсетү итеп карамакчылар. Дөрес түгел. Муены булмаган баш җирдә тәгәрәп ята. Баш ул, бары тик муен булганда гына, биектә утыра һәм, муен кая борылса, шул якка борылырга мәҗбүр. Гаиләдә генә түгел, төзелештә дә шулай.

Сорау: Сезнеңчә, иң бәхетле гаилә нинди була?

Марат Бибишев: Иң зур гаилә бәхетле. Безнең ике улыбыз бар. Алар минем һөнәрне сайладылар. Ата кеше өчен моннан да зуррак бәхет юктыр.

Сорау: Сезне Брежнев шәһәренә килгәннән бирле уңайлыклары шактый чикле бер квартирада яши, дип, аптырап сөйлиләр. Балконыгыз да юк икән, бүлмәләрегез дә кечкенә, ди. Инде әллә нинди яңа проектлар буенча бик җайлы өйләр салынган. Яңа өйгә күчәргә тәкъдим ясаганнар. Күзгалмагансыз. Әллә атомчылар янына, Кама Аланына китәргә чамалап торасызмы?

Марат Бибишев: Үземнең кайда яшәү турында уйларга вакытым да юк минем. Дөрес, матурлыкларына сокланган шәһәрләрем күп: Киев, Фрунзе, Ташкент, Балтик буендагы совет республикаларының искиткеч күркәм шәһәрләре... АЭС кешеләре яшәячәк Кама Аланы да бик матур, җыйнак, уңайлы кала булачак. Тик, яшәр өчен кайсын сайлыйсың, дисәләр, мин... авылга китәр идем. Әнә, безгә якын гына Суксу авылы бар... Киләчәктә авыл өйләренә бөтен уңайлыклар кертелер, нык юллар сузылыр һәм кешеләр авылга кызыгырлар. Татарстан атом электр станциясе энергетикларына без бүләк итәчәк яңа шәһәр дә кешеләрнең шундый омтылышларын күздә тотып салыначак.

— Җавапларыгыз өчен рәхмәт. Изге теләкләрегез тормышка ашсын!

Әңгәмәне язучы **КОЯШ ТИМБИКОВА** алып барды

Фәтхулла Абдуллин

# ҖЫЛЫ ЮЛЛАР

ОЧЕРК



Соңгы вакытта Гыйльметдинов егетләре шәһәрдән пионер лагерена юл сузалар иде. Лагерь елганың дугайланып, ярымутрау хасил иткән матур бер урынына салына. Яр буйлары — тоташ урман. Башлары күккә тигән көяз наратлар, нәфис юкәләр, колач җитмәслек юан имәннәр үзара аралашып үскәннәр. Куаклык, аланлыклар мәһабәт урманның нәкъ кирәкле төшен сайлап утырганнар. Табигать, әйтерсең, бу урынны, кешеләргә ял итәр өчен, махсус ясап куйган.

Төзүчеләр лагерьның торак биналарын, клубын өлгертеп киләләр. Юл салучыларның да эшләре әйбәт кенә бара. Күп булса, ун-унбиш көннән эшләр төгәлләнәчәк. Озакламый бу төбәктә бала-чага чыр-чуы яңгырап торачак иде. Минсәгыйр Талипович, шуларны уйлап, ирексездән елмаеп куйды. Төзүче өчен үз эшеңнең нәтиҗәсен күрү — күңелле хәл, әлбәттә. Ләкин... Их, шлагбаум киртәсе кебек, юлыңа аркылы төшүче шул «ләкин»нәр булмаса! Кичке киңәшмә беткәндә генә, идарә начальнигы Гыйльметдиновка карап калды.

— Пионер лагерена юл салуны туктатыгыз, иптәш Гыйльметдинов! Иртәгәдән этиленга күчәсез. Аңладыгызмы?

Менә сиңа, мә! Лагерь юлын төгәллибез, дип торганда гына... Минсәгыйр Талипович калкынып куйды.

— Биш километрын салдык, биш йөз метрына калгач, туктыйкмы? — диде ул сабыр гына.— Берочтан бетереп куярга иде инде аны!

— Бүгенгесе көндә безнең өчен этилен цехлары мөһимрәк. Юллар булмаса, аларны беренчеләр комиссия дә кабул итмәячәк. Аңлыйсызмы, иптәш Гыйльметдинов? Кичә штабта да, Кәрим Хәмидуллович, тематикадан артта каласыз, дип, мине кыздырды. Иртәгәдән кешеләрең анда булсын! Әгәр дә, башбаштакланып, монда да мөгез чыгарсагыз, үзегезгә үпкәләгез!

Гыйльметдиновның бер башлаган эшне ничек тә төгәллисе килә иде. Хәзер әнә яз җитте. Лагерь юлы барыбер кирәк булачак. Ә бер калдымы, кала инде ул. Тизрәк эшләнәсе эшләр, тагын да мөһимрәк объектлар табылып кына торачак. Борынгылар юкка гына, калган эшкә кар ява, димәгәннәр инде.

— Җир асты коммуникацияләрен салып бетергәннәрме соң әле анда? — диде ул аптырагач.— Соңыннан безнең юлны ватып, траншея казымаслармы?

— Бетергәннәр, иптәш Гыйльметдинов, бетергәннәр! — диде идарә начальнигы, аның ни әйтәсен алдан ук сизеп.— Бетермәсәләр, безгә әйтмәсләр иде.

Участок начальнигы тәмләп кенә пылау ашаганда теш арасына таш эләккән кеше сыман йөзләрен чытты. Дөрес, тематикадан артта калырга ярамый — аны-

сы аңлашыла. Шулай да, ни өчен нәкъ менә аның участогы барырга тиеш соң әле анда? Идарәдә тагын дүрт участок бар лабаса...

Минсәгыйр ай ярым элек кенә, идарә начальнигы белән хәйран чәкәләшкән иде. Яңарак кына өйләнгән Василий торак мәсьәләсендә ярдәм итүләрен сорап, начальник катына барган икән, аңа:

— Тиз генә хәл итеп булмас! — дигәннәр. Башын түбән игән, бөтенләй борыны салынган егетнең.

— Китәргә туры килер инде, абый...— ди.

Участок начальнигы бер карусыз эшләп йөргән бу егетне кызганып куйды. Әле яңарак кына килүенә карамастан, ут уйната. Кайбер бушбугазлар кебек, бер тиенлек эшләп, ун тиен даулый торганнардан түгел. Яшь кәләше белән торырга куышы, һич югы, баракның бер почмагы булса, эшләячәк, бер урыннан икенче урынга чабып йөрмәячәк. Дөрес, башыннан сыйпап юатырга ул инде сабый түгел. Шулай да, кеше күңеле — пыяла, кайчагында җиткән егетләргә дә акыллы киңәш бирүче кирәк.

— Василий энем, борчылма. Бәлки берәр җае табылыр. Иртәгә профком председателе белән үзем сөйләшеп карармын.

Профком председателе белән генә сөйләшеп калмый Минсәгыйр, идарә начальнигына ук барып җитә.

— Бер ел эшләмәгән кеше өчен приемга йөргәнче, әнә, участогыңны монда күчер! — ди аңа идарә начальнигы.

— Участок?! Анда торса ни дә, монда булса ни. Аннан берни дә үзгәрми. Менә Василийга ярдәм итәсе иде, Михаил Алексеевич. Тырыш егет бит ул безнең. Эш өчен җанын аямый торган егет.

— Юк, син ишеттеңме мин әйткәнне? — дип үзсүзләнә идарә начальнигы Василий хакындагы сүзне беткәнгә санап.— Ничу участогыңны анда, бетон заводы янында тотарга. Җыелышка дисәң, артыңнан курьер йөгертергә туры килә. Җитте сиңа! Утырма анда, үзеңә бер автономия ясап.

Участокны төзелеш базасы янында тотуның үзенә күрә уңайлыклары да бар шул. Ара якын булгач, төзү материаллары ташыганда, эш икеләтә тизрәк бара. Куштылар дип кенә тик торганда, участокны кузгатып булмый, файдасыз шөгыль.

— Юк, Михаил Алексеевич, хәзергә аңа тотынмыйм, көн җылыта башлагач, төзү материалларын объектларга ташыйбыз. Менә шунда бәлки, участокны да...

Идарә начальнигы өстәл сугып кычкыра:

— Участогың иртәгә үк диспетчерлык каршында булсын! — Ул чагында начальник әйткәнчә эшләмәде Минсәгыйр. Тактасын түгел, шырпысын да күчермәде. Тора-бара әле бөтенләй киресенчә килеп чыкты. Бер ай үттеме, юкмы, диспетчерлык пункты утырган урынга йортлар сала башладылар. Шул сәбәпле калган участоклар да Минсәгыйр тирәсенә елышты. Василийның торак мәсьәләсен дә, күмәкләшеп, бик тиз хәл иттеләр алар. Пропилен заводы булачак урында киселгән агачларны яздырып алдылар да йорт бурап бирделәр... Ә хәзерге мәсьәлә катлаулырак. Мәскәү контрольлегендә торган объект белән шаярырга ярамый. Сызымнар белән танышканнан соң, участок начальнигы, прорабларны алып, яңа объектны карарга китә. Цехлар арасында да, резервуарлар тирәсендә дә торба салучылар күренми. Траншеяларның эзе генә калган. Күрәсең, алар, чыннан да, үз эшләрен төгәлләгәннәр иде. Ә юл полотносында!.. Кырмыска оясына таяк тыкканнармыни! Бер якта куәтле скреперлар тырыша-тырыша балчык, ком-таш ташыйлар. Тагылмалы катоклар өелгән балчыкны тыгызлап йөри. Икенче якта автогрейдерлар эшли. Егетләр мастерны күреп сөйләшәләр.

— Кайчан әзер булыр икән? — ди Минсәгыйр, балчык өеменә ишарәләп.

— Берәр атнадан төгәлләрбез, дип уйлыйм.

Атна сүзен ишеткәч, Гыйльметдиновның борчулы йөзе яктырып китә.

— Һа, егетләр, болай булгач, пионерларга да байтак нәрсә майтарырга өлгерәбез әле!

— Хуҗа тагын тузынмасмы соң? — ди Әхмәтшин шикләнеп.

Ахунҗанов яшьләргә хас кайнарлык белән аның сүзләрен әләктереп ала.

— Ул идарәгә хуҗа булса, участокка без хуҗа!

— Шулай да бригадирлар белән сөйләшик әле.

Анысына барысы да ризалаша.

Менә ничә сәгать инде аларның сүзе һаман шул бер мәсьәлә тирәсендә әйләнә. Кемдер берсүзсез күчәргә тәкъдим итә, икенчесе аңа каршы төшеп кенә калмый, кызып ук китә. Стена буенда утырган Андреевның да борчуы йөзенә чыккан. Башкорт егете Миннәхмәт тә, карашын бер ноктага төбәп, уйланып утыра. Тәҗрибәле Георгий да бүген аптырап калган. Аны да шул ук сорау борчый.

— Нишләргә соң инде хәзер безгә, нишләргә?

— Аптыраган инде! — ди. Әхмәтшин җилкәләрен җыерып куя.— Күчмәсәң дә яхшы түгел, күчсәң дә әллә ничек... җитмәсә, кызларыма да, лагерь юлын салып бетерәбез, дигән идем. Аларга хәзер нәрсә диярмен?..

Индус Әхмәтшинның сүзләре Минсәгыйрнең дә үзәгенә төште. Аның да өч кызы бар ич. Хәер, монда утырган һәркемнең баласы үсеп килә.

Прораб бүлмәсендә авыр тынлык урнашты. Ачык тәрәзә аша, кайдадыр, еракта гүләгән машиналар тавышы, трамвайлар чыңгылдыгы ишетелә. Аларга участок тирәли утырткан имәннәр шавы килеп кушыла. Бүлмә эчендә тын булса да, дөньяда хәрәкәт тукталмаганын исбатлап, яшь яфраклар шыбырдаша.

Тынлыкны беренче булып Ахунҗанов Хәлим бозды.

— Болай булмый, егетләр!

Моңарчы башкаларны тыңлап утырган Минсәгыйр күңелендә төпле бер фикер туган иде.

— Әйдәгез, болай итәбез! — диде ул.— Тәвәккәлләп, участокны икегә бүләбез! Вакытлыча.— Минсәгыйр Талипович, иң ахырдан, уенын-чынын бергә кушып дигәндәй, бүлмәдәгеләргә карап, бармак селкеп куйды.— Колагыгызга киртләп куегыз, егетләр, бу турыда беркем белергә тиеш түгел!..

Бер бригада яңа урында хәстәрлек эшләрен карый торды, шул ук вакытта икенче бригада лагерь юлына бетон түшәүне дәвам иттерде. Начальник сизмәсен өчен, бетонга да яңа объект хаҗәтенә сорап, заказ бирделәр. Прораб Ахунҗанов исә көн саен, иртән заводка килеп, аларны кирәкле юнәлешкә җибәрә торды. Диспетчерларның «ялгышын төзәтә» иңсе.

Тегендә дә, монда да эшләр көйләнеп кенә барганда, Василий ут капкандай йөгереп, Минсәгыйр янына килеп керде. Гыйльметдинов шикләнә калды — тагын ни кирәк икән бу егеткә?

— Минсәгыйр Талипович, бригадирыбыз авырый, больницага озатырга кирәк!

— Шайтан алгыры! — дип куйды Гыйльметдинов үзалдына.— Шундый чакта кирәк бит!

Андреевның кан басымы югарылыгын ул белә иде. Аңа беренче кварталда ук путевка бирергә тиешләр иде дә бит, нишләптер, һаман суздылар да суздылар. Иртәгә профком председателе янына кереп чыкмый булмас, ахры. Ул тиз генә куен дәфтәрен тартып чыгарды да, нидер сызгалап, Василийга сузды.

— Мә, бу кәгазьне Индус абыеңа бир. Беренче килгән машинаны туктатыгыз да, авыруны врачка илтегез. Ә син — Андреев савыкканчы — бригадир.

Василий ни әйтергә белми икеләнеп калды. Ничек инде, шулай көтмәгәндә генә? Участокта аннан башка да, Кузнецов Алексей, Хәйруллин Шамил, Хамматов Абдулла кебек унар-унбишәр ел эшләгән кешеләр бар ич.

— Минсәгыйр абый, мин бит әле...

— Объектны бригадирсыз калдырып булмый бит инде. Үзең беләсең, эш тукталмаска тиеш.

Василийның әле һаман икеләнеп торуын күреп, ул тагын өстәде:

— Ә син курыкма! Ярдәм итәрбез.

...Алар этилен цехларына илтүче юлларны вакытында өлгерттеләр. Шуңа күрә дә бүген төзүчеләрнең күңелләре күтәренке. Аларның шатлыклары йөзләренә, елмаюлы күзләренә үк күчкән иде.

Борылыштан җиңел машина килеп чыкты. Төзүчеләр аны төсеннән үк таныдылар. Ул — юллар һәм җир асты коммуникацияләре салучы дүрт идарәне бер-

ләштергән «Спецстрой» тресты начальнигы Кәрим Хәмидуллович Вәлиуллинны-кы. Җиңел машина төркем янына ук килеп терәлмәде, яңа салынган бетонга җитәрәк туктады. Чем-кара елгыр «Волга»дан Кәрим Хәмидуллович белән бергә партком секретаре һәм кулына байрак тоткан профком председателе дә чыктылар. Зур җиңүгә багышланган митинг ачык дип игълан ителгәч, Кәрим Хәмидуллович сүз алды. Ахырдан:

— Булдырдыгыз! — диде ул. Гыйльметдиновның кулын кысты.— Сынатмадыгыз! «Спецстрой» трестының күчмә Кызыл Байрагы бу юлы да сезгә тапшырыла!

Тирә-юнь алкыш тавышларына күмелде. Бу алкышлар Василийга язгы ташкын шавы кебек тоелды. Ел фасылы буенча, чыннан да, һәр тарафка яз исе таралган иде. Кая карама, табигатьнең уянуы сизелә. Цехларның аерым бинала-ры арасындагы агачлар яфрак яра башлаган, җирдә үлән шытып килә, тугайларда беренче чәчәкләр, беренче кузгалаклар күренә башлаган.

Кәрим Хәмидуллович идарә начальнигы белән участок начальнигы арасындагы конфликтны белә иде. Митинг тәмамлангач, ул әйтә куйды.

— Иртәгәдән тегендә калган эшегезгә тотыныгыз. Анысы да — безнең җилкәдә.

Участок начальнигы белән бригадир янәшә басып торалар иде. Алар, берберсенә карашып, мәгънәле генә елмаештылар, икесе берьюлы:

— Ә без аны күптән төгәлләдек инде! — диделәр.

— Кайчан? Ничек?

— Анысы — хәрби сер.

Кәрим Хәмидуллович аларны ачуланырга да, ачуланмаска да белми аптырап калды: вәт шайтаннар! Кайчан өлгергәннәр диген! Тантана иткәндә, бу турыда төпченү килешми иде.

— Ух сезне, партизаннар!

Ул бу сүзләре белән шелтәләү белдерергә теләсә дә, чынлыкта алар мактау кебек яңгырады.

— Кәрим Хәмидуллович, яңа объектка кайчан күчәбез инде? — диде Василий түземсезләнеп. Аның тизрәк яңа урынга, тагын да зуррак объектка күчәсе килә иде.

«Спецстрой» начальнигы — Василийга текәлде, елмаеп бармак селкеде.

— Сез болай да күчкәнсездер инде.

— Без бит әле кая күчәргә икәнен дә белмибез.

— Әнә, участок начальнигыгыздан сорагыз инде,— диде ул, буйга уртача гына булса да, имәндәй нык гәүдәле Гыйльметдинов ягына ишарәләп.— Киләсе айда кайда эшлисен ул биш бармагы кебек яхшы белә. Төнлә уятып сорасагыз да, әйтеп бирер.

Бу минутта төзүчеләрнең яуда җиңүчеләр белән уртаклыгы бардыр сыман тоелды миңа. Алар да, бер крепостьны алып, икенчесен штурмларга юнәлгән сугышчылар сыман, бер объектны бетерәләр дә икенчесенә юнәләләр. Минсәгыйр Талипович Гыйльметдинов егетләре изопрен каучук, изопрен-мономер, ике стадияле дивинил, бутиллатекс объектлары, этилен һәм пропилен комплексларына юл салдылар.

Бүгенгесе көндә алар Түбән Кама — Чистай арасына юл сузалар. Көн матур. Мондый көндә эшлә дә эшлә генә. Куәтле «МАЗ»лар, «КамАЗ»лар бетонны опалубка арасына китереп аударып торалар. Кызлар аны тиешле калынлыкта тигезләгәч, өстеннән вибратор үткәрәләр. Бетон астына комташ-түшәк җәю белән генә чикләнмиләр, җәймә урынына су үткәрми торган кәгазь дә салалар. Өстен дә җылы юрган: 20—25 сантиметр калынлыкта пычкы чүбе белән җентекләп түшиләр. Яңа салынган бетонны, кавырсыны катканчы, 28 тәүлек буена әнә шулай яңа туган баланы тәрбияләгән кебек кадерләп, һәр даим күзәтеп торалар: җылылык җитәрлекме? Суы җитешлеме? Кибәрлек түгелме? Чиләкләп койган яңгырда да юл салырга ярамый. Чөнки ул аның башын — бетонның ныклыгын тәэмин итүче цемент «сөтен» юа. Корбанова Фәһимә, Кәрамова Даимә, Шәмсиева Сабира, Шәйхетдинова Нурания, Хәйруллина Әкълимә кебек унбишәр-уналтышар ел буе юл салган кешеләр моны яхшы белә. Әнә бит, икенче смена инде күптән

килгән, алар әле һаман бетон тирәсендә кайнашалар. Әле виброрейка астыннан сыгылып чыккан бетонны кире опалубка арасына салалар, әле югарак ябылган тәшен табып пычкы чүбен өстиләр. Кайбер кыбырсыграк яшь-җилкәнчәк түәми, автобус ишегеннән башын тыгып кычкыра.

— Эш сәгате беткәч, нишләп торабыз? Әйдәгез, кайтыйк инде!

— Вахта машинасы китә. Тизрәк булыгыз!

— Хәзер, хәзер!

Бетон юллар! Бу сүзләрне әйткәч, күп кешеләрнең күз алдына өстеннән машиналар тыз-быз чабучы, таш кебек каты юл килеп баса торгандыр. Ә сезнең үз гомерегездә бер генә тапкыр булса да, шул юлларны кулыгыз белән тотып, капшап караганыгыз бармы? Карагыз әле: ул чакта, сез, һичшиксез, гомерләрен юл салуга багышлаган кешеләрнең йөрәк җылысын да тоярсыз.

# *Бер сорауга—бер җавап*

**Сорау:** *Җыр язучы композиторларга, шагыйрьләргә нинди теләкләрегез бар?*

**Заһит Хәбибуллин:**

*— Иң башта шул: шагыйрьләр белән композиторлар дуслыгы тагын да ныгысын иде. Аннан соң: сюжетлы җырлар да күбрәк булсын иде... Тагын: мәхәббәт турында җырларыбыз күп, әмма соңгы елларда туганнары арасында чын мәгънәсендә моңлы да, матур да булганнары аз. Мәхәббәт турындагы җырлар үзләре дә гүзәл булырга тиешләр!*

*Күңелле, шаян җырлар ешрак туса да, бик сөенер идек!*

Илдус Ахунҗанов

# КҮҢЕЛ КАЙНАРЛЫГЫ

Чаң сугудан башланып китте безнең дискуссия. Дөресен генә әйткәндә, әдәбиятыбыз күгендә давыллы яңгырның беренче билгеләре инде күптәннән сизелә иде. М. Мәһдиевнең «Әдәбиятта яңалык тойгысы» («Казан утлары», 1981, 10 сан) исемле сөйләшүдә әйткән сүзләре шушы давылның беренче хәбәрчесе кебек булды. Һәрвакыт үзенчәлекле фикерли торган бу язучы ул чакта беркатлырак итеп: «Кайчан безнең китапларыбызны, Айтматов китаплары кебек, чиратка язылып укырлар икән», — дип әйткән иде. Монысы күбрәк аның үзе турында булды. Ә менә тулаем татар әдәбияты алдына таләпләрне: «Айтматов, Быков, Абрамов, Бондарев, Распутиннар осталыгына ирешергә кирәк», дип куйды язучы.

Аяз Гыйләҗевның бу сөйләшүгә сәбәпче булган «Тынычлану зарарлы!» дигән мәкаләсе әдәбият күгендәге яшен уты кебек тәэсир итте. Яза белә Аяз, шәп яза. Образлы тел белән һәм көн кадагына сугып яза. Безнең әсәрләребезне рус, совет, хәтта бөтендөнья әдәбияты мисаллары белән чагыштыра, нәтиҗәләр ясый. Аның мәкаләсе миңа Леонид Утесов җырлаган иске бер җырны хәтерләтте: «Все хорошо, прекрасная маркиза, все хорошо, за исключением пустяка...» Ә «пустяк» дигәне янгын икән ләбаса. Шуның шикеллерәк түгел микән бездә дә? Әнә шуңа күрә чаң сугабыз түгелме?

А. Гыйләҗевның проблемага субъектив карашы — мәкаләнең көчле ягын тәшкил итә! Чөнки субъективизм белән субъективлык арасында искиткеч зур аерма ята. Йөрәк ялкыны белән акыл, белем кушылганда, А. Гыйләҗевның аерым язучыларга карата әйтелгән чәнечкеле сүзләре, арттырып җибәрүләре үзләреннән үзләре аклана, һәм романтизм белән сугарылган пафос яңа сыйфат ала. Бәхәс тә кызыклы, эчтәлекле була. Бу очракта мин дә, әдәбиятыбызның уңышларына сөенүче кешеләр белән бергә аның пафосына кушылмый кала алмыйм.

Әдәби тәнкыйть — әдәбиятның документларга нигезләнгән төгәл өлкәсе. Чикләнмәгән хыял җимеше булган прозадан, поэзиядән, драматургиядән аермалы буларак, тәнкыйть даими үзгәреп, хәрәкәтләнеп торган әдәби процесс белән эш итә. Һәм шуңа күрә ул үзе һәрвакыт объектив, төгәл, фәнни булырга тиеш. А. Гыйләҗевка килсәк, ул, художник буларак, теоретик Гыйләҗевтан күп тапкыр көчлерәк һәм өстенрәк. Бу аның мәкаләдә китергән фактларында да чагыла. Гадәттә, киң күңелле тәнкыйтьчеләр гомуми картина дөрес булганда аерым очракларга гына бәйләнеп тормыйлар! Әмма бәхәс барганда кечкенә генә факт та игътибардан читтә калмый һәм, кылычларны чыңлатып, аларның да асылын аңларга кирәк була. Әйдәгез, А. Гыйләҗевка «Йөз ел ялгызлык» романы авторы Габриэль Гарсиа Маркес үгет-нәсихәт бирсен әле. Ә минем вазыйфам Г. Маркесның «Чуайава исе» дигән китабыннан тиешле юлларны гына китерү булыр.

**Аяз Гыйләҗев:** Билгеле, әдәбиятта гомуми законнар юк...

**Габриэль Маркес:** Ирекле тоелган иҗат эшендә һәрвакыт төгәл закончалыклар хөкем сөрә...

**Аяз Гыйләҗев:** Асылда Эдуард Касыймов — бер генә китап авторы...

**Габриэль Маркес:** Китаплар күп томнарда һәм төрле исемнәр белән чыксалар да, һәр язучы бер генә китап авторы.

Үз темасын тапкан андый язучылар татар әдәбиятында да берничә дистәгә җыела...

Дискуссия барышында әдәбияттагы прогресс, үсү, алга таба бару мәсьәләләре калкып чыккан икән, миңа да, телимме-теләмимме дигәндәй, оппонентыма җавап бирергә туры киләчәк. Гомумән, әдәбиятта үсү, алга китү нәрсә ул? Аны ничек билгеләргә мөмкин?

Минемчә, әдәбияттагы прогресс мәсьәләсенә зур үлчәүләр, глобаль масштаблар белән килергә кирәк һәм позициян теоретик яктан ачык, методологик яктан дөрес булырга тиеш.

Яңа кешене тәрбияләү эшендә әдәбиятның роле ничек кенә зур булмасын, ахыр чиктә, барыбер, прогрессның нигезен материаль базис тәшкил итә. Әлбәттә, материаль тормыш һәм яңа кешене тәрбияләү чаралары үзара нык бәйләнештә була, бер-берсенә тәэсир итә. Ләкин шуны да онытмыйк: ФТР производствога торган саен күчлерәк тәэсир итә, җитештерүче көчкә әверелә бара. Кыскасы, фән һәм техниканың тормышка тәэсире әдәбият-сәнгатьнекеннән күчлерәк була бара.

Әмма тарихта җәмгыятьнең рухи тормышын нәкъ менә әдәбият әйдәп барган чорлар да булган бит. Безнең чорда әлеге тигезсезлек нилектән килеп чыга соң? Сәбәбе нәрсәдә? Моны ничек аңлатырга?

Үткән заманнарның лабиринт кебек катлаулы иҗтимагый тормышында буталып калмас өчен, безгә К. Маркснын «Экономик кулъязмаларга кереш»ендә әйтелгән фикерләре методологик нигез булып хезмәт итә. «Сәнгатькә карата шунысы билгеле,— дип яза К. Маркс,— аның чәчәк атуының мәгълүм чорлары һич тә җәмгыятьнең гомуми үсешенә һәм, димәк, җәмгыять оешмасының скелетын тәшкил итә торган нәрсә — аның материаль нигезе үсешенә дә туры килмиләр».

Бу сүзләрдә, фокуска җыелгандай, сәнгатьтәге прогрессның специфик үзенчәлекләре чагыла.

...Россия XIX йөздә экономик яктан артта калган дәүләт булып яшәде. Шул ук вакытта бу дәвердә бөек рус әдәбияты искиткеч биек баскычка менде. Шундый биек баскычка менде ки, дөньяның иң бөек әдәбиятына әверелде. Пушкин, Лермонтов, Белинский, Гоголь, Гончаров, Герцен, Тургенев, Достоевский, Некрасов, Островский, Салтыков-Щедрин, Чернышевский, Толстой.

Китап киштәсеннән Сергей Залыгинның «Литературные заботы» исемле китабын алам, 282 битен ачам. Анда «Язучы һәм традицияләр» исемле мәкалә урнаштырылган. Укыйм: «Бер үк хатын-кыз бу кешеләрнең барысына да ана була алыр иде: ул 17 дә Пушкинны тапса, 46 да Толстойны тудырыр иде». Кемне генә алма — барысы да титаннар! Безнең күз алдына гениальлардан гына торган бер зур гаилә килеп баса.

Бер гасырдан соң татар әдәбияты да шуңа охшаш прогресска иреште. Габдулла Тукай, Гафур Колахметов, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Мирхәйдәр Фәйзи, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев кебек татар әдәбияты классиклары 1905 елгы беренче рус революциясе дулкынында үсеп чыктылар. Әгәр миннән рус әдәбияты белән татар әдәбиятының типологик охшашлыгы нәрсәдән гыйбарәт дип сорасалар, бераз схемалаштырып булса да: «Самодержавиегә каршы протесттан гыйбарәт!» — дияр идем.

Рус әдәбиятында да, аның белән тыгыз бәйләнештә булган татар әдәбиятында да тарихи яктан караганда социалистик реализм критик реализмнан биегрәк баскычта тора, чөнки ул — социалистик тормыш җимеше. Ул критик реализмнан прогрессиврак күренеш. Без һәрвакыт совет әдәбиятына новаторлык, яңалык хисе хас дибез, чөнки совет әдәбияты дөнья әдәбиятының үсеш юлында яңа бер этап булып тора. Совет әдәбиятының төп лозунгы — социалистик җәмгыятьне раслау! Шуңа күрә анда уңай геройның роле критик реализмдагыга караганда күп тапкырга артты. Әмма моның белән генә социалистик реализмның эстетикасы һәм поэтикасы чикләнә микән? Ачылган мөмкинлекләр бер нәрсә, ә бит реаль нәтиҗәләр бөтенләй икенче нәрсә!

Совет әдәбиятының хәзерге казанышлары зур. Әмма безгә критик реализм ирешкән уңышларны да онытмаска кирәк. «Үзең яшәгән чор прогрессы белән горурлану,— дип яза Белинский,— үз казанышларың түгел әле ул. Һәм үзеңә кадәр яшәгәннәрдән алда булу да һәр очракта да алардан өстен, яхшырак һәм мактауга лаеклырак дигән сүз түгел».

Егерменче елларда, үткән заманнарның культура мирасын инкяр итү модага кергәч, футуристлар: «Пушкинны заман корабыннан ташлап калдырырга!» — дип шаулаштылар. Алар Тукайны да шулай ук инкяр итәргә маташтылар. Вакыт исә, киресенчә — Пушкинның да, Тукайның да үткәндә генә түгел, ә киләчәктә дә яшәячәген раслады — совет әдәбиятының киләчәгендә дә!

Сәнгатьтә зур сүзне һәрвакыт зур шәхес, талант әйтә. Заман, тарих, вакыт таләпләрен истә тотканда, аңлаганда, художникның иҗаты искиткеч бай җимешләр бирә. Һәм менә кайбер тәнкыйтьчеләр (арада язучылар да бар) замандашларының китапларын үткән дәвер шедеврлары белән чагыштыралар да ялгыш фикергә киләләр. Мисалны әллә кайдан эзлисе юк, ул шушы дискуссиядә дә байтак күренә.

Әйтик, В. М. Шукшинны без барыбыз да яратабыз. Әмма моңа карап кына әле Шукшин белән Чехов арасына тигезлек билгесе кую кирәк микән? А. Гыйләҗев үз мәкаләсендә мондый билгене куя. Дөрес, үзен аклар өчен ул бер дәлил дә китерә: янәсе, әдәбиятның асылын һәрвакыт кешеләр, характерлар билгеләде, һәм Шукшин бу ягы белән йөзләгән, меңләгән язучылардан аерылып тора.

Классиклар һәм хәзерге заман язучылары турында уйланганда, иң элек охшашлыкны түгел, аерманы эзлисең. Талантлы язучы Шукшин әсәрләрендә, мәсәлән, Чехов белән Бунинда булмаган сыйфатлар — кинематографиклык бар. Шул ук вакытта Шукшинга Чехов белән Бунин әсәрләрендә булган сыйфатлар — чынбарлыкны универсаль күрү, вакламыйча тасвирлау җитенкерәми. Аннан соң мәсьәләнең асылы шунда — алар икесе ике тарихи дәвер, ике социаль система вәкилләре һәм шуңа аларны янәшә кую, чагыштыру мөмкин дә түгел. А. Гыйләҗев арттырып җибәрүен үзе дә сизә шикелле, шуңа күрә ул гомумиләштерүдән ерак торган «миңа калса» сүзен куллана, фикеренең шәхси мөнәсәбәт кенә икәнен яшерми.

А. Гыйләҗев позициясе Фуат Галимуллин тарафыннан берсүзсез кабул ителә. Дискуссияне башлап җибәрүченең дәртле, форма ягыннан да кызык килеп чыккан мәкаләсеннән сихерләнеп (А. Гыйләҗев чыгышы булмаса, мин бәлки кулыма каләм дә алмас идем, ди ул), «Мөмкинлекләр бар!» исемле мәкалә язган. Мәкалә тулысы белән А. Гыйләҗевны һәм башка язучыларны яклауга багышланган. Аның: «Гомумән, тәнкыйть язучының шәхесенә карап түгел, әсәрнең үзеннән чыгып кына язылырга тиеш» дигән сүзе дә бик гаҗәп! Бу — методологик яктан башка сыймаслык установка! Марксистик тәнкыйть, француз тәнкыйтьчесе Сент-Бев нигез салган биографик мәктәп казанышларыннан файдаланып, сәнгать әсәрен һәрвакыт художник шәхесе белән берлектә өйрәнә. Ф. Галимуллин ирекле манерада язылган Корней Чуковский, Юрий Тынянов, Виктор Шкловский, Ираклий Андронников китапларын күрмәде микәнни?! (Бездә бу жанрда язучылар чыннан да аз — Рафаэль Мостафинның «Өзелгән җыр артыннан»ы белән Ибраһим Нуруллинның «Габдулла Тукае» гына искә төшә.)

Ни өчен бәхәсләшәбез соң ул чакта?

Рафаэль Мостафин үз мәкаләсендә проблеманы реалистларча аңлаган. Бөтен союз масштабларында фикер йөртүче тәнкыйтьче соңгы еллардагы татар прозасын безгә уч төбендәге кебек күрсәтеп бирде. Беренче чиратта авторның оста полемист икәнлеге күзгә бәрелә. А. Гыйләҗевка хөрмәте зур булуга да карамастан (бәлки нәкъ шуның аркасындадыр да), ул бәхәстә үз карашын кыю үткәрә һәм язучыны субъективлыкта, волюнтаризмда гаепли. Р. Мостафин мәкаләсендә үткәрелгән концепция белән мин тулысынча килешәм. Аның мәкаләсе менә бер уңайдан гомуми күзәтүләрдән, төрле авторларның фамилияләрен санаудан азат итә. Анализ ясамыйча гына исемнәр әйтү акылга да, күңелгә дә берни бирми. Ә бу хәлне, кызганычка каршы, тәнкыйтьтә без еш очратабыз.

Шулай итеп, бәхәс кызганнан-кыза бара. Журналда яшь тәнкыйтьче Фәез Зөлкарнәевнең «Чакма чакмый ут чыкмый» (нинди кызык исем!) исемле мәкаләсе дә басылды. Аның мәкаләсенең яхшы якларыннан берсенә генә тукталам. А. Гыйләҗев М. Мәһдиев стиле турында язганда аның поэтик үзенчәлеге итеп стиленең фрагментлардан торуын әйткән иде. Тәнкыйтьчеләрне шул индивидуаль стильнең серен ачарга да чакырган иде. Шул ук вакытта ул Мәһдиев стилендә «өзелмәс моң бар» дип тә язды. А. Гыйләҗевтан аермалы буларак, Тәлгат Галиуллин үз мәкаләсендә М. Мәһдиев стиленең «серен» психологизм һәм милли колоритта күрде. Аларга өстәп, Ф. Зөлкарнәев кино сәнгатенә нигез салучыларның берсе булган Дзига Вертовтан

уңышлы цитата китерә һәм Т. Галиуллинның фикерен тагын да җитдиләндереп, киңәйтеп җибәрә. М. Мәһдиевнең мозаик, фрагментлар стиленә характеристика бирә. Бу характеристиканы да бераз киңәйтергә кирәктер, күрәсең. Әлбәттә, гүзәллекне төрле стиль, төрле алым кулланып тудырып була, шул ук М. Мәһдиевкә хас алым белән дә. Әмма фрагментлар белән мавыгу — нишләсәң дә, җитешсезлек, көчсезлек билгесе! Геройның эчке дөньясын күрсәтү, психологизм, һәр детальгә тукталып, характерны җентекләп тикшерү — хәзерге рус прозасында бик тә гадәти хәл (татар прозасында гына ул ниндидер яңалык булып кабул ителә), һәм бу нәрсә беркайчан да сюжет төзүгә, композициягә игътибарны киметергә тиеш түгел. Сюжет, фабула, кискен хәлләр, вакыйга булдыру — тулы канлы әдәби образ тудыру өчен алыштыргысыз нәрсәләр. Кызыктыргыч сюжет ярдәмендә киң катлам укучы күңеленә ачкыч табып була. Шуңа күрә М. Мәһдиевкә сюжетны ныгыту өстендә күбрәк эшләргә кирәк, һәм шул ук вакытта йөрәккә үтеп керә торган шигърилеген, моңсу юморын, әсәрләрендәге музыканы да югалтмасын иде ул.

Мәкаләнең логикасы буенча миңа күптән инде тәнкыйтьләр башларга вакыттыр, күрәсең.

Сүзне тәнкыйть нинди стиль (фәнни яки образлы) белән язылырга тиеш дигән бәхәсле проблемадан башлап карыйк. Хәтерегездәме, дискуссия барышында Ф. Зөлкарнәев Р. Мостафин өстенә: «Оригиналның асыл сыйфатын белмәгән, аның тәэсир көчен татымаган кеше кебек...» һ. б. шундый гаепләр ташлаган иде. Дөресен генә әйткәндә, Р. Мостафин бу сүзләрне ишетергә тиеш түгел иде. Моның шулай икәне Ә. Еникинең «Глядя на горы» китабына язган тирән мәгънәле, язучының иҗатын бөтен нечкәлекләре белән ачып салган кереш сүзендә дә раслана. Ф. Зөлкарнәев мәкаләсендә игътибарны җәлеп иткән артык фәнниләштерелгән бер урын булмаса, яшь тәнкыйтьченең бу сүзләрен искә дә алып тормас идек, ләкин моны искәрми үтеп булмый. Нәрсә яза соң ул? «Р. Мостафинның факт дигәне артефакт түгел микән, дим мин!» Брр! Тапкан бит сүзен дә, ә?! Специалист кына аңларлык. Ләкин Ф. Зөлкарнәевнең моңа исе дә китми. Сүзлекләр исән булсын, алар булганда нәрсә куркып торырга! Сүзлекне ачабыз, карыйбыз: «Артефакт — ялгыш аңлашылган күренеш, бер системага хас сыйфатларны икенчесенә күчерү». Яшь тәнкыйтьченең мәкаләсендә адым саен структуралистларга хас терминнар очрый: «эчке структур сыйфатлар...», «структураның аерым элементлары» һ. б. Кыскасы, Ф. Зөлкарнәевтә, А. Толстой әйтмешли, «художестволы рефлексларның фәнниләшүе» сизелә. Әмма бу әтәчләнү дә аңа ярдәм итми,— мәкаләнең публицистик кайнарлык, дәрт белән язылган өлеше барыбер кызыклырак килеп чыккан, әдәби талант барыбер үзенекен иткән.

Кызык кына парадокс килеп чыга! Бер яктан, шигырьләр дә иҗат иткән Ф. Зөлкарнәев фәннилеккә омтыла, икенче яктан, сәләтле галим Т. Галиуллин шушы бәхәстә әдәбилеккә тартыла, җиңел укыла торган стиль белән яза. һәм уңышка ирешә дә. Мин, әлбәттә, бирегә Т. Галиуллин яклы. Тәнкыйть бер үк вакытта фәнни дә, әдәбиләштерелгән дә булырга тиеш.

Әлбәттә, бу проблема һаман әле бәхәс кузгата, тәнкыйть һәм әдәбият белеменең әдәбиятның бер төре булуын шик астына куя торган дәлилләр дә китерелә. Әмма шуны әйтергә кирәк: язылу ысулы белән алар әдәбият булса, методы белән — фән! Шулай да бу дискуссия барышында күренгәләгән кайбер үземә ошамаган нәрсәләр турында әйтеп китмичә булдыра алмыйм.

«Каршылыклы чорыбыз чагылышы — каршылыклы күңелләргә без бай,— дип яза шул ук Ф. Зөлкарнәев,— ләкин андый шәхесләр шул каршылыклар арасында изаланудан котылып, шуларны үзләре өчен хәл итеп, шулардан өстен булып, үсеп китә алмыйлар... Күңел каршылыклары талантның көчен тарката, ваклый». Тарката микән? Монда әле уйлап карыйсы бар. Партиячел принципиальлек, эрудиция, дөньяга булган киң караш — чынбарлыкны гомумиләштерүче факторлар; шушы сыйфатлар булмаганда, материалны яхшы белә торып та китап язарга утырмаска кирәктер, күрәсең. Болар барысы да аңлашыла, тик бер нәрсә генә аңлашылмый — ничек инде су түгәм дип, тагарактагы баланы да төшереп җибәрергә мөмкин? Партиячел принципиальлек, эрудиция һ. б. язучының тормыш күренешләреннән туган икеләнүләренә, кызгану хисенә, андагы рефлектив башлангычка, кеше җаны өчен ахырына хәтле көрәшү теләгенә һич тә каршы килмиләр (М. Горькийның «Дело Артамоновых» романын язу

тарихын гына укып карагыз). Киресенчә, алар янәшә торып, үзара гармониядә, диалектик бердәмлектә яшиләр. Ф. Зөлкарнаевка менә шундый бердәмлек турында кайгыртырга кирәк иде. Ә ул: «...шулардан өстен булып...»,— ди. Болай итсәң, кешеләрне ярату урынына, алардан аерылып, модернизм сазлыгына кереп батуың да бар.

Бирелә безгә татар, рус һәм бөтенсоюз әдәбияты тәҗрибәсе ярдәм итә. Тукай иҗатының бөтен рухы кыерсытылганнарны кызгану, яклау, алар өчен газаплanудан гыйбарәт. Гамлет, Печорин, Раскольниковларны гына алыйк! Алар күңелендә төрле икеләнүләргә, мәңгелек мәсьәләләр белән газаплануларга урын булмаганмы әллә? Әмма аларның рефлексиясе дөньяны гуманистик идеяләр яктылыгында берүзең үзгәртеп корырга теләүдән килә. һәр яңа буын өчен алар бүтәнчә яңгыраячак, чөнки чын әдәбиятның әхлакый мөмкинлекләре, заманнар килгән саен, ачыла гына бара. Шекспир, Лермонтов, Достоевский, Толстой. Бу шәхесләр үз-үзенә сораулар бирүче җанның, аңның чиксез тирәнлекләренә үтеп кереп, шул ук вакытта гражданлык һәм әхлакый бурычлар югарылыгында кала алмаганнармы әллә?! Алар яхшы мәгънәдә тенденциоз булганнар, ягъни үз концепцияләрен, үз позицияләрен гениаль рәвештә чагылдыра белгәннәр. Чернышевскийның Толстой иҗатына карата әйтелгән «җан диалектикасы» дигән сүзе үз вакытында революцион-демократик тәнкыйтьтә зур яңалык булып яңгырады. Чернышевский әйтүенчә, Толстой иҗаты башка талантлардан — башыннан ахырынача күрсәтелгән психологик процесс, аның формалары, законнары, рухи тормышның, фикернең, хисләрнең үзгәреп торуы белән аерылып тора. «Күңел диалектикасы» — бу шул ук күңел каршылыгы түгелме соң? Ә Ф. Зөлкарнаев аны язучылар практикасыннан сызып ташларга чакыра. Критик реализм теориясенә нигез салучы Чернышевский рецензиясеннән түбәндәге юлларны китермичә булдыра алмыйм: «Үзен кеше буларак өйрәнмәгән кеше башкаларны беркайчан да тирәнтен белә алмаячак»,— ди ул.

Кызык кына килеп чыга бит әле: иҗаттагы икеләнүләрне, шәхеснең икегә бүленүен инкяр иткән Ф. Зөлкарнаев үз мәкаләсен нәкъ менә шул ысул белән, ике тавышның бәхәсе формасында язган. Бу ике тавыш, яшь тәнкыйтьченең әйтүенә карағанда, бәхәскә керә. Журналистика тарихында мәкаләнең эчтәлеге «теза», ә формасы «антитеза» булуы — сирәк очрый торган хәл. Яшь тәнкыйтьче бу ике «тавышның» ниләр кыландырганын читтән генә карап тормакчы булса да, алар ахырда кушыла башлый.

Татар язучыларының, русча тәрҗемә ителеп тә, бөтенсоюз күләмендә яңгыраш таба алмавының сәбәбе нәкъ менә тәрҗемәләрнең начар булуында диючеләр белән килешмичә булдыра алмыйм. Әмма бу фикерне дә ачыклап үтәсе килә. Шактый катлаулы мәсьәлә бу. Монда сәбәпләр күп. Бер яктан, татар язучысы бөтенсоюз укучысына барып ирешә, ә икенче яктан, җирле укучыдан канәгать булып яшәргә мәҗбүр.

Хәзер бездә әсәрләре бөтенсоюз укучысына барып ирешкән язучылар күплеген берәү дә инкяр итә алмый. Кайберләре хәтта Европа телләренә дә тәрҗемә ителде. Үрнәк өчен бер генә мисал. Укучылар Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»е, Гомәр Бәшировның «Намус» романнары СССР Дәүләт премиясе белән бүләкләнүен әле дә булса хәтерлиләрдер. Зур бүләккә лаек булу бу романнарның бөтен ил күләмендә абруен күтәрде, аларны тугандаш халыклар гына тәрҗемә итеп калмады, чит ил телләрендә дә басылып чыктылар. Күптән түгел миңа «Полымя» журналын җибәрделәр,— анда минем белорус-татар әдәбияты бәйләнешләрына караган мәкаләм басылган иде. Тышлыкның өченче битендә «Юность» нәшриятының белдерүенә күзем төште: Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте белорус теленә тәрҗемә ителгән. Димәк, белорус укучылары татар халкының тормышы, гореф-гадәтләре, борын-борыннан килгән югары әхлак традицияләре белән танышачак. Аксакалыбызны совет әдәбиятында шундый озын гомер яшәве белән котлыйсы гына кала!

Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев, Нурихан Фәттах, Атилла Расих, Әхсән Баянов, Вакыйф Нуруллин кебек танылган прозаикларыбызның әсәрләрендәге геройларны (алар күптән инде русчага тәрҗемә ителгәннәр) бөтенсоюз укучысы һәм Мәскәү тәнкыйтьчеләре игътибар белән рәк тә барлый алган булырлар иде. Әлбәттә, монда сәбәпләр күп, һәм аларга туктала башласаң, мәкалә бик озынга сузылыр иде.

Инде тәнкыйтьнең татар әдәбиятын пропагандалауда тоткан урынына әйләнеп кайтыйк. Соңгы елларда күпмедер җанлану сизелүгә карамастан, тәнкыйтебез һаман да әле бүгенге проза, поэзия, драматургиядән артта кала. Тәнкыйть йоклый, Тукай әйтмешли, аны уятырга кирәк. Үзәк һәм башка республика матбугатында чыгыш ясаган тәнкыйтьчеләрне бармак белән санап була.

Шул ук вакытта культураның дәрәҗәсен, бигрәк тә милли культураның дәрәҗәсен, үз халкы өчен зур булган әдипнең башка халыкларда да популяр булуы белән генә билгеләү гаять кыен. Милли әдәбиятларның үз юлы, тизләтелгән үсү ритмы бар. Бу ритмны аларга Бөек Октябрь бирде. Һәм алар үзләренә хас милли үзенчәлек белән алга баралар.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Ю. В. Андропов СССРның 60 еллыгына багышланган берләштерелгән утырышта ясаган докладында болай диген иде: «Эшнең бүгенге таләпләргә туры килә торган, культураларның бер-берен баетуын нәтиҗәләрәк итәргә, барлык кешеләргә халыкларыбызның һәркайсының культурасы бирердәй бөтен яхшы нәрсәгә киңрәк юл ачарга мөмкинлек тудыра торган формаларын һәм методларын тырышып эзләргә кирәк...»

Мәкаләнең ахырында әдәби мөнәсәбәтләребезнең стиленә тукталып, дискуссиядә катнашучыларның һәм аны укып баручыларның игътибарын бер мәсьәләгә юнәлтәсем килә.

Без еш кына: китапны яратыгыз — китап белем чыганагы, дибез! Шул ук вакытта бер-беребезне күп укуда, китапка таянып язуда гаеплибез, күп уку икенчел продукция генә тудыра, дибез. Әмма ияреп язу, эпигонство — ул культура дәрәҗәсе түбән булган кешегә генә хас нәрсә. Яхшы китап сәләтле язучыда һәрвакыт тирән уйланулар уята, хисләрен кузгатып җибәрә, ул аны үзенчә кабул итә, яхшы китап иҗатчы өчен зур этәргечкә әверелә.

Чын язучылар үзләренә остаз итеп һәрвакыт зуррак һәм тирәнрәк язучыларны сайлыйлар. Үсәр өчен. Ә үзләре бөтенләй икенче төрле язалар. «Бу кабинетта булды. Лев Николаевич өстәлгә килгән килеш мине күрмәгән дә шикелле эшләп утыра. Кырыйдарак торган кечкенә генә лампа аның өстәлен яктырта. Ул, кашларын җыерып, язуын белә... Утыра-утыра да, кәгазьдән башын күтәрми генә, нидер кычкырып куя: «Ах!» Димәк, нәрсәдер барып чыкмаган — төзәтә, юл арасына тагын нидер кыстыра, аннан дәвам итә».

Бөек рус язучысы турындагы әлеге күзәтүне «Л. Н. Толстой в последний год его жизни» исемле китап авторы Валентин Булгаков язып калдырган. Ул чакта аңа әле 22 яшь кенә булган. Билгеле китап булса да, минем кулга ул әле генә килеп керде. Шундыйрак берәр нәрсә укысам, мин үзебезнең әдәбиятта да шуңа охшаш әйберләр эзлим. Әлеге юлларны укыгач, хәтергә 1955 елның 3 январенда булган бер хәл килеп төште. Миңа да бер вакыт В. Булгаков ролендә булырга туры килде. Яшь, «өметле» тәнкыйтьче буларак, миңа ул чакта «Совет Татарстаны» газетасы Сервантесның «Дон Кихот»ына 350 ел тулу уңаеннан мәкалә язарга тәкъдим итте.

Билгеләнгән сроктан биш көн соңарып, кыяр-кыймас кына редакция бүлмәсенә килеп кердем. Мин күренгәч, Фатих Хөсни урыныннан ук торып басты. Ләкин сер бирми, мәзәк сүз белән каршылый.

— Мин инде көтә-көтә көтек булып беттем! Алып килдеңме язмаңны? — ди.

Шуннан минем материалны редакцияләргә керештек. Ул — өстәл артында, мин каршысында утырам. Чал керә башлаган куе чәчле башын игән дә материалны укый.

Ф. Хөснинең тынгы белмәс шаян характеры шунда ачылды да куйды. Мин аның йөз үзгәрешләрен, фикер хәрәкәтен, берәр фразаны ошатмаса, елмаеп куюын күзәтеп утырам; менә ул бер авыр җөмләгә тукталып, аңа яңа деталь, төсмер өсти, аннан: «Я, ничек булыр?» — дип хәйләкәр генә карап ала. Минем белән киңәшә, янәсе. Ә мин, урындыкка кадаклангандай, баш кагып утырам. Кайда инде ул бәхәсләшү! Ул чакта Ф. Хөсни танылган язучы иде инде, яше дә кырык алтынчы белән бара, мин аны картая башлаган язучыга санап йөри идем. Ничек ялгышуымны хәзер генә аңлыйм!

Күп милләтле илебез әдәбиятлары, бигрәк тә рус әдәбияты контекстында дөнья күләм багланышлар мәсьәләсе аерата киң урын ала. Киң катлам укучылар һәм тән-

кыйтьчеләр фикеренә караганда, хәзерге көндә алгы сафка чыгып баскан Ч. Айтматов, Ю. Бондарев, В. Астафьев, Н. Думбадзе, В. Белов, В. Распутин, Г. Матевосян һ. б. язучылар үз иҗатлары өчен бик күп нәрсәне Достоевский, Толстой, Чехов, Бунин, Горький кебек зур әдипләр тәҗрибәсеннән алганнар. Хәзерге чорда классиканың гүзәл үрнәкләрен саклау һәм үстерү рухи һәм социаль прогрессыбызның төп максатына әверелеп бара.

Соңгы сүз итеп, әдәбиятыбызда киң карашлы, җәмгыять интереслары өчен янып иҗат итүче язучыларның аз булуын әйтеп үтәсе килә. Кыскасы, бездә кайбер авторларның тормышка булган ныклы карашлары юк. Шуның аркасында сүлпән әсәрләр туа, «буяулар» төссезләнә, күргәнне генә кәгазьгә төшерү хөкем сөрә. Тормышның үзәгендә кайнаган, аның бөтен каршылыкларын күңеленә сыйдырган, шуларны уйлап борчылган геройлар җитми безгә. Андый геройларны зур шәхес булган язучы гына тудыра ала. Язучының җаны, күңеле бертуктаусыз эштә, хәрәкәттә, уйда булырга тиеш. Шул вакытта гына заманыбызның гүзәл, катлаулы кешеләре аның әсәрләренә керә алачак.

# ТОРМЫШ КУЙГАН СОРАУЛАР...

Зурдан кубу булса булыр, әмма ләкин сүземне Эрнест Хемингуэй белән Альберт Эйнштейннан башлыйм әле.

Язучы һәм физик. Беренче карашка, аларны янәшә куярга ярамый да шикелле. Ләкин, миңа калса, «Карт һәм диңгез» әсәре белән чагыштырмалык теориясе арасында шактый гына охшашлык та бар. Һәр икесе иң кыска формада бәян ителгән, һәр икесе Нобель премиясенә лаек булган. Һәм, ниһаять, һәр икесе бөтендөнья әдәбияты, фәне үсешенә ифрат зур йогынты ясаган.

Әдәбияттагы һәм фәндәге бу ике гигантка тукталуым тикмәгә генә түгел иде, әлбәттә. Аңлашыла булса кирәк, бирелә сүз аларга тиңләшү турында бармый. Бөекләрнең гомер юлы, иҗаты, аларның тормыш ваклыгыннан һәм, ахыр килеп, үлемнән өстен кала белүләре — һәркайсыбыз өчен зур сабак һәм гыйбрәт.

Бу җәһәттән, дискуссиядә еш ишетелә башлаган «бөтенсоюз, бөтендөнья әдәбияты югарылыгында язу» дигән тезис минем үземә беркадәр аңлашылып та җитми. Әйтергә кирәк, соңгы еллар әдәби тәнкыйтендә дә бу фикер белән күп очрашырга туры килә. Таләп куела, ләкин бәяләү критерийларына килгәндә, күп нәрсә билгесез, аңлаешсыз кала.

Журналның 3 сандагы мәкаләсеннән аңлашылганча, Рафаэль Мостафин башка телләргә тәрҗемә ителеп, киң катлау укучыларга барып ирешкән һәм популярлык казанган байтак кына повесть-романнарны зур таләпләр югарылыгында язылган әсәрләргә керту ягында тора. Ләкин һәр популяр әсәр халыкчан була алмаган шикелле, һәр халыкчан әсәр дә, популярлык казана алмаска мөмкин бит. Моның кайбер мисалларын татар әдәбиятыннан да китерергә була. Әллә кая ерак китәсе юк: Хәсән Туфан һәм Әмирхан Еники иҗатын гына алыйк. Күз алдыбызда ич: бүгенге көнгә тикле аларның һәр икесенең Союз күләмендә көчле яңгырый алганнары юк. Алай булгач, Туфан һәм Еники иҗаты, бүген бөтен илгә яхшы мәгълүм Расул Гамзатов һәм Мостай Кәрим, Юван Шесталов һәм Эдуардас Межелайтис, Кайсын Кулиев һәм Әнвәр Әлимҗанов иҗатларыннан кайтышмыни?! Һич юк, әлбәттә!

Һәр халыкта әдәбиятның йөзен билгеләүче әдипләр була. Югарыда исемнәре телгә алынган авар һәм башкорт, манси һәм литва, балкар һәм казах әдәбияты әһелләре дә нәкъ менә шундыйлар исәбенә керә. Әлеге халыклар әдәбиятының бүгенге торышы, үсеш дәрәҗәсе турында без алар иҗатына карап фикер йөртәбез. Димәк, тәрҗемә бездә дә кемнәрнеңдер хосусый шөгыле итеп түгел, ә дәүләткүләм әһәмиятле эш итеп каралырга тиеш.

Әлбәттә, бу өлкәдә татар әдәбиятының җитди генә уңышларына күз йому да

дэреслеккә хилафлык китерү булыр иде. Мәсәлән, соңгы елларда Мөхәммәт Мәһдиев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харисларның русча китаплары, Туфан Миңнуллинның драма әсәрләре киң катлау укучылар, тамашачылар һәм әдәби җәмәгатьчелек арасында зур кызыксыну уятты. Бу әдипләр иҗаты турында үзәк матбугатта да әледәнәле мәкаләләр күренеп тора. Күп очракта бәяләр көнкүредә шатлык катыш горурлык тойгысы уята.

Бүгенге татар әдәбияты, аерым алганда, проза турында сөйләгәндә, соңгы елларда телдә гаять актив кулланыла башлаган «производство һәм авыл темасына язылган әсәрләр»гә тукталмый һич мөмкин түгел. Мондый кискен бүленеш белән һич тә килешәсе килми.

Минемчә, тема, беренче чиратта, язучыга тирән социаль-психологик анализ ясау өчен форма булып хезмәт итә. Бары кәсепче кулында гына тема «зур кодрәткә» әверелергә мөмкин. Кызганычка каршы, «актуаль тема» артына яшеренү бүген дә үзен нык сиздерә әле.

Бүгенге татар прозасының иң уңышлы әсәрләре белән без, нигездә, «Казан утлары» журналы буенча танышып барабыз. Зур булмаган мәкаләдә аларның һәммәсе турында тәфсилләп сөйләү мөмкин булмаганлыктан, мин үземне аеруча нык дулкынландырган бер әсәргә, дөресрәге бер образга тукталу белән чикләнергә телим.

«Казан утлары» журналының 1982 елгы сигезенче санында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Исәнме, Кәшфи абый!» дигән яңа повесте басылып чыкты.

Иң әүвәле шунысын искәртү урынлы булыр: М. Мәһдиев элегрәк язган әсәрләрендә тышкы эффект тудыру белән аеруча нык мавыга иде. Әсәр дәвамында, укучыны бераз ял иттерим дигәндәй, кызыклы вакыйга-анекдотлар да сөйләп алгалый иде. Соңгы повестенда исә язучы болардан шактый арына төшкән.

Беренче карашка, әсәр механизатор Кәшфи гаиләсе мисалында авылның тарихи үсеш процессын, бүгенге хәлен тасвирлый шикелле. Авылның киләчәге мәсьәләсе дә әсәрдә бөтен кискенлеге белән куелган: «...Менә мин төннәр буе авыл урамындагы йортларны санап ятам: әһә, бу йорт бер-ике елдан бетә. Әһә, бу йортның гомере — күп булса ун ел. Чөнки малай чыгып китте дә шәһәргә урнашты, йортта пенсионер әти-әни генә калды. Монда өченче буын кителми. Бетәсе хуҗалык нинди? Өченче буын кителмәгән хуҗалык...»

Ләкин язучы шушы урында гына тукталып калса, көн кадагына сугып алудан әллә ни ерак китмәгән булыр иде. Ә чынлыкта повестьның фәлсәфәсе тирәндәрәк ята. Әсәрдә ул тирәнлек Тавис образы белән билгеләнә. Кәшфи абыйның улы — Тавис әсәргә очраклы килеп кермәгән. Аның реаль җирлеге, мәгънәсе бар. Карагыз, нинди парадокс: гомере буе илгә, Ватанга игелекле хезмәт иткән орденлы тракторчының улы җәмгыять өчен куркыныч тип булып формалашкан. Тавис — табигатька, кешеләргә һәм хәтта үз ата-анасына кизәнергә җөрьәт итә! Ул Вөҗдан һәм Хәтердән мәхрүм ителгән. Чыңгыз Айтматовның соңгы романын укыганда да без шушыңа охшаш тип белән очрашкан идек түгелме соң?! Ч. Айтматов әсәрендә ул риваять формасында тасвир ителсә, М. Мәһдиев повестенда исә Тавис безнең мохиттә, безнең арада яшәүче буларак гәүдәләнә. Әмма һәр икәвенең язмышлары бер: алар коточкыч авыруга — хәтерсезлек авыруына дучар ителгәннәр. Ләкин укучыда ирексездән сорау туа: ничек итеп?

Югыйсә, Тависнең башына Ч. Айтматов әсәрендәге риваятьтәгечә, дөя тиресеннән тегелгән башлык та киертелмәгән бит. Әти-әнисе дә — кешелекле кешеләр. Бертуган апасы да әйбәт юлда: югары уку йорты тәмамлаган, эшли.

Тависне тарихтан, бүгенге дөнья хәлләреннән бөтенләй хәбәрдар түгел дип тә әйтеп булмый. Ул бүгенге көндә «милитаристларга, бактериологистларга, путчистларга, экстремистларга каршы көрәш» баруын да факт буларак яхшы белә. Ләкин шунысы бар: ул юк-бар сүз сөйләүдән, лыгырдап йөрүдән ары китә алмый.

Ни өчен?

М. Мәһдиев повестенда бу сорауга ачык кына җавап юк.

Ә җавап, һичшиксез, табылырга тиеш. Бүгенге татар прозасының максатын тормыш куйган әнә шундый үткен сорауларга ышанычлы җаваплар эзләүдә күрәм мин...

**Газинур МОРАТОВ.**

# БҮГЕНГЕ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**Узган елның декабрь аенда Мәскәүдә РСФСР Язучылар союзы идарәсенең драматургия, театр тәнкыйте һәм әдәби тәрҗемә советларының берләштерелгән утырышында бүгенге татар драматургиясенең үсеш мәсьәләләре каралды. Анда С. В. Михалков, А. Г. Алексин, Г. А. Ахунов, Н. И. Мирошниченко, В. В. Фролов, П. М. Градов, Ю. П. Чепурин, Н. Ю. Голикова, Ю. А. Мочалов, В. В. Губин, И. Г. Лазутин иптәшләр катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Утырышта шулай ук Казаннан килгән театр белгечләре А. Г. Әхмәдуллин, И. И. Илялова, Р. М. Игъламов, драматурглар Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев, Диас Вәлиев һ. б. катнаштылар.**

**Түбәндә без укучыларны әлеге утырышта ясалган кайбер чыгышларның кыскартылып алынган стенограммалары белән таныштырабыз.**

**С. В. МИХАЛКОВ:**

— РСФСР Язучылар союзы идарәсенең иҗат советлары һәм Секретариат безнең милли әдәбиятларыбыз һәм аерым жанрларны үстерү турында даими кайгыртып тора. Бик күп санлы семинарлар, киңәшмәләр, утырышлар уздырыла. Мондый фикер алышулар, семинарларда әйтелгән фикерләр эзсез югалмый, алар аерым җыентыкларга туплана. Шулай итеп, безнең тәнкыйть семинарлары нәтиҗәсендә яңа, яшь әдәби көчләр үсешен чагылдыручы китаплар басылып чыга. Яшь әдәбиятлар үсеше турында кайгыртуның ачык мисалы инде бу.

Россия әдәбиятын без беркайчан да зур яисә кечкенә әдәбият дип бүлеп йөртмәдек. Кайда тууына карамастан, безнең олы Россия әдәбиятыбыз бар. Безнең барлык тугандаш халыкларыбыз ничек бертигез булса, әдәбиятларыбыз да шулай. Бу безнең социалистик чынбарлыгыбыздан, СССРны тәшкил иткән бердәм, нык республикалар Союзы чынбарлыгыннан туа һәм ул очраклы хәл түгел, ә социалистик җәмгыятебезнең закончалыгы. Бу хакыйкатьне без бүген олы, күп милләтле, куәтле совет дәүләте СССР төзелүгә 60 ел тулу алдыннан бигрәк тә яхшы тоябыз.

Безнең берләштерелгән утырышыбызда игътибар үзәгенә татар драматургиясенең бүгенге үсеш мәсьәләләре куела. Әлеге мөһим мәсьәләне утырышка куюның сәбәбе нәрсәдә? Әлбәттә, гадәттән тыш хәл килеп чыгуда түгел, киресенчә, аның көчле булуында. Әмма без кемгәдер мәдхия җырларга дип тә җыелмадык. Принципиаль тәнкыйть, иптәшлек позициясеннән чыгып, һәркем тиешле бәясен алыр. Ә шулай да без татар драматургларын тәнкыйть камчысы белән тәрбияләргә җыенмыйбыз. Биредә иҗади, эшлекле әңгәмәгә профессионаллар җыелганнар, шуңа күрә сөйләшү дә партиялелек һәм профессиональлек югарылыгында алып барылачак.

Татар әдәбияты, татар драматургиясенең бик тирәнгә, революциягә кадәрге чорга барып тоташкан бай тарихы бар. Туган илебезнең, союздаш һәм автономияле республикаларның гүзәл бердәмлеген чагылдырып, күренекле Татарстан республикасы халкы тормышына һаман саен тирәнгәрәк үтеп кереп, татар әдәбияты бертуктаусыз алга атлый.

Татар драматургиясе соңгы ун ел эчендә аеруча зур үсешкә иреште. Бу безне бик шатландыра. Әлеге алга омтылышны чагыштырмача яшь драматурглар әйдәп бару безне куандыра. Алар өлкән буын тәҗрибәсен оста файдаланып, татар драматургиясендә бер адым алга киттеләр. Болай дигәндә мин Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Д. Вәлиев һәм башкаларны күз алдында тотам. Алар чагыштырмача кыска

вакыт эчендә республиканың күренекле драматурглары булып җитештеләр һәм бөтенсоюз аренасына чыктылар. Бу инде республика, милли драматургия җиңүе генә түгел, ә безнең бөтен совет театрыбызның зур казанышы.

Бүгенге татар драматургларының башка тугандаш әдәбиятлар белән уртак, аваздаш проблемалары бар. Шуның өстенә бары тик үзләренә генә хас, җирле характердагы, дәресрәге «интим» проблемалары да бар.

Мәсәлән, татар сәхнәсенең бүгенге көн уңай герое проблемасы. Татар драматургиясендә коммунизм төзүче кешенең иң яхшы сыйфатларын чагылдыручы күзгә бәрелеп торган уңай герой, заман герое бармы?

Партия Үзәк Комитетының 1982 елгы ноябрь Пленумы яктылыгында коммунистик җәмгыять төзүче совет кешеләренә аяк чалучы кимчелекләрне партиячел, принципиаль анализлау зур әһәмияткә ия.

Болай дигәндә мин, әлбәттә, партиячел сатира жанрын күз алдында тотам. Татарлар шаяртып, уен-көлке белән яза беләләр һәм шаяртып кына да җитди әйберләр әйтә беләләр.

Әлбәттә, бөтен совет әдәбиятының төп бурычы — яңа җәмгыять төзүче замандашыбызның күркәмлеген һәм уңышларын талантлы һәм образлы итеп чагылдыру.

Ләкин патриотизм һәм туган халкыңа мәхәббәт хисе җәмгыять каршында үз бурычын яхшы аңлаучы, илдә бара торган эшләр белән тирән бәйләнешле булган чын художниктан үз әсәрләрендә, партия позициясендә торып, тормышның яңа җәмгыять төзүгә аяк чалучы кимчелекләрен күрсәтүне дә таләп итә.

Кыскасы, проблемалар бар һәм алар хәл итүне көтәләр. Ә аларны КПСС Үзәк Комитетының 1982 елгы ноябрь Пленумы карарларын искә алып хәл итәргә кирәк.

Без барыбыз да шул Пленумда иптәш Ю. В. Андропов сөйләгән эшлекле һәм бик принципиаль речь тәэсирендә йөрибез. Анда безнең үсеш юлларыбыз, перспективаларыбыз күрсәтелгән, проблемаларыбызга басым ясалган. Без, художниклар, аларга нык игътибар итәргә тиешбез.

Безнең берләштерелгән утырышыбыз югары таләпчәнлек рухында, дусларча ягымлылык, бер-береңә теләктәшлек атмосферасында, партиялелек рухында үтәр дип ышанам. һәм бу татар драматургиясе өчен генә түгел, әйткәнемчә, башка милли драматургияләр үсеше өчен дә файдалы булыр. Чөнки уртак проблемалар байтак.

**В. В. ФРОЛОВ:**

— Мин бик шатланып татар драматургларының 15 пьесасын укып чыктым. Алар миңа бик кызыклы, күренекле иҗади шәхесләр ачып салдылар. Мин Татарстан сәнгатен күптәннән күзәтеп барам. Тәнкыйтьчеләрнең иҗади лабораториясенә сигез еллап җитәкчелек итәм. Казаннан килгән бүгенге кунаклар арасында минем шәкертләрем дә бар.

Татарстанның Россия белән элемтәсе тирән һәм иҗади. Ул уртак элемтә Россия татар интеллигенциясенә бертуктаусыз ярдәм итеп килгән, ә татар интеллигенциясе рус интеллигенциясенә үзенең культурасы, милли традицияләре, татар теленең матурлыгы белән йогынты ясаган.

СССРның 60 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә тугандаш культураларның үзара бәйләнеш мәсьәләсе аеруча актуальләшә. Татарстан культурасы Россиянең үзәгендәге зур республиканың рус культурасына, Идел-Урал буе республикалары культураларына тирән тамырлар белән берегүнең ачык мисалы. Татар культурасы, татар театрының йогынтысы бик күп республикаларга тарала.

Минем иң башта татар драматургиясенең төп проблемасына — жанрлар төрлелеге, бүгенге драматургиянең практикасында жанрлар кушылмасы, аларның үзара бәйләнеше мәсьәләсенә тукталасым килә. Җитлеккән социализм эпохасында театр сәнгате тирән эчтәлеккә ия булды. Ул актив, милли генә түгел, күпмилләтле, колоритлы, үзенчәлекле. Ул һәр милләтнең традицияләренә бәйле. Совет сәнгате бигрәк тә җитлеккән социализм эпохасында эчтәлеге белән социалистик, милли формалары белән күп төрле, рухы һәм характеры белән интернациональ сәнгать ул. Аның рухы белән интернациональ булуы бигрәк тә әһәмиятле. Бу җитлеккән социализм эпохасы сыйфаты гына түгел, ә сәнгатьчә гомумиләштерү югарылыгы, бөтен кеше-

лек дөньясы өчен уртак коммунистик әхлакны аңлауга күтәрелү. Әхлак проблемасы бөтен кешелек өчен уртак, интернациональ мәгънәсендә татар драматургиясендә төп урында тора.

Яңа әхлак — бөтен кешелек дөньясына уртак нәрсәләр — образлылыктан, миллилектән һәм конкрет сюжетлардан, жанрдан үсеп чыгуны раслаучы совет әдәбияты, драматургиясе, шул исәптән, татар драматургиясе практикасында соңгы елларда үсеш алган, формалашкан яңа сыйфат ул. Болар барысы да дөньяга марксистик-ленинчыл караш нигезендә формалаша. Яңа шартларда социалистик, коммунистик әхлак әнә шулай үсеп чыга.

Татар драматурглары пьесаларының уңышын мин конкрет материалдан, бүгенге милли колориттан бөтен кешелек дөньясына уртак мәсьәләләргә булган карашлар системасының барлыкка килүендә күрәм.

Татарстан язучыларының пьесаларында совет драма жанрында формалашкан барлык мәсьәләләр дә чагылыш табамы? Бүгенге эшлекле кеше проблемасы, производство темасы, минемчә, бераз күләгәдә калып бара кебек. Һәрхәлдә, мин укыган пьесалар арасында андыйлар туры килмәде. Әмма мин моны гаеп итеп әйтмим, чөнки татар язучыларының драма-комедияләрендә, хәтта трагедияләрендә дә фәлсәфи нигез бар. Бөтен кешелек дөньясы өчен уртак, безнең социалистик җәмгыятебезгә хас тирән сыйфатлар бар. Ләкин, бәлки, сезнең И. Дворецкий, А. Гельман, Н. Мирошниченко әсәрләре кебек пьесаларыгыз әлегә юктыр. Булса да азрактыр. Ә шулай да сезнең лирик драмаларыгыз, драма-притчаларыгыз, драма-легендаларыгыз — алар барысы да драма жанрын, әдәбиятны бизи һәм алар югары профессиональлек, тормышны бик яхшы өйрәнү, аны сәнгатьчә югары гәүдәләндерә белү билгесе булып тора.

Мин чыгышымның конкрет өлешен комедия жанрыннан башлыйм.

Укылган комедияләр җылы лирик юмор, күзгә артык бәрелеп тормый торган тыныч юмор белән сугарылган. Катгыйлык юк. Тискәре герой оятсызлыгына басым ясап әйтү өчен кирәк булган очракларда әсәргә кертелсә, ул диссонанс булып яңгырый. Кискенлек сезнең комедияләрегезгә хас түгел. Сезнең комедия төзелеше милли мотивлардан һәм характерлардан, кешегә милли караштан чыгып эшләнә. Тискәре герой төзәлер, безгә үзенең уңай ягы белән борылыр дигән өметкә нигезләнә.

Мондый мактау сүзләрен мин Р. Хәмиднең «Иске йорт кешеләре» исемле комедиясе турында да әйтеп узар идем. Бу әсәрдә кеше квартираларын бинокльдән карап, үзенә кызык табучы Әнисә түти сурәтләнә. Аның эчке дөньясы да бик сәер. Ул үз йортын тарихи архитектура әсәре дигән уйдырма белән яши. Чынлыкта исә ул йорт кайчандыр аның әтисенең трактиры булган, ә ире, каяндыр табып, аңа колонналар куйдырган икән.

Әсәрдә Әнисә түти мещанка итеп сурәтләнә. Ул бик җиңел, лирик күтәренкелек белән, нәфрәтсез генә көлкегә алына. Шунысы миңа бик ошады. Әсәрдә яңа геройлар Ренал, Резеда, ялгыз ана беренче планга чыгарылган. Финалда сәхнәгә беренче ранглы капитан керү дә күңелгә хуш килә. Башта, катнашучылар исемлеге белән танышканда, миндә: «Капитан монда нәрсәгә кирәк, ул нинди роль уйнар икән».— дигән уй туган иде. Ахырда аның Әнисә түти янына үзенең дә бинокле барын, ул да бинокле белән күршеләрен күзәткәнен әйтергә кергән булып чыкты. Бу Р. Хәмиднең югары зәвыгы, көчле тәэсирле әйберләр таба белүе турында сөйли торган бик оста зирәклеге.

Мин тагын талантлы комедиограф Ю. Сафиуллинның ике әсәре белән таныштым. Берсе «Әллә өйләнергә инде» дип исемләнгән. Бу комедиянең төп герое аш пешерүче булуы сөендерә. Пешекчеләргә, гадәттә, караш шаплардан түгел. Еш кына алар турында сатирик әйберләр языла һәм бу профессия кешеләре надан, карак дип тасвирлана. Ә менә Ю. Сафиуллин комедиясендә аш пешерүче — игелекле, яхшы кеше. Шуның өстенә милли ашлар турында китап та яза, һәм ул китап бездә генә түгел, чит илдә дә басылып чыга. Ул мөлкәтле кеше, әмма саран түгел. Кунакханәдә эшләүче дусты өчен ул үз акчасына йорт төзи, катер сатып ала. Аның акчага карашы башкалар карашыннан нык аерылып тора. Аны берәүгә өйләндерергә телиләр, тик ул башка кешене ярата.

Әсәр матур шигърият, юмор белән сугарылган. Мин үзем комедия турында сүз алып барганда «уңай герой» дигән нәрсәне яратмыйм. Яхшы кеше, шәхес, кешеләргә изгелек эшләүче кеше дисәк, дөресрәк булыр.

Әлеге повар дөньяны аңлый, кешеләргә яхшылык эшли һәм бу турыда сөйләшеп йөрми, моны геройлык дип санамый. Кешеләрнең бу тибы милли тормыштан, көнкүреш үзәгеннән алынган. Бу миңа бик тә ошады.

«Менә без очраштык та» дигән икенче комедиянең миңа төзелеше, структура алымы ошады. Пьесада төрле тавышлар бар: дорфа тавышлы кеше, арган тавышлы кеше h. б. Кызык алым бу.

Минем тагын Т. Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» һәм «Әлдермештән Әлмәндәр» (Ю. Мочалов тәрҗемәләре) дигән талантлы әсәрләренә тукталасым килә. «Дуслар җыелган җирдә»— бик әйбәт комедия. Мин бу әсәрнең рус сәхнәсендә дә баруын теләр идем.

Нурислам исемле художник, мастерскоен, әсәрләрен күрсәтер өчен, дусларын кунакка чакыра. Аларга ул мәгънәле бер тост тәкъдим итә. Дусларын, иптәшләрен яхшы белгәнгә күрә, ул ике бөкре кеше турында тирән мәгънәле һәм гыйбрәтле хикәят сөйли. Бер бөкре урман аланында бертуктаусыз «Чәршәмбе, чәршәмбе» дип кычкырып, биеп йөрүче парилар төркемен күреп ала. Ул көнне җомга булса да, бу бөкре дә, париләргә кушылып, «Чәршәмбе» дип кычкыра башлый. Парилар башлыгы моңардан: «Бүген җомга икәнен белә торып, син нишләп «чәршәмбе» дип кычкырасың әле?»— дип сорый. «Сез «чәршәмбе» дип кычкырасыз ич, минем дә шуңа күрә «чәршәмбе» дип кычкырасым килә»,— ди бөкре. Парилар башлыгы аның бөкресен юкка чыгара.

Моны күреп шаккаткан икенче бөкренең дә үз җитешсезлегеннән котыласы килә. Беренче бөкре аңа урман аланына барырга һәм хикмәтнең нәрсәдә икәнен төшенергә кирәклеген аңлата. Икенче бөкре, аландагы париләрнең «чәршәмбе» дип кычкырып йөргәнен күргәч: «Сез нишләп чәршәмбе дисез, бүген җомга ич»,— ди. Дөрестән дә җомга булганга, ул үзе бертуктаусыз «җомга» дип кабатлый. Парилар башлыгы белән дә дөреслекне яклап бәхәскә керә. Дөресен әйткәнне яратмаучы парилар башлыгы ачуыннан моңа тагын бер бөкре өстәп куя.

Минем бик күп комедияләр укыганым бар, әмма мондый көчле логикалы комедияләр бик сирәк очрый. Гади комедия түгел, ә логик көч, логик төзелешле комедия бу. Биредә комедия логик төзелештән туа.

Нурисламның бу тостыннан соң дуслары тирән уйга кала. Алар үзләре теге парилар кебек «чәршәмбе» дип кычкырып йөрмиләр микән соң? Таралгач та бу уй аларны борчып тора һәм алар кайбер эшләре өчен үкенә башлыйлар. Шулай итеп, бу комедия бик тапкыр, зирәк психологик комедия.

«Әлдермештән Әлмәндәр»— комедия-притча. Биредә авторның фантазиясе Гоголь, Булгаков дәрәҗәсенә күтәрелгән. Ходай тәгалә Газраил пәйгамбәргә туксан яшьлек Әлмәндәр картның җанын алырга боера. Күп яшәгән, җитәр, янәсе. Үлем бу алтын куллы карт янына килә, ләкин гадәттәгечә үзеннән куркып калу белән очрашмый, киресенчә, халыкчан тапкырлык, хәйләкәрлек, тормыш сөю һәм егетлеккә тап була. Биредә автор кешенең үлемне җиңеп чыгуын сурәтли. Дөрес, бу дүртенче килүендә үлем Әлмәндәрне алып китә, тик карт җиңелми, тирән оптимизмын югалтмый. Бу әсәрне мин Гетеның «Фауст»ы, Р. Ролланның «Кола Брюньон»ы, Шарль де Костерның «Уленшпигель турында легенда»сы, Гогольнең «Тарас Бульба»сы кебек дөньякүләм үрнәк әсәрләргә якынайган сокландыргыч әсәр дип карыйм. Ул — әдәбиятның иң яхшы традицияләре дәвамы. Әгәр дә автор киләчәктә дә ашыкмый эшләсә, мин аңа зур өметләр баглыйм.

Б. Турай-Р. Батулланың «Кичер мине, әнкәй!» исемле комедиясе турында да минем уңай фикер әйтәсем килә. Бу әсәр олы, әхлак мәсьәләләре, гаилә, көнкүреш, якыннарыңа игелекле мөнәсәбәт мәсьәләләре күтәрүе, мелодрамага барып тоташуы белән дә кызыклы.

Бераз гына кыскартканда, бу пьеса тагын да әйбәтрәк булыр иде. Ул мелодрамага тарткан урыннары белән озынрак булып күренә. Мелодрама биредә сыер савучы Зифа исемле колхозчы хатынның сеңелесе Дилә ташлап киткән малайны тәрбияләүдә, ничә еллардан соң малайның үз әнисе кайтып, малайны алып китәргә мата-

шуында. А. Блокның «Незнакомка», «Балаган» дигән пьесалары искә төшә. Аларда да мелодрама бар, һәм ул трагедия, комедия белән кушылган. Мелодрама рус, татар әдәбиятында милли традицияләргә якын торган, бик милли һәм әйбәт жанр. Турай әсәрендә мелодрама өстенрәк чыга, ә комедия күмелебрәк кала. Автор үзе әсәрен моңсу комедия дип атаган.

Бүгенге татар драматургиясенең бик яхшы драмалары бар. Мәсәлән, Р. Хәмиднең «Кайтыр идем...» дигән драмасы. Ул төп драматургик алымга нигезләнгән бик яхшы, чын лирик драма. Әсәрдәге мин әйткән алым — Зирәк Замановның балачагы темасына мөрәҗәгать итүе. Герой безне елга буена алып килә һәм үзенең яшүсмер чагы, шул вакыттагы вакыйгалар белән таныштыра. Заманов — бүгенге көн герое, бригадир, агроном. Ул хатыны Зилә аркасында газаплы язмышка, күңелсезлекләргә дучар була. Зирәк Зиләгә гашыйк булып, аңа өйләнә. Һәм менә бала туа. Ләкин аның Зирәкнеке түгел, башка берәү — Азатныкы булуы ачыклана. Соңыннан Азат килеп чыга һәм баласын таләп итә башлый.

Кайвакыт драма яисә комедия укыйсың, аларда кешеләр михнәт чигәләр, ә синең күңелдә аларның хәленә керергә теләү хисе тумый. Р. Хәмиднең бу әсәрен укыганда исә герой башыннан узганнарны без ничектер үзебезнеке кебек, күңелебез белән кабул итәбез, йөрәгебез аша уздырабыз. Автор драматик вакыйгалар аша характерлар, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен чагылдырып әхлакый мәсьәләләрне тирәннән яктыртa белә.

Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасы башкачарак планда язылган. Мин аны мелодрама дияр идем. Пьесаның темасы — анага, иң кадерле кешегә рәхимсезлек, миһербансызлык темасы. Тирән, дөньякүләм тема. Әсәрдә бер гаилә тасвирлана. Ана дүрт-биш малай табып үстерә. Аларның берсе сугышта һәлак була, икенчесе сугыштан Ватан бүләкләре алып, инвалид булып кайта. Калган ике малайның берсе әле яшь егет, игелекле, мәрхәмәтле кеше, ә менә икенчесе — Ислам — тупас, әшәке бәндә, акча колы. Исламның туганнары фронтта кан койганда, ул дезертир була, төрмәдә утыра. Аннан чыккач, төньякта унбиш ел рудникта эшләп акча туплый. Аннары Казанга кайтып йорт сала, өйләнә, бала үстерә.

Ананың бу дөньяда санаулы көннәре генә калып бара — ул начар авырудан интегә. Аңа тәрбия кирәк, ләкин төрле сәбәпләр аркасында аны үз янына алырга кеше табылмый. Исламның мөмкинлеге бар, ләкин аның авыру ана белән җәфаланасы килми. Хатыны да аңардан җирәнә, авыруы кызына йогар дип курка. Ә шулай да ананы карарга берәү риза була — аны кече улы Сәярнең квартира хуҗасы үзләренә ала. Римма белән Сәяр әле бик яшьләр, тормышларын башлап кына җибәргәннәр, аларның берниләре дә юк, аның каравы хуҗа хатынның күңеле киң, шәфкатьле, мәрхәмәтле кеше.

Ислам кебек кабәхәт кеше тормышта каян килеп чыга соң? Менә дигән ана тәрбияләгән яхшы гаиләдән шундый каты күңелле, әшәке кеше килеп чыксын өчен аның тормышында нинди тетрәндергеч хәл булырга тиеш түгелме? Автор моны күрсәтми, шуңа күрә әсәр язылып бетмәгән кебек тоела. Мондый характер өчен мелодрама чит нәрсә бит. Шуңа күрә явызлык һәм әхлаксызлыкны тасвирлауда еш очрый торган чамасызлык, арттырып җибәрү түгел микән бу?

Безнең социалистик заманыбызда, бөек гуманизм заманында Ислам кебек хәшәрәттә дә нинди кешелек сыйфатлары булырга тиеш. Ул безнең чынбарлыкта үскән кеше ич. Акча артыннан куып, тормышын бозып бетергән булса да, аның да нинди уңай яклары булырга тиеш. Һәм бу әшәкелекнең чыганаклары турында да уйларга кирәк.

Драмада Ана образы һәм аның төпчек улы Сәяр образы бик матур бирелгән.

Татар драматургиясендә поэзиягә, лирикага, эпоска якын драма хакимлек итүенә мин бик шатландым.

Минем хәзер шактый сирәк очрый торган трагик формаларда язылган бик кызыклы легенда турында әйтәсем килә. Сүз И. Юзеевның «Онытылмас бәет» исемле әсәре турында бара. Пьесаның хәзерге заман мифына корылуын мин беренче мәртәбә очратам. Гадәттә мифлар һәм легендалар борынгы заманнардан алыналар. Ә бу очракта Бөек Ватан сугышыннан соң туган легенда алынган.

Табигатьнең бик матур бер почмагында кеше язмышы драмага дучар була. Ике

фронтташ, Шаһинур һәм Вәдүт сугыштан кайткач, Хәтимә исемле кызга гашыйк булалар. Мәхәббәт көрәшендә Вәдүт җиңеп чыга, Хәтимәгә өйләнә. Көннәрдән бер көнне Вәдүткә йөз мең сум дәүләт акчасын районга илтергә кушыла. Хатынының тирәюньдә бандитлар күренгәли икән, йөрмә, диюенә карамастан, Вәдүт юлга төнлә чыгып китә һәм юкка чыга. Имеш-мимеш хәбәрләр, легендалар йөри башлый. Берәүләр аны үтереп, акчасын алганнар, дип сөйли, икенчеләр Шаһинурдан шикләнә. Саф намуслы егет күңеленә бу авыр таш булып ята. Тиздән, дөньяга кыз бала китереп, Хәтимә вафат була. Шулай итеп, Шаһинур кеше баласын үстерә.

...Вакыт уза. Көннәрдән бер көнне авылга 70 яшьлек Вәдүт кайтып төшә. Ул кызын эзләп таба һәм илле мең сум акча бирергә теләвен әйтә. Кызы аны танымый, акчасын алмый. Кызы гына түгел, ничек кенә иналмәсен, аны хәтта элекке дусты да танымый. «Бу кешене белмим мин»,— ди ул.

Пьесада шундый бер урын бар.

— Мин сезгә яңа белән илле мең акча бирергә телим. Тормыш тәҗрибәсе туплаган, тормышның кайбер серләрен аңлаган кеше буларак, минем сезгә файдалы киңәш бирәсем килә,— ди Вәдүт.— Тормыш — ул язгы ташкын. Яши белмисең икән, батасың. Әгәр башкаларны батырырга, түбәнсетергә, хәтерен калдырырга курыксаң, син үзең өлешсез каласың.

Тартып ал, урла. Менә Вәдүтнең әхлакый позициясе. Рәхимсез позиция. Горькийның «Тормыш төбендәге» Карты кебек коточкыч кеше ул Вәдүт.

Бу формада кумәклек, бердәмлек принцибы хөкем сөргән бүгенге авыл, аның хезмәтчән кешеләре фонында ялгызлык трагедиясе кичерүче кеше сурәтләнә. Мораль караклык юлына баскан олы яшьтәге, кайчандыр фронтовик булган кеше ялгызлыкка, бәхетсезлеккә дучар. Аңа син карак, жулик, диюче юк. Кешеләр аңардан баш кына тарталар, кешелексез эш эшләгән кешене беркем дә таныырга теләми.

И. Юзеев пьесасында, шулай итеп, комсызлык психологиясен җиңеп чыккан яңа социалистик әхлак, саф намус философиясе чагыла. Легенданың мәгънәсе әнә шундый тирән.

Белинский трагедияне драматик шигърияттнең таҗы дип атый. Трагедия — читен жанр. Шуңа күрә бу жанрга якын торган һәр пьеса безне шатландыра.

Трагедия — олы конфликт, герой җиңеп чыга алмаслык конфликт, геройның «трагик гаебе». Бу классик жанрның төп сыйфатлары әнә шундый.

Д. Вәлиев ике пьесасын «1887 ел» һәм «Икс көне» дип исемләп, аларның жанрларын трагедия хроникасы белән билгеләгән. Беренче пьеса, минемчә, драма-хроника. В. Ульянов һәм аның студент иптәшләре Казан университетында сходка оештыруга багышлап язылган талантлы пьеса ул. Әсәрдә капма-каршы көчләрнең бәрелеше бар. Студент Никонов, жандарм вәсвәсәсенә бирелеп, рухи бәлага очрый һәм, хыянәтче булып калмас өчен, трагик гаебеннән үлеме бәрабәренә акланмакчы була. Никоновның сөйгән кызы Звонарская да, берниндн гаебе булмауга карамастан, егете артыннан үлемгә бара. Широков язмышы да нәкъ шундый трагик бизәкләр белән гәүдәләндерелгән. Әсәрдә студентлар, Широковны хыянәтче дип уйлап, аны үлемгә хөкем итәләр. Ә соңыннан хыянәтченең ул түгел, ә башка кеше — Бронский икәне беленә. Әсәрдә мондый трагик халәт бар: бер якта — революцион яшьләр, Ульяновлар лагере, икенче якта — көчле жандарм Гангардлар дөньясы. Дошманнар лагере автор тарафыннан фальшьсыз язылган, монда карикатура кебек нәрсә аз гына да юк. Әмма бу ике лагерь яшәешендә тоташ бер бөтенлек юк. Бер яктан — революцион яшьләр, икенче яктан — акыллы булса да, жандарм. Алар арасында нинди бердәмлек булсын инде?

Д. Вәлиевнең «Икс көне» драмасы миндә тетрәндергеч тәэсир калдырды. Ул — М. Җәлилнең көрәше һәм үлеменә багышланган трагедия хроникасы. Бу әсәр, һичшиксез, авторның зур уңышы.

Мин М. Җәлилгә багышланган тагын бер пьеса — И. Юзеевның «Соңгы төн» әсәрен укыдым. Бу бик яхшы пьеса, һәм минем авторны зур уңышы белән котлыйсым килә. Әсәрнең уңышы нәрсәдә? Минемчә, аның нәфис сәнгать законнары, символлар һәм метафоралар законы буенча язылган булуында. Пьеса персонажы Мефистофель шагыйрьнең җанын сатып алырга тели, ә моның өчен аңа тормыш, шатлык бүләк

итәргә җыена. Д. Вәлиев реалистик сюжет линиясе белән барса, И. Юзеев аңа тагын да читенрәк, шартлылык юлы белән килә. Шагыйрьне без М. Җәлил, Гете дип уйлыйбыз. Биредә тагын да илһамлырак, Шекспирча, чын сәнгатьчә максат куелган.

Пьеса турында бик күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Ул шагыйрьнең мәңгелек, мәхәббәт рухы, аның иреге турында. Шагыйрь җаны сатылмый.

**Әзерләнә дөнья һәлакәте...**
**Җир тынмаган әле, Җир яна...**
**Саклагыз сез, кешеләр, Җир-Ананы,**
**Син үзең дә саклан, Җир-ана!**

Шагыйрьнең соңгы рефрены бу. Шагыйрь үлемгә бара, әмма сөйгән анасына, Ватанына турылыклы булып кала. Мефистофель аның турында: «Ул җанын сатмады»,— ди.

Алдарак мин, татар драматургиясендә лирик драмадан тарихи трагедиягә кадәр төрле жанрлар булуы шатландыра, дигән идем. И. Юзеев пьесасы — трагедия жанрында яңа баскыч ул, минемчә. Д. Вәлиевнең трагик хроникаларыннан соң бу әсәр иң югары дәрәҗәдәге әсәр.

Төрле-төрле жанрларга бай татар драматургиясенең иң яхшы әсәрләре кешеләргә яңа дөнья ача, рухи матурлыкка өнди, табигатьнең һәм кешелек җәмгыятенең гүзәллеген аңларга, тормышның социалистик, интернациональ рухын төшенергә чакыра.

**Ю. П. ЧЕПУРИН:**

— ...Мин татар драматургларының ике әсәрен — Р. Хәмиднең «Синең урыныңа кайттым» һәм «Китәм инде...» пьесаларын укыдым. Бу әсәрләрнең мине шатландырган ягы — авторның бүгенге көннең иң зур, иң җитди проблемалары хакында үз сүзен әйтергә теләге булуда.

«Синең урыныңа кайттым» драмасында авторның төп фикере бик көчле, сәнгатьчә гәүдәләндерелгән. Биредә драматик әдәбиятның иң яңа, заманча формасы табылган, геройлар бик ачык, күзгә бәреләп торган итеп бирелгән, характерлары җентекләп, уйланылып язылган. Метафоралылык гомуми атмосфера, шигъри фон корырга ярдәм итә.

Р. Хәмид бу пьесасында бик әһәмиятле мәсьәлә — кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны турында уйлана. Кеше үз-үзенә бәя бирә беләме? Ул бәя сиңа тирә-юньдәгеләр биргән бәя белән туры киләме? Сүз әнә шул турыда бара. Автор үзенең персонажларын бик кыю бәрелештерә, аларның характерларын чәкештерә. Әти-бабайлар, ата-аналар, балаларның, ягъни туганнарның гаилә мөнәсәбәтләре аша олы социаль проблемалар күтәрә һәм бик төгәл, нечкә һәм сәнгатьчә чагылдыра белүен мин Р. Хәмиднең уңышы дип атар идем.

Бу хәл драмада катнашучы персонажлар составын артык киңәйтмәскә мөмкинлек бирә. Һәм авторга әйтәсе фикерен әйтү өчен шактый зур урын калдыра.

Пьеса ни өчен актуаль һәм бик әһәмиятле? Ул бүгенге, хәтта иртәгәге көн җитәкчесенең нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеген бәян итеп, аның кешеләр белән, халык белән аралашу юлларын, кайсы юл халыкка якынрак булуын һәм эштә яхшы нәтиҗәләргә алып баруын тикшерә.

Биредә кайбер геройларның характерындагы рәхимсезлекне чагылдырганда саграк булу кирәклеге турында әйтелде инде. Р. Хәмиднең бу пьесасында да бераз чамадан чыгу сизелә. Төп герой Наил характерында кансызлык сыйфатлары кимрәк булса, образ эрерәк һәм отышлырак булыр иде, минемчә. Буяуларны куертыбрак җибәрү Р. Хәмиднең «Китәм инде...» дигән пьесасының кайбер геройларына да хас. Шуның аркасында образлар беркатлырак һәм схематиграк килеп чыга.

Җитәкчеләр үзләре һәм аларның эш стиле нинди булырга тиеш? Алар ничек яшәргә, уйларга, үзләренең тормыш һәм көрәш тәҗрибәсеннән эштә ничек файдалана белергә тиеш? Авторның уңышы турында әйткәндә, мин иң элек сәхнәдә зур яңгыраш тапкан менә шушы проблемаларны бер гаилә члennарының үзара мөнәсәбәте аша күрсәтә белүен күз алдында тотам.

Пьесаны укыганда аның милли драматург тарафыннан язылганын тел үзенчәлекләреннән, милли билгеләрдән танныйсың. Ә тел — драматург өчен төп корал ул!

Әйтик, «Синең урыныңа кайттым» пьесасында «Без Хәбировлар», «Син Хәбиров» дигән сүзләрнең рефрен булып кабатлануыннан башта уңай герой кебек күренгән Наилнең ахырга таба әтисе шикелле үк халыктан читләшүен, аның кире традицияләрен дәвам итүен, бабасы кебек үк кешеләр тормышында үз ролен артык күпертүен аңлыйсың. Әнә шулай тискәре якларның буыннан буынга күчеп баруын күреп, без Наил кебекләргә алмашка гадел, шәфкатьле, кеше хәленә керә белә торган кешеләр килсен өчен бик күп эш эшлисе барын төшенәбез.

**Н. Ю. ГОЛИКОВА:**

— Мин чыгышымны бөек рус художнигы И. Репинның милли формасын югалткан художник художниклыгын югалтуы турындагы сүзләре белән башлыйсым килә. Татар пьесаларын укыганда мин үзенә бер аерым, тирән милли тамыр җибәргән дөньяга юлыктым. Легендалар, шигърият, милли көнкүреш билгеләре Д. Вәлиев, Р. Мингалимов, И. Юзеев пьесаларында күп очрый. Мин укыган пьесаларның күбесе трагедия жанрына тартым. Д. Вәлиев тарихи драмасын трагедия дип билгели. И. Юзеев гаилә драмасын трагедия дип атый. Жанр өлкәсендә үзенчәлекле һәм кызыклы эзләнүләр бу. Эзләнүләр трагедия жанрында бигрәк тә күп алып барыла.

Авторлар драмада да, комедиядә дә, трагедиядә дә мелодрама элементларын оста куллана беләләр. Татар драматургиясе үсеше бик индивидуаль, бик үзенчәлекле юл белән бара. Үз тавышлары, үз проблемалары белән сәхнәгә менеп, театр тормышын билгеләүче татар драматургларының яңа буыны эзләнүләрендә, уйлануларында, тәҗрибәләрендә гомуми агымга — без яңа драматургия дип атый торган драматургия агымына кушылып баруы бик куанычлы.

Яңа драматургиянең төп сыйфатларыннан берсе — әхлак проблемаларына кискен борылыш. Татар драматурглары камил идеяләрне әхлаклы кешеләр тормышка ашыра, дигән фикерне бик әйбәт уздыралар. Д. Вәлиев әсәренең бер персонажының этика категорияләрен алсак, халыкта бер кеше тормышын гына түгел, ә дәүләт тормышын күрә белергә кирәк булуы турында дөрес әйтә.

Шәхесенә, аның уңай якларына гына түгел, җитешсезлекләренә дә, кешене камилләштерү мәсьәләләренә дә зур игътибар бирү — боларның барысын да кеше рухын туктаусыз өйрәнгәндә генә булдырырга мөмкин. Гаилә драмасына кискен борылыш, аны зур кызыксыну белән тирәнтен өйрәнү — татар драматургларына хас сыйфатлар.

Алар хикәяләп, бәян итеп бирү моментын бик актив кулланалар. Хикәяләү моменты — персонажларга монологлар, эч серләреңне ачып бирү алымы. Монологик структураны, кеше биографиясе, аның башыннан узганнары һәм тормышы белән таныштырырга омтылуын мин үзем укыган пьесаларның күбесендә очраттым. Менә шундый притчага тартымлык, ераклаштырып, читләтеп әйтү Р. Мингалимовның «Дүрт кешелек утыргыч», «Өченче бүлмәдә эт яши» пьесаларына хас. Бу аз персонажлы әре планлы әсәрләр һәркемгә дә ялгызлык килергә мөмкин һәм аңардан котылу — башкалар белән аралашуда, дигән фикерне алга сөрәләр. Беренче пьеса — сәхнәгә куяю өчен читенрәк булса да, изгелек һәм явызлык, җинаять һәм җәза кебек тирән төшенчәләр категорияләр турында бик җитди фәлсәфи әсәр. Геройларын бер төенгә ныклап бәйләмәсә дә, автор аларның әхлагын тулысы белән ачып бирә алган. «Өченче бүлмәдә эт яши», «Кайда сез, ирләр?» әсәрләрендә сүз гаилә мөнәсәбәтләре, ирләр үзләренең ир, ә хатын-кызлар үзләренең хатын-кызлыгын оныткан чакларда туган хәлләр турында бара. Бернича гаилә урманга ялга чыга. Алар белән чыккан кыз Луиза үзенең кияүдәге иптәшләрен: «Ирләрегезнең кадерен белмисез»,— дип үгетләргә тырыша. Ирләрегез минем белән шаярмакчы булалар дип тә өсти. Луизага күзе төшкән егет килеп керә дә аны үзе белән алып китмәкче була. Бу оятсыз егеткә ирләр түгел, ә хатын-кызлар каршы чыга. Ирләр белән хатыннарның урыннары алышына. Менә шушы хәл инде комедиянең нигезен тәшкил итә. Шушы вакыйгадан файдаланып, автор тамашачы алдына: «Кайда сез, ирләр?»— дигән сорауын куя һәм уйланырга мәҗбүр итә.

Диалоглар һәм ситуация мина авыррак тоелуын да әйтми булмый. Бу Р. Мингалимовка гына хас нәрсә түгел. Татар драматургларының җитешсезлекләре дә уртак. Бигрәк тә композиция төзүдә. Әсәрләренә кискен һәм зур күләмле, һәрберсе аерым

пьесаның нигезе булып хезмәт итәрлек шартлар тутырып, алар еш кына композицияне читенләштерәләр, төп фикерне читкәрәк этә төшәләр. Бу кимчелек Ә. Гаффарның «Соңгы ләкләк» пьесасын укыганда бигрәк тә күзгә ташлана.

**В. В. ГУБИН:**

— Татарстан драматургларын һәм аларның әсәрләренең күбесен белгәнгә күрә, минем татар драматургиясе чыннан да алдынгы драматургияләрнең берсе дип әйтәсем килә. Бөтенсоюз һәм республика смотрының тәмамланган этабы бу драматургиянең нык алга китүе турында сөйлиләр. Татар драматургиясенең туктаусыз үсә баруы, бу өлкәдә системалы рәвештә яңа исемнәр туа торуы республиканың партия оешмалары, Язучылар Союзы, РСФСР һәм ТАССРның культура министрлыклары, Бөтенроссия театр җәмгыятенең зур тырышлыгы белән бәйләнгән.

Д. Вәлиев, Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Р. Хәмид, Б. Турай, Р. Мингалимов кебек талантлы драматургларның исемнәре Татарстанда гына түгел, башка республикаларда да билгеле.

Милли драматургия әсәрләрен пропагандалауда һәм таратуда тәрҗемәләрнең роле аеруча зур. Соңгы елларда бүгенге татар пьесаларын рус теленә тәрҗемә итүдә талантлы һәм югары квалификацияле язучылар — В. Розов, Ю. Эдлис, В. Тур, О. Перекалин, В. Коростылев, С. Прокофьев, Ю. Мочалов, Л. Виноградов һ. б. катнашуы бик мактаулы эш. Аларның милли авторларга, бигрәк тә яшь драматургларга пьесаларын әдәби эшкәртүдә, редакцияләүдә, сәхнәгә төзеп бирүдә ярдәме дөньяга чыккан әсәрләрнең идея-художество сыйфатын нык күтәрде.

Чынбарлыкның иң мөһим проблемаларына мөрәҗәгать итү, совет халкының социаль һәм мораль асылының милли үзенчәлекләр белән тыгыз бәйләнешен чагылдыру, гәүдәләндерелгән тормыш материалының яңалыгын, колоритлы һәм үзенчәлекле характерлар, жанр һәм тематик яктан төрлелек — бүгенге татар драматургиясенең иң яхшы әсәрләренең характерлы сыйфатлары.

Совет кешесенең актив тормыш позициясен формалаштыру, хезмәт эшчәнлегенең әхлакый аспектлары мәсьәләләре татар драматургларын нык кызыксындыра.

Бу мәсьәләләр Д. Вәлиев иҗатында төп темага әверелделәр. Аның хезмәт кешесенең характерын өйрәнүгә, эшчеләр коллективы тормышы проблемаларына багышланган «Сиңа тормыш бүләк итәм» дигән әсәре хәзер бик нык танылды.

Г. Ахуновның «Хәзинә» романының инсценировкасы («Кошның да үз оясы була») Татарстан нефтьчеләренең героик хезмәте турында. Бүгенге көн шәхесе үсешен сәнгатьчә анализлап, автор әсәрнең үзәгенә скважина бораулауда рекорд куйган производство алдынгысы мастер Кәримнең психологик катлаулы образын куйган. Масаю, мин-минлек, иптәшләренә кимсетеп карау аны трагик үлемгә дучар итә. Автор моңа капма-каршы итеп, кешегә ягымлы, үткен фикерле егет Шәвәлинең көр күңелле оптимизмын, югары әхлакый кешелеклеген куя.

Талантлы драматург Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесасында безнең гади генә замандашыбыз Мәдинә Сафинаның уңай образы үзәккә куелган.

Шушы ук автор үзенең «Әлдермештән Әлмәндәр» дигән талантлы комедиясендә гади бер кешенең рухи матурлыгын, тормыш сөюен, характер ныклыгын бик матур чагылдырган. Әсәрендә Т. Миңнуллин, комедия жанрының законнарыннан оста файдаланып, кеше тормышының асылы һәм әһәмияте, үлем һәм үлемсезлеге турында иркен, күңелле һәм бер үк вакытта үткен итеп тирән фәлсәфи әңгәмә алып бара.

А. Гыйләҗевнең «Китмәгез, тургайлар» дигән пьесасы персонажы энергияле яшь колхоз председателе Азамат Актай тавында кешелек, гаделлек, тормыш шигърияте чишмәсе суын эчә.

Чибәр яшь егет Алим — А. Гыйләҗевның «Әңгер-меңгер» исемле икенче пьесасының төп герое. Ул хезмәт сөя, яхшылыкны начарлыктан аера белә, үзен кыерсытырга ирек куймый. Ә иң мөһиме — Алим игелекле, ул олы, зур эшләргә ашкына.

Драматург И. Юзеев җир йөзендә матур тормыш, табигатьне һәм кешелеклелекне саклау өчен көрәштә актив тормыш позициясен ныгыту мәсьәләләренә «Сандугачлар килгән безгә» исемле пьесасын багышлаган.

Әлбәттә, бу пьесалар сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан бер үк төрле түгел. Кайберләрендә ситуацияләрнең өслегеннән генә бару, беркатлы драматик алымнар, кай-

бер проблемаларны хәл иткәндә тирәнлек һәм гакыл җитмәү, характерлардагы штамплар еш очрый. Бу кимчелекләр драма әсәрләренең танып-белү кыйммәтен һәм эстетик йогынтысын чикләми калмый, ә шулай да авторларның типик характерларны гәүдәләндерүгә, җәмгыятебезнең зур, җитди мәсьәләләрен чишәргә омтылуларын мактамыйча булмый.

Бүгенге татар драматургиясенең үсешендә икенче мөһим юнәлеш — тарихи-революцион, героик-патриотик тема, совет халкының революцион, сугышчан һәм хезмәт традицияләрен үстерүгә һәм дәвам итүгә багышланган тема.

Д. Вәлиевнең М. Н. Ермолова исемендәге Мәскәү театрында, Казанның Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театрында куелган «Казан университеты» исемле пьесасы В. И. Ленин биографиясендәге әһәмиятле эпизодларның берсен, студентлар революцион хәрәкәтенең авырлыклар аша туып килүен тасвирлый.

Драматург булачак юлбашчы шәхесенең формалашу процессын ачып бирергә тырыша, В. Ульяновны башка студентлардан аерып торган сыйфатларны күрә, көрәшнең авырлыгына яңача караш таба. Бүгенге буын тамашачылары өчен әле тормыш һәм көрәш тәҗрибәсе булмаган революцион студентларның рәхимсез патша ялчылары белән интеллектуаль, психологик бәрелеш сәхифәсе батырлык, революцион идеалларга тугрылык, Ватан өчен көрәштә үз-үзеңне аямаучанлык үрнәгенә әверелә.

Д. Вәлиевнең үзенчәлекле героик-политик «Икс көне» исемле әдәби әсәре авторның кешеләргә, вакыйгаларга кыю карашы белән үзенә җәлеп итә. 1943—1944 елларда булган вакыйгаларны эченә алган бу трагик хроника М. Җәлил һәм аның дусларының фашист концлагеренда алып барган көрәше турында. Реаль шәхесләре арасына хыялый персонажлар кертеп, Д. Вәлиев аларның язмышларын, тормыш һәм үлемнәрен фәлсәфи планда ачарга омтыла. Тормышта исән калуны хыянәт бәрабәренә сатып алган кешеләр халык нәфрәтеннән барыбер котыла алмый. Хыянәтче эзсез югала. Ә фашизмны тар-мар итү, югары патриотик идея өчен үз-үзләрен корбан иткән М. Җәлил һәм аның көрәштәшләре үлемсезлеккә ирешә.

Үлем бугазыннан тоткач та куркып калмыйча, ирек өчен көрәшүче кеше, вакыт узу белән онытылмый, киресенчә, ныгый гына бара торган батырлык темасы үзенчәлекле һәм сәләтле икенче бер драматургны — Т. Миңнуллинны да дулкынландыра һәм үзенә тарта.

Ул да «Моңлы бер җыр» исемле пьесасын М. Җәлилгә багышлаган. Җәлил рухының, ихтыярының көче нәрсәдә? Менә шушы сорауга җавап эзләп, безнең көннәрдә яшәүче шагыйрь хыялында Ватан сугышының трагик көннәренә барып җитә. Ике буын кешеләре турындагы тынгысыз фикерләр пьесаны югары патриотик аһәң белән сугара. Бүгенге көн шагыйренең үлемнән котылу юлларыннан башка төрле вариантлары булгандыр ич, диюенә каршы М. Җәлил: «Вөҗдан, намус бер генә бит ул, вариантлык юк»,— дип җавап бирә. Менә шуңа күрә дә бүген, вакыт һәм пространство чикләрен үтеп, үлемсез М. Җәлил яңа буын кешеләре белән Ватан алдында кешенең изге бурычлары турында әңгәмә алып бара, ә аның батырлыгы, тормышы һәм көрәше героик җыр булып яңгырый.

Югары идеяләр белән рухланып, олы максатка юнәлгән көчле ихтыярлы, героик характерлар гәүдәләндерүгә омтылып, әле санап киткән авторлар совет сәнгатенең художестволы эзләнүләренең төп юнәлешләренә барып чыгалар. Татарстан драматурглары коммунистик мораль, яңа совет кешесен тәрбияләү өлкәсендә актив эшлиләр. Бу тематик юнәлештә — коммунистик әхлак идеалларын ныгыту юнәлешендә эзләнүләр аларны уңышларга алып килә.

Б. Турайның «Кичер мине, әнкәй» дигән пьесасы герое 16 яшьлек Миргаян тормышта үзе өчен бик мөһим мораль ачышлар ясый. Яманаты чыккан хатын исемен йөртүнең авырлыгына карамастан, нәни чагыннан ук кеше баласын карап үстергән Зифаның рухи батырлыгын йөрәге белән аңлый һәм бәяли Миргаян.

Мораль проблемалар Р. Хәмид иҗатында да зур урын тота. Хәбировлар гаиләсенең рухи таркалуы, бер караганда, башкалар кебек үк булса да, күкрәгендә йөрәк урынына арифмометр йөртүче робот-кешенең кансыз, рәхимсез эшләре, аның әхлакый һәлакәте «Синең урыныңа кайттым» исемле пьесаның төп проблемасы.

Шул ук авторның «Иске йорт кешеләре» дигән әсәре дә бүгенге мещаннарны тәнкыйть утында көйдерүгә һәм коммунистик мораль темаларын ныгытуга багыш-

ланган. Тиздән Р. Хәмиднең тагын бер әсәре — русчага В. Розов тәрҗемә иткән «Китәм инде...» пьесасы дөнья күрәчәк. Бу драма бик үзенчәлекле, ул авторның тирән шәхси карашы белән сугарылган. Үзара дошманлыкта яшәүче ике семьяда туып-үскән яшь егет һәм яшь кыз мәхәббәтенә багышланган бик таныш сюжет линиясен кулланып, автор үз әсәрендә кешенең киләчәк алдында, яңа буыннар алдында җаваплылык бурычларын куя.

Т. Миңнуллин «Дуслар җыелган җирдә» дигән әсәрендә яшьлек идеалларына турылыклы булып калу никадәр мөһим икәнлеге турында сүз бара.

«Без уникe кыз идек» дигән пьесаның авторы А. Гыйләҗев үзенең героиняларын яшьлекләрен искә төшерергә, үткән юлларына борылып карарга мәҗбүр итә. «Син кем, башкалар авырлыкларга очраганда, синең кешелегең, дуслык хисләрең, мәрхәмәтлелегең кая китә?»— дип сорый автор үзенең персонажларыннан һәм һәрбер тамашачыдан.

Семья, көнкүреш проблемаларын, әхлак мәсьәләләрен хәл иткәндә, әсәрләренең финаллары еш кына күңелсез бетсә дә, татар драматургларына пессимизм һәм күңел төшенкелеге ят нәрсә икәнен аерым әйтеп үтәсе килә. Аларның пьесаларында геройлар шәхси драмага очрап, үзләре өчен бик мөһим ачышлар ясыйлар, үткәннәренә башка күз белән карарга өйрәнәләр, искечә, гадәттәгечә, җиңел генә яшәүдән баш тарталар.

Татар драматургиясенең тематик киңлеген, әсәрләрдә гәүдәләндерелгән тормыш материалының күп төрлелеген, жанрларның күпкырлылыгын да әйтеп китми мөмкин түгел.

Болар барысы да һәр авторның индивидуальлеген ачып бирә һәм бу пьесаларны татар культурасы гына түгел, бөтен совет культурасы байлыгы итә.

Минем бу пьесаларны тарату мәсьәләсенә дә тукталасым килә. Пьесаларның тематикасы, әдәби югарылыгы аларның милли театрларны гына түгел, РСФСР һәм башка союздаш республикалар театрлары афишаларын да бизи ала дип расларга хокук бирә. Кайбер татар пьесалары Татарстан чикләреннән чыгып китә алса да, шактый күп санлы әсәрләр әлегә бердәнбер театр милке булып кала бара. РСФСР Культура министрлыгына, РСФСР Язучылар союзына, ВТО га, ВАППка һәм Татарстан республикасы дәүләт оешмаларына милли драматургияне пропагандалау турында җитди үйланасы бар.

Ә шулай да теге яки бу әсәр популярлыгының төп сәбәбе — пьесаның тирән эчтәлекле булуында һәм әдәби яктан яхшы эшләнешендә. Кызганычка каршы, нык алга киткән социалистик җәмгыятьнең оптимистик тормышын чагылдырган, зур-зур проблемаларны эченә алган пьесалар татар драматургиясендә әле җитәрлек түгел. Татарстан — һәм промышленносте, һәм авыл хуҗалыгы, һәм культурасы зур үсеш алган республика. Аның тарихы революцион, сугышчан һәм хезмәт традицияләренә бик бай. Республикада бу темаларга алынып һәм җиренә җиткереп эшләрлек талантлы драматурглар да җитәрлек. Тамашачылар аларның әсәрләрендә республиканың йөзен күз алдында үзгәртеп коручы бүгенге көн геройларын, илнең актив гражданнарын, заман үсешен күрергә телиләр. Әмма татар драматурглары чиктән тыш кысан тематик бертөрлелек эченә кереп бикләнгәннәр, тормышны белеп җиткермиләр. Мондый әсәрләрнең эчтәлеге сай, проблемалары ясалма булуы, конфликтларының әле дә тормышта очрый торган вак-төяк негатив мәсьәләләр, мәхәббәт кичерешләреннән уза алмавы, табигый, аларга киң җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итә алмый.

Әйткәнемчә, Татарстанда талантлы драматурглар җитәрлек, аларның кызыклы әсәрләре дә шактый, ләкин ирешелгәннәргә таянып, алга барудан туктамаска кирәк.

**И. И. ИЛЯЛОВА:**

— РСФСР Язучылар союзында татар драматургиясенең торышы хакында бүгенге сөйләшү бик табигый хәл. Чөнки бу драматургиягә берничә елдан йөз яшь тула. Безнең драматургия театрыбыздан алданрак туган һәм аның үсешенә зур йогынты ясаган. Минем дә үземнең чыгышымда драматургиябез күтәреп чыккан проблемаларга тукталасым килә. Ә алар совет драматургиясе белән уртак безнең. Татар драматургиясенең үсеше совет драматургиясе үсеше югарылыгында бара. Тарихи-рево-

люцион темамы ул, хәрби-патриотик яки авыл темасы, яисә мораль-этик тема булсынмы, әсәрләрдә гомумхалык һәм милли сыйфатлар тыгыз бердәмлектә бирелә.

Шунысы да кызыклы, безнең драматургия, әйтик, производство мәсьәләләрен күтәрсә дә, аны әхлак проблемалары аша бирә, аларны хәл иткәндә кешенең мораль сыйфатлары ачыла, актив тормыш позициясе формалаша һәм активлаша.

Т. Миңнуллинның «Монда тудык, монда үстек» пьесасы да эшчеләр, нефтьчеләр династиясе турында гына түгел. Бу проблема аша хәтер, патриотизм, туган җиргә рухи якынлык темалары да күтәрелә. Бу пьеса бик кешелекле, ул сәхнәдә дә шундый булып чыкты. Пьесаның авторы һәм спектакльнең режиссеры, төп рольләрне уйнаган артистлар Ш. Биктимеров, Р. Таҗетдинов, Р. Хәйретдинова «Драматургия һәм театрда бүгенге заман эшчесенең образы» девизы белән уздырылган Бөтенроссия театр фестивалендә хаклы рәвештә лауреат исеменә лаек булдылар.

Безнең драматургия кеше хәтере, аның туган җиренә рухи якынлыгы проблемасына зур игътибар бирә. Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Монда тудык, монда үстек», «Моңлы бер җыр» пьесалары әнә шушы яктан бик характерлы. Соңгысында автор поэтик трагедия жанрыннан файдаланып, совет Ватанын чын күңелдән сөючә, тормышка гашыйк патриотны сурәтли. Ләкин ул яшәү белән үлем арасында да намусына тап төшерми, намусының вариантларын эзләми, туган илгә тирән мәхәббәт барысыннан да өстен чыга. Бу пьеса совет кешеләренең иң яхшы сыйфатларына мәдхия җырлый.

И. Юзеевның «Кыр казлары артыннан», А. Гыйләҗевның «Югалган бер көн» әсәрләрендә дә төп фикер туган җирне, аның бөек матурлыгын саклау турында бара.

Татар драматурглары әсәрләрендә гаҗәеп дәрәҗәдә матур картлар образлары бар. Әлмәндәр («Әлдермештән Әлмәндәр»), Хәмзин («Сандугачлар килгән безгә»), Бикташев («Кыр казлары артыннан») һ. б. Алар — Ватанның, халыкның рухи байлыгын, совет кешеләренең төрле буыннары бердәмлеген тәшкил иткән образлар. Милли драматургиядә бу бик кызыклы күренеш, һәм аның нигезендә олы, тирән фикерләр ята.

Шушы ук проблематика эчендә безнең драматурглар кеше тәрбияләү, рухи тазалык һәм сукырлык, мораль яктан җитлеккән һәм җитлегеп бетмәгән шәхес мәсьәләләрен дә күтәреп чыгалар. Яшәү һәм үлем, үлем һәм үлемсезлек кебек фәлсәфи мәсьәләләр дә аларның игътибар үзәгендә. Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» исемле әсәрендә палач һәм шагыйрь образлары капма-каршы куела, палач образы инкарь ителә һәм коммунистик идеяләргә турылыклы булып калу проблемасы чишелеш таба.

Р. Мингалимовның бәхет, шәхси тормышта чын кеше булу мөһимлеген алга куючы «Өченче бүлмәдә эт яши» исемле әсәре дә зур кызыксыну уята. Бу тема безнең бүгенге көн драматургиясендә бик актуаль һәм актив тема. Шуңа күрә ул театрда да үзенә киң яңгыраш таба.

# ИХТИРАМ

Ихтирам... Бу язманы нәкъ менә шундый баш астында һәм шундый сүздән башлыйсым килде. Тәнкыйтьтә әйтергә теләгән уй-фикерне шулай башта ук чекерәйтеп алга кую бигүк урынлы саналмаса да — башкача булдыра алмадым. Чөнки рус тәнкыйтьчесе — яшьтәшем Вадим Дементьевнең «Шигърият ялкыны»[1] дип исемләнгән әдәби тәнкыйть китабын укып чыккач та күңелгә килгән иң беренче сүз иде ул. Мәскәүнең «Яшь гвардия» нәшриятында дөнья күргән, күләме белән артык зур булмаган юка тышлы бу китап кай яклары белән уятты икән соң ул хисне?

Бүгенге совет әдәбиятының иң зур казанышы, әлбәттә, аның күп милләтле һәм күп бизәкле булуында, һәм шул хәлендә аерылгысыз бөтенне, бердәм процессны тәшкил итүендә. Бу һәркемгә мәгълүм һәм закончалыклы күренеш. Ләкин, шуңа да карамастан, тугандаш әдәбиятларның үзара мөнәсәбәтендәге һәм аралашу процессындагы үзенчәлекләр җитди игътибар үзәгендә торырга, даими рәвештә өйрәнелергә тиешле актуаль проблема. Чөнки ул туктаусыз хәрәкәттә булган җанлы процесс. Әдәбият үсә барган саен, аның яңа, тагы да кызыклырак булган яклары ачылганнан ачыла гына бара. Вадим Дементьев китабы, барыннан да элек, нәкъ менә шушы гаять киң колачлы, катлаулы һәм җитди өлкәгә багышланган булуы белән җәлеп итә.

Китап танылган совет шагыйре Расул Гамзатовның, күләме белән кыска, әмма тирән мәгънәле, күп сыйдырышлы кереш сүзе белән ачыла. Ул да җаваплы һәм үтә әһәмиятле юнәлештәге бу эзләнүләрне яшь тәнкыйтьченең иҗади кыюлыгы дип билгели. Сүз дә юк, берьюлы бөтен совет поэзиясен күз алдында тотып, төрле халык вәкилләренең иҗатын анализлау, алай гына да түгел, аерым шагыйрьләр иҗаты нигезендә, бүгенге әдәби процессның гомум үсеш тенденцияләрен билгеләү — әйтеп бетергесез зур кыюлык һәм җаваплылык сорый торган катлаулы бурыч. Ләкин китапның «Без синең таянычың, Ватан...» дип исемләнгән беренче бүлеге белән танышкач та, ирексездән, автор өчен куанып куясың. Чөнки алдында куелган җитди принципиаль мәсьәләләрдә аның һәм теоретик, һәм практик яктан зур әзерлекле, киң карашлы тәнкыйтьче булуы шундук күзгә ташланып өлгерә. Гомумтеоретик мәсьәләләрдә генә түгел, аерым милли әдәбиятларда барган эзләнү һәм үсеш процессларының характерлы үзенчәлекләрен тоемлауда да аның шактый ук тирән мәгълүматлы булуы игътибарны җәлеп итә.

Төрле әдәбият вәкилләренең шигъри иҗатын, нигездә, бары тәрҗемәләре аша гына өйрәнгән тәнкыйтьче ышандыру көченә, анализдагы тирәнлеккә ничек ирешә соң? Аның фикерләре инде әдәби тәнкыйть практикасында күп тапкырлар кабатланып, шаблонга әверелә барган гомуми сөйләшүләргә генә кайтып калмыймы? — Кемнеңдер күңелендә шундый шиксораулар да туарга мөмкин, әлбәттә. Әмма китап сәхифәләрен ачкач та алар шундук юкка чыга. Һәм әлеге шик-шөбһәләрнең шулай тиз генә юкка чыгуына сәбәпче — ул, иң элек, ихтирам хисе.

Әйе, ихтирам хисе... Вадим Дементьев китабында унике шагыйрьнең иҗат портреты урын алган. Дөрес, жанр күзлегеннән аларның һәммәсен дә иҗат портреты дип исемләү бигүк төгәл дә булмас. Хәер, ул хактагы сүзне кичектереп торыйк. Унике шагыйрь дигәнебез — ун милләт вәкилләре: рус, украин, белорус, таҗик, ногай, удмурт, бурят, алтай, адыгей һәм татар шагыйрьләре. Ун милләт вәкиле дип, әйтергә генә җиңел! Һәр милли поэзиянең

[1] Дементьев Вадим. Пламя поэзии. М., «Молодая гвардия», 1982.

үз нигезе, үз чыганаклары, традицияләре бар. Шуның өстенә һәр шагыйрь үзе бер индивидуаль дөнья. Әгәр бу факторларның берсен генә искә алып җиткермәсәң дә, ялгыш нәтиҗә һәм хата фикерләргә юлыгудан котылырмын димә. Һәм нәкъ менә шушы урында киң күңелле, бай рухлы тәнкыйтьчегә анык күңелендә булган зур байлык — ихтирам хисе кул суза, ярдәмгә килә. Гомумән, шигърияткә генә түгел, аерым милли әдәбиятларга, аларның җирлегенә, нигез ташларына һәм бүгенге халәтләренә ихтирам хисе бу. Төрле милләт вәкилләре арасындагы тугандаш мөнәсәбәтләргә нигезләнгән ихтирам. Чын интернациональ рух белән өртелгән ихтирам хисе!

В. Дементьев тәнкыйтенең бу матур үзенчәлеге, аерым алганда, адыгей шагыйре Нальбий, алтай шагыйре Бронтой Бедюров һәм ногай шагыйрәсе Кадрия иҗатларына багышланган бүлекләрдә бигрәк тә тулы ачыла. Ул әлеге өч шагыйрь иҗатын, үзенең замандашлары һәм бүгенге совет поэзиясе вәкилләре буларак, чиксез бай традицияле рус әдәбиятында кабул ителгән критерийлардан чыгып кына анализласа, үзе телиме-юкмы, кайбер хаталануларга юлыккан булыр иде. Ә тәнкыйтьче бердәнбер дөрес юлны сайлый. Ул һәр шагыйрь иҗатына шул халыкның язма әдәбияты һәм фольклор традицияләре аша килергә омтыла. Һәм шушы юнәлештә берсеннән-берсе кызыклырак һәм гыйбрәтлерәк булган иҗат портретлары тудыруга ирешә. Адыгей, алтай һәм ногай халыкларының тарихын күздән уздырып, шул халыкларның фольклор үзенчәлекләренә нигезләнеп иҗат иткән тәнкыйтьче милли әдәбиятларның үз белгечләре өчен дә яңалык булырлык күзәтүләр ясый. Ул халыкларның сан ягыннан күпме булуы, язма әдәбият традицияләренең ни дәрәҗәдә зурлыгы аның өчен артык әһәмиятле түгел. Һәр халыкның бай тарихы, бетмәс-төкәнмәс рухи байлыкларга мул авыз иҗаты һәм тугандаш совет әдәбиятлары гаиләсендә тоткан кабатланмас үзенчәлеге, үз бизәкләре бар. Тәнкыйтьче Вадим Дементьевның адыгейлы Нальбий, алтайлы Бронтой Бедюров һәм ногай шагыйрәсе Кадриягә булган ихлас мөнәсәбәте әнә шундый принципиаль хакыйкатькә нигезләнгән. Әмма шул урында тагы бер тапкыр автор күңелендәге милли әдәбиятларга булган ихтирам хисен бер сокланубелән искә алмый мөмкин түгел. Чөнки шул ихтирам хисе белән язылган иҗат портретлары өч милли әдәбиятның талантлы яшь вәкилләрен бөтенсоюз укучысына лаеклы рәвештә тәкъдим итә.

Милли фольклор, әдәбият һәм культура традицияләренә ихтирам күзгә бәрелеп торган тышкы күрсәткеч кенә түгел, ул хис В. Дементьев тәнкыйтенең һәм идея, һәм эстетик күзлекләрдән тирәнлеген, практик әһәмиятен билгели. Әйтик, халыкларның рухи чыганакларына битарафлык күрсәткән тәкъдирдә аерым шагыйрьләрнең эстетик идеалы хакында фикер йөртеп булыр идеме? Юк, әлбәттә. Эстетик идеал, матурлыкны тану тойгысы иҗади шәхес формалашкан шартлардан аерылгысыз. Әлбәттә, бишек җыры булып сабый чактан ук күңелгә кергән халык авыз иҗаты әсәрләре монда гаять әһәмиятле роль уйныйлар. Эстетик идеал формалашуга шагыйрьнең туган-үскән җире, туган як табигате һәм хәтта андагы һава шартларының да актив тәэсир итүен оныту ярамас. Тәнкыйтьченең әледән-әле илебезнең теге янсә бу төбәгенә барып чыгуы, сәяхәтләр һәм күңеленә сеңеп калган очрашулар турында искә алуы, үзенең истәлекләре белән уртаклашуы бер дә юкка гына түгел. Әлеге сәяхәтләрдә тәнкыйтьче шагыйрьне иҗатка рухландырган чынбарлык белән күзгә-күз очраша һәм, нәтиҗәдә, аның белән фикер алышу, бәхәсләшү хокукын яулый. Бу күзлектән аның Таулы Алтайда булуы турындагы язмалары һәм Бронтой Бедюров шигъриятенең нигез чыганаклары хакында уйлануы аеруча гыйбрәтле. Бу шагыйрь иҗаты хакындагы аерым фикерләрен тәнкыйтьче аның туган җире буйлап сәяхәттә, аны иҗатка илһамландырган табигать белән очрашуларында шәхсән кичерә, яңабаштан үз күңеленнән уздыра. Нәтиҗәдә, талантлы алтай шагыйренең иҗат казанышлары белән бер очтан, аның кайбер җитешсезлекләре хакында да икеләнмичә фикер йөртә. Каләмдәшебез Вадим Дементьевның әлеге иҗат тәҗрибәсе күп кенә тәнкыйтьчеләр өчен бер үрнәк буларак тәкъдим итүгә лаек. Чөнки, яшерен-батырын түгел ич, без тәнкыйть мәкаләләрендә чамадан тыш дип әйтерлек әдәби текстка ябышып ятарга күнеккән. Ә ул строфа артында, ул юллар артында нинди иҗади шәхес һәм нинди тормыш материалы тора — анысы, кагыйдә буларак, игътибардан читтә кала. Шагыйрьне шәхес буларак формалаштырган чынбарлык, аңа иҗат канатлары биргән, аның матурлыкка

соклану һәм матурлыкны танып белү тойгыларын уяткан урман-кырлар, тау һәм су буйлары ич. Әдәби-нәфис әсәрләр хакында фикер йөрткәндә боларны ничек искә алмаска кирәк, гүзәллекнең беренчел чыганакларына битарафлык күрсәткән тәнкыйть — тәнкыйть буламы икән?..

Рус тәнкыйтьчесе Вадим Дементьевның «Шигърият ялкыны» дип исемләнгән китабын укыганда күңелдә әледән-әле шундый сорау-уйлар рефрен булып кабатланып торды. Чынлап та, илебезнең төрле төбәкләрендә яшәгән шагыйрьләрнең иҗаты хакындагы сөйләшү, һәр очракта дип әйтерлек, аерым милли әдәбиятларның кабатланмас үзенчәлекләре һәм үсеш закончалыклары хакындагы җитди сөйләшүгә әверелгән. Таҗик шагыйрәсе Гөлрухсор Сафиева бай шигъри традицияләре булган Көнчыгыш поэзиясенең талантлы бер вәкиле буларак күз алдына килеп басса, бурят кызы Галина Раднаева җитди иҗади эзләнүләре, бурят шигъриятенә алып килгән яңа бизәкләре белән игътибарны җәлеп итә. Себердә туып үскән рус шагыйрәсе Татьяна Реброва исә шулай ук кызыклы эзләнүләр чорын кичерә. Әмма әле аны үз иҗат индивидуальлеген тулысынча ачкан дип тә әйтеп булмый, әлегә Татьяна ихлас тойгылар белән өртелгән мәхәббәт лирикасында кызыклырак. Белорус шагыйре Владимир Некляев гражданлык тойгылары һәм БАМ төзүче яшьтәшләре тормышын чагылдырган колачлы поэмасы белән аерылып тора. Украин егете Михайло Шевченко иҗаты да тирән гражданлык рухына нигезләнгән. Әмма аның лирикасы җир, игенче язмышы турындагы уйланулардан гыйбарәт. Тәнкыйтьче, шул рәвешле, рус шагыйре Николай Дмитриев, удмурт шагыйре Владимир Романов һәм җитди эзләнүләр чорын кичергән белорус шагыйре Петр Кошель кебек яшь талантларның да иҗат үзенчәлекләрен, күпмилләтле совет поэзиясенә алып килгән яңалыкларын билгели.

Гомумән, Вадим Дементьев китабында бүгенге совет шигъриятендә торган саен исемнәре ешрак һәм ышанычлырак яңгырый барган, киләчәкләре тагы да зуррак булган байтак яшь шагыйрьләр иҗатына киң урын бирелгән. Һәм шулар арасында якташыбыз, татар шагыйре Равил Фәйзуллинга да махсус бүлек багышланган булуы безнең өчен исә икеләтә куанычлы. Тәнкыйтьче татар шагыйренең фәлсәфи лирикасына югары бәя бирә. Равил Фәйзуллинның тынгысыз эзләнүләре соңгы еллар татар поэзиясендә генә түгел, бөтенсоюз күләмендәге шигъри хәрәкәттә дә игътибарга лаек урын алып тора, диелә китапта. Һәм шунда ук бүгенге татар поэзиясендә аның бер ялгызы булмавы искәртелә. Автор Гәрәй Рәхим һәм башка татар шагыйрьләре иҗаты хакындагы аерым фикерләре белән уртаклаша. Гомумән, бүгенге татар шигърияте хакында В. Дементьев һәрчак югары фикердә булды, шуңа күрә әлеге хезмәтендә дә ул бай традицияле поэзиябезне аерым бер ихтирам белән даими рәвештә күз уңында тота. Татарстанның гүзәл табигатен, андагы якын дусларын һәм истәлекле очрашуларны һәрчак күңелендә йөрткән тәнкыйтьчегә күңелдә шулай ук ихтирам хисе уяна. Татар шигырен ул нәкъ безнең кебегүк яратып, үз итеп оригиналдан укып өйрәнгән диярсең — фикерләре оригиналь, күзәтүләре гыйбрәтле.

«Шигърият ялкыны» хакында сөйләшеп тә, тәнкыйтьче В. Дементьевның язу үзенчәлеге һәм профессиональ осталыгына игътибар юнәлтми калу мөмкин түгел. Чөнки әлеге китапта урын алган һәр иҗат портреты форма җәһәтеннән дә бер оригинальлеге белән игътибарны җәлеп итә. Әйтик, адыгей шагыйре Нальбий иҗатына багышланган бүлектә шагыйрьнең үз хатлары тәнкыйть мәкаләсенә фикри динамика һәм композицион бөтенлек алып килсә, бурят шагыйрәсе Г. Раднаевага адресланган ачык хат шигърият хакындагы сөйләшүгә эчкерсезлек, ихласлык һәм күңел җылылыгы өсти. Ногай шагыйрәсе Кадрия иҗатына багышланган сәхифәләргә дә шундый ук ихласлык һәм эчкерсезлек хас. Тәнкыйтьче бу очракта шагыйрьнең үзе белән түгел, ә күңелендә сакланып калган якты образы белән серләшә сыман. Кадрия лирикасына аеруча хас булган үзенчәлек — ихласлыкка мөрәҗәгать итеп, Вадим бу очракта да укучы күңеленә юлны җиңел таба. Кадриянең әйтергә теләп тә әйтергә өлгермәгән җылы, ягымлы сүзләрен җиткерергә тели ул безгә. Рус шагыйре Николай Дмитриев иҗаты хакындагы бүлек тә форма оригинальлеге күзлегеннән аерым игътибарга лаек. Бу очракта тәнкыйтьче яшь шагыйрьне аның остазы, танылган шагыйрь Николай Старшинов белән янәшә куеп өйрәнә. Ул, әйтерсең лә, яшь шагыйрьне үзенең остазы белән бәхәскә чакыра. Буыннар арасындагы бәйләнеш хакында уйлануларны эченә алган

бу мәкалә — әлеге форма үзенчәлеге бәрабәренә — зур поэзия хакындагы җитди сөйләшүгә үскән. Китапта юлъязма һәм сәяхәт формасында, әңгәмә, фикер алышу һәм уйлану характерында язылган бүлекләр, үзара аралашып килеп, гаять кызыклы бер бөтен ансамбльне тәшкил итәләр. Нәкъ менә шуңа күрә дә «Шигърият ялкыны» турында — мәкаләләр җыентыгы дип түгел, ә китап дип әйтү кулай күренә.

Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы дибез. Рус тәнкыйтьчесе Вадим Дементьевның Мәскәүнең «Яшь гвардия» нәшриятында чыккан яңа әдәби тәнкыйть китабын укыганнан соң тагы бер кат күңелне Ватаныбыз һәм аның кырларында чәчәк атучы күпмилләтле совет әдәбияты белән горурлану хисләре били. Шуңа күрә дә милли әдәбиятларга бер дәрәҗәдә олы ихтирам белән мөрәҗәгать иткән тәнкыйтьче яшьтәшемне, иҗади уңышы белән котлап, аның кулын кысасы килде. Әлеге рецензия ихтирам билгесе булсын.

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ.**

# КЫРЫС РЕАЛИЗМ

Аяз Гыйләҗевнең яңа китабына[1] өч повесть кергән. Аларның берсе «Өч аршин җир» инде күптән язылган һәм журналыбызда басылган иде. Повесть зур бәхәс уятты, капма-каршы фикерләр күп булды, бәхәскә хәтта «Литературная газета» да кушылды. Аннары повесть, рус теленә тәрҗемә ителеп, «Дружба народов»та басылды, журналның махсус премиясенә лаек булды. «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» — әдипнең соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре.

Татар укучысы А. Гыйләҗевне егермеләп пьеса язган драматург буларак та, романчы итеп тә, хикәяче буларак та әйбәт белә. Әмма әдип прозада аеруча зур уңыш казанды. Минем уемча, А. Гыйләҗевнең «Өч аршин җир», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Язгы кәрваннар», «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» кебек иң яхшы повестьларын татар прозасының бу жанрдагы иң олы казанышлары белән янәшә куярга мөмкин.

Аяз Гыйләҗев повесть жанрын нигә бик ярата соң?

Бердән, татар һәм күп милләтле совет әдәбиятында хәзер бу жанрның чәчәк аткан чагы. Бездә повестьлар романнардан күбрәк басыла. һәм әле, ихтимал, әйбәт хикәяләргә караганда да күбрәктер алар. Күрәсең, повесть үзгәрүчән чынбарлыкның төрле якларын оператив тасвирларга мөмкинлек бирә торган өлгер һәм күп сыйдырышлы жанрдыр. Роман язу өчен вакыт та, көч тә күбрәк сарыф ителә бит. Хикәя исә катлаулы тормышны диалектик үзгәрешләрдә чагылдырып бетерә алмый. Моның өчен аның күләме кечкенә. Повесть авторга нинди дә булса бер фикергә, проблемага яки геройга тукталып, бу проблеманы төрле яклап яктырту мөмкинлеге бирә.

Икенчедән, монда, күрәсең А. Гыйләҗев иҗатына гына хас үзенчәлекләр дә чагылыш табадыр. Аның нәкъ менә повестьлары озын гомерле булыр дип уйлыйм мин. Аларда А. Гыйләҗев каләменә хас булган сыйфатлар ачыграк күренә. Менә шуңа күрә дә яңа китап безнең прозаны күптән инде төпкә җигелеп тартучы, әмма тәнкыйтьчеләр тарафыннан һаман әле тиешенчә бәяләп җиткерелмәгән бу көчле һәм үзенчәлекле язучының бөтен иҗат юлына киңрәк караш ташларга мөмкинлек бирә.

Тегеяки бу язучының йөзен билгели торган төп сыйфатны табу җиңел түгел. Ник дисәң, язучы бер урында гына тормый, аның иҗаты камилләшә, үсә, ул яңа буяулар эзли. Әмма үзгәреш нинди генә зур булмасын, бу үзенчәлекне табарга мөмкин. А. Гыйләҗевка хас төп сыйфат — кырыс һәм хәтта, әйтер идем, аяусыз реализм.

А. Гыйләҗев үз заманы һәм үз буыны турында дөресен генә яза. Бу дөреслек нинди генә авыр булмасын! Ул хәтта үз буыннары кичергән кыенлыкларны, мох-

[1] Аяз Гыйләҗев. Җомга көн кич белән... Повестьлар. Казан, 1982.

таҗлыкларны кайчакта калкытыбрак та тасвирлый, төчелектән, сентиментальлектән кача. Чынбарлыкны бизәп күрсәтүдә һич тә гаепләп булмый аны!

А. Гыйләҗевкә хас бу сыйфат аның стилен Р. Төхфәтуллин стиле белән чагыштырганда ачык күренә. Р. Төхфәтуллин да сугыштан соңгы авылның авыр көнкүреше турында яза, әмма аның әсәрләрендә лирик агым көчлерәк. Р. Төхфәтуллин күбесенчә эчке монолог алымыннан файдалана, чөнки бу алым эмоциональ киеренкелекне бирү өчен бик кулай. А. Гыйләҗевнең стиле исә сабыррак, хәтта бераз корырак та күренә. Аның лиризмы тирәнгәрәк яшеренгән, һәм ул әйтерсең лә әсәрләрнең эчке агымын тәшкил итә. Өске агымда — тыенкы сурәтләр, җыйнак һәм саран детальләр.

Кыенлыкларны яшермичә, чынбарлыкны артык матурлап күрсәтмичә язу М. Мәһдиевкә дә хас. Ләкин аның күзе кешеләрдә иң элек нинди дә булса көлкеле сыйфатны, күңелгә ятышлы әкәмәт якны күреп ала. Мәһдиев — юмористик деталь остасы, һәм аның иң чын, иң рәхимсез әсәрләре дә йомшак, игелекле, ә кайчакта мыскыллы елмаю белән өретелгән була (моны Гыйләҗевтә бөтенләй диярлек очратмыйсың).

Аяз Гыйләҗев реализмының кырыслыгы заман чалымнарын, кыенлыклар һәм мохтаҗлыкларны дөрес тасвирлауда гына түгел, ә бәлки иң элек үз геройларына карата аяусыз булуында күренә. Геройларны ул иң кыен, иң драматик ситуацияләргә куя.

«Бераү» повестеннан Исхакны гына искә төшерик. Ул мәхәббәтен, яраткан эшен, кешеләргә ышанычын, ниһаять, иң кадерле нәрсәне — туган ягын, үзе туып-үскән һәм гомерен багышларга ниятләгән авылын югалта. Шуңа да карамастан, ул үзен, үз йөзен җуймый. Яки менә «Җомга көн кич белән» повестеннан Бибинурны алыйк. Кем соң ул? Беркемсез калган ялгыз карчык. Ул хәтта иң гади бәхетеннән — балалар бәхетеннән дә мәхрүм. Ә үги балалары аны кирәксенми. Бибинур карчык мохтаҗлыкта яши, тиеннәрен санап көн күрә. Аның каравы күңеле нинди бай, йөрәге нинди игелекле! «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» повестендагы Арзуга, «Язгы кәрваннар»дагы Адиләгә, «Өч аршин җир»дәге Шәмсегаянга да авыр-авыр тормыш сынаулары төшә. Җиңел язмышлы кешеләр язучыны бөтенләй кызыксындырмыйлар да. Ул кешедәге түземлекне, рухи көчне чамалап карарга тели.

Әгәр Аяз Гыйләҗев геройларын, әйтик, Н. Фәттахның «Артта калган юллар» повесте персонажлары белән чагыштырсак, аның геройларына хас тагын бер сыйфатны ачык күз алдына китерербез. Н. Фәттахның Хәмдиясе — тормыш шартлары корбаны. Ул фаҗигале хәлләрдән чыгу юлын таба алырлык түгел — артык сүлпән. Хәмдиягә капма-каршы буларак, Гыйләҗевнең күп геройлары үз дәрәҗәләрен беркайчан да югалтмыйлар һәм явызлык белән актив көрәшәләр. Әйтик, «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» повестенда Арзуның хәле Хәмдиянекеннән җиңел түгел, ләкин ул бу язмышны үзе сайлый, газиз кешесен коткарып калу өчен төрмәгә керә. Ул үзен түбәнсетми, һәм шуңа да бездә кызгану хисе түгел, бәлки ихтирам уята.

Бер әңгәмә вакытында («Казан утлары», 1973 ел, 11 сан) А Гыйләҗев үз кыйбласын менә болай аңлата:

— Шәхсән минем үземне «гыйбрәтле» геройлар кызыксындыра, мин шундый кешеләрне яратам. Үзләре яшәгән чорга битараф булмаган, мәхәббәтне һәм нәфрәтне сиземли торган кешеләр... Уйлана һәм уйландыра торган кешеләр! Коммунизм идеалларына турылыклы кешеләр... Шул ук вакытта ул турылыкларын лозунг итеп күтәреп йөрми торган тыйнак кешеләр. Киң күңелле кешеләр.

А. Гыйләҗевнең геройлары һәрвакыт гади кешеләр, күбесенчә авыл халкы булыр. Ләкин аларның эш вазифалары гына гади, ә эчке дөньялары һич тә гади түгел. Бу да очраклы рәвештә килеп чыкмый. Шул ук әңгәмәдә, А. Сент-Экзюпери иҗаты турында әйтеп, А. Гыйләҗев болай ди: «Гади кешеләрдә бөеклек сыйфатлары таба алу, аны күрә, аера белү, үзеңнең күзәтүләреңне укучы белән уртаклашу — язучының иң гүзәл сыйфатларының берсе шул түгелмени?»

Бу сүзләр әдипнең үз иҗатына да кагыла.

Әлбәттә, язучы тудырган һәр уңышлы образ тормышның үзендә барлыкка килгән типны чагылдыра һәм шуңа күрә уникаль була. Әмма язучы битараф көзге түгел. Фәлсәфи термин кулпансак, ул объектив дөньяның субъектив образын иҗат итә. Язучы үз шәхесеннән, моңарчы тупланган бөтен тәҗрибәсе, биографиясе, кызыксынулары, белеме киңлегеннән баш тарта алмый һәм тиеш тә түгел. Менә шу-

ңа күрә әдәби геройлар, нинди генә үзенчәлекле, кабатланмас булмасыннар, алар автор шәхесен дә чагылдыралар.

Мәрхүм Хәсән Сарьян язучы Аяз Гыйләҗевне мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы дип атаган иде. Бу сүзләрдә А. Гыйләҗевнең талантын билгеләүче икенче бер сыйфат — аның кайнарлыгы, ваемсыз булмавы бик дөрес тотып алынган. Язучы нәрсәнедер җаны-тәне белән ярата, мөкиббән китә, нәрсәнедер кабул итә алмый, җене сөйми. Әнә шул чагында ул кулына каләм ала. Гыйләҗевнең геройларын хисләр көрәшенә бәйле рәвештә ике төп категориягә бүлергә мөмкин.

Менә «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» әсәре. Биредә бер якта — Искәндәр һәм Арзу, Хәбибрахман агай һәм Рәхимҗан бабай, Искәндәрнең дуслары, ә икенче якта — Мәүлиха апа һәм аның ялкау кызлары. Язучы яхшылыкны, гаделлекне, намусны никадәр көчле яратса, намуслы кешеләргә тыныч яшәргә һәм эшләргә комачаулый торган һәр нәрсәне шундый ук көч белән кабул итә алмый. «Моңарчы ялкаулык дисәләр — күз алдыма Мәүлиха апа килә иде. Моңарчы гайбәт дисәләр — бары тик аны уйлый идем, Мәүлиха апаны. Моннан соң, мәкер дисәләр, шул апаны исемдә тотармын». Иксез-чиксез мәхәббәт һәм ташып чыккан нәфрәт шуңа китерә: әдип инде уңай һәм тискәре сыйфатларны тигезләргә омтылмый башлый. Ул кешене я тулаем, булганынча кабул итә яки аны катгый рәвештә кире кага, аңа хурлык тамгасы суга. Бу аның кайбер геройларын бер яклырак итә. Авторның көче дә нәкъ шунда, чөнки аның актив позициясе чагыла. Чыннан да, әгәр Мәүлиха апа гаебе белән әйбәт кешеләр газап чигә икән, әгәр ул үз бәхетен башкаларның бәхетсезлегендә кора икән, автор аның турында ничек итеп тыныч яза алсын ди!!

«Онытырлык итмәде. Нәфрәт тә мәхәббәт кебек үк үзен мәңгеләштерә белә! Моннан соң нәфрәт дисәләр, хәтеремә кара күләгә булып шушы көн, шушы көннең илһамчысы булып Мәүлиха апа иңәр! Их, чыраена берне төкерергә! Үтмәс пычак белән тиресен тунарга!» Бу сүзләр повестьның төп герое Искәндәр исеменнән әйтелә, әмма аларда авторның үз мөнәсәбәтен дә сизәсең.

«Дүртәү», «Бераү», «Җомга көн кич белән» повестьларында, «Урамнар артында яшел болын» романында, әдипнең бөтен әсәрләрендә дә диярлек геройларның шундый ике лагерьга бүленүен әермачык күрәсең.

Әмма кайчакта нәфрәт авторның күзен томалый, менә шул чакта ул чаманы югалта. «Мең чакрым юл» повестенда шулай. Шактый зур һәм таркау повестьның башыннан ахырына кадәр язучы төп герой Әскәр Моратовның яңадан-яңа ямьсез якларын ача тора. Чыннан да, Моратовны кабул итмәс өчен сәбәпләр җитәрлек — ул әдәбиятның чиста тәнендәге паразит. Тик аны фаш итү өчен шул хәтле тырышырга кирәк идеме соң? Укучылар нәфрәт белән йөз чөерсен өчен автор үзенең герое турында сөйләгәннәренә уннан бере дә җитәр иде бит. Ә язучы, ихтыярыбызга каршы килеп, безне аның белән йөзгә-йөз тота, чама хисен югалтып, укучыда бүтәнчә реакция тудыра.

«Җомга көн кич белән» повестенда Бибинурның тискәресе буларак аның бертуганы Зөһрәбану бирелгән. Бибинур карчык никадәр сокландыргыч булса, аның кыз туганы шулкадәр дәрәҗәдә үк начар, ялганчы, җәнҗалчы. Әмма, язучы аның характерының эчке пружиналарын ачмаган, Зөһрәбануның үз туганына булган нәфрәтен эчтән күрсәтмәгән. Шуңа күрә мин — укучы — образга ышанмыйм, авторның нәфрәте мине аптырата, ризасызлык уята.

Мин боларны язучының көчле яклары да, көчсез яклары да бер чыганактан — тормышка битараф карый алмаудан, аны яратудан икәнлеген ассызыклау өчен әйтәм.

Гыйләҗев геройларының кискен рәвештә яхшы күңеллегә һәм усалга, уңайга һәм тискәрегә бүленүе аның әсәрләрен тирән конфликтлы, драматик итә. Усаллыкны гәүдәләндерүче кешеләр булганда (бигрәк тә алар көчкә, властька ия икән), көрәш тә үткен, драматик, ә кайчакта хәтта трагик үк төс ала. Ул бер персонаж күңелендә барырга яки тышкы көчләргә, тормыш шартларына каршы юнәлгән булырга мөмкин. Әмма аларда көрәш һәрвакыт бар.

А. Гыйләҗев җиңел аңлашыла торган язучы түгел. Чөнки әсәрләрдә тормыш катлаулылыгы чагыла. Аларда фәлсәфи ишарә күп. Әдип яшәү максаты, яхшы белән яманның кеше күңелендә барган мәңгелек көрәше турында уйлана. Әлеге фәлсәфә күбесенчә образлар логикасыннан килеп чыга. Әмма ул кайчак лирик чигенешләр, авторның уйланулары рәвешендә дә бәреп чыга. «Зәй энҗеләре» повесте

әйтик, менә болай башланып китә. «Кеше... Уйлап торсаң, гаҗәпкә калырлык. ...Сансыз-исәпсез урманнарда бер-берсенә тәмам охшаган ике яфраклы агач юк диләр. Бер-берсенә охшаган, аерып ала алмаслык ике кеше бармы дөньяда?»

Бу эзектән күренгәнчә, язучыны алга илтә һәм яңа иҗади эзләнүләргә илһамландыра торган хис — кешенең үзенә генә хас сыйфатларны табу теләге. Ул төрле калыпларны, әзер схемаларны дошман күрә, үз иҗатында «тормыш — үзе дә кабатланмас нәрсә бит ул» дигән принциптан чыгып эш итә.

«Өч аршын җир» повестендагы Мирвәли дә — катлаулы язмыш иясе. Ул гомер буе үз авылдашларына ачу саклый һәм үләр алдыннан гына аңлый: аны рәнҗетмәгәннәр, ул аларны үзе кимсеткән икән. Ул халык байлыгын яндыра, турый, иң ач, авыр елларда ашлыкны, кием-салымны юк итә. Әлбәттә, авылдашлары ансыз да яши, ә Мирвәли алардан башка гомер итә алмый һәм зур мәрхәмәт сорарга — туган авылы зиратында өч аршын җир сорарга мәҗбүр. Кеше һәм җәмгыять — автор әлеге повесть материалында әнә шундый гаять җитди социаль һәм фәлсәфи проблеманы куя.

А. Гыйләҗев реалистик төгәл детальләр остасы. Аның әсәрләрендә һәрвакыт икенче план, аскы агым сизелә. Язучының төп жанры — лирик-фәлсәфи ишарәсе булган реалистик повесть. Ул эчке монолог алымына бик сирәк мөрәҗәгать итә. Сүз беренче заттан барган очракта да тыныч хикәяләү өстенлек итә. Тыныч хикәяләү, ләкин битараф түгел!

Кайберәүләр язучыларның үзенчәлеген формада гына күрәләр. Әмма яңача тасвирлау чаралары үзеннән-үзе генә табылмый бит. Ул үзе — яңа эчтәлек, чынбарлыкка бүтәнчә мөнәсәбәт, дөньяга яңа төрле караш нәтиҗәсе.

Аяз Гыйләҗев яраткан бер фикер бар. Ул аның бөтен зур әсәрләре аша диярлек кызыл җеп булып сузыла. Туган ягыннан, сине аштаткан-эчерткән, тәрбияләп үстергән туган авылыңнан аерылу кешенең эчке дөньясын тетрәндерә — бу фикер «Берәү», «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән» повестьларында, «Урамнар артында яшел болын» романында һ. б. әсәрләрдә үткәрелә. Ул бераз шиклерәк тоелырга мөмкин. Чөнки авылдан китүчеләрнең барысы да аерылуны авыр кичерми бит. Күпләр яңа урында төпләнеп, әйбәт кенә яшәп тә китәләр. Шәһәргә күчүнең һәрвакыт рухи югалтуга китерүе һич мәҗбүри түгел. Шәһәр кешене күпмедер дәрәҗәдә баета да бит әле. Фән-культура казанышларын үзләштерергә, потенциаль мөмкинлекләреңне, сәләтеңне тулырак ачарга җай тудыра.

Шулай да бу фикернең җирлеге бар.

Туган җирдән аерылу — кеше күңеле өчен кайтарып булмый торган югалту. А. Гыйләҗев әнә шул хакыйкатькә таяна. Туган авылларын ташлап киткән геройларның күбесе туган якларны сагына, алай гына да түгел, күңелләрендә тирән яра йөртә, ә кайберләре танымаслык булып үзгәрә дә.

«Җомга көн кич белән» повестенда Бибинур карчыкның балалары әнә шундый үзгәреш кичерә. Авылдан киткәч, аларның тормышлары герләп бара кебек: зур исемдәрәҗәгә ирешәләр, материаль як та шәп, һәркайсының үз квартирасы, дачасы бар, инде машина алу турында уйлыйлар. Тик, байлык артыннан куып, алар күңел җылысы һәм рәхим-шәфкать кебек иң күркәм сыйфатларын югалтып бетергәннәр. Бу аларның әниләренә мөнәсәбәтләрендә ачык күренә. Алар башта Бибинур карчыкның бар нәрсәсен алып бетерәләр, аны онытalар, ә инде алыр әйберсе калмагач, аңа хат та язмый башлыйлар. Язучы безнең алда антитеза кора: бай тормышлы балалар рухи яктан хәерче, ә карчык, үзе фәкыйрь булса да, бай күңелле.

Язучының иҗат манерасы үзгәрешсез түгел, аның әсәрләрендә әледән-әле яңадан-яңа төсләр күренә. Еллар узу белән, әдипнең әсәрләрендә элек булмаган сарказм, киная, һәм хәтта гротеск очрый башлый. «Әтәч менгән читәнгә» повестенда автор гаять мөһим һәм актуаль проблема — хосусый милекнең кеше күңеленә тәэсире проблемасын күтәрә. Бу турыда безнең әдәбиятта аз язылмады. Тик язучыларыбыз, урнашкан традиция буенча, комсызлык, байлык артыннан куу кебек сыйфатларны башлыча тискәре геройларга гына бирә килделәр. А. Гыйләҗев повестенда исә яхшы күңелле, хезмәт сөючән, мөхтәрәм кешеләр сурәтләнгән. Ләкин әлеге «авыру» аларга да йоккан. Димәк, хәтәр чир бу, һәм аның турында зурдан кубып сөйләргә кирәк.

Әдипнең әсәрләрендә икенче символик мәгънәгә ия детальләрнең дә әһәмияте арта. Исегезгә төшерегез: бер малай иске зиратта кеше башы сөягенә тибә. Футбол

тубына типкән кебек, ул шулай авылның үткәненә, тарихка, культура, традицияләргә тибә... Яки менә автомобиль узышы: җиңүчеләр юк, барысы да оттыра. Бу күренеш безне шундый фикергә юнәлтә: байлык артыннан куганда, туктап калу мөмкин түгел, оту да мөмкин түгел. Ә оттыру котылгысыз һәм зур: намусны, горурлыгыңны, кешелегеңне оттыра аласың...

Мондый мисалларны А. Гыйләҗев әсәрләреннән күпләп китереп була.

Әйе, язучының яңа китабы сөендерә. А. Гыйләҗевнең бүгенге рухи көрәшләрдә актив катнашуына тагын бер мәртәбә ышана укучы.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# «АЛТМЫШ АРБА БОДАЙ БИР...»

Соңгы елларда халкыбызның поэтик иҗатын өйрәнү һәм аны бастырып чыгару эшендә зур җанлылык сизелә. Фольклор буенча хезмәтләрнең төп өлеше Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторында, Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасында һәм Алабуга педагогия институтында башкарыла. Шуның өстенә соңгы елларда бу юнәлештә Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасында да нәтиҗәле эш алып барыла башлады. Менә егерме еллап инде әлеге кафедра тарафыннан Башкортстанда яшәүче татарларның поэтик иҗатын җыю буенча студентларның фольклор экспедицияләре оештырылып килә. Җыелган материаллар кафедра каршындагы фольклор фондына тапшырыла, һәм бу фонд, әйтергә кирәк, хәзер татар фольклоры туплanмаларының иң байларыннан санала. Татар халык иҗатының 12 томлык җыелмасына да әлеге фондтан алынган материаллар байтак кертелә. Кыскасы, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы халык иҗатын туплау һәм өйрәнү буенча мөһим үзәкләрнең берсе булып танылды.

Шунысы куанычлы, кафедрада соңгы елларда татар фольклорына багышланган фәнни тикшеренүләр дә языла башлады. Шулар арасында филология фәннәре кандидаты Риф Мөхәммәтҗановның хезмәтләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Аның 1977 елда «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (туй поэзиясе)» дигән хезмәте дөнья күргән иде. 1982 елда исә, шул хезмәтнең дәвамы төсендә, календарь йола поэзиясенә багышланган китап басылып чыкты[1]. Р. Мөхәммәтҗановның бу хезмәте татар фольклористикасында аз өйрәнелгән өлкәгә багышланган, һәм аны, тулаем алганда, йола фольклоры буенча беренче монографик хезмәт дип бәяләргә була.

Билгеле булганча, халыкның борын-борыннан формалашып килгән фәлсәфи һәм эстетик карашлары, милли психологиясе йола фольклорында аеруча ачык чагылыш таба. Йола «үзендәге һәр ритуалны төгәл һәм үзгәрешсез үтәүне таләп иткәнгә» күрә, алардагы поэтик иҗат өлгеләре дә заманалар дәвамында аз үзгәргәннәр, һәм шунлыктан халкыбызның борын-борыннан килгән традицияләрен без йола иҗатыннан ачыграк күз алдына китерә алабыз. Йола поэзиясен тикшерүнең фәнни-теоретик әһәмияте шуның белән аңлатыла.

Шунысын да билгеләп узыйк, хәзерге чорда этнографлар һәм фольклорчылар алдында территориаль яктан бик күп төбәкләргә сибелгән, этник яктан бик күп төркемнәр тәшкил иткән татар халкының барлык йолаларын, йола фольклорын туплап, бер системага салу бурычы тора. Бу гомумиләштерүне, әлбәттә, күп тикшеренүчеләрнең күмәк тырышлыгы белән төрле регионнардагы йола ритуалларын һәм йола иҗатын мөмкин кадәр тулырак өйрәнгәннән соң гына ясап булачак.

Бу җәһәттән карaганда, Р. Мөхәммәтҗанов хезмәтенең тагын бер әһәмиятле ягы ачыла. Анда әле фольклорчылар һәм этнографлар тарафыннан тикшерелмәгән тулы бер регион — Ык буенда яшәүче татарларның йолалары һәм йола фольклоры турында сүз бара.

---

[1] Мөхәммәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (календарь поэзия) Уфа, 1982.

Хезмәтенең кереш өлешендә «йола» һәм «гадәт» терминнарына аңлатма биреп, автор татар йола һәм йола поэзиясен өйрәнү тарихына тукталә һәм бу регионда әүвәлге чорда гамәлдә йөргән календарьлар турында мәгълүмат бирә. Ел фасыллары белән бәйләнешле һәм халыкның практик хезмәт тәҗрибәсе нигезендә туган мәкаль, әйтемнәргә, сынамышларга анализ ясый.

Китапның төп өлеше Ык буе регионында яшәүче татарларның календарь йолаларын һәм шул йолалар вакытында кулланылышка кергән поэтик иҗат әсәрләрен тикшерүгә багышлана. Анда «Нардуган», «Нәүрүз», «Сөрән», «Кышны озату», «Җимчәчәк», «Карга туе», «Яңгыр боткасы», «Җар салулар», «Сабантуй», «Җыен», «Келәүләр» кебек бу төбәккә хас йолаларга күзәтү ясала, аларның тулы картинасы тасвир ителә.

Хезмәттә анализланган йола поэзиясе үрнәкләренең байтагы әлегәчә татар фольклорчылары тарафыннан өйрәнелмәгән иде. Әйтик, «Нәүрүз» йоласы (Яңа елны каршы алу, мартның 21 енә туры килә) вакытында өйдән-өйгә кереп, хуҗаларны котлап йөрүче яшьләр тарафыннан әйтелә торган поэтик әсәр шундыйлардан санала:

Нәүрүз килә яшәреп,
Яшәреп тә теш ярып,
Сөләйман абзый котәмсең,
Табак-савыт бирәмсең.

Нәүрүзгә табак кирәк,
Табакка кабак кирәк,
Май, күкәй, калак кирәк,
Сиңа яшь кортка кирәк:
Тамагыңны туйдырыр,
Күп балалар тудырыр,
Иген-икмәк уңдырыр.
Күмәчең дә кызганма,
Озак яшә, сызланма,
Нәүрүз, Нәүрүз!

Шулай ук уракны тәмамлагач, хатын-кызларның җирдә аунап:

«Җир, җир, көчем бир,
Ябага тайның көчен бир,
Алтын алма төсен бир,
Алты атыма куәт бир,

Алтмыш арба арыш бир,
Алтмыш арба борай бир,
Алтмыш арба бодай бир...»

дип келәү әйтү йоласын да беренче тапкыр Р. Мөхәммәтҗанов язып алган. Китапта йола фольклорына караган башка күп кенә яңа материаллар һәм күзәтүләр бар.

Автор бу тикшеренүендә шулай ук «Каз өмәсе», «Тула өмәсе», «Орчык өмәсе» кебек көзге-кышкы айларда үтә торган йолаларның да тасвирламаларын бирә.

Билгеле, конкрет анализ һәм гомумиләштерүләр җәһәтеннән хезмәт кайбер кимчелекләрдән азат түгел әле. Ләкин аның аша Ык буе татарларының йола һәм йола поэзиясе шактый тулы булып күз алдына килеп баса.

Автор бу хезмәтен югары уку йортларында татар фольклорын өйрәнү буенча уку әсбабы итеп әзерләгән. Аның татар халык йолаларын өйрәнүче галимнәр өчен дә, киң катлам укучылар өчен дә кызыклы китап булуын билгеләп узасы килә. Күп кенә йолаларның, әйтик, «Каз өмәсе», «Тула өмәсе», «Карга боткасы» кебек йола бәйрәмнәренең тасвирламасын җыр-бию ансамбльләренең, фольклор коллективларының репертуарын төзегәндә дә файдаланырга мөмкин.

**РӘШИТ ЯГЪФӘРОВ.**

# МИРСӘЙ ӘМИР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Башкортстан хатын-кызлары өчен чыга торган «Яңа юлда» газетасы редакторы булып эшләгән чакта, 1934 елның февраль урталарында Уфада өлкә газеталары хезмәткәрләренең киңәшмәсе булып узды. Казаннан да берничә язучы килгән иде. Алар арасында Мирсәй Әмирнең булуы гомерлеккә хәтеремдә калды. Тәнәфес вакытында төрле өлкәләрдән һәм районнардан килгән вәкилләрнең күбесе белән якыннан таныштык. Бер-беребез белән эш тәҗрибәләрен уртаклаштык. М. Әмир үзенең Мәләвез районы Җиргән авылыннан икәнлеген әйткәч, мин: «Бу авылны яхшы беләм, барганым да бар, ирем Абдулла Баязитов шул авылдан»,— дип әйтеп бетерергә дә өлгермәдем, ул: «Алай булгач, сез безгә кодача буласыз икән. Абдулла бит безгә кода тиешле»,— дип елмайды. Шуннан соң без күптәнге танышлар кебек сөйләшә башладык. М. Әмир газетабыз эше белән бик кызыксынды, аның тоткан урыны, анда хатын-кыз хәбәрчеләренең ни дәрәҗәдә катнашуы турында сорашты.

Шушы киңәшмәдән соң шактый еллар очрашырга туры килмәде. Без бары тик 1957 елны Мәскәүдә уздырылган Татарстан әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә генә күрешә алдык. Шул вакытта Мирсәяф белән Абдулла авылда кабат очрашырга сүз куештылар.

М. Әмир белән Фәүзия ханым август аенда үзләренең туган-үскән яклары Башкортстан туфрагына — туган авыллары Җиргәнгә бөтен гаиләләре белән сәфәр чыгалар. Алар артыннан без дә Җиргәнгә юл тоттык.

Авылда күптәнге танышларыбыз белән очрашып, кунак булып йөргәннән соң, без Уфага кайтып киттек.

Казан кунаклары авылда калдылар... Алар Җиргәннән туп-туры безгә килделәр, һәм берничә көн тордылар, Башкортстан язучылары белән очраштылар. Башкортстан язучылары кунаклар хөрмәтенә бик шәп әдәби кичә оештырдылар, әйбәтләп кунак итеп, Казанга озатып калдылар.

М. Әмир һәм Фәүзия ханым белән миңа бүтән очрашырга туры килмәде. Әмма без һаман хәбәрләшеп тордык. Әдип еш кына типография буявы да кибеп бетмәгән яңа китапларын «Кадерле якташларым Абдулла белән Галиягә» дип язып җибәрә иде. Аның хатлары күләмле бер әсәрне күз алдына китерә. Моңа мисал рәвешендә аның хатыннан кечкенә генә бер өзекне укып карыйк:

«Кадерле Галия кодача!

Үзегезгә, хөрмәтле авылдашыбызга, Абдулла кодага, шулай ук ул-кызларыгызга бездән сәлам.

Үзебез, чирләштерә-чирләштерә булса да, исән-сау йөреп ятабыз әле. Сезнең белән күрешмәгәнгә 13 еллап вакыт узып китсә дә, бездә картаюдан башка әллә ни үзгәрешләр юк кебек.

Үзем 1969 елдан Язучылар союзы председательлегеннән бушадым. Хәзер төп вакытым иҗат эшенә бирелә. 7 ел буе председатель булып эшләвем сәбәпле, каләм эшендә отчет-докладлары, әдәбият турындагы мәкаләләр, публицистик чыгышлар язудан ары китә алмаган идем.

Бушангач, беренче эшем итеп, шул характердагы хезмәтләремнән бер җыентык төзедем. Хәзергә басылып чыкмаган әле. Тагы «Җан көеге» дигән бер повесть яздым. Анысы да хәзергә беркайда да басылып чыкмаган. Яңа бер повесть өстендә эшлим.

Галия! Сез миннән «Башкортстан кызы»на яза торган мәкаләгездә кулланырлык сүзләр көтәсездер инде. Кызганычка каршы, капыл гына әйтергә матур фикерләр башка килми. Җайлабрак уйлап утырырга вакытым тыгызрак чакка туры килде: иртәгә Мәскәүгә китәргә җыенам. (Юбилей сессиясендә катнашырга чакыралар.) Хәзергә шуны гына әйтә алам:— Башкортстан кызларына минем рәхмәтем бик зур. Алар арасында минем укучыларым бик күп. Әсәрләрем турысында фикерләр әйтеп, матур-матур сүзләр язалар. Миңа яхшы теләкләрен белдерәләр. Шулай күңелемне күтәреп, мине, якташларын, яңа әсәрләр язарга рухландырып торалар.

Хәтта ул Башкортстан кызларының берсе һәрвакыт минем янымда була. Уңышларыма минем белән бер дәрәҗәдә куанган кебек, кайгыларыма да үзем белән бер дәрәҗәдә хәсрәтләнә. Яңа әсәрләр язган чакларымда ул минем беренче укучым һәм иң туры сүзле, кырыс таләпле беренче тәнкыйтьчем дә. Алай гына да түгел, мин яздырган газета-журналларны, мин алган китапларны үземә караганда тизрәк һәм күбрәк укып өлгерә дә, үзенчә һәйбәт дип, бик кирәк дип тапканнарын миңа да укырга куша. Ул тәкъдим иткәннәрне укып бер вакытта да үкенгәнем юк. Кайберләрен укып өлгермәсәм, эчтәлеген сөйләп бирергә дә иренми. Ничек рәхмәт әйтмисең шундый Башкортстан кызына?

— Кем соң ул?— дисезме?

Фәүзия кодачагыз инде, кем булсын.

Тагы бер Башкортстанга кайтып, таныш якташлар белән күрешеп, таныш булмаганнары белән танышып киләсе, яшь чакта туган якларда торып калган истәлекләрне яңартасы килә.

Күңелемдә үткән тормыш юлына нигезләп, бер әсәр язу теләге йөри. Шуны тормышка ашырырга насыйп булса, ул истәлекләр бәлки файдалы гына бер эшкә ярап куяр иде. Исән булсак, мөгаен бер кайтып күрешербез әле дигән өметтә калабыз.

Барыгызга да күп сәлам белән, М. Әмир.

16/IV—1970 ел».

Хат ахырында тагын мондый юллар да бар:

«Хәзерге кыяфәтемне чагылдырган бер фоторәсememне җибәрәм һәм шушы форсаттан файдаланып, Сезгә, кадерле авылдашларым итеп, өч томлык әсәрләр җыентыгымны да («Агыйдел» повестен да) салам.

Бәләкәй генә бер русча җыентыгымны да кыстырам.

Боларны аерым бандероль итеп җибәрәм».

М. Әмирнең зур бәйрәмнәребез белән котлап язган открыткалары һаман килеп торды. 1980 елда Май бәйрәме белән котлап язган открыткасы — аның безне иң соңгы котлавы булды.

**ГАЛИЯ МИРЗАГИЛДИНА-БАЯЗИТОВА.**

Марсель Сәлимов

# ЧЭПЭ

ЮМОРЕСКА

Мөхтәсим эштән соңлап кайтты.

Моңача бер дә андый хәл булганы юк иде. Хатынының күңелендә шик яралды.

— Нигә алай озак?

— Бүген кайтып җиткәнгә рәхмәт әйт! — диде Мөхтәсим, гомерендә беренче тапкыр хатынына каты бәрелеп.

— Өс-башыңны кара, пальтоң мунчалага әйләнгән!— Хатынның шиге арта төште.— Кайда шулай әвәләнеп кайттың?

— Кайдан булсын, эштән!— диде Мөхтәсим.— Уф, тәмам хәлем бетте!..

Хатыны ирнең пальтосындагы сыңар җепкә генә эләгеп торган төймәне өзеп алмакчы иде, төймә арасына кысылган берничә бөртек чәчне күреп алды.

— Бу кем чәче?

— Мин каян белим! Бәйләнмә әле!

— Әх, шулаймы?!— Хатыны тагы да яманрак бәйләнергә тотынды.— Кем янында булганыңны да белмисеңме?

Ул Мөхтәсимнең пальтосыннан да төрле төстәге чәч бөртекләре чүпләде.

— Кара син, җилкуар, бер кичтә күпме хатын-кызның башын әйләндергән!

Мөхтәсим ничек акланырга да белмәде:

— Син нәрсә?..

Шул чак хатын аның муенындагы помада эзләрен шәйләп алды.

— Ах, хыянәтче! Кызыл иренле хатыннар янында булдыңмы?

Мөхтәсим помада буявыннан да ныграк кызарып чыкты.

— Юк, түзә алмыйм бу гарьлеккә! — дип пыр тузды хатыны.— Иртәгәдән үк, син алдакчыны ташлап, әнкәйләргә китәм. Юлга акча бир!

Ул иренең кесәләрен әйләндереп карады. Чалбар кесәсеннән... трамвай билеты килеп чыкты.

— Ничек кергән ул синең кесәгә?

— Үзем салдым,— диде Мөхтәсим.— Бүген эштән беренче тапкыр трамвай белән кайткан идем.

Хатын, ниһаять, иркен сулап куйды.

— Исән! Ничек исән-сау калалдың, картым!— дип, үзе дә сизмәстән, иренең муенына килеп асылынды.

[1] Чэпэ — гадәттән тыш хәл

# Кизэнов

## Тәкәббер тәкә

Кәтүдә дә, абзарда да,
Өскә тәбәп күзен,
Эре тота үзен:
Дәшми, сәлам бирми,

Елмаймый һәм көлми,
Аңлап булмый сүзен...

Димәк, белми әле шашлык
Буласын ул күзен.

## Сөйли халык

— Сөйли халык, чынмы: имеш, син бит
Кемгәдер ярдәм иткәнсең:
«Упкынга батыра алмаммы
Икән?!» дип ярдан эткәнсең?!

## Калдыктан... байлык

Төзелеш калдыгы дигән
Чүп-чар саткан кеше таптым.

Һәм... шуңардан менә дигән
Ике дача төзеп саттым.

## Үзе һәм улы

Кайнар күмер көри үзе көн дә
Кеше кулы белән.

Һәм акчаны эштә бергә урлый...
Кече улы белән.

## Бичара күргән чара

Төзелеш конторасында
Иң дәү түрә утыра.
Ә тишек түбәдән үткән
Яңгыр һаман котыра.

Шундый көнгә калыр икән
И бичара, и мескен:
Киптергеч белән... киптереп
Утыра өстәл өстен.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

29 апрельдә булып узган ачык партия җыелышында совет әдәбиятын пропагандалауда язучыларның Тукай исемендәге клубының эшчәнлеге тикшерелде. Клуб мөдире Ә. Рәшитовның чыгышыннан соң, язучылар А. Шамов, Г. Бәширов, Н. Дәүли, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев, Р. Кәрами, Р. Батуллин, композитор С. Садыйкова чыгыш ясадылар. Җыелышта клубның эшен тагын да киңәйтү буенча тәкъдимнәр кертелде.

### XVIII ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган шигырь бәйрәме бөтен апрель буе дәвам итте. Ул Казан, Брежнев, Әлмәт, Түбән Кама, Алабуга һәм башка зур шәһәрләрдә узды. Казан язучылары, өч төркемгә бүленеп, Арча районында әдәби кичәләр оештырдылар. 26 апрельдә «Казан утлары» журналының Татарстан атом электростанциясе төзелешендәге әдәби посты Кама Аланы поселогында шигъри митинг уздырды.

Казанда әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре юлбашчыбыз В. И. Ленин һәйкәленә, Г. Тукай, А. Пушкин, М. Җәлил, М. Горький һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар. Аннары М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Г. Тукай һәйкәле алдында шигъри митинг булды. Аны шигырь бәйрәмен уздыру комиссиясе председателе Ренат Харис алып барды.

1983 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары язучы А. Гыйләҗев һәм композитор Р. Еникеев чыгыш ясадылар.

Шагыйрьләрдән С. Хәким, Н. Дәүли, И. Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Мингалимов, А. Минһаҗева, Э. Блинова, Ә. Рәшитов, Зөлфәт, Р. Миңнуллин үзләренең шигырьләрен укыдылар. Бәйрәмгә килгән кунаклардан Магнитогорск вагоннар депосы эшчесе, коммунистик хезмәт ударнигы Р. Мостафин чыгыш ясады, РСФСРның һәм Татарстан АССРның халык артисты Ф. Насретдинов җырлады.

Шигырь бәйрәменең махсус эмблемасы булдырылды. Шул эмблема сурәтләнгән истәлекле значоклар шигъри митингта катнашучыларга бүләк ителде.

* * *

Чиләбе шәһәренең татар-башкорт китапханәсе уку залында халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 97 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып үтте. Кичәне китапханә белән берлектә Муса Җәлил исемендәге әдәби берләшмә оештырды.

Кичәдә катнашучылар шагыйрә Салисә Гәрәева, Мәхмүт Янбаев, Әхмәт Рафиков иптәшләрнең чыгышларын, шулай ук «Таң нурлары» дигән ансамбльнең Г. Тукай әсәрләреннән төзелгән концертын тыңладылар.

### ӘДӘБИ ЮБИЛЕЙЛАР

17 майда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советы белән Татарстан Язучылар союзы идарәсенең демократ язучы Нәҗип Думавиның 100 еллыгына багышланган берләштерелгән утырышы булды.

Язучының иҗаты һәм тормыш юлы турындагы сүз белән филология фәннәре кандидаты Резеда Ганиева, Н. Думави әсәрләрен текстологик әзерләү турында Зөфәр Рәмиев чыгыш ясадылар. Фикер алышуда Нил Юзиев, Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Ринат Мөхәммәдиев катнашты. Галимнәр һәм язучылар катнашы белән узган гыйльми совет утырышында Нәҗип Думавиның уллары Чыңгыз һәм Илтәзәр Нәҗипович Тохтамышевлар чыгыш ясады.

* * *

12 апрельдә шулай ук Тел, әдәбият һәм тарих институтында Әхмәт Фәйзинең тууына 80 ел тулуга багышланган гыйльми совет үткәрелде. Анда әдипнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бу өлкәдәге бурычлар турында филология фәннәре докторы Нил Юзиев сөйләде. Фикер алышуларда тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов, тарих фәннәре докторы Я. Абдуллин катнашты.

* * *

Күренекле татар совет язучысы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Галинең тууына 90 ел тулу уңае белән Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советының киңәйтелгән утырышы булды.

Мөхәммәт Гали турында доклад белән өлкән гыйльми хезмәткәр Нур Гыйззәтуллин чыкты. Язучының институтта саклана

торган кулъязма хезмәтләре, төрле документлары турында фәнни архив җитәкчесе Гамир Дәүләтшин сөйләде. Доклад буенча фикер алышуларда әдәбият галимнәре Нил Юзиев, Баян Гыйззәт һ. б. иптәшләр катнашты.

## МӘСКӘҮДӘ ЗУР СӨЙЛӘШҮ

16—17 февральдә Мәскәүдә СССР Язучылар союзы матур әдәбиятны пропагандалау Советының XV пленумын уздырды. Анда катнашу өчен әлеге совет члены шагыйрь Р. Фәйзуллин һәм ТАССР Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау Бюросы директоры Р. Кәрами чакырылган иде. Пленумда Р. Кәрами чыгыш ясады һәм үзе җитәкләгән Бюроның эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

22 апрельдә язучы һәм галим Ибраһим Нуруллин Казанның Яшьләр үзәгендә мәктәп укучылары, 28 апрельдә Мәгариф работниклары йортында шигырь сөючеләр белән очрашты, Тукай иҗаты турында сөйләде һәм сорауларга җавап бирде.

*
*   *

11 мартта язучы Аяз Гыйләҗев Минзәлә педагогия училищесы студентлары һәм укытучылары белән очрашып, бүгенге татар әдәбияты, язучылар алдында торган яңа бурычлар турында сөйләде, үзенең яңа әсәрләрен укыды, иҗади планнары белән уртаклашты.

*
*   *

Шагыйрь Гамил Афзал Әлмәт шәһәренең 5 нче мәктәп укучылары белән очрашты. Шагыйрь үз тормышы һәм иҗат юлы белән таныштырды, яңа шигырьләрен укыды.

*
*   *

7 апрельдә Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, шагыйрь Роберт Миңнуллин һәм башкорт шагыйре, «Башкортстан пионеры» газетасы редакторы Сафуан Әлибаев Башкорт дәүләт университетының «Акчарлак» һәм «Шоңкар» әдәбият-иҗат түгәрәкләре членнары белән очраштылар. Сүз татар һәм башкорт әдәбиятларының бүгенге торышы турында барды. Шагыйрьләр яңа шигырьләрен укыдылар, сорауларга җаваплар бирделәр.

*
*   *

12 февральдә Казанның Галимнәр йортында шагыйрь Р. Бохараев, 17 февральдә В. И. Ленин исемендәге Культура сараенда драматург Р. Батулла һәм яшь язучы К. Кәримов әдәбият сөючеләр белән очраштылар. Алар үзләренең әсәрләрен укыдылар, сорауларга җаваплар бирделәр.

*
*   *

Казан химия-технология институты студентлары язучылар белән тыгыз элемтәдә торалар. 19 февраль көнне аларда кунакта ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты прозаик Г. Ахунов булды. Очрашу бик җанлы үтте.

*
*   *

24 февральдә язучы Г. Паушкин сәүдә хезмәткәрләре культура йортының китапханәсендә, прозаик М. Хәбибуллин Урицкий исемендәге культура сараенда өлкән класс укучылары белән очраштылар. Үзләренең чыгышларында алар хәрби патриотик темага, һөнәр сайлауга кагылышлы мәсьәләләргә тукталдылар.

*
*   *

Февраль ахырында прозаик В. Нуруллин Казан авыл хуҗалыгы институтында китап сөючеләр белән очрашты. Язучы студентларны һәм укытучыларны 1982 елда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган китаплар һәм алдагы елларга эш планнары белән таныштырды. Узган ел журналда дөнья күргән «Һәлакәт» повестена кагылышлы сорауларга җаваплар бирде.

*
*   *

Январь аенда республикабызның В. И. Ленин исемендәге фәнни китапханәсендә оештырылган китап күргәзмәсе айлыгы төгәлләнде. «Татарстан язучыларының әсәрләрендә халыклар дуслыгының чагылышы» дип аталган бу күргәзмәдә барлыгы егермедән артык язучы катнашты. Күргәзмәнең йомгаклау өлешендә язучылар Ш. Рәкыйпов, Г. Паушкин, Р. Кутуй, Р. Кәрами һәм Ә. Гадел чыгыш ясадылар.

*
*   *

Хезмәт ияләренең ялын оештыру буенча күп кенә Дәүләт учреждениеләре эшләп килә. Шундыйлардан «Казанский» «Васильево» һәм «Крутушка» санаторийлары, В. И. Ленин исемендәге завод, моторлар төзү заводы профилакторийлары да бар. Һәм аларда январь аенда язучылар Г. Ахунов, К. Миңлебаев, Н. Орешина, Г. Зәйнашева, М. Хөсәен, М. Зарецкий, К. Кәримов һәм күп кенә артистлар чыгыш ясадылар.

Укучыларның кышкы каникул көннәрендә Казанның В. И. Ленин исемендәге музее драматург Риза Ишморат белән очрашу үткәрде.

* * *

Электрон-хисаплау машиналары заводы һәм ясалма күн әйберләр эшләү заводы тулай торакларында М. Мәһдиев, Р. Батулла, Р. Хәлиуллина һәм Д. Гисметдиновлар чыгыш ясады.

* * *

Шагыйрьләр Р. Гәрәй һәм Ә. Рәшитов 26—27 январьда Буа районында булып кайттылар. Алар Югары Чәчкап урта мәктәбендә һәм СССРның 60 еллыгы исемендәге колхозда әдәбият сөючеләр белән очрашулар үткәрделәр.

* * *

Апрель аенда язучылар В. Нуруллин, М. Хәбибуллин, М. Мәһдиев, Р. Кәрами, Р. Гәрәй, Ә. Гадел, Р. Кожевникова, Б. Сулимов, Ә. Мушинский «Татхимпрепараты» һәм Татарстан киемнәр тегү производство берләшмәләрендә, компрессор заводларында эшчеләр һәм инженер-техник хезмәткәрләре алдында чыгыш ясадылар.

* * *

25 апрельдә бер төркем язучылар Габдулла Тукайның туган ягына бардылар. Көндез Г. Ахунов, М. Мәһдиев — Казанбаш, Т. Миңнуллин, И. Юзеев, И. Нуруллин, А. Гыйләҗев — Тукай-Кырлай, Р. Мөхәммәдиев, Р. Кәрами Наласа авылларында мәктәп укучылары белән очраштылар. Ә кичен Арча педагогия училищесында зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелә.

* * *

Январь аенда шагыйрь М. Хөсәен Казанның 33 нче техник училищесында һәм 20 нче кичке мәктәптә поэзия сөючеләр белән очрашуда катнашты. Шагыйрь яшьләргә үзенең соңгы вакытта иҗат иткән шигырьләрен сөйләде, сорауларга җавап бирде.

* * *

11—16 апрель көннәрендә Мәгъсүм Хуҗин, Камил Кәримов һәм Флера Низамовалар Азнакай районы хезмәтчәннәре белән иҗади очрашуларда булдылар.

## ЯҢА КЛУБ

Брежнев шәһәре язучылар оешмасында «Кызыклы очрашулар» клубы эшли башлады. Беренче очрашуга Мәскәүдән танылган язучы Петр Гуцал чакырылды. Ул үз биографиясеннән кайбер истәлекләр белән уртаклашты, әйтик, М. Горький, М. Шолохов һәм башка язучылар белән очрашуы турында сөйләде. Очрашуда катнашучылар аның Австралия, Һиндстан, Ливан, Сүрия, Мадагаскар һәм башка илләргә сәяхәте, шулай ук Кампучиягә багышланган «Упкын аша» повестен язу тарихы турында сөйләвен кызыксынып тыңладылар.

## ЛЕНИНГРАД СӘХНӘСЕНДӘ

10—11 мартта Казан театр училищесын 1983 елда тәмамлаучы бер төркем яшь артистлар училищеның шефы булган Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кинематография институты каршында иҗат отчеты тоттылар. Н. Исәнбәтнең «Портфель» һәм Т. Миңнуллинның «Яшьлегем-җырлар легем, яшьлегем-гүзәллегем» дигән пьесалары буенча куелган спектакльләрне Ленинград тамашачылары яратып карадылар.

Яшь артистлар Ленинград театрларында танылган сәхнә осталарының иҗаты белән таныштылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен художник **Илдар Зариповка**. РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 26 апрель Указы белән, **«РСФСРның атказанган художнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

# КОНДРАТ МАКСИМОВ ҖИЛӘКЛӘРЕ

Сынлы сәнгатьне сөючеләр РСФСРның атказанган, Татарстанның халык художнигы Кондрат Максимовның иҗатын профессиональ осталыгы, әсәрләрендәге образларның гадилеге һәм ачыклыгы өчен күптән яратып өлгерделәр. Рәссам үзенең калын урманнары, мәһабәт киңлекләре белән күпләрне сокландырган Вятка губернасындагы Шишкино авылында туып үсә. Казан сәнгать мәктәбендә укый. Аның хезмәтләре беренче мәртәбә 1928 елда Ленинградтагы А. И. Куинджи исемендәге җәмгыять күргәзмәсендә урын ала.

Пейзаж һәм натюрморт рәссам иҗатының төп жанры булып санала. Бу әсәрләр аша табигать белән аралашканда, күңелдә җирнең иксез-чиксез байлыкларын татып карау шатлыгы уяна.

Ә менә урман киңлекләре К. Максимовның иң яраткан күренешләре булса кирәк. Күзгә артык ташланып тормаган матурлыклары белән җәлеп иткән урманнар, кояш нуры тулы кырлар, яктыдан-якты наратлыклар, чытырманлыклар — болар барысы да кечкенәдән табигатькә гашыйк рәссамның йөрәк җылысы белән өретелгәннәр.

Гомеренең соңгы елларында К. Максимов искиткеч матур натюрмортлар иҗат итә. «Көз», «Йөзем белән ак ваза», «Җиләк» — боларның исемнәрен генә ишеткәч тә, менә дигән «чәчәкле» серия күз алдына килә. Үтә күренмәле сынлы сәнгатьне, чәчәк төсләренең нечкә нәфислеген, форма үзенчәлекләрен, сурәтне хыялый тоюын файдаланып, рәссам бәйрәмне, гүзәллек бәйрәмен иҗат итә. Автор натюрмортларында һәрбер чәчәк яисә чәчәк сабагы төзелешенең үзенчәлеген ачып бирә. Чөнки ул кечкенә генә детальдә дә гомумматурлыкның, дөнья камиллегенең дәвамын күрә.

«Җиләк» натюрмортына күз салыйк. Өстәлгә җәелгән ашъяулык өстендәге вазада — кыр чәчәкләре бәйләме. Ваза алдындагы тәлинкәдә — кып-кызыл җиләкләр. Натюрмортта табигать, урман-болыннарның, гөлбакчаларның күңелләрне дулкынландырырлык хуш исләрен саклаган хәлдә, бөтен тормышчан яктылыгы белән тасвирлана.

Өстәл өстендә кояш нурларының уйнаганы күренми. Әмма сурәт балкып тора. Чөнки җиләк һәм чәчәкләр кояш нурын эчкәннәр. Шуңа күрә алар нур сибәләр, безнең күз карашларын җәйнең җылы җилләре белән иркәлиләр шикелле...

Бу әсәр хәрәкәтләргә бай булуы белән аерылып тора. Автор биредә тере табигать сулышын һәм кеше кулларының эзен бик оста «тотып» алган. Өлгереп житкән сусыл җиләкләр ашыгыч кына тәлинкәгә бушатылган. Артык аерып тормыйча, тиз-тиз генә җыелган чәчәкләр әле генә сулы вазага куелганнар һәм төрлесе төрле якка тайпылган. Әйтерсең лә, алар әле дә кыр киңлекләрендә яшиләр, җилләрдә тирбәләләр.

К. Е. Максимовның «Җиләк» натюрмортын җиләкле-чәчәкле болын тәрәзәсенә, җәй көннәрендәге ярсу табигатьнең бер мизгеленә охшатырга мөмкин булыр иде.

**Д. САДЫЙКОВА,**
*Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре*

●

*Тышлыкның дүртенче битендә: РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров.*

Рөстәм Мансуров слайдлары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210

